ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

3.2008





*Фатих Хөсни*
*(1908-1996)*

# Казан утлары
# Qazan utları

*2008*

**3**

(1025)

*Гамәлгә куючы:*
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*
**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—541-38-77.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Газинур МОРАТ. Юл тамгасы—йолдыз язуыннан... *Шигырьләр.* ..... 5
Равил ВӘЛИ. Канатлы татар. *Роман.* ..... 9
Клара БУЛАТОВА. Дөнья тулы, юкса, умырзая. *Шигырьләр.* ..... 50
Әнәс ХӘСӘНОВ. Әнис алмалар. *Повесть.* ..... 54
Рөстәм ЗӘКУАНОВ. Чатыртауга менәм... *Шигырьләр.* ..... 98
Әлфия СИТДЫЙКОВА. Мәңгелек ямь эзләп. *Шигырьләр.* ..... 100
Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Өзелгән гөл. *Хикәя.* ..... 102

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Ләйсән ЯКУПОВА. Яшенле төндә. *Шигырьләр.* ..... 112

**«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА—90**

Камил КӘРИМОВ. Уноченче өмет *(М. Сәфәров белән әңгәмә).* ..... 114

**«КЫЗЫЛ ТАҢ»ГА—90**

Камил ЮЛАЕВ. Мәҗит Гафури иҗатындагы мөһим баскыч. ..... 117

**РАБИТ БАТУЛЛАГА 70 ЯШЬ**

Фәрит ХАТИПОВ. Тынгысыз җан. ..... 120

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Гамьле шагыйрь бакчасы. ..... 133

**ХӘТЕР**

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Затлылык. ..... 135
Аяз ГЫЙЛӘҖЕВ. Гомернең бер елы. *(Көндәлек сәхифәләреннән).* ..... 147

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ..... 157
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 161

Юбилейлар. ..... 171
Безнең календарь. ..... 175
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 176
Берлекнең яңа әгъзалары. ..... 178

**АК ҖИЛКӘН**

Рәйсә ЮСУПОВА. Тәтчер мажаралары. ..... 180

**ЮМОР-САТИРА**

Роберт МИҢНУЛЛИН. Дусларым, дус-ишләрем. *Эпиграммалар.* ..... 183

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Р. ВАЛИ. «Крылатый татарин» (продолжение), повесть А. ХАСАНОВА «Анисовые яблоки», рассказ А. АХМЕТГАЛЕЕВОЙ «Вырванный цветок», стихи Г. МУРАТА, К. БУЛАТОВОЙ, Р. ЗАКУАНОВА, А. СИТДИКОВОЙ.
«Творчество молодых»: стихи Л. ЯКУПОВОЙ.
«К 90 летию газеты «Ватаным Татарстан»: К. КАРИМОВ «Тринадцатая надежда».
«К 90 летию газеты «Кызыл Таң»: статья К. ЮЛАЕВА.
«К 70 летию Р. Батуллы»: Ф. ХАТИПОВ. «Беспокойная душа».
«Книжное обозрение»: статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА на книгу Г. Мухаметшина.
«Память»: М. УСМАНОВ. «Интеллигентность», А. ГИЛЯЗОВ. Странички из дневника.
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение); Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень (продолжение).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Белый парус»: Р. ЮСУПОВА. «Приключения Тэтчера» (продолжение).
«Юмор-сатира»: Р. МИННУЛЛИН. Эпиграммы.
В номере отмечается 80 летие С. Ибрагимовой, Г. Галиевой.
Новые члены Союза писателей.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Оттепель». Картина Б. ГИЛЬФАНОВА. Поэтесса Луиза ЯНСУАР.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by R. VALI «Winged Tatar» (continuation), story by A. HASANOV «Anis apples», story by A. AHMETGALEEVA «Pulled out flower», verses by G. MURAT, K. BULATOVA, R. ZAKUANOVA, A. SITDIKOVA.
«Youth creativity»: verses by L. YAKUPOVA. «To 90th anniversary of newspaper «Vatanym Tatarstan»: K. KARIMOV «Thirteenth hope».
«To 90th anniversary of newspaper «Kyzyl Tan»: article by K. YULAEV.
«To 70th anniversary of R.Batulla»: F. HATIPOV. «Restless soul».
«Book review»: article by R. FAYZULLIN on book by G. Muhametshin.
«Memory»: M. USMANOV. «Intelligence», A. GILYAZOV. Pages from diary.
«Science»: A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation» (continuation); F. GARIPOVA. «History of our villages" (continuation) Pages from «Tatar encyclopedia».
«White sail»: R. YUSUPOVA. «Thatcher's adventure» (continuation).
«Humour-satire»: R. MINNULIN. Epigrams.
In number is celebrated 80th anniversary of S. Ibragimova, G. Galieva.
New members of Union of writers.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Thawing weather». Picture by B.GILFANOV. Poetess Louise YANSUAR.

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 26.02.2008 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Т–196 Тираж 5151.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2008 ел.



Газинур
Морат

# ЮЛ ТАМГАСЫ—ЙОЛДЫЗ ЯЗУЫННАН...

## Әткәй гәҗит укый

*(Хатирә)*

Үз сәгатең суккач, китүләр бар,
Ә кайтулар, бәлки, юктыр да.
Күз алдымда бер манзара тора:
Әткәй гәҗит укып утыра.

Әткәй гәҗит укый.
Көяз генә
Төзәткәләп куя күзлеген.
Хәлфәләрдән алган сабагы да
Тик башлангыч кына үзенең.

Гомер буе нужа йөген тартып,
Иңә төшкән инде иңе дә.
Тормыш биргән сабагын да кушсаң,
Бер талмудлык булыр кимендә.

Әткәй гәҗит укый.
Вакыт-вакыт
Көрсенгәләп ала.
Аннары
Үзалдына гына әйтеп куя:
«Влач безне тагын алдады.
Теге чакта да шул влач иде,
Беләсеңме, безне нишләтте—
Өй салырга дигән маяны да
Калдырды ул тик бер бишмәтлек.

Инде менә кабат алдадылар,
Ә без менә кабат алдандык.
Кемнәр, энә, «шинельдән дә чыккан»,
Без бишмәттән чыга алмадык...

---

Газинур МОРАТ (1959) *—шагыйрь, публицист; «Мин дөньяны тыңлыйм», «Җәяүле кошлар», «Төнге әверелеш» һ.б. китаплар авторы. М. Җәлил исемендәге республика һәм Г. Исхакый премияләре лауреаты. Казанда яши.*

Дөньясы да юкса үзгәрде күк,
Гел үзгәрде бишмәт хакы да.
Без дә үзгә хәзер.
Ә бу влач
Ник үзгәрми икән чак кына?

Ә бит үзе гел дә бердәмлеккә,
Гаделлеккә безне чакыра».

...Бу сүзләрне әткәй әйттеме соң,
Әллә үзем—әткәй җаена...
Хатирәләр арта барган саен,
Уй чуала, хәтер саега.

Үз сәгатең суккач, кайтулар бар,
Ә китүләр, бәлки, юктыр да.
Күз алдымда тора бер манзара:
Әткәй гәҗит укып утыра...

## Ятим

Тәкъдир аны иркәләп тә,
Типкәләп тә сынады.
Еллар исәбен җуйса да,
Яна әле чырагы.

Дөнья дигән бер куышта
Яши ул ялгыз башы.
Хәл-әхвәл белешергә дә
Калмады бер кордашы.

Кордашлары, кардәшләре
Ашты күптән гарешкә.
Ул үзе дә юкса Локман
Хәким белән бер яшьтә.

Йөртәдер җирдә бәндәне
Җыясы тәгам, ашы.
Ярый әле дисбесе бар,—
Шул бердәнбер уйдашы.

Элек дөнья йөген тартты,
Хәзер—дисбе төймәсен...

Вакыт исәбен җуйса да,
Икендесен, өйләсен
Яттан белә ул.
Догадан
Калдырмый төп-ыруын.
Амин тоткач, көе килсә,
Әйтеп куя җыруын:
«Иделдә үтте тугыз хан,
Җаекта үтте сигез...
Шул ханнарны күреп белгән
Карт булам мин—белегез».

Тәкъдир аны тол итеп тә,
Кол итеп тә сынады.
Вакыт исәбен җуйса да,
Яна әле чырагы.

Дөнья көтеп ята шулай,
Башка эше юк аның.
Дога багышлар бәндәнең
Көтә әле туганын...

## Буйдак

Пар мендәрдә ялгыз башы
Ята төнне ябынып.
Сөяр иде, яры юк шул,
Сөяр иде, яры юк.

Тәүге ярын төштә күрсә,
Гел яхшыга юрады.
Сөяр иде, яры юк шул,
Сөяр иде, юк яры.

Гөнаһларның кершәне дә
Тәкъдиренә ягылып
Калды бугай...
Сөяр иде,
Яры юк шул, яры юк.

Тәүге яры төшләрендә
Рәшә кебек югалды.
Сөяр иде, яры юк шул,
Сөяр иде, юк яры...

## Шәҗәрә

*Дамир Гарифуллинга*

Ерак әлгәрләрне барлап
Утырган чакларым бар.
Кыйссаларын сыктый-сыктый
Укыган чакларым бар.

Кыйссаларын көйли-көйли
Уйланган чакларым бар.
Атилла хан ыстанында
Уянган чакларым бар.

Нух бабайның көймәсендә
Иделләр кичкәнем бар.
Әбелхәят суларын да
Кушучлап эчкәнем бар.

Иманнны сатмаган өчен
Ил белән бөлгәнем бар.
Шәҗәрәләр бакчасында
Казганып йөргәнем бар.

Шәҗәрәнең тамырлары
Сау, шөкер, исән-аман.
Ябалдашы гына менә
Коргаксый бара һаман.

Күктә тамырланып үсәр
Шәҗәрәдер, югыйсә.
Безнең гомерләр дә, бәлки,
Сыктап укыр бер кыйссадыр,
Көйләп укыр бер кыйсса...

## Франсуа Вийон

«—Мин үземнән гайре барысын да беләм:
Абага ник чәчкә атканын да,
Сулар нигә үргә акканын да.

Мин үземнән гайре барысын да беләм:
Ике икең ник биш икәнен дә,
Хозыр картның кая киткәнен дә.

Мин үземнән гайре барысын да беләм:
Бу дөньяның иң зур хатасын да,
Гайсә пәйгамбәрнең атасын да.

Мин үземнән гайре барысын да беләм:
Бу юлларның кая илтәсен дә,
Кузгалырга вакыт җитәсен дә.

Мин үземнән гайре барысын да беләм...»

## Торналар киткәндә килгән уй

*(Тәкълид)*

Фал китабын ачып юрасаң да,
Юш килмәстер мәгәр юраганың.
Бу дөньяда кеше дигәнең дә
Оча-оча китеп югаладыр.

Кошлар кебек ул да адашмыйдыр,
Очар юлы кыйбла ягынадыр.
Күктә күрмешләре—тәкъдиренең
Кара әрҗәсенә языладыр.

Бу дөньяда Вакыт дигәнең дә
Кошлар юлы кебек җуеладыр.
Кара әрҗәдәге соңгы хәбәр
Күкләр хәтеренә уеладыр.

## Минем сәгать әкрен йөри бугай...

Минем сәгать әкрен йөри бугай,
Гел соңарам, һаман кабаланам.
Ямчы агай камчылаган саен,
Мин дөньядан артта кала барам.

Артта кала барам, чабышларда
Иң соңарып килгән чаптар кебек.
Дөньясы да юкса сәер генә—
Алга карап, артка чапкан кебек.

Дөнья куа белми йөдәгәнгә,
Артта кала барам заманадан.
Минем дәрвиш икәнлекне Вакыт
Күптән инде, ахры, чамалаган.

Минем сәгать шуңа әкрен йөри,
Әкрен яна бугай учагым да.
Гел кичегәм... Миңа насыйп яр да
Күптән инде ятлар кочагында.

Дөнья куа белми йөдәгәнгә,
Җәяү атлыйм Киек Каз юлыннан.
Юл тамгасын таныйм
Илаһының
Күккә уйган йолдыз язуыннан.

«Ул гел кичекте», дип, фәрештә дә
Язып куяр гамәл дәфтәремә.
Тик мин шуны беләм:
Беркайчан да
Соңга калмам соңгы сәфәремә.

Ямчы агай камчылаган саен
Мин дөньядан артта кала барам.
Мин үзем дә иске сәгать бугай,—
Гел соңарам, һаман кабаланам...

## Меланхолия

Бу араларда
Шундый хәл, туган:
Уй качты баштан,
Эш төште кулдан.

Моң качты җырдан,
Кот качты илдән.
Күз—түбән тездән,
Сүз—түбән билдән.

Мәхшәр көнмени,—
Катарсың шаклар,—
Кая карама—
Шартлау да шартлау.

Сәясәтләре
Туксак та чатан.
Бар дөньясында
Туй итә шәйтан.

Барасы юлны
Каплаган томан...
Бу араларда
Шундый хәл, туган.

Равил
Вәли

# КАНАТЛЫ ТАТАР

РОМАН

## 15

Киров театрының күпме вакытлар әйдәп баручы биючесе булу өстенә, озак еллар баш балетмейстер хезмәтләрен дә башкарган Сергеевның, әлбәттә, күп жирдә, шул исәптән Питер каласының партия һәм совет житәкчеләре арасында да сүзе жинел үтә, шуна күрә Нуриев кебек яшь әтәчләргә аяк чалу ана берни тормый иде. Яшьләрнең 1959 ел августында Вена каласында узачак халыкара фестиваленә Ленинградтан барырга тиешле яшь биючеләр исемлегендә үзен күрмәгәч тә Рудольф артык югалып калмады. Ул мондый аяк чалуларга күнегеп килә иде инде. Монысы да шул көнче күбәләкләр эше булырга тиеш! Аның белән бергә укыган һәм аннан күпкә кайтышрак Юрий Соловьев, Татьяна Легат, Нинель Кургапкина, Алла Сизова, Алла Осипенко һәм Ирина Колпакова исем-фамилияләре бар, ә алардан бер башка өстенрәк Рудольф Нуриевныкы булмаска тиеш, имеш!..

Театрның хәзерге директоры Борис Фенстер, совет тематикасына кызыл эчтәлекле балетлар кую белән мавыккан Сергеевтан аермалы буларак, көнбатыш тарафлардан искән замана жилләренә күбрәк колак сала иде. Шунлыктан ул өметле яшь биюче Рудольфны бер ел элек эшкә үзе ике куллап алды. Бүген дә ачык йөз, жылы сүз белән кабул итте:

—О-о, Нуриев!.. Әйдүк, әйдүк!.. Гомумән алганда, без синең биюдән бик канәгать, энем! Киләчәктә дә шулай дәвам ит!

—Бик дәвам итәсе иде дә...—диде Рудольф, кайчандыр үзе дә танылган биюче булган башлыгының мактавына бик алай эреп төшмичә генә.

—Йә, йә... Ни булды әле, Рудольф Хәмитович? Нигә алай йөзең карангы?

—Ничек инде карангы булмасын? Венага баручылар исемлегенә кертмәсеннәр дә...

—Ә-ә, яшьләрнең теге халыкара фестиваленәме?

—Сон...

—Бик барасын киләме?

—Ничек инде килмәсен?

Үз уйларына чумып бераз торгач, житәкче кәнәфиендә утыра-утыра инде шактый юанаеп өлгергән Фенстер кинәт сорап куйды:

—Сина ничә яшь әле, Рудик?

—Егерме бер.

—Ә мин инде иллегә якынлашып киләм. Тик шушы көнгә тикле әле бернинди чит илгә чыгып караганым юк. Хрущевка рәхмәт әйтергә кирәк.

*Дәвамы. Башы узган санда.*

Ил чикләренә Сталин корган тимер пәрдә читен аз гына күтәрә төшеп, ул Мәскәүнең Зур театрына 1956 елда Лондон гастрольләренә барып кайтырга ирек бирде.

—Бик бирмәс иде дә—арты юеш!

—Ә ник юеш?

—Чөнки совет гаскәрләре шушы ук елны Венгриягә басып кергәч, атом һәлакәте чүт-чүт кенә купмыйча калып, Советлар Союзына карата бөтен көнбатышның нәфрәте туып өлгерде. Совет артистларын Англиягә җибәреп, әнә шул нәфрәтне тизрәк киметергә кирәк булды. Ә Пастернак соң, Борис Пастернак? Совет матбугатында әле кайчан гына үтереп тәнкыйтьләнгән «Доктор Живаго» романының узган елны хәтта Нобель премиясенә лаек булуы. Һәм, КГБ агайларының көчле басымы аркасында, күренекле әдипнең дәрәҗәле бүләктән баш тартырга мәҗбүр ителүе...

Фенстер, андый-мондый озын колаклар тынлап тормыймы дип шикләнгәндәй, башта як-ягына каранып куйды һәм сәясәт белән кызыксынмый, шуңа күрә әле һаман комсомолга да кермичә йөри дигән кара даны чыккан Рудольфка сынаулы караш ташлады:

—Дөрес, Рудик... Тиздән менә без дә ерак юлга җыена башларбыз дип торабыз.

—Кая?

—Башта—Франциягә, аннары—Англия белән Америкага.

—Оһо-һо!.. Ә Венага?

Директор Фенстер үз каршында яткан исемлекне кулына алды:

—Бик теләгәч, барып кайт соң, энем! Хәзер өстәп язып куябыз үзеңне... Тик карап йөри күр анда! Дошманнарың да, көндәшләрең дә буа буарлык!—диде ул һәм бераздан өстәп куйды—Хәер, бу нәкъ менә шулай булырга тиештер дә! Чөнки зур дингезнең давылы да көчлерәк булучан. Шуңа күрә аптырама һәм һич тә бирешә күрмә, егет! Сине алда, һичшиксез, зур һәм матур киләчәк көтә. Мин моңа чын күңелемнән ышанам һәм бел: боларны сиңа якын күреп әйтүем.

—Рәхмәт, остазым.

—Йә, ярый... Хәерле юллар үзеңә...—диде Фенстер һәм, кинәт йөзен чытып, бияләй хәтле куллары белән йөрәк турысына үрелде.—Гафу ит... Йөрәк...

Моны күргәч, табанына ут капкан кешедәй, Рудольф утырган җиреннән сикереп торды:

—Ашыгыч ярдәм чакыртыйммы?

—Юк, кирәкми. Хәзер үтәр ул, Рудик! Хуш...

Юк, бу юлы Рудольф Нуриевка соңгы яхшылык кылган изге күңелле директор Фенстер аяктан егылмады. (Аның сәхнәгә үзе куйган яңа балеты барганда, инфаркт сугып, нибары кырык алты яшьтә йөрәге ярылып үләренә тагын бер ел чамасы калган иде әле).

Фенстер ихтыярына каршы килүче булмады. Рудольф тыныч күңел белән ерак юлга әзерләнә башлады. Тиздән, инде бик тиздән аңа киң һәм иркен дөньяның монарчы тыелган тагын бер гүзәл почмагы ачылып китәчәк!

Әйе, балет артистларына соңгы вакытларда гына тәти башлаган бик тансык һәм кадерле сәфәр иде бу. Аның кадере шунда: гастроль көннәре өчен бирелә торган тәүлеклек акча шул илнеке, ягъни валюта белән түләнә. Ә бу хәл артист халкына монарчы төшләренә дә керә алмаган өр-яңа мөмкинлекләр бирә. Хатын-кызлар, билгеле инде, затлы тукымасы һәм тегелеше белән әлегәчә күрелмәгән төрле кием-салым, чүпрәк-чапрак вә бизәнү әйберләренә ябырыла. Бу көннәрдә ашасын ашамыйча, эчәсен эчмичә коры-сары белән җан асраса асрый, нишләтәсең аларны, ләкин менә ябырыла инде!

Ирләрне исә күбрәк вак-төяк техника ише әйберләр кызыксындыра. Шулай итеп, ике-өч атна, кайчакларда хәтта берничә ай барган гастрольләрдән кайтып

кергәндә, күпчелек артистларнын юл капчыклары туган-тумачалары, дус-ишләре һәм таныш-белешләренә бүләк ителәчәк дефицит товар белән тулган була. Ә кем белә, күп балалы, такы—токырак көн күргән сәнгать әһелләре һәркемнең күзе төшәрлек мондый әйберләрне базарга алып чыгып саталардыр да әле. Менә ни өчен яшь һәм карт артистлар, мөмкин булган һәм булмаган барлык чараларны эшкә жигеп, чит ил гастрольләренә бару ягын кайгырта. Житәкчелек исә мондый тансык сәфәрләрне үзенә күрә кызыктыру, бүләкләү яки мәхрүм итү чарасы буларак бик оста файдалана иде.

Рудольфның һичкайчан мондый ялтыравык әйберләр өчен жан атканы булмады. Бүтән төбәкләргә, башка шәһәрләргә барырга туры килгәндә, ул Чайковский, Шостакович, Бах, Скрябин кебек яраткан композиторларының сирәк очраучы пластинкаларын, ил тарихын, әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләрен яктырткан китапларны эзләргә тотына иде. Тапкан очракта, кош тоткандай сөенә, сабый балалар кебек куаныр иде.

16

Вена тарафларына кузгалганчы, Мәскәүнең жиз иләге аша үтәргә кирәк иде әле. Комиссия каршына барып басар алдыннан, тиешле репетицияләр ясау өчен, аларны бетон идәнле фехтование залына урнаштырып торырга мәжбүр булдылар. Чөнки очсыз-кырыйсыз СССР империясенең иксез-чиксез почмакларыннан бу көннәрдә Мәскәү аша Вена фестиваленә агылган барлык делегацияләрнең дә көен көйләп өлгерерлек түгел иде. Аяк сеңерен өздерү фажигасен кичереп, әле яңа бии башлаган Рудольфка исә бетон идәндә катлаулы күнегүләр ясарга һич кенә дә ярамый иде. Шуңлыктан ул сабыр итәргә булды.

—Нәрсә... Нуриевнын чираттагы капризы дип аңлыйкмы инде моны?— дип жикеренде яшь биючеләр төркеменең башлыгы.—Бүтәннәргә яраган сиңа ошамыймы?

Рудольф аны әлегә сабыр гына тынычландырмак булып та карады:

—Сез бит минем нигә ике ай буе биеми торуымны беләсездер, шәт?

—Белсәм соң... Нуриевнын ныгып житмәгән аяк сеңерләре кабат өзелә күрмәсен дип без бу фехтование залына агач идән жәеп чыгарга тиешмени инде?

—Жәймәгез... Нигә жәясез?

—Алайса, нишләргә соң?

—Фестивальгә сайлап алу комиссиясен читләтеп үтеп, туп-туры Венага гына уздырып жибәреп булмыймы соң? Һәм вәссәләм.. Мина комиссия алдында түгел, Вена сәхнәсендә бию мөһимрәк.

—Менә анысын инде комиссия үзе хәл итәр...

Рудольфның биючелек осталыгы бер дә алай тел-теш тидерерлек түгел иде. Шуңлыктан, әле кайчан гына яшь биючеләрнең Мәскәү феставаленда жиңеп чыгуын да искә алып, комиссия иләге аша аны бик тиз һәм жиңел уздырып жибәрделәр.

Алы булды—инде гөлө кирәк! Аларны Мәскәүдән Вена каласына галәмәт озын автобус алып барды. Күптән көтелгән мондый сирәк һәм тансык сәфәргә кузгалганда кәефләр һәрчак күтәренке булучан. Бу юлы да Мәскәүне чыгып бераз баруга, алгы рәтләрдә утырган кемдер жыр башлап жибәрде:

> Широка-а страна моя родная,
> Много в ней-й лесов, полей и рек...

Бераздан аны бүтәннәр күтәреп алды:

> Я друго-ой такой страны не знаю,
> Где так во-ольно дышит человек!

Бөтен автобус шашып җырлый. Тик Рудольфның гына һәр юлыннан, һәр сүзенән ачыктан-ачык ялган, оятсыз һәм әрсез фальш бөркелеп торган бу җырга кушыласы килмәде. Нишләп артык иркен соң әле ул ил, рәхмәт төшкере?! Нигә кырлары һәм урман-суы чиксез күп? Чөнки күрше дәүләтләрнең, шул исәптән Казан һәм Себер, Әстерхан һәм Кырым ханлыклары кебек төрки мәмләкәтләрнең дә җирләрен басып алып, алар һәм үз киләчәгенә, әйе, әйе, нәкъ менә үз киләчәгенә дә иләмсез тышау салганга! Дөньяның алтыдан бер өлешен биләгән, шунлыктан юньләп идарә итеlә алмаган, авызын ачса—үпкәсе күренеп торган хәерче халкы исә бар тапкан байлыгын ашкынып кораллануга тотарга мәҗбүр ителгән СССР империясенең иркенлегенә сөенергә түгел, ә көенергә кирәк тә бит!

Ә безнең кебек иркен сулау мәсьәләсенә килгәндә... Бу очракта «вольно» сүзен «больно» дип җырлау дөресрәк буладыр бәлки?

Рудольф хәтта үзе үзгәрткән җыр азагын авыз эченнән генә пышылдап—көйләп тә карады:

Я друго-ой такой страны не знаю,
Где так бо-ольно дышит человек!

Ничек килешепләр торуын кара син! Һәм бернинди ялган, косасыны китергән бернинди фальш юк!

Шулчак, борчулы уйларыннан арындырып, кемдер Рудольфның кабыргасына төртеп куйды:

—Нигә җырламыйсыз, Нуриев? Бүтәннәр җырлаганда—җырларга, елаганда—еларга кирәк!

Кара, Ленинградтан килгәннән бирле яшь биючеләр арасында бутала башлаган бу киң эшләпәле, кара плащлы таныш түгел егет Рудольфның фамилиясен дә белә икән бит. КГБдан ияртеп җибәрелгән күләгәдер, мөгаен. Димәк, сөйләшкән сүзләрендә генә түгел, уйлаган уйларында да бик сак булырга кирәк!

Теге күләгә тагын кабырганы санап китмәсен дип, Рудольф йокымсыраган кешегә сабышты. Ул хәтта, хәйләсенә ышандыру өчен, үз янәшәсендә утырган Нинель Кургапкина иңбашына башын сала төште. Ә сәхнәдәш пары—галәмәт талантлы татар егетенә күптән инде күз атып йөргән бу биюче кызга шул гына кирәк иде дә. Ул да, рәхмәтле җавап йөзеннән, сары чәчле пумала башын Рудольфныкына салды. Башны башка терәп шулай байтак баргач, йокысыннан айныган кешедәй, Рудольф кинәт күзләрен ачып җибәрде. «Иркен сулый торган» халыкның үз гомерләрендә беренче мәртәбә чит илгә юл тоткан уллары һәм кызлары, шашып җырлый-җырлый тәмам арып, инде тирән йокыга талганнар иде.

Яшьләр фестивалендә катнашучылар белән шыплап тутырылган Мәскәү автобусы менә Вена каласындагы үзәк кунакханәләрнең берсе каршына килеп туктады. Автобустан төшеп беренче кат чит ил туфрагына аяк басуга, Рудольф үзен ябык читлектән яңа чыгарылган сайрар коштай хис итте. Бүтән артистларның күбесе, эреле-ваклы кибетләргә тукталып, инде бүгеннән үк юл капчыкларын тутыра башлау хәстәренә керешге. Ә Рудольф, Нинель белән житәкләшеп, Вена каласының бөек Моцарт моңнары сеңгән киң, якты урамнарыннан атлап китте. Аның тизрәк Австрия башкаласының истәлекле урыннары белән танышасы килә иде...

## 17

Фестиваль бәйгесенең икенче көнендә Алла Сизова белән Рудольф Нуриев «Корсар» балетыннан атаклы па-де-де вариациясен башкарып дан казандылар. Алар чыгышы мөмкин булган иң югары—уникe балл белән бәяләнде һәм

фестивальнен алтын медаленә лаек булды. Ленинградтан Ирина Колпакова белән Юрий Соловьев, Мәскәүдән Елена Максимова белән Владимир Васильев парларына да, түбәнрәк балл җыюларына карамастан, шушындый ук беренче урын бүләкләре бирелде.

Мондый «гаделсезлек»кә Рудольфның җан ачуы чыкты:

—Алла, минем алтын медалемне дә апкайтырсың, яме!—диде ул, фестивальнең бүләкләү тантанасына барудан кискен баш тартып.

—Ә ник, Рудик? Әйдә, кәҗәләнмә инде... Бергә биедек—медален дә бергә алыйк!

Ләкин, үгетләү түгел—хет артын дегетлә, Рудольфның үз туксаны туксан иде:

—Юк,бармыйм дигәч, бармыйм!.. Чөнки беренче урын, галәттә, берәү генә була!

Алла Сизова, тирән итеп сулыш ала-ала, йөзен җыерды:

—Их, Рудик, Рудик! Нигә шундый икән син?

—Нинди?

—Артык гадел димме... Алтын медальләрнең нуры алтыбызга да җитәчәк бит.

—Ә миңа менә җитми!

—Нигә җитми?

—Чөнки, кабатлап әйтәм, театрның баш балетмейстеры берәү генә булган кебек, һәр ярыш-бәйгенең дә алтын медале алтау була алмый.

—Ләкин монда бит бөтенләй башка хәл, Рудик.

—Нәрсәсе башка?

—Бөтен дөньясы карап-күреп тора! Җитәкчеләребез ни әйтер? Безгә күз-колак итеп җибәрелгән усал күләгәләр ни дияр?—диде Алла Сизова һәм, үкси-үкси, елый башлады.—Тиздән Париж белән Лондонга барачакбыз, имештер... Безне бит болай чит илгә бүтән аяк бастырмаячаклар, Руденька!.. Ни өчен синең чираттагы үҗәтлегең аркасында, мин ул гүзәл калаларны күрмәскә, алардагы затлы сәхнәләрдә биемәскә тиеш ди әле?.. Аңлыйсыңмы шуны?!..

Рудольф, сәхнәдәш парын җәлләп, Алла Сизованың дер-дер калтыранган иңбашларына кулын салды:

—Йә, тынычлан, акыллым.

Алла Сизова сәхнәдә генә түгел, тормышта да гаҗәеп назлы, мөлаем һәм ягымлы була белә иде:

—Ә элегрәк матурым дип дәшә идең...—диде ул Рудольфның көчле күкрәгенә башын куеп.—Руденька дим... Зинһар, үз җиңүең өчен тиешле алтын медальне үз кулларың белән ала күр! Минем хакка! Сәхнәдәш парың гына түгел, өч ел бергә укыган сабакташың, болар гына җитмәсә, уртак фатирда яшәгән күршең хакына!..

—Шулай дисәң генә инде, Алла...

Рудольфның күбрәк балл җыеп, дөнья бәйгесендә Мәскәү биючеләре борыннарына чиерткәне өчен, Зур театр артисты Владимир Васильев та кара коелып йөрде. Әле кайчан гына: «Мәскәүгә күчеп кил—Зур театр сәхнәсендә бергәләшеп биербез!»—дип сайраган бу яшь йолдызга әллә нәрсә булган иде. Кая ул үзе килеп котлау? Ул хәтта, пьедестальдән төшкәч, Рулоьфка кул бирергә дә теләмәде. Кара көнчелек дигәннәре менә шушы була торгандыр инде.

Тиздән Мәскәүнең яшь биючеләрен яман көнләштергән тагын бер хәл булып алды.

Вена фестиваленнән алар поездга утырып, Болгария җире аша кайттылар. Тарих китапларын кечкенәдән җыярга һәм укырга яраткан Рудольфның Кубрат хан токымы белән бәйләнешле ерак бабалары яшәгән бу мәмләкәт туфрагына тынгысыз башын күптән орасы килеп йөри иде. Шуна күрә,

әлеге ил чигеннән үтеп керүгә, ул ачык пыялалы поезд тәрәзәсе каршына килеп басты. Жылы август җиле, «исәнме, кардәш!» дигәндәй, аның тынлаусыз маңгай чәчләрен килеп тарады.

Ә күз каршыннан яшел бакчалы авыл-шәһәрләр, түгәрәк гөмбәзле биек чиркәүләр йөгерешеп үтә торды. Тик, никадәрле генә тырышып күзәтсә дә, Рудольф ярым айлы, яшел манаралы мәчетләрне күрә алмады. Ана, никтер, бик, бик монсу һәм ямансу булып китте. Ирексездән, Башкортстан, Дунай болгарларына тугандаш Идел төркиләренең оныклары яшәүче күрше Татарстанның кичәгесе һәм бүгенгесе турында уйланды. Һәм ул үзе өчен шактый борчулы ачыш ясады.

Әйе, киләчәккә үткен гыйбрәт булып барырлык бик тә аяныч һәм искитмәле хәл килеп чыккан. Мөселман динле Төркия карамагыннан котылып, Дунай буендагы славяннар кабаласына килеп эләккән Болгариянең бүген бәйсез үз дәүләте бар, ә күпме гасырлар сөйләшкән туган теле юк! Россиянең Башкортстан белән Татарстан кебек төрки мәмләкәтләрендә исә киресенчә: ерак бабалары сөйләшкән телләре әлегә исән, ә бәйсез үз дәүләтләре юк! Вәт менә бу—гыйбрәт дисәң дә гыйбрәт!

Хәер, синен үз тормышын да, Рудольф, бик тә гыйбрәтле гыйбрәт түгелмени?! Син соң, энекәш, син соң кайсы телдә сөйләшәсен? Синен туган телең нинди? Урысчамы, әллә инде онытылып бетә язган татарчанмы? Дөрес, бабаларың телендә ипи-тозлык кына беләсең анысы. Ләкин газиз әниең хәтле әниең белән сирәк-мирәк очрашкан чакларда да: «Акчаң бармы? Юк? Мә, алайса!»—дип күбесенчә дүрт-биш сүз белән генә үз телендә сөйләшкәч, син дә туган телен югалткан нәкъ менә шушы Болгария дигән искиткеч гүзәл һәм коточкыч кызганыч та булган ил-дәүләткә охшап калгансың түгелме соң?! Их, Рудольф, Рудольф!.. Дөрес, махсус курсларга йөреп, син хәзер инглизчә дә әйбәт кенә сукалый башладың. Менә бит—тырышкач була икән ич!..

Ләкин, нихәтле генә үкенечле булмасын, туган телен җитәрлек белмәүдә Рудольф үзен һәм әти-әнисен генә гаепли алмый иде. Аның бит бөтен балачагы кече Ватаныннан читтә узды диярлек...

Рудольфны күнелсез уйларыннан арындырып, сузып-сузып тепловоз кычкыртты. Поезд София каласының үзәк вокзалына якынлашып килә икән...

Фестивальнең махсус билгеләре белән бик мул итеп бизәлгән вагоннар әле перронга килеп тукталганчы ук, ачык тәрәзәдән чәчәк бәйләмнәре очып керә башлады. Кемнәрдәр сап-сары әфлисунлы кәрҗиннәр, тагын әллә нәрсәләр сузды.

Ул арада, шашып кул чаба-чаба, кычкыра ук башладылар:

—Ну-ри-ев! Ну-ри-ев!! Ну-ри-ев!!!

—Җиңеп кайтуың белән!

—Алтын медалең котлы булсын!..

Рудольф бу шат тавышларның сәбәбен шунда ук аңлап алды: аларның Венадагы зур җиңүле чыгышлары турындагы хәбәр, күрәсең, бирегә үзләреннән элгәрәк кайтып җиткән икән. Алайса, ник бер дә «Со-ловь-ев!» яки «Ва-силь-ев!» дип кычкырган тавышлар ишетелми? Юк, бу очракта аларның Рудольфтан кимрәк балл җыю, сүрәнрәк биюләрәендә генә түгел иде бугай хикмәт. Рудольф ниндидер ерак гасырларга барып тоташкан эчке тойгылары белән сизеп алды: Дунай болгарлары дөнья бәйгесендә җиңеп чыккан яшь биюченең үзләренә кандаш-тугандаш татар егете икәнлеген аңлап алганнар, әнә шуңа бөтен вокзал тирәсен гөр китереп кул чабалардыр төсле иде. Озын-озак кул чабулар һәм «Ну-ри-ев!» дип бервзлексез кычкыру-чакырулар һаман тынмагач, Рудольф ачык ишекле тамбурга чыгып басты. Аны шунда ук танып алдылар һәм, аяк-кулларыннан эләктереп, вокзал күгенә чөйделәр. Аннары тагын, тагын чөйделәр. Әйтерсең, ул—татарча көрәш мәйданында җиңү яулаган Сабантуй батыры!

Әллә тиздән кузгалып китәсен белдереп, әллә Вена каласыннан җинеп кайтучы татар егетен котлап, тепловоз йөртүче чираттагы сигналын биреп куйды. Канкардәшләре тарафыннан һаваларга чөелгән Рудольф бу минутларда үзен ерак туган җирендәге талбишектә тирбәлгән бик бәхетле сабый итеп тойды.

## 18

Киров театрына Юрий Григорович дигән гаҗәеп талантлы яшь балетмейстер килгәч, композитор Адольф Аданның «Жизель» балетын куюга әзерлек эшләре башланды. Бу бөркетнең киләчәктә үзеннән дә биектәрәк очачагын баш балетмейстер Константин Сергеев бик тиз аңлап алды һәм, ни кылыр икән әлеге яшь әтәчләр дип, читтән генә күзәтеп йөри башлады.

Ә Григорович тотты да Альберт ролен биергә театрның яшь йолдызы Рудольф Нуриевны чакырды:

—Утыз ел бии-бии, Сергеев картайтып бетергән бу образны күптән яшәртергә вакыт. Ничек итеп—әйдәгез, бергәләп уйлашыйк,—диде ул, иҗади хезмәттәшлеккә чакырып.

Рудольф театрда, ниһаять, үз фикердәше табылуга куанып бетә алмады:

—Ә мин күптән инде шундый ук теләк белән янамын!

—Бик яхшы... Ә хәзер бераз эчкәрәк керик. Сергеев күпме еллар биегән Альбертның, әйтик, сиңа нәрсәсе ошамый?

—Хәерче крестьян кызы Жизельне алдап, аксөякләр вәкиле Альбертның рухи газаплану түгел, ә физик канәгатьләнү кичерүе.

Григорович, кош тоткандай куанып, Рудольфның кулын килеп кысты:

—Менә-менә... Шулай, Рудик, шула-ай! Бөтен хикмәт тә аристократ Альбертның рухи газаплану кичерергә тиеш булуында! Менә бу иҗади табыш булачак, ичмаса!

—Һәм хөрмәтле Сергеевның утыз ел куйган хезмәтен бер селтәнүдә юкка чыгарумы?

—Чыксын!.. Сергеев Альберты моңа бик лаек! Ике яшь йөрәк арасындагы саф мәхәббәтне социаль конфликтка борырга һич ярамый. Көнбатыш күршеләребездән оят.

—Аның каруы, Советлар Союзында монархчы гел мактала килгән.

—Дөрес әйтәсең, Рудик. Утыз ел буе әнә шулай макталганга күрә дә, Сергеев биегән классик балетлардагы күпчелек геройлар социаль конфликт дигән ялган каршылыкка корылган.

Рудольф, нәтиҗә ясагандай, әйтеп куйды:

—Моның сәбәбе, минемчә, бер генә.

—Нәрсәдә?

—Сергеевның, театр түрәсе булып, партия һәм совет идарәчеләре арасында артык еш чуалырга яратуында.

Григорович, килешүен белдереп, Рудольфның тагын бер кат кулын кысты:

—Бир бишне, Рудик!.. Ә хәзер—эшкә! Безгә әле ерак-еракларга барасы!..

Шулай итеп, беренче очрашып сөйләшүдә үк, тиздән сәхнәгә менәчәк «Жизель» балетының хореографы белән төп биючесе арасында тулы аңлашу җепләре сузылып өлгерде. Хәзер инде Сергеев Альбертының капма-каршысы булган өр-яңа геройны сәхнәдәге бию телендә гәүдәләндереп бирү турыдантуры Рудольф талантыннан бәйле иде.

Иң беренче эш итеп, Альберт роленнән ул бер аякны икенчесенә бәреп сөенү хисләрен белдергән, балет телендә «бризе» дип аталган бию хәрәкәтләрен алып атты. Сергеев Альберты бу мактанчык, ялган куаныч хәрәкәтләрен авыл кызы Жизельне алдагач ясый. Ничек инде бу оятсызлыкка сөенеп булсын? Юк, әлеге урында Рудольф Альбертының рухи газапларын ярсу антрашалар, ярсу өермәле биек пируэтлар сөйләп бирәчәк!

Аннары кием мәсьәләсе. Тәбәнәгрәк гәүдәсен биегәйтеп күрсәтү өчен, Рудольф күптән инде камзул итәкләрен кисеп өскәрәк менгерергә, ягъни бот-балтырларын күбрәк ача төшәргә кызыгып йөри иде. Гаурәт жирләрен каплап торган балет панталонын да, монарчы күнегелгәнчә, тән төсендәге юка трико өстеннән түгел, ә астыннан кияргә! Шулай итеп, сәхнә күгендә очып йөриячәк гәүдәсен тоташ бер кош рәвешенә китерергә! Әлбәттә, бу кемнәргәдер ошап бетмәс. Атаклы биюче Вацлав Нижинскийны да бит тол патшабикә Мария Федоровна нәкъ менә үтә күренмәле трикосы өчен эшеннән кудыртган диләр.

Шулай итеп, үз Альбертын яңача киендерүе белән Рудольф бер атуда ике куянга тидерә алачак! Озын сүзнең кыскасы, янача киемле, янача уйлана һәм газаплана белүче бу образ Сергеев героеның нәкъ капма-каршысы булачак. Ягъни сөекле хатыны Дудинская белән бөтен дөньяга билгеле классик балет персонажларын утыз ел буе «кызартып» тасвирлаган хезмәтләренен тамырдан ялгыш булуын тәмам исбат итеп бирәчәк!

Күпме йокысыз төннәр, күнегүләр залында түгелгән күпме тозлы тирләрдән соң, ниһаять, ике ижатчы-новатор тарафыннан бөтенләй яңача куелган «Жизель» балетының сәхнәгә менәр көне дә житте. Шимбә, ягъни ул елларда әле эш көне булуга да карамастан, Киров театрының тамаша залы шыгрым тулы иде.

Һәм күпләр игътибар итмәгән тагын бер яналык: алгы рәтләрнең берсендә инде тәмам чаларган чәчләре урталай икегә бүлеп таралган алтмыш яшьләр тирәсендәге бер хатын утыра иде.

Бу ханым Уфадан Ленинградка—төпчек һәм бердәнбер улы Рудольфнын биюен карарга килгән Фәридә Нуриева иде.

Ул һич кенә дә болай ук булыр дип уйламаган иде.

«Жизель» спектакле башлануын белдереп, әле сәхнә пәрдәсе дә күтәрелмәгән, ә инде түземсез тамашачылар, урыннарыннан тора-тора, гөр китереп кул чаба да башладылар. Ә үзләре бертуктаусыз анын улы фамилиясен кабатлыйлар:

—Ну-ри-ев! Ну-ри-ев!..

Ленинградтагы атаклы Киров театрының тамаша залын дер селкеткән бу алкышларны ишеткәч, ана кешегә бик рәхәт һәм... унайсыз да булып китте. Чөнки анын, гомер буе Уфадагы кара эшләрдә бил бөгеп чәч агарткан гап-гади бер татар хатынынын, мондыйлар да затлы һәм дәрәжәле-күркәм залда беренче мәртәбә генә утыруы иде әле. Улы Рудольф чакыртты—ул килде. Төньяк башкаласы Ленинградны һәм газиз улы биячәк балетларны карарга дип килде!

Сугыш елларында дошманның озын-озак камавын үз башыннан кичергән Ленинград халкының бер-берләренә һәм бүтәннәргә үтә дә игътибарлы булуы, гомумән, рухи үсеш дәрәжәләре белән илнең башка төбәкләреннән шактый аерылып торулары хакында монарчы да ишеткәне бар иде инде Фәридәнен. Шулай икән шул, белми сөйләмиләр икән!

Залда Рудольфның ерак Урал якларыннан килгән кунак әнисе утыруын кайдан белеп өлгергәннәр диген, ул арада түземсез тамашачылар:

—Фә-ри-дә! Фә-ри-дә!..—дип тә алкышлый башладылар.

Үз гомерендә анын хөрмәтенә болай беренче мәртәбә кул чабулары иде әле. Оялу-тартынуданмы, әллә Ленинград кына түгел, инде бөтен ил, хәтта дөнья тамашачылары күнелен яулап ала башлаган биюче улы өчен тирән горурлык хисләреннәнме, ана кеше нишләргә дә белмәде. Анын утырган жиреннән торып басасы һәм артка таба борылып: «Сөекле улымның кадерле тамашачылары! Нигә шулай иртә кул чабасыз әле? Биесен башта бераз улым. Ошатсагыз—аннан соң да алкышларга өлгерерсез»,—диясе килә иде.

Фәридәне бик рәхәт һәм бик унайсыз да булган бу рухи халәттән коткарып, ниһаять, «Жизель» балеты башланып китте.

Әнисе янәшәсендә анын Уфадан күчеп килеп, инде Ленинградта—Рудольф фатирында яши башлаган өлкән кызы Роза да утыра иде. Әнесе кебек үк кечкенәдән үз мәктәпләрендәге бию түгәрәгендә шөгыльләнеп үскәнгәме, әллә соңгы вакытларда Киров театрындагы тамашаларга еш йөри башлаганга күрәме, ул балет әсәрләре белән дә ярыйсы ук танышып өлгергән иде. Шуна күрә Роза баштарак, әнисе әсәр эченә кереп киткәнче, сәхнәдә барган хәлләргә пышылдап кына гел анлатма биреп утырды:

—Әнә авыл кызы Жизель. Хәзер сәхнәгә аны алдап китеп бармакчы булган, ләкин кызны җәлләп, ана муеннан гашыйк булган принц Альберт чыгачак...

—Җәлләп гашыйк булганмыни, кызым?

—Шулай, әни, шулай... Җәлләп!

—Яхшы егет булган икән, алайса... Нәкъ әтиен кебек!

—Ул да сине җәлләп яраттымы әллә, әни?

—Әйе, кызым, әйе... Җәлләп!

Менә, утлы-канатлы ярсу өермә кебек бөтерелеп, сәхнәгә Рудольф-Альберт килеп чыкты. Чыкты да, кискен сикерешле, сирәк очрашлы көч-куәт бөркелгән бию хәрәкәтләре белән бөтен тамаша залынын игътибарын үзенә бәйләп куйды. Юк, анын ярсып янган күз карашларында кешеләргә сихри төстә тәэсир итә ала торган ниндидер тылсымлы көч бар икән бит! Карале, анын улы Рудик та тач әтисенә охшаган түгелме соң? Кунадай кин-таза шундый ук җилкә. Эшләп чыныккан бал кортларыныкыдай нечкә бил. Артык озын булмаса да, юлбарыстай көчле-житез гәүдә... Әйе, әйе! Ходай Тәгалә аны нәкь менә сәхнәләрдә шашып биесен, гүзәл кызларны баш очында каз каурыедай очыртып кына әйләндерсен өчен яраткан икән бит!

Фәридә бүген тагын бер кат шуна ышанды: чибәр йөз-кыяфәте, ыспай-көчле гәүдәсе, каударлы-житез хәрәкәтләре белән улы әтисе Хәмиткә кисеп каплагандай охшаган иде.

И Хәмит, Хәмит!

Исендәме икән Казан каласы читендәге чыгырлы коедан икәүләшеп су алган ул көннәр? Онытмадынмы?! Без ул чакта чыгырлы кое төбеннән сулы чиләкләребезне генә түгел, ә мөлдерәмә тулы бәхетебезне дә тартып чыгарганбыз икән бит!.. Әнә ул бәхет бүген, меңләгән, йөз меңләгән бихисап тамашачыларны сөендереп, төньяк мәркәзнен ин биек, ин затлы сәхнәләрендә гизә!

Ә син, Хәмит, өч кызына бердәнбер ир бала булган нәсел дәвамчынны күпме еллар анлый алмыйча яшәден. Еш кына: «Биеп тамак туймый—әнә, әтисе кебек хәрби офицер яисә инженер-фәлән булсын!» ,—дия иден. Сүзен дәлиллерәк чыксын өчен, мондый чакларда хәтта такмаклап та ала иден:

Бие, бие, Хәйбулла—
Биегән кеше бай була.
Биегән кеше бай булса да,
Кесә төбе сай була!

И Хәмит, Хәмит!

Ул чакларда газиз улынның балачак хыялларына аяк чалырга маташып ничек ялгышуынны сонлап булса да анладын микән син хәзер? Юктыр. Моны анлау өчен улын биюе тамаша залларын ничек тетрәндерүен үз күзләрен белән күреп утыру кирәктер шул!

Күпме чакырмады, күпме үгетләмәде ирен Фәридә:

—Әйдә, бердәнбер һәм газиз улыбызның Ленинград хәтле Ленинград сәхнәләрен ничек шаулатуын бергә барып күрик!—диде.

Хәмите исә:

—Юк, башта үзең генә барып күр. Энәсеннән җебенә тикле мина да сөйләрсең. Кирәк тапсам, киләсе җәйдә икәү барып карарбыз,—дип, ирлек горурлыгын, ата кеше горурлыгын саклап маташты.

И Хәмит, Хәмитем минем!

Син дә бит кайчандыр, Жизельне җәлләп гашыйк булган принц Альберт кебек, ятим Фәридәгә бер күрүдә күзен төшкән, бүген сәхнәдә очыныплар биегән улың шикелле үк яшьлек дәртең ташып торган кавалерист егет идең. Ул вакытлардан соң инде утыз еллап узып та киткән. Ә барысы, барысы да әле кичә генә булган кебек!

«Жизель» балеты үз җае белән әйбәт кенә дәвам итте. Ләкин ана кешенең мангай күзләре сәхнәдә булса да, күңел күзләре, ерак-еракларга төбәлгән хәтер күзләре белән хәзер ул вакыт пәрдәсе каплаган егерменче еллар Казанында йөри иде инде...

## 19

...Фәридә белән Хәмит беренче мәртәбә Казанның Иске бистәсендәге чыгырлы кое янында очраштылар.

Фәридәнең, көянтәле чиләкләрен асып, үз йортлары каршындагы коедан су алырга чыккан чагы иде. Озын чылбыр чорналган юан чыгыр тоткасын акрын гына әйләндерә-әйләндерә, ул кое чиләген төпкә төшереп җибәрде. Аннары су тулган авыр чиләкне житез генә тартып менгерде дә аны үзенекенә аударып сала башлады.

Ә бу минутларда бистә читендәге хәрби өйрәнүләр кырыннан, тирләп пешкән атын сугару өчен, әлеге кое янына бер кавалерист егет якынлашып килә иде.

Шулчак әллә нәрсә булды! Аяз көнне күк күкрәвен хәтерләтеп, хәрби өйрәнүләр кыры ягыннан нәрсәдер шартлаган тавыш ишетелде. Көтелмәгәндә яңгыраган әлеге шартлау Фәридәгә шулхәтле тәэсир итте ки, артык каушаудан кулын ычкындырып, ул яртылаш кына тулып өлгергән үз чиләген кое төбенә төшереп җибәрде. Һәм, аркасыннан сөлек кебек сузылган кара чәч толымнарын юеш җиргә тидергәнче чүгәләп, үкси-үкси елый башлады:

—Һай, беттем!.. Яңа чиләген коега төшереп җибәргәнем өчен, җингәмә ниләр генә әйтермен икән? Болай да тырнак астыннан гел кер эзләргә генә тора иде... Унбиш ел яшәгән өйдән куып чыгарса, һай, нишләрмен, һай, кайларга гына барырмын?!..

Кое янына килеп туктаган кавалерист җәһәт кенә ияреннән сикереп төште дә, күз ачып йомганчы, Фәридә янәшәсенә килеп тә басты:

—Каяле, матурым, бир әле кулыңны!—дип, ул башта Фәридәне йомшак кына тартып торгызды.—Йә, ник елыйбыз инде, матурым?

Фәридә билен зур прәшкәле киң каеш белән кысып буган, башындагы йолдызлы буденновкасы озынча-чибәр йөзенә галәмәт килешеп торган урта буйлы кавалерист егеткә күтәрелеп карады:

—Әнә ич!.. Кое төбенә өр-яңа чиләгем төшеп китте. Уф-ф-ф!...Җингәм күзенә сыңар чиләкле көянтә белән ничекләр кайтып күренермен инде?!

—Ә нигә сыңар чиләк күтәреп кайтырга? Хәзер апчыгабыз ул икенче чиләгеңне!—диде кавалерист егет таныш өчен кулын сузып.—Минем исемем Хәмит булыр. Ә синеке?

—Фәридә.

—Матур исем...

Хәмит, кынлы кылыч тагылган бил каешын салып, кое рәшәткәсенә элеп куйды. Аннары, чишенеп, чылбыры сүтелгән чыгыр янына килеп басты. Аска күз ташлады. Кабан күле читендәрәк кенә булгангамы, кое әлләни тирән түгел иде.

—Мин төшеп киттем, Фәридәкәй, кире чыкканда, кое чыгырын әйләндергәләп, бераз булышкалап торырсың,—диде ул һәм, чылбырга тотынып, күздән дә юк булды.

Фәридә бар көченә кое чыгырына барып ябышты. Юк, аны әйләндерү бу юлы әлләни авыр булмады. Чөнки бер аягы белән коеның буш чиләгенә басып алган Хәмит, борадагы бүрәнә почмакларына тотынып үрмәли-үрмәли, эшне бик җиңеләйткән иде.

Менә кое авызында бер кулына Фәридәнең яньчелгән чиләген тоткан Хәмит үзе дә күренде. Әлеге чиләкне күргәч, Фәридә бер мәртәбә генә «ах!» дип куйды да, бөтен игътибарын аның өчен салкын коеларга хәтле төшкән кавалерист егеткә күчерде. Егерме яшенә җитеп, аның монарчы мондый кайгыртуны күргәне булдымени соң? Ул бит борынгы Болгар-Әлки төбәгендәге Төгәлбай авылында тиф чиреннән дөнья куйган әти-әнисеннән җиде яшьтә дөм ятим калган бер бәхетсез һәм бик моңлы кыз.

Шуннан кырыс һәм мәрхәмәтсез язмыш җилләре аны Казандагы ипи кибетләренең берсендә йөк ташучы булып эшләгән, мәрхүм әтисенең бертуган абыйсы фатирына китереп ташлады. Кояш булса—кеше йөзенә чыкмас, болыт булса—адәм йөзеннән китмәс җиңгәсе аны ашка төшкән таракан кебек кабул итте. Ләкин үсмер Фәридә, аның акыру-җикеренүләренә игътибар итмәскә тырышып, агасының балаларын карашты, йорт эшләренә булышты. Тик зәһәр җиңгәсенә барыбер ярамады.

Менә хәзер бәхетсез Фәридә усал җиңгәсенең яңа чиләген тагын кое төбенә төшереп җибәрде. Тукта! Аның каруы, тирән кое төбеннән кавалерист егет Фәридәнең булачак мәхәббәтен, булачак ирен һәм бәхетен дә тартып чыгарды түгелме соң әле?! Әгәр аны бер күрүдә ошатмаса, аны чын күңеленнән җәлләмәсә, әлеге егет кое хәтле кое төпләренә шулай тиз генә төшеп китәр идеме соң?

Фәридә инде хәрби киемнәрен киеп җибәргән Хәмиткә ягымлы караш ташлады. Ә ул, кылычының авыр сабы белән тук та тук китереп, яңа чиләкнең яньчелгән урыннарын тигезләп-төзәтеп маташа иде инде. Моны күргәч, җиңгәсеннән куркып, Фәридә тагын авыр сулап куйды.

Хәмит дигән егет кызны нәрсә борчыганын күптән аңлап алган иде инде:

—Кайгырма, Фәридәкәй! Өегездә орышырлар дип курыксаң, икәү бергә кайтырбыз.

Фәридә, килешмәвен белдереп, яшел яулыклы башын сүзсез генә чайкап куйды:

—Әем...

—Ә нигә куркасың, Фәридәкәй?

—Кое яныннан егет ияртеп кайткансың—инде шул көнгә төштеңме, оятсыз дисәләр?

—Димәсләр... Әйдә, киттек!

—Әгәр әтием абыйсының өеннән куып чыгарсалар? Кайларга, кемнәр бусагаларына гына барып егылырмын икән, Ходаем!

—Егылмассың... Җан биргәнгә—җүн бирер дигәндәй, бүтән җаен табарбыз. Менә хәзер Акбәкәлемә су гына эчерим дә.

Акбәкәл тулык чиләккә җиз тәнкәле йөгән кигән башын төртте дә, комсызланып су эчә башлады. Хәмит исә, әле сызгырып, әле такмаклый-такмаклый, аны кыстый, аңа көч биреп тора иде:

—Эч, әйдә, эч, Акбәкәл! Ыс-ыссс...

Ничә еллар әтисе абыйсының усал хатыны күзләренә карап яшәгәч, бу кыз бала кечкенәдән ятим калган, ятим үскән, димәк ки, эче тулы моң булырга тиеш! Туктале, ничегрәк җырлый икән—тикшереп карыйк әле. Ә Хәмиткә килгәндә, ул үзе дә җырларга ярата, матур җырлаган һәм аеруча тыпырдатып биегән бүтәннәрне дә бик якын итә.

Хәмит, Фәриданең күңел кылларын капшап карарга теләп, теленә беренче килгән җыр сүзләрен такмаклады:

Ат эчерә торган иде,
Сызгыра торган иде...

Аны Фәридә эләктереп алды:

Күтәрелеп караса да
Кызара торган иде.

Хәмит төскә-биткә чибәр генә түгел, телгә дә оста булып чыкты:

—Ә ник кызарды икән ул егет, Фәридә?

Фәридә оялчан карашын аска яшерде:

—Чөнки яраткан, димәк ки...

—Мин дә шулай дип уйлыйм, Фәридә!

Хәмит, ниндидер кискен карарга килгән кешедәй, кинәт тиз-тиз генә Фәридә янәшәсенә килеп басты һәм аның дер-дер килә башлаган ябык иңбашына кайнар кулын салды:

—Фәридә дим, Фәридәкәй!..

—Әү, Хәмит?

—Мин сине беренче күрүдә үк бик ошаттым бит, Фәридәкәй!

—Җәлләпме?

—Бәлки...

—Мин дә.

—Нәрсә мин дә?

—Ошаттым диюем...

Хисләренә түзә алмыйча, Хәмит Фәридәне көчле куллары белән кочаклап үк алды:

—Шулай дисеңме? Дөресен әйтәсеңме, Фәридәкәем минем?!

Фәридә каршы килеп тормады, үзе дә Хәмитнең кинәт дөп-дөп итеп, күкрәк читлегеннән очып чыгардай булып тибә башлаган йөрәге турысына сыенарак төште:

—Шулай, Хәмит, шулай...

Хәмит кызны кочагыннан чыгарды да Фәриданең пешкән шомырт төсле җемелдәгән күзләренә томырылып карады:

—Ә хәзер киттек, Фәридәкәй.

—Кая?

—Башта син яшәгән фатирга көянтә-чиләкләреңне кертеп куябыз...

—Юк, мин куркам, Хәмит!

—Кемнән?

—Җиңгәйдән.

—Ә син хәзер беркемнән дә курыкма, Фәридәкәй. Чөнки синең хәзер ышанычлы терәгең бар. Ул—мин булырмын, Фәридәкәй!

—Рәхмәт, Хәмит!

—Киттек, алайса?

—Киттек, Хәмит...

## 20

Җиңгәсе кое янында булып алган хәлләрне ишетеп өлгергән иде инде, күрәсең. Берсе яньчек чиләк тоткан, икенчесе ат житәкләгән Фәридә белән Хәмитне ул капка төбендә үк каршы алды. Һәм, үзенә таныш түгел хәрби белән исәнләшүнитү юк, эчендәге зәһәрен пуләмиттән сиптергәндәй чәчәргә дә керешге:

—Суга киткән жиреннән нигә һаман кайтмый да кайтмый бу дисәм, кое янында ул чибәр егет белән менә ничекләр чәчәк атып яткан икә-ә-ән!.. И нурсыз.. И Әлки хәерчесе!.. Кайда минем яна чиләгем? Йә, әйт, ыштыр бит, оятсыз!..

Сул як билендә чайкалган кылыч кынын бер кулы белән тотып, Хәмит мәче житезлеге белән усал килен каршына килеп басты:

—Йә, йә... Бик чәпчемик әле, апасы! Дөм ятим һәм хезмәтче кызнын кансыз хужабикәсе булдым дигәч тә...

Килен кеше күзләренең агы белән Фәридәгә карап куйды:

—Булмассын монда...

—Монын өчен бездә берәүнен дә башыннан сыйпамыйлар, апасы. Йә, йә... Тынычландык!—диде дә, Хәмит теге үзе төзәтеп маташкан чиләкне усал килен каршына ук китереп куйды.—Бүгенгә мондые да ярап торыр. Ә иртәгә өр-янасын кибеттән сатып алып, үзем кертеп бирермен.

Килен кеше, ата каз кебек ысылдап, Хәмитнен яшел гимнастеркасыннан эләктереп алды:

—Туктале, энем, туктале!.. Кызыл йолдыз тактым дигәч тә... Кем дип белик әле сине? Монарчы бер дә күзгә-башка чалынганын булмады. Әллә чыгырлы кое төбеннән тартып чыгардылармы үзенне?

—Юк. Без ул кое төбеннән Фәридәкәй ялгыш төшереп жибәргән яньчек чиләкне генә тартып чыгардык

—Әйтәм жирле... Аһ, черек кул дисән дә, черек кул!

—Һәм Фәридәкәй белән шул кое төбендә вәгъдәләр бирештек.

—Нәрсә турында?

—Бергә тормыш корырга!

—Кайчан?

—Кавалеристлар курсындагы укуымны гына тәмамлыйм да.

—Ә анарчы Фәридәкәен кайда яшәп торыр икән?

—Бүтән инде сезгә ялынмабыз дип уйлыйк.

Килен кеше теге яньчек чиләген кинәт ертык галуш кигән аяк очы белән тибеп жибәрде:

—Үксез бозау асраудан ул туйганнарым! Китегез! Хәзер үк күземнән югалыгыз!

Яньчек чиләк тәгәри-тәгәри барды да, минем ни гаебем бар инде дигәндәй, урам уртасына ук чыгып туктады.

Килен кеше Фәридәнен әйберләрен Төгәлбай авылыннан бирле ияреп килгән иске фанер чемоданына алдан ук тутырып куйган иде, күрәсен. Менә капка келәсе ачылып китте һәм ишегалды ягыннан ул чемодан очып чыкты. Иске чемодан кадаклары күптән какшап-күгәреп беткән иде инде. Шуна күрә нәни йозагы бер якка чәчрәгән чемодан жиргә килеп төшүгә, кинәт ачылып китте. Эчендәге чүпрәк-чапраклары исә урамга чәчелде.

Үз әйберләрен кызганудан бигрәк, хурлану, кимсенү ачысына түзә алмыйча, Фәридә ачык чемоданы өстенә барып капланды:

—И Хәмит, Хәмитем! Ничә ел балаларын карашкан бер ятимәне урамга чыгарып ыргытсыннар әле! Бу хурлыкка ничекләр түзим?!

—Елама, Фәридәкәй! Барысы да жайланыр...

Фәридәнен урамда чәч-баш килеп яткан әйберләрен ватык чемоданга ничек кирәк алай жыеп салдылар. Бераздан ул чемоданны, ычкынмаслык итеп, Хәмит йөгән сабагы белән ияргә бәйләп куйды.

Аннары бер кулы белән атын, икенчесе белән Фәридәсен житәкләп тотты:

—Ә хәзер, китик, Фәридәкәй, бу карангы почмактан!

—Кая?

—Киләчәгебез танына.

Фәридә Хәмитнең жете яшел күзләренә томырылып карады:

—Ә ул таңнар кай тарафларда икән, Хәмит?

—Тукай яшәгән «Болгар» кунакханәсе тирәсендә. Ишеткәнең бармы?

— Ничек инде булмасын? Казанда унбиш еллап гомер кичерим дә... Беләсең килсә, Хәмит, мин син әйткән ул төштәге бер мәдрәсәдә укыдым да әле.

Хәмит гаҗәпләнеп сорап куйды:

—Син?.. Мәдрәсәдә?.. Кайчан өлгердең әле?

—Төгәлбайдан Казанга күчеп килгәч, әтиемнең абыйсы шунда укырга биргәние.

—Димәк, син гарәп язуын да беләсең?

—Ничек инде белмәскә? Әлбәттә, беләм.

—Монысы яхшы, бик яхшы, Фәридәм... Ә синең хәзер кайда укыйсың, кем буласың килә?

—Укытучы булыр идем, Хәмит.

—Әһә-ә... Димәк, педагогия институтына!—дип нәтиҗә ясап куйды Хәмит.—Тик аз гына сабыр итәргә туры килер, Фәридәкәй.

—Ни өчен, Хәмит?

—Башта мин укуымны тәмамлыйм! Аннары син белемеңне күтәрергә керешерсең.

— Анарчы?

—Өйдә утыр! Институтка керергә әзерлән! Мин эшләгән акча икебезгә дә житәр. Булачак офицерларга начар түләмиләр, шөкер.

—Ә кайда утырырга?

—Хәзер күрерсең. Барып житәргә ерак калмады...

Хәмит Фәридәне Түбән Кабан буендагы бер ялгыз әби йортына алып кайткан булып чыкты. Хәерниса исемле хуҗабикә карчык аларны такта чәй, якты чырай белән каршылады:

—Әйдәгез, балалар, әйдәгез... Түргә узыгыз!

—Менә, әбекәй!—диде Хәмит.—Бу чибәр туташның исеме Фәридә булыр.

—Әссаләмү галәйкүм, кызым!—диде әби, күрешергә ике кулын сузып.

—Вәгаләйкүм әссәләм, әбекәй.

—Бик хуп, бик хуп... Йә, кайдан, кайлардан табып алдың инде мондый чибәркәйне, Хәмит улым?

—Кое төбеннән тартып чыгардым, Хәерниса әбекәй, кое төбеннән!

—Әстәгъфирулла!.. Ничек инде кое төбеннән?

—Чынлап та, Хәерниса әбекәй!.. Хәзер анлата башласам, бик озынга китәр. Бер сөйләрмен әле.

—Ярый, Хәмит улым, ярый... Тик шулай да кем дип белик инде бу Фәридә балакайны? Булачак киленме?

—Әүвәл укып бетерәм әле, Хәерниса әбекәй.

—Ә анарчы икегез бездә яшәрсезме?

—Юк. Фәридә генә.

—Ә син кая барырсың, Хәмит улым?

—Кавалеристлар тулай торагына. Анда бер урын гына табылмый калмас әле.

—Үзең беләсеңдер, Хәмит улым, үзең беләсеңдер... Рәхмәт инде, кыз балага ярдәм кулы суза белгәч!

Җиз самавырын кайнатырга куйды да, нindидер йомыш табып, хуҗабикә карчык күршеләренә кереп китте. Ике гашыйк бер бүлмәдә ялгыз гына калдылар. Ярату-назга сусаган иреннәр бер-берләренә үрелде. Хәмит ничектер, ләкин Фәридәнең, шушы яшенә житеп, беренче мәртәбә генә үбешүе иде әле бу! Менә ничек тәмле, ничекләр татлы була икән ул яраткан кешеңнең үбүе!

—Фәридә! Фәридәкәй!.. Мин сине бигрәкләр дә ошаттым!—дип пышылдады Хәмитнең сусыл ирennәрe.

—Мин дә, Хәмит бәгырькәем!..—дип җавап кайтарды Фәридә.—Сина инде нинди генә рәхмәтләр әйтсәм дә аз булыр кебек.

—Ни өчен?

—Тулай торакларга чыгып китә-китә, үзен яшәгән фатирга мин ятимәне сыендыра алганын өчен!

—Тагын, тагын?

—Тагынмы?—дип бераз уйланып торды Фәридә.—Мине ятимлек баткагыннан тартып алганын өчен.

—Ә син, Фәридә, бүген мине үзен коедан тартып алдын!

—Ә мина, Хәмит, синен белән бергә коедан уртак бәхетебезне дә тартып чыгаргандыздыр кебек тоела.

—Матур уйлый беләсен... Сина, һичшиксез, укырга кирәк, Фәридә!

Тозлы иреннәреннән суырып үпте дә, яратып, Хәмит Фәридәне кайнар кочагына кысты. Кыз каршылык күрсәтмәде. Анын тыгыз күкрәкләре Хәмитнен дөп-дөп типкән йөрәк турысына килеп төртелде. Рәхим итеп, тәмам пешкән җимешне өзеп кап кына! Кызнын Хәмиткә карата ышанычы бу кайнар, акылны югалтырлык мизгелләрдә шул дәрәҗәгә җиткән иде ки, ул барысын, барысын да, хәтта кызлык сафлыгын да сөйгәненә бүләк итәргә әзер иде. Ләкин Хәмит кирәгеннән артыгына үрелмәде, тиешле урында үзен йөгәнли белде.

Бераздан самавыр да кайнап чыгып, киткән җиреннән хуҗабикә әби дә кайтып җитте. Алар, өчәүләшеп, чөкердәшә-чөкердәшә, бик тәмләп чәй эчтеләр.

Ә аннары Хәмит өйдәгеләр белән җылы гына саубуллашты:

—Хуш, Хәерниса әби!

—Хуш, балам! Онытып бетермә...

—Хуш, Фәридәм! Мин әле иртәгә дә, бүтән көннәрне дә монда гел килеп йөрермен.

—Көтәбез, Хәмитем...

## 21

«Жизель» балетынын бер өлеше тәмамланып, азрак ял итеп керү өчен, тамашачылар ул арада урыннарыннан тора башладылар. Әнисе янәшәсендә монарчы тыныч кына утырган Роза да, тирән уйларыннан айнытып, Фәридәнен күлмәк җиненнән тартты:

—Әни, дим...

—Әү, кызым!.. Нәрсә, спектакль бетте дә мәллә?—дип куйды Фәридә, әле һаман күптәнге еллар турындагы уйларыннан айнып җитмичә.

—Юк, тәнәфескә генә туктаддылар. Әйдә, әни, без дә чыгып керик.

—Аз гына сабыр итик, кызым. Хәтер күзләрем ачылып җитсен инде... Альбертнын Жизельне ничек җәлләп ярата башлавын күргәч, минә әнием дә яшьлек елларына кайтып килде бит әле, кызым. Әтиен Хәмит тә мине нәкъ менә шулай җәлләп ярата башлаганые бит.

—Сиздем инде... Шуна уйларыннан бүлдерәсем килмәде дә. Зарар юк, әни! Акча түләп керәсе булмагач, теләсән, иртәгә монда тагын килербез.

—Телим, кызым, улымнын ничек биегәнен иркенләп карарга бик телим!

—Ярар сон... Ә хәзер, бүтән тамашачылар кебек, без дә тәнәфескә чыгып керик.

—Әйдә, кызым, әйдә, бик әйбәт булды бит әле бу!

—Нәрсә әйбәт булды, әни?

—Чишенү бүлмәсендәге тунымнын исән-иминлеген дә белеп керербез.

Роза, ризасызлык белдереп, сәер тавыш белән әйтеп куйды:

—И әни, әни-и! Йә, кем инде Ленинград тикле Ленинград театрына килеп, раздевалкадагы затлы тунын чәлдермәделәр микән дип тикшереп йөри?

—Алай димә, кызым! Күпме көттереп туган бердәнбер һәм газиз улымның Болгариядән тикле әнисенә дип апкайткан туны бит ул!

—Булса... Инде хәзер шул тунны тикшереп кеше көлдерикме?

—Йә, сабыр... Чәпчемә әле, кызым!

—Чәпчемәссең монда... Биюче Нуриевның якын туганнары дип, йөз яктан йөз төрле күз карап торсын да!

—Ә без тун тикшерүебезне берәүгә дә сиздермәсәк, кызым?

—Ничек итеп?

—Менә хәзер күрерсең, алайса...

Хәйләкәр Фәридә чишенү бүлмәсе каршына барып басты һәм кием биреп торучыларга тишекле калаен сузды:

—Бер генә минутка тунымны бирә алмассыз микән, матурларым?

—Нәрсә, Фәридә апа, кесәсендә әйберегез онытылган мәллә?

—Шулай иде шул, матурларым—кульяулыгым онытылган. Ә сез минем исемне каян беләсез әле?

—Ничек инде белмәскә? Рудольф Нуриевның әнисе булыгыз да...

—Рәхмәт инде хөрмәтегезгә!

Кием биреп торучылар менә Фәридәнең чәшке тиресеннән тегелгән затлы тунын китереп бирделәр. Аның исән-иминлеген күреп, ана кешенең күңеле тәмам тынычланды. Шулай да, сер бирмәс өчен, тун кесәсеннән ул нидер алгандай итте...

## 22

«Жизель» балетын караганда ниләр кичереп утыруларын Рудольфка әнисе үзе һәм апасы Роза сөйләгәннәр иде. Аларны менә хәзер—яшерен фатирдагы бикләнүдә тагын бер мәртәбә хәтердә янарткач, ничектер, җинелрәк булып китте.

Ләкин көннәр буе иректә тоткынлык һәм эшсезлектә аунап ятып, Рудольф бик алҗыды. Совет шымчылары күзеннән бөтенләй юкка чыгып тору мәҗбүрилеге кимегәч, аның хәлен белергә килгән иң беренче кеше, әлбәттә, Клара Сент булды. Ул үзе белән бер кочак гәҗит-журналлар һәм яна сатып алынган... балет чүәкләре вә уенчык электр поезды да алып килгән иде.

Алар башта, көлешә-көлешә, үзләре турында, аеруча Рудольфның иреккә хөр сикерүе хакында бик күп һәм җентекле итеп язган көндәлек матбугат белән танышып чыктылар. Нуриевны мәгълүм балетның төп герое Ромеога тиңләгәннәр. Ә Клара Сент—шул Ромеоны муеннан гашыйк итә алган Джульетта! Ленинградтагы Киров театры һәм совет мәдәниятенең кайбер рәсми әһелләре Ле Бурже аэропортында килеп чыккан гадәттән тыш хәлне нәкъ менә шушы көтелмәгән мәхәббәт белән генә бәйләп аңлатканнар. Имештер, монда берниндн сәяси сәбәп тә юк, имештер, барысы да шул гыйшык-мыйшык мажаралары аркасында килеп чыккан! Фәлән-фәсмәтән...

Шулчак Клара Сент, гаять оста үрелгән мәкерле ялганга исе китеп, нәфрәт хисе белән әйтеп куйды:

—Сезнекеләрне әйтәм... Ай-йай шомартырга яраталар!

—Гафу ит... Инде хәзер «сезнекеләр» түгел!—диде Рудольф, Клара сүзләренә төзәтмә кертеп. Һәм бераз сүзсез торганнан соң өстәде.—Ә беләсеңме, Клара, бу шомартуларның артында ни ятуын?

—Көнбатышта, аеруча Америкада советча яшәү үрнәгенең дәрәҗәсе төшүдән куркумы?

—Менә-менә... Франция белән Англиядә йөреп кайткач, мәгълүм ки, Киров

театры Америкага өч айлык бик җаваплы гастрольгә чыгып китәчәк. Шунарчы мин кабызган ялкынны ничек тә дөрләтмәскә, сәяси шау-шу куптармаска тырышачаклар. Менә күрерсең...

—Килешәм, Руди, килешәм.

Ә менә Клара Сент мәгълүматларын тыңлаган журналистлар үз басмаларына чын дөресен шомартмый-киметмичә язганнар. Шуңа күрә аларны Рудольф та бик теләп һәм игътибар белән укыды.

Аннары Рудольфның эштән буш вакытларында иң яраткан мавыгуы— үзйөрешле электр поезды белән уйнап алдылар. Озын һәм киң коридор буйлап сузылган пар рельсләрнең ике очына икесе барып бастылар да, келтер-келтер тәгәрәгән поездны әле берсенә, әле икечесенә таба этеп-этеп җибәрделәр.

Ләкин атна буе тик ятып арыган-алҗыганга күрәме, һәрвакыт балачак-үсмер елларын, туган ягын хәтерләткән бу уен бүген Рудольфны тиз туйдырды. Келтер-келтер тәгәрәгән поездны куллары белән тотып туктатты да, пар рельсләргә карап, менә ул тирән уйга талды.

Пар рельсләр!

Алар да инде кыска гына вакыт аралыгында турылыклы юлдаш була алуын матур сүзләр түгел, ә ышанычлы гамәлләре аша раслап күрсәткән Клара белән тормыш дигән олы юлдан менә шушы пар рельсләрдәй гел янәшә, гел бергә бара алырлармы? Гомумән, алар әле бер-берсен яратып өлгерделәрме?

Бу һәм бүтән кайбер сорауларга җавап эзләп, Рудольф коридорның икенче очындагы Клара Сентка күтәрелеп карады. Ни гаҗәп: яшел кофта кигән кызның да шундый ук төстәге күзләре бу мизгелдә әнә шул пар рельсләргә төбәлгән иде.

Клара Сент алып килгән балет чүәкләренең әле берсен, әле икенчесен киеп, менә Рудольф ат ятып аунарлык киң-озын коридорда төрле рәвештәге бию хәрәкәтләрен ясап карады. Һәм шул җитте: атна буе ирекле тоткынлыкта ята-ята, ябыгып, сулыгып калган егетнең тән буыннарына, әйтерсең, әбелхәят суы бөркеделәр! Аның агарган битенә, яшәү суты булып, кызыл төс йөгерде. Әле кайчан гына айлар буе күнегүләр ясап ныгыткан кул һәм аяк мускуллары, каз күкәе хәтле булып, калкып-кабарып чыкты. Өермәле ут-ялкын кереп тулган күзләреннән тагын кайнар очкыннар сибелеп тора башлады. Борын тишекләре киң булып киерелгән, үзе исә еш-еш сулыш алып тора башлаган Рудольф бу минутларда менә-менә чабышка кузгалып китәргә торган Сабантуй атына охшап калган иде.

Һәм Клара Сент бөтен ачыклыгы белән бернәрсәне аңлап алды: соңгы көннәрдә бөтен күңелен, бөтен җанын биләгән рухи тетрәнүләрдән арынып аякка басу өчен, Рудольфка мөмкин хәтле тизрәк бии башларга кирәк иде. Ләкин кайда, нинди сәхнәдә? Тукта! Хәзер ул Рудольфны эшкуар-рәссам әтисенең һәм, димәк, үзенең дә күптәнге танышы вә дусты—Париждагы дәүләти булмаган балет төркеме башлыгы Раймундо де Ларрен янына алып барачак!

Рудольф Клара Сент тәкъдименә дүрт куллап риза булды:

—Ә-ә, кайчандыр патша Россиясенең атаклы шамакае Григорий Распутинны үтерүдә катнашкан татар фамилияле рус кенәзе Феликс Йосыпов... Парижда шул кенәзгә ялланып эшләгән Чили егете—булачак маркиз де Куэвас... Маркиз үлгәч яки үтерелгәч, аның байлыгына хуҗа булып алган Раймундо де Ларрен... Шул Раймундомы?

—Шул инде, шул! Тик миңа, Руди, аңлашылып җитми...

—Нәрсә, акыллым?

—Йосыпов... Үзе Парижда яшәп үлгән рус кенәзе, үзенең фамилиясе татарча. Моның сере нидә икән?

—Моның сере, Клара, бик тирәндәге тарих төпкелләренә үк төшеп китә...

—Ә шулай да?

—Казан ханбикәсе Сөембикә турында ишеткәнең яки укыганың булмады микән синең?

Клара Сент нәфис-түгәрәк мангаен яртылаш каплап торган каштан төсендәге чәч көлтәсен кисәк кенә артка таба чөеп җибәрде:

—Мәскәү әсирлегенә апкителгән тол ханбикәме?

—Менә-менә... Рус кенәзе Йосыпов дигәнебез менә шул ханбикә әтисе Йосыф морзаның ерак бер туганы була инде.

—Кызы-ык...

—Кызык һәм гыйбрәтле,—диде Рудольф, кыска торыклы, тыгыз мускуллы аякларына сыланып торган тар балаклы чалбарын киеп куеп.—Әйдә, киттек, Клара: бу турыда калганнарын, әгәр бик теләсәң, юлда барышлый сөйләшербез.

—Телим, билгеле. Кенәз Йосыпов—минем өчен бик кызыклы шәхес!

—Мина да... Монарчы ишеткәләгәнем булса да, кайчандыр нәкъ менә шул кенәз Йосыпов эшкә алган Чили егете де Куэвасның матди һәм рухи дәвамчысы Раймундо де Ларрен белән күптән якынрак танышасым килеп йөри иде. Ни генә әйтмик, биер сәхнә, түләнер хезмәт хакы сорап, шул Чили баена баш иеп барырга туры киләчәк бит.

—Ә нигә Париж Операсына түгел? Анда да, минемчә, Советлар иленнән качып чыккан синең кебек йолдызны бик шатланып кабул итәчәкләр.

—Ай-һай... Нәкъ менә качып чыкканга күрә, коммунистлар йогынтысы көчле булган бу илдә Советлар Союзының куркыныч басымыннан бик тиз шүрләп калырга мөмкиннәр.

—Анысы шулай инде.

—Шулай итеп, Клара дустым, безнең өчен бүген бөтен юллар да Раймундо де Ларренга илтә.

—Киттек, Руди...

## 23

Раймундо, Раймундо!

Ул житәкчелек иткән иҗат төркеме рәсми төстә «Маркиз де Куэвасның гран-балеты» дип йөртелә һәм күптән түгел вафат булган бу маркизның хатыны—Америкадагы нефть алласы, череп баеган атаклы миллиардер Джон Рокфеллерның оныгы Маргарет акчасына яши иде. Дәүләти кысалар белән исәпләшмәгәч, биредә хезмәт хакын да шактый күбрәк түлиләр иде.

Ә маркиз де Куэвас үзе кем булган, Рокфеллерның төпсез акча капчыгына якынаю юлын ул ничек тапкан соң? Хәерчелек шартларында үскән бу Чили егете егерменче елларда Парижга бер тиен акчасыз килеп чыга һәм Франция башкаласының Модельләр йортын тоткан кенәз Феликс Йосыповка гади хезмәтче булып яллана. Менә шул хезмәттә чагында бу йортка еш килеп йөргән байбичә Маргарет йөрәгенә тиешле ачкычны тапкач, Жорж де Куэваска күк капусы ачылып китә. Кесә тутырып акча йөртә башлауга, иң беренче эш итеп, бай кияү яңа балет төркеме туплый һәм, аңа үз исемен куштыргач, Аурупа вә Америка илләренә озын-озак гастрольләр белән чыгып китә. Тиздән классик бию сәнгатенең оста эшкуары буларак, маркиз де Куэвас исеме бөтен илгә, бөтен дөньяга таныла.

Эшне хатыны һәм миллиардер оныгы Маргаретның исәпсез-чутсыз акчасына алып баргач, маркиз де Куэвас хәтта кайчакларда балет сәнгатендәге хореография таләпләре белән дә исәпләшеп тормый. Танылган биюче һәм хореограф Серж Лифарь сәхнәләштергән бер спектакльдә кайбер күренешләрне үз белдеге белән үзгәрткәч, эшләр хәтта дуэльгә хәтле барып житә.

1958 елда бөтен Париж теленә кергән бу вакыйга болай була. Серж Лифарьның чираттагы ризасызлыгына үпкәләп, маркиз де Куэвас тамашачылар алдында аның җәлпәк борынына кулындагы пирчәткәсе белән суга:

—Менә сиңа—күпне күрсән!

—Хореограф иҗатын бозарга ни хокукыгыз бар?

Маркиз де Куэвас, көн күрмәгән көн күрсә—көндез чыра яндырыр дигәндәй, кесәдәге акчаларын һавага чөеп җибәрә:

—Менә минем хокукым! Ә син, Лифарь—ата хәерче! Һәм мондый алама холкың белән мәңге шулай булып калырсың да!

Мескен Лифарь нишләсен:

—Ә мин, маркиз, сезне дуэльгә чакырам!

Де Куэвасның да җыелган халык алдында сынатып торасы килми:

—Мин бу чакыруны, Лифарь, бик теләп кабул итәм!

Ачу чыккан чак—кулда пычак дигәндәй, булачак дуэльнең тиешле секундантлары да билгеләнә. Ә бит монархы биюдән башканы белмәгән мескен Лифарьның үз гомерендә кылыч-мылтык дигән нәмәстәкәйләрне хәтта кулына да тотып караганы булмый лабаса! Маркиз исә, киресенчә, кылыч белән алышуда бер пот тоз ашаучылардан санала.

Ничек кенә булмасын, дуэль тиздән башланып китә. Маркиз очлы кылыч белән бер селтәнүгә, биюче беләгеннән чәчрәп кан чыга. Аны күрүгә, йөгереп килә дә, Серж Лифарь уеннан уймак чыгара язган маркизны кысып кочаклый:

—Кан чыкты—димәк, намус чистарды!

—Нәкъ шулай!—дип килешә маркиз де Куэвас һәм кылычын бер читкә ташлый.

Ленинградтагы Киров балеты Парижга гастроль белән килер алдыннан гына, ниндидер көтелмәгән сәбәп белән, маркиз де Куэвас дөнья куйган була. Нәкъ менә шул көннәрдә Маргарет байбичә тирәсендә Раймундо де Ларрен бөтерелә башлый.Ул үзен де Куэвасның туганнан туганы дип таныштыра. Гәрчә маркиз кызы бу шикле туганлыкның була алмавын кат-кат әйтеп торса да.

Тиздән Раймундо де Ларрен бай толбикәгә өйләнеп үк җибәрә. Бу вакытта кияү буласы егет кырык ике, ә килен-әби сиксән яшьтә була! Тик акча дигәндә нәрсә ул яшь аермасы, нәрсә ул картлык белән яшьлек?

Шулай итеп, Раймундо де Ларрен үз максатына ирешә. Беренче иреннән аермалы буларак, гомер-гомергә бию сәнгатен сөймәгән байбичә маркиз де Куэвасның балет театры белән идарә итүне тулысынча яшь хуҗага тапшыра.

Менә нинди азу ярган балет эшкуары кулы астында хезмәт итәргә туры киләчәк горур җанлы, буйсынмас холыклы Рудольфка беренче көннәрдә. Шунсыз булмый—чөнки баш иеп әлегә бүтән барыр җире юк!

Рудольфның булачак хуҗасы турында сөйләшә-сөйләшә барып, Бонапарт урамына ничек килеп җитүләрен дә сизми калдылар. Биредә Раймундо де Ларренның офисы урнашкан. Беренче карашка шактый нәзакәтле күренгән, һәр кешенең хәленә кереп сөйләшә белгән чандыр гәүдәле, карчыга томшыгыдай кәкре борынлы бу ир-атның беренче күрүдә үк күзгә ташланучы сәер яклары байтак иде. Әйтик, хатын-кызларныкыдай озын-нечкә бармакларындагы тырнакларны нигә әле ул зәңгәр төскә буяган? Ә шулай ук озын-нечкә муенын кара син аның, муенын! Ул бертуктаусыз хәрәкәттә. Авыру кош муены кебек. Раймундо аны йә өскә чөя, йә эчкә җыеп куя иде.

Хәйләкәр импрессарио, сүзнеерактан урап китереп, үзе җитәкләгән балет театры хакында әүвәл Рудольф Нуриев фикерен сорашты:

—Ничек биибез? Киемнәребез ничек? Бароннар чорын яхшырак күз алдына бастыру өчен, аларны тагын да купшылатырга кирәк түгелме? Әгәр кирәксә, без—дәүләти балет түгел: акча бездә һәрчак бер букча!

Купшылану, мактану кебек нәрсәләрне Рудольфның җене сөйми иде. Һәм сәхнәдә, һәм тормышта! Шунлыктан ул эчендәгесен ярды да салды:

—Сезнең театрдагы төсле пумаладай ул париклар, иске гармун күрекләредәй киң балаклы ул ыштаннарның нигә хаҗәте бар? Хикмәт киемдә түгел, ә биюнең үзендә! Кайсыдыр чор сулышын нәкъ менә бию хәрәкәтләре аша чагылдыра алуда.

—Ә үзегездә соң, месье Нуриев, үзегездә? Ул Киров театры артистларының әллә кайчан тузып, телгәләнеп беткән киемнәренә хәтта карау оят!

—Гафу итегез, месье Раймундо! Минем хәзер Киров театры биючесе түгел икәнлегемне яхшы беләсездәр дип уйлыйм.

—Ә-ә, шулай бит әле!.. Әйдәгез минем труппага! Ике куллап кына түгел, сездәй йолдызны хәтта дүрт куллап кабул итәчәкбез.

—Күпме хезмәт хакы белән?

—Сигез мең чамасы җитәрме?

Үз гомерендә мондый күләмдәге хезмәт хакын беренче мәртәбә ишеткән Рудольф, ышанып бетмичә, кабатлап куйды:

—Сигез мең су-у-ум!!! Мин бит Ленинград балетының төп биючеләреннән берсе була торып, айга нибары ике йөз дә кырык сум алып эшләдем.

—Сездәге... гафу итегез, Советлар Союзындагы агач сум түгел—сигез мең доллар!—дип төзәтмә кертте бай хуҗа.—Ә аерма бар һәм бик зур. Бу—беренчедән. Икенчедән исә, ул бит Ленинградта, ә монда—тулы ирек, кочак-кочак акча, шуларның кадерен белеп, тик яши һәм иҗат итә генә бел, месье Нуриев!

—Рәхмәт.

—Шунысын да әйтим, месье Нуриев, мондый күләмдәге айлык хезмәт хакын әлегә дөньяның бер генә театрында да түләгәннәре юк. Һәм түләмәсләр дә! Чөнки аның өчен дөнья байларына балет сәнгатен минем кебек үлепләр яратырга кирәк!

—Тагын бер кат рәхмәт, месье Раймундо!.. Димәк, иртәгедән эшкә?

—Көтәбез, месье Нуриев!

## 24

Дәүләти булмаган балет театрында акчаны күрәп түләсәләр дә, биредә эшләүнең уңайсыз яклары үзләрен бик тиз сиздерде. Әйтик, Англиягә барган очракта, Рудольф Нуриев Лондон сәхнәсендә беренче мәртәбә 23 июнь көнне—Чайковскийның «Йокыга талган гүзәл» балетында чыгыш ясарга тиеш иде. Үз труппасына искиткеч шәп реклама булачагын аңлап алып, балет эшкуары Раймундо де Ларрен Париж сәхнәсендә Рудольфның нәкъ менә шушы көнне һәм нәкъ менә шушы спектакльда бии башлавын теләде.

Советларның борыннарына тагын бер мәртәбә чиртеп алуда галәмәт отышлы гамәл булачак бит бу! Чөнки Киров театры биючеләренең Лондондагы гастроле 19 июньдә ачылды. Ул көнне Рудольф анда болай да чыгыш ясарга тиеш булмаган. Ә шулай да совет биючеләренең Англиядәге дебюты ничек узуны карарга, бер авызлары пешкәч, Мәскәүдән СССР мәдәният министры Екатерина Фурцева үзе килеп җиткән.

Ә менә бүген, 23 июнь көнне, Лондонда һәм Париж сәхнәсендә бер үк «Йокыга талган гүзәл» балеты күрсәтеләчәк. Тегендәгесендә Рудольфны алыштырырга мәҗбүр булган билгесез яшь биюче Юрий Соловьев, мондагысында исә дөньяның булачак бөек биючесе үзе чыгыш ясаячак! Күрсеннәр, чагыштырсыннар һәм тиешле нәтиҗәне ясасыннар!

Кесәләрендә Рокфеллер алтыннары әкәмәт күп булгач, Раймундо де Ларрен озын-озак уйлап торучылардан түгел иде. Баягы уйны тизрәк гамәлгә ашыра башлау өчен, ул шунда ук үз бүлмәсенә Рудольф белән соңгы вакытларда

анын аерылмас юлдашы һәм рухи кинәшчесенә әйләнгән Клара Сентны чакыртып кертте:

—Бүген 23 июнь—истәлекле көн!—дип куана-куана, ул хәтта кулларын бер-беренә шапылдатып куйды.

—Ә нигә истәлекле?—дигән булды Рудольф, берни аңламаганга сабышып.

—Чит илдән кайтмый калган балет йолдызы Рудольф Нуриевнын бүген Париждагы дебют спектаклендә һәм нәкъ менә «Йокыга талган гүзәл»дә биергә тиеш булуында.

—Ә-ә, булмый калган Лондон дебюты...

—Әйе! Нәкъ менә шунын өчен, месье Нуриев!

—Ә нәрсә... Мин әзер!

—Бик яхшы, месье Нури...

Аңа әйтеп бетерергә ирек бирмичә, шулчак сүзгә монарчы бер читтә тыныч кына утырган Клара Сент килеп кушылды:

—Туктале, Раймундо! Син алай дисен дә... Тик ни бит... Рудига Парижда совет чекистлары янаган куркыныч әле тәмам бетеп житмәгән бит.

—Үз илемдә яши торып, әллә алардан шыр жибәрергәме? Ю-юк! Хәзер алар Рудольф Нуриевка түгел, ә беренче нәүбәттә мина янауларын яхшы аңлаячак! Аңламасалар, бик тиз төшендереп бирербез!

—Ярый, монысы шулай да булсын...—диде Клара Сент.—Ә Британия импрессариосы Виктор Хохаузер әйткәннәр белән нишләргә?

—Ә-ә... Лондонда яшәгән коллегаммы? Ул кайда, кайчан һәм ни дип әйткән?

—Кичә «Би-би-си» радиосында ясаган чыгышында...

—Үкенеч ки, тынламый калганмын... Йә, ниләр сөйләде?

—Менә шул... Ленинград артистларынын Британиядәге чыгышларын оештыручы ул импрессарио: «Әгәр бу гастрольләр вакытында Рудольф Нуриев Париждагы «Маркиз де Куэвас гран-балет»ы сәхнәсендә бии калса, мин бу труппаны ике дә уйламыйча судка бирәчәкмен!» дип масайды.

—Бирсен! Аннан гына курыккан юк: акча бездә—бер букча!

—Шулайдыр...

Ләкин Клара Сентны шактый нык борчыган тагын бер сәбәп калган иде әле:

—Франция хөкүмәтенен шушы көннәрдә Мәскәү тарафыннан кискен кисәтелүе хакында ишеткәнсендер инде?

—Каян ишетим? Мин бит хөкүмәт кәнәфиендә утырмыйм... Анысы ниткән кисәтү тагын?

—Әгәр иленә хыянәт иткән Нуриев рәсми төстә финанслана торган Париж Операсына эшкә алынса, совет-француз мәдәни бәйләнешләрен бөтенләй туктату белән куркытканнар.

Бу кисәтү турында ишеткәч, Раймундо де Ларрен буялган тырнаклы озын-нечкә кулын исе китмәгән кешедәй селтәп куйды:

—Куркытсыннар!.. Монысы безгә кагылмый. Чөнки без—дәүләти булмаган труппа. Акча дигән иң кодрәтле көчне әлә беркемнең буйсындыра алганы юк... Ә хәзер—сәхнәгә! Уңышлы дебют телим, месье Нуриев!

—Рәхмәт...

—Ә яна йолдызыбызнын шәхси иминлегенә килгәндә, бер дә борчылмагыз—хәзер аны дистәләгән тән сакчылары озатып йөриячәк!

Бу яңалыкны бик ошатып житкермичә, Рудольф теш агартып куйды:

—Бәдрәфкә дәме?

Төртмәле шаярту дигәндә, Раймундо де Ларрен да сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел иде:

—Бәдрәфкә генә түгел, хәтта сәхнәгә биергә чыкканда да!

Шулай итеп, сәхнә эшкуары Раймундо де Ларреннын тәки үз туксаны туксан булып чыкты. Аңа акча һәм реклама, реклама һәм акча барысыннан да изгерәк, һәммәсеннән дә кадерлерәк иде. Шуна күрә ул Ле Бурже аэропортындагы легендар сикерүеннән соң исеме дөньяның һәммә почмагына мәгълүм булган Рудольф Нуриевны «Маркиз де Куэвас» театрында бии башлаган беренче көннәреннән үк үз файдасына эшләтергә кереште.

Керешмичә соң! Мондый майлы калҗа кулга көн саен эләгеп тормас. Айга сигез мең доллар түләп булса да сау һәм сык, сык һәм сау син сөтле сыерны!

Сигез мең доллар!

Миллиардер Рокфеллер киявенең симез букчасы өчен бу акча чүп кенә. Ә шулхәтле зур таланты була торып, моңарчы ыштан төшеп китмәслек кенә хезмәт хакына колларча гомер кичергән Нуриев өчен—коточкыч сан! Ул елларда профессор хәтле профессорлар нибары биш йөз сумга бил бөкте. Ә анықы хәтта сигез мең доллар!

Әйе, шушы көннән, нәкъ менә шушы көннән Рудольф Нуриев өчен дә чын мәгънәсендә күк капусы ачылды!

Ә бай хуҗа Раймундо де Ларрен исә, Нуриев исеменнән озын-озак әңгәмәләр вәгъдә итүе өчен һич уңайсызлык кичермичә, Парижда төпләнеп эшләүче чит илләр журналистларын бүген кич «Йокыга талган гүзәл» балетында чыгыш ясаячак яшь, ләкин мәшһүр биюче дебютына килергә чакырып чылтырата башлады.

Ле Бурже аэропортында совет чекистлары кулыннан хөр иреккә сикерә алган каһарман Нуриев, бер атналык ябылуда ятканнан соң, Париж сәхнәсендә бүген кич тагын бии башлаячак! Бу хәбәр яшен тизлегендә таралып өлгерде. Чакыру игъланнары бик соңлап кына эленсә дә, тамашачылар театр бинасына язгы ташкындай агылды. Ике мең кешелек зур-иркен тамаша залындагы рәт-рәт тезелгән йомшак эскәмияләр арасына өстәмә урындыклар куеп чыгылды. Алар гына да җитмәгәч, түземсез тамашачылар Нуриевның могҗизалы биюен хәтта аягүрә баскан килеш тә карарга ризалаштылар.

Ә балет театры директоры Раймундо де Ларрен өстәлендәге кызыл телефон тамаша башланыр алдыннан ут кебек кызды:

—Зинһар, ике билет!

—Берәү дә җитә.

—Юк, аягөсте басып карарга да ризабыз...

Гозерле чылтыраулар арасында куркыныч-янаулылары да еш ишетелде:

—Сез нигә дип әле анда хыянәтчеләрне эшкә аласыз?

—Карагыз аны—ут белән шаярмыйлар!

—Ул ут, бүген кич үк инде, Нуриевның үзен һәм сезне дә пешерә башламагае...

Бу янаулардан, әлбәттә, Мәскәү кубызына биеп күнеккән француз коммунистларының исе килә иде. Һәм әлеге янауларның юкка түгеллеге тиздән ачыкланды.

## 25

Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырларсың ди!

Ленинград сәхнәсендә биегән елларында Рудольф Нуриев шундый гадәтне үзенең алтын кагыйдәсе иткән иде: спектакль башланырга бер сәгать кала, бизәнү-киенү бүлмәсен эчке яктан бикләп алып, һичкемне кертмәскә; хет «Би-би-си»нең үзеннән килгән хәбәрче булсын—бернинди интервью-фәлән бирмәскә; гәҗит-журналлар укымаска—барлык игътибарны алда торган биюнең бөтен нечкәлекләренә хәтле тагын бер кат уйлауга тупларга!

Бүген кич тә ул шулай эшләмәк булды. Зур-түгәрәк көзге читендәге стена сәгатенә күз төшереп алды да, тиешле вакыты җитүне күреп, бүлмә

ишеген бикләп куйды. Аннары, тыныч та, тынгысыз да уйларына чумып, йомшак кәнәфигә килеп утырды.

«Йокыга талган гүзәл» балетында тиздән үзе башкарачак принц Флоримондо роле өчен жаны тыныч иде анын. Чөнки бу рольне Ленинград сәхнәсендә Рудольф инде йөз мәртәбәләр биеде. Принцесса ролендәге Розелла Хайтауэр өчен дә баш ватасы юк. Чөнки бу ханым көнбатышнын балет сәнгатендә инде күптән танылган биюче иде.

Ә менә шушы ук балетта па-де-де дип аталган Зәңгәр кош биюе?! Дөресен генә әйткәндә, Рудольф Нуриев Ленинград сәхнәсендә, аннары Мәскәү, Вена фестиваль-конкурсларында нәкъ шушы бию белән танылды да. Әлеге бию ана бик күп сөенечләр вә... көенечләр дә алып килде. Чөнки СССРда Зәңгәр кош биюен ана үзе теләгәнчә башкарырга ирек бирмәделәр. Ул аны яшәешнен һәр мизгелендә, һәр халәтендә очарга талпынган кош итеп тасвирларга теләде. Ә аннан талпынучы түгел, инде очыштагы кошны таләп иттеләр. Талпына— димәк, нигәдер очып китә алмый дигән сүз! Аерма бар һәм бик зур бит!

Инде, ниһаять, Рудольф иректә. Бүген Париж сәхнәсендә ул, ниһаять, кичәге үз язмышын—башта ашкына-ашкына талпынган, аннары үзен канатларыннан күпме вакытлар артка таба тартып торган бәйдән ычкынып китеп биек күккә томырылган Зәңгәр кошны биеп күрсәтергә тиеш!

Бәйдән ычкынып китеп очу!

Рудольф Нуриев кебек чын иҗатчылар гына уйлап таба алган искиткеч уңышлы һәм символик образ иде бу! Хәтта, әйтергә мөмкиндер ки, бөек образ! Ләкин сәнгатьтә жырнын сүзләрен алмаштырып куеп булмый, дигән канун бар. Дөрес сүзләр! Тик шул ук фикерне көйнен нота авазларын үзгәртеп булмый дип тә әйтергә мөмкин бит. «Йокыга талган гүзәл» балетынын музыкасы бөек Чайковский тарафыннан инде әллә кайчан язылган һәм халык күнелендә шул мәгълүм темплары, мәгълүм нота-авазлары белән урын алган. Һәм ул темпларны хәзер берничек тә үзгәртә алмыйсын. Чөнки бөтен музыкага зыян киләчәк.

Әйе, болары шулаен шулай. Ләкин, музыка темпларын элеккечә калдырып та, бию хәрәкәтләрен үзгәртергә, әйтик, бу очракта икеләтә тизләтә төшәргә бик мөмкин бит. Һәм шушы тизләтүләр исәбенә Зәңгәр кошны гади очыштагы түгел, ә бәйдән ычкынып очкан итеп сурәтләп бирергә! Ләкин мона ничек, нинди илаһи хәрәкәтләр аша ирешергә? Мәсьәләнен бөтен кыенлыгы да нәкъ менә шушында иде шул!

Әһә! Әгәр болай итсәк...

Рудольфны бик мөһим уйларыннан бүлдереп, кинәт ишек кактылар. Эчке яктан җавап бирүче яки бикне ачучы булмагач, тагын, тагын кактылар. Мондый чакларда ярсу канлы Рудольфнын кинәт кызып китеп, үзен-үзе белештермичә ниндидер гөнаһлы гамәл кылып куя торган гадәте дә бар иде. Шушы уттай холкынын алама сыйфатына тугры калып, ул бу юлы да тупыйк очлы балет чүәкләрен тотты да ишеккә томырды.

Ләкин ишекне тагын шакыдылар:

—Ач әле ишекне, месье Нуриев! Бу мин—Раймундо...—дигән тоныкк кына тавыш килде тышкы яктан.

—Ни булды?

—Мөхтәрәм кунаклар алып килдем әле үзенә.

—Кемнәр?

—Хәбәрчеләр...

Ачты ишекне Рудольф. Ник ачмасын—туйдыручы хуҗан бусагала үзе басып торсын да! Монда сина Ленинград түгел, ә Париж каласы!

—Кабул итеп ал, месье Нуриев!—диде директор Раймундо де Ларрен, кош тоткандай балкып.—Менә сина өч журналист. «Юманите» басмасынын үзеннән!

Менә, ичмасам, авыртмаган башка—тимер таяк! Ә балет башлыгы үз

юлыннан китте дә барды. Аңа шау-шу белән реклама күбрәк булса, шул житкән!

Әрсез хәбәрчеләр, сәхнәгә чыгар вакыты житеп килгән биюченең айваена карамыйча, ул арада эшкә дә керештеләр. Сорауларның һәммәсе бертөрле һәм ярсу канлы Рудольфны гына түгел, теләсә кемне чыгырдан чыгара алырлык иде:

—Месье Нуриев, төнге Париж урамнарында йөрү туйдырмадымы әле?

—Рус акгвардиячеләре ресторанында ризыкны тәмле пешерәләрме?

—Төнге клубтагы кызлар күбрәк ошадымы, әллә малайлармы?..

Спектакль башланыр алдыннан махсус әзерләнеп киленгән бу провокацион сорауларга җавап биреп тормаска да була иде. Ләкин өч хәбәрченең икесе иңнәренә төрле аппаратлар элгән фотографлар иде. Алар, озын муенлы объективларын челт тә челт китереп, башта Рудольфны төрле яктан фотога төшереп алдылар. Аннары, иңнәренә эленгән тирән сумкаларыннан алып, Нуриев кулына Уфадагы әтисе белән Ленинградтагы остазы Пушкиннан ике хат һәм газиз әнисеннән бер телеграмма тоттырдылар. Һәм, сәхнәгә чыгарга ашыкканда вакытсыз борчулары өчен гафу үтенгәндәй кыланып, бүлмәдән гаип тә булдылар.

Әйтерсең, Рудольфның кулына учактан алынган утлы күмер тоттырып чыгып киттеләр! Ул күмернең пешерүенә түзә алмыйча, Нуриев әлеге хатларны шунда ук укымакчы да булып карады. Ләкин, бар ихтыяр көчен бер йодрыкка туплап, аларны өстәл тартмасына салды. Юк, хәзер ярамый! Тыныч күңел белән, ярсымаган килеш башта сәхнәгә чык та—башкарасы ролеңне әйбәт кенә биеп кер! Һәм нинди көнне бит әле—күптән хыялланган Зәңгәр кош очышын бөтенләй яңача биисе кичне!

Ләкин Рудольфның да бу минутларда дулкынланудан еш-еш сулыш алган күкрәгендә йөрәк урынына таш утырмый иде шул! Күптән кан басымы чире белән интеккән әнисе ничек икән анда? Баш миенә кан савып яки йөрәген тотып егылмаганмы? Гомер-гомергә кызыл комиссар булып йөргән майор әтисе үз нәселен дәвам итәргә тиешле бердәнбер улының һичнинди киртәләргә сыймый торган бу коточкыч «хыянәт»ен ничек кабул кылган? Сүккәндер, каргагандыр инде... Ә Ленинград хореография училищесында өч ел буе аны балет серләренә өйрәткән хөрмәтле остазы Пушкин соң, Пушкин? Ул үз хатында ниләр язды икән?

Юк, утлы ялкын өргән бу хатларны укымыйча һич түзәрлек түгел иде. Ни булса—шул булыр дип, Рудольф әле бая гына кысып ябылган өстәл тартмасын тагын тартып ачты. Әнисе исеменнән җибәрелгән телеграммада нибары өч сүз язылган иде: «Кайт, улым! Көтәм!» Һәртөрле алтын-көмешләрдән да кадерлерәк бу өч сүзне укыгач, Рудольфның күз читләреннән өч кайнар тамчы бәреп чыкты. Ул туган илсез, туган җирсез калды. Ләкин Рудольфның һәрнәрсәдән газизрәк әнисе исән, исән иде әле!

Нибары өч сүз язылган телеграмма кәгазен иреннәре белән үбә-үбә, Рудольф хәтта үз-үзенә пышылдап куйды:

—Кичер мине, әнкәй!

Әтисе хатыннан Рудольф бүтәнне өмет тә итмәгән иде. Кызыл тегермәнгә су коя торган һаман да шул төче сүзләр: «Совет патриотизмына тап төшерә торган бу хурлыклы адымны син ничек ясый алдың?» Фәлән-фәсмәтән...

Ул күпме табынган, күпме яратып йөргән остазы Александр Пушкин да әтисеннән әлләни ерак китә алмаган иде: «Черек кыйблалы көнбатышта калып бик нык ялгышкансың. Сине алда, һичшиксез, деградацияләнеп юкка чыгу, рухи үлем көтә!»

Әтисе һәм остазы тарафыннан язылган сүзләрнең бер үк каләм очыннан төшкәнлеге әллә кайдан күренеп тора иде. Юк, боларның барысын да кемдер

әйтеп яздырткан, кемдер махсус оештырган! Хәер, кем икәнлеге әйтмәсән дә билгеле бит инде!

Моны аңлау тудырган ачудан Рудольфның бая гына йомшап киткән тән буыннарына кинәт көч-гайрәт кереп тулды. Учларын ныгытып йомарлаудан теге ике хат шытыр-шытыр килеп бөгәрләнде һәм ертылды. Ә өч сүз язылган телеграмманы, бер үк каләм очыннан төшүен белсә дә, никтер, Рудольф кабат өстәл тартмасына салып куйды.

Ләкин монарчы кичергәннәре бүген күрәселәрнең баласы гына булган, ә анасы дигәннәре алда басып торган икән әле.

Тамашачыларны залга керергә чакырып, менә бер-бер артлы өч мәртәбә кыңгырау чылтырады. Рудольф Нуриев та сәхнәгә чыгу өчен һәм физик, һәм рухи яктан тәмам әзер булып, бизәнү бүлмәсендәге биек көзге каршына килеп басты. Алтынсу бизәкләр белән каймаланган зәңгәр трикосы, башындагы таҗына кадалган ак каурыйлар, биленә бәйләнгән кара тасма, принц Флоримондодан бигрәк, аны менә-менә бәйдән ычкынып очарга җыенган Зәңгәр кошка охшатып калдырган иде.

Чайковскийның гүзәл музыкасы агыла башлауга, вак-вак адымнар белән һәм сынын катырып сәхнәнең алгы өлешенә чыгып басты да, ак каурыйлы таҗын салып, Рудольф залга башын иде. Аның биюен бер атна буе күрми торган тамашачылар, «Мерси!» дип кычкыра-кычкыра, озын-озак итеп кул чаптылар.

Спектакль башланып китеп байтак вакытлар узгач, ниһаять, Рудольф Нуриевның күпме хыялланган теге Зәңгәр кош биюен башкарасы иң җаваплы, иң изге минутлары җитте. Шулчак тамаша залының алгы, урта һәм арткы рәтләреннән ул монарчы бөтенләй ишетеп карамаган куркыныч-кыргый акыру сүзләре бөселеп чыга башлады:

—Хы-я-нәт-че!

—Москвана сыпырт!

—Синең урының сәхнәдә түгел—төрмәдә!..

Ул арада булмады, Рудольф биегән сәхнәгә черек помидорлар, чи күкәйләр, телем-телем бөгәрләнгән банан кабыклары, төчкертүче борыч салынган кәгазь төргәкләре ява башлады. Бер явызы хәтта тузып беткән урам себеркесе ыргыткан иде. Ул себерке, черек помидорлар белән тәгәри-тәгәри килде дә, сәхнә уртасына җиткәч, кинәт туктап калды.

Ә тамаша залыннан, черек помидорлар белән бергә, зәһәр мыскыллау сүзләре очып килә торды:

—Менә сиңа бездән күчтәнәч!

—Рәхәтләнеп төчкер!

—Төчкерт һәм моннан элдерт! Һәм үз артыңнан себереп китәргә дә онытма!

—Ха-ха-ха...

Рудольфның җәрәхәтле йөрәгенә төбәп җибәрелгән бер помидор менә аның күкрәгенә килеп тиде һәм, зәңгәр трикода аләм каныдай кызыл тап калдырып, сәхнә идәненә чәчрәп төште. Бу этлекләрнең һәммәсен КГБ кушуы буенча француз коммунистлары оештыруын яхшы аңлаган горур биюче исә, кызыл хурлауларга игътибар бирмәскә тырышып, үз чыгышын дәвам итте.

Түзәргә, түзәргә һәм, тешне кысып, тагын бер кат түзәргә!

Совет империясенең кызыл киртәләре аша сикерүчегә ачуларыннан күзләре тонганнарны ташка каршы таш атып түгел, балет сәнгате дигән бөек көч белән—биеп җиңәргә!

Менә, ниһаять, балет телендә Зәңгәр кош па-де-десе дип йөртелгән кодрәтле көчне кулланыр чак та килеп җитте. Нишләрләр Париж тамашачылары, аңларлармы инде йөз мәртәбә каралган спектакльгә Рудольф Нуриев керткән яңалыкны, төшенерләрме ирек-азатлыкка сусаган кол биюченең ни әйтергә теләгәннәрен!

Салмак кына биеп барган җиреннән, музыка кысаларыннан чыкмыйча, менә Зәңгәр кош адымнарын кинәт кызулатты. Янга калдырылган шушы вакыт хисабына, кул-канатларын җилпи-җилпи, ул очып китәргә җыена башлады.

Зәңгәр кош талпына, ләкин билендәге теге озын кара тасма аны бер карыш та алга җибәрми, гел артка таба тартып тора иде.

Ул талпына, ләкин иңендәге кара язмыш аны гел артка өстери!

Соңгы көчен туплап, Зәңгәр кош менә кабат өскә—ирек вәгъдә иткән хөр иркенлеккә ыргылды. Бу ыргылу, бу талпыну көче шундый зур, шундый куәт-кодрәтле иде ки, аның артыннан сузылган озын кара тасма сүтелә-сүтелә килде дә, ниһаять, өзелде!

Китте очып Зәңгәр кош бәйдән ычкынган канатларын рәхәтләнеп җилпи-җилпи!

Очты Зәңгәр кош очсыз-кырыйсыз күктә һич арымый!..

Әйе, СССР дигән ил читлегеннән хөр ирекка очып китә алган Рудольф Нуриевның балет телендә галәмәт аңлаешлы һәм, иң мөһиме, образлы итеп сөйләп биргән үз тормышы, үз язмышы иде бу! Классик әсәр эчтәлегенә һичнинди зыян китермичә, киресенчә, аны баетып һәм тагын да балкытып җибәргән иҗади табыш-яңалыкны сизгер тамашачылар маңгай күзләре белән генә түгел, күңел күзләре белән дә бик тиз күреп алдылар. Һәм ифрат талантлы шундый биючегә карата кылынган пычрак гамәлләре өчен француз коммунистларына тирән нәфрәт, иелеп төшмәгән Рудольфка исә рәхмәт, теләктәшлек йөзеннән, утырган урыннарыннан торып, бик озаклап кул чаптылар.

Бу алкышлар Гиннеслар китабына кертерлек дәрәҗәдә—кырык минуттан да артыграк дәвам итте.

Оятларына көч килде, күрәсең. Шулчак француз коммунистлары, кыяр-кыймас атлап, тамаша залыннан үкчәләрен ялтыраттылар. Ишектән чыгып барганда аларның берсе кинәт артына борылды да, чикерткә кебек сикереп, сәхнәгә менде. Башта ул, бер читтә тәгәрәп яткан теге иске себерке белән селтәнә-селтәнә, черек помидорлар, бозык күкәйләрне, банан кабыкларын, төчкерткеч борыч капларын бер күчкә җыйды. Аннары, кесәсеннән полиэтилен пакет алып, әлеге чүп-чар калдыкларын шул пакетка тутырды. Иң соныннан, гафу үтенеп, чал чәчле башын түбән иде.

Сонлап булса да үз ялгышын аңлаган бу француз агаеның әлеге гамәлен хуплап, тамаша залында тагын көчле алкышлар яңгырады!

Ә Рудольф Нуриев төрле яклатып сәхнәгә сибелгән чәчәкләр яңгыры астында торып калды. Шулчак ул, үзе дә сизмәстән, теге агай пакетыннан тырпаеп торган иске себеркене сорап алды. Һәм аны, чәчәк бәйләме кебек иттереп, бер кулына күтәрде.

Ә икенче кулына кемдер ал-кызыллы чәчәкләр китереп тоттырды...

Себерке һәм чәчәк!

Дөньяның бөек биючесен гомер-гомергә озатып барачак гаять төгәл, искиткеч уңышлы, галәмәт образлы һәм әкәмәт көчле символик күренеш иде бу!

Де Шанз-Элиза театрының ике мең кешелек тамаша залын дер китереп, тагын көчле кул чабу тавышлары ишетелде.

## Икенче кисәк

### 26

Беркөнне, Клара Сент аша уртак танышлыгын эшкә җигеп, Раймундо де Ларрен бүлмәсенә Ле Бурже аэопортындагы легендар сикерүдә мөһим рольләрнең берсен башкарган Пьер Лакотт килеп керде. Килеп тә керде, сүзне мөгезеннән алып, мәсьәләне кабыргасы белән куйды:

—Эш бит менә нәрсәдә, месье директор...

—Тынлыйм, месье Лакотт.

—Совет системасы куйган тимер киртәләрне вата-вата, Рудольф Нуриевның хөр иреккә сикерүе баеп кесә калынайту өчен түгеллеген инде яхшы аңлыйсыздыр, шәт?

Раймундо, килешмәвен белдереп, зәңгәр тырнаклы кулларын як-якка җәеп җибәрде:

—Ә нигә соң, алайса...

—Нуриевка, месье директор, беренче чиратта бию осталыгын арттырырга, классик балет сәнгатендә кабатланмас үз стилен булдырырга кирәк.

—Арттырсын!.. Булдырсын!.. Моның өчен бездә мөмкинлекләр җитәрлек.

—Ай-һай...

—Ә нигә шикләнергә?

—Тимер читлекме, әллә алтынмы—былбыл кош өчен ул барыбер читлек инде, месье директор. Ә сайрар кошка кысан читлек түгел, хөр ирек кирәк!

—Ягъни мәсәлән?

—Нуриев кебек бию бөркетен читлектә һичкайчан тотып булмаячак! Ана Франциянең генә түгел, дөньяның үзе теләгән һәр сәхнәсендә чыгыш ясый алу мөмкинлеген бирергә кирәк.

Раймундо де Ларрен сәхнәләрдә үзе чыгыш ясамаса да, артистлар белән эш иткәч, аларча киенеп йөрергә ярата иде. Суларга кинәт һава җитми башлавын тоеп, менә ул ак күлмәк якаларын кысып торган кара канатлы күбәләген бушатып җибәрде:

—Менә хәзер аңлашылды, месье Лакотт.

—Нәрсә аңлашылды?

—Монда нигә килүең!.. Йә, әйт, Нуриевны кая, кайсы театрга кодаларга дип килдең инде бирегә?

—Әлегә театрга түгел—киногa.

—Кинога? Монысы ни дигән сүз тагын?Ялгышмасам, месье Нуриев монарчы кинода уйнамый, ә сәхнәдә бии генә иде түгелме соң?

—Шулай иде...—диде Пьер Лакотт, текә-биек ияген аска кагып.—Ә менә беркөнне атаклы биюче Вацлав Нижинскийның сеңлесе Бронислава Нижинская Париж сәхнәсендә Рудольф Нуриев чыгышын күргән дә, аның ярсу биюен һәм үзен нәкъ абыйсына охшаткан.

—Китче!.. Чынлапмы?

—Ыһы... Суйган да каплаган—нәкъ тере Нижинскийның үзе ди инде, менәтерә!

—Шуннан, шуннан?

—Шуннан менә шул: кайсыдыр илнең ниндидер киностудиясендә дөньяның егерменче йөз башындагы иң атаклы биючесе Вацлав Нижинский турында фильм төшерергә ният иткәннәр һәм бу рольгә кеше эзлиләр икән. Бронислава Нижинская исә тоткан да әлеге рольгә безнең Нуриевны тәкъдим иткән.

—Ничек.. Ошатканнар микән?

—Әлегә Нуриевның үзе белән очрашып сөйләшергә генә килгәннәр.

—Кем килгән?

—Кайсыдыр илнең ниндидер продюсеры.

—Ул хәзер кайда?

—Сезнең приемныйда утыра, месье директор.

Ярсу холыклы Раймундо де Ларренның каны кызганнан-кыза барды. Менә ул кәнәфиеннән сикереп торды да Пьер Лакоттның каршысына ук килеп басты:

—Кайсыдыр ил... Ниндидер продюсер, имеш... Син нәрсә көпә-көндез

минем күзгә зәңгәр төтен җибәреп утырасың ә? Турысын әйт, месье Лакотт: башта Нуриевны киного, аннары кайсыдыр балет труппасына суыртып алырга уйлыйлармы?

—Ә мөнә монысы, месье директор, Рудолфьның үзеннән, бары тик аның теләгеннән генә бәйле булачак.

—Ничек инде үзеннән генә?.. Ә мин? Дөньяның булачак бөек биючесенә бүген үк инде дөньяның иң зур хезмәт хакын түләп торучы кеше читтә кала булып чыгамы?

—Әйттем бит инде: алтын аяклы бию бөркетен алтын читлектә һичкайчан...

Ачуыннан шартлый язган Раймундо де Ларрен Париж Операсының бер гади биючесе Пьер Лакоттка әйтеп бетерергә ирек бирмәде:

—Җитте!.. Аңлашылды.. Ә хәзер, месье Лакотт, минем приемныйда утырган кайсыдыр илнең ниндидер продюсерын җитәклә дә, алдыңа карап, атыңны куала! Һәм дустың Нуриев турында онытъ! Ул сезгә тәтемәс дип уйлыйк.

—Карарбыз—кемгә тәтер бит әле!..

Ачуыннан табак битле йөзе чөгендер төсенә кергән Пьер Лакотт авыр-имән ишекне шундый каты ябып чыгып китте ки, аның артыннан хәтта тәрәзә пыялалары зеңгелдәп куйды.

Раймундо де Ларрен йөрәк ярсуын басарга теләп бераз ишекле-түрле йөрде дә, озын муенлы савыттан голт-голт агызып, салкын су эчте. Аннары күрше бүлмәдә утырган сәркәтип кызга дәште:

—Месье Нуриев хәзер үк монда керсен!

—Тыңлыйм, месье директор...

Аптыравы чибәр йөзенә чыккан әлеге кыз берничә минуттан әйләнеп тә керде:

—Месье директор...

—Ә Нуриев кайда?—дип бүлдерде аны Раймундо де Ларрен.

—Месье Нуриев репетицияләр залында яньып-пешеп күнегүләр ясый.

—Ә ник монда кермәде?

—Бик ашыгыч сүзе булса—месье директор үзе монда керсен, ди.

Раймундо де Ларрен, ачуын кая куярга беличә, чикләвек кадәрле генә кечкенә йодрыгы белән өстәлгә сугып куйды:

—Уф-ф!.. Менә сиңа кирәмәт татар дисәң дә кирәмәт татар! Пардон!.. Хезмәт хакын кискен арттырып, аның белән төзелгән контрактны кичекмәстән озайтырга кирәк. Юкса, элеккесе ярты еллык кына иде. Дилбегәне бер мәртәбә кулдан ычкындырсаң, Нуриевны түгел—эзлә аннары кырдан җилне!

Юан култыксалы йомшак кәнәфиеннән җәлт кенә сикереп торды да, китте төшеп Раймундо де Ларрен беренче каттагы күнегүләр ясау залына.

Рудольф бу юлы карышып маташмады. Түшәмгә башы тиярлек итеп иң соңгы пируэтын ясады да юмарт хуҗасы каршына килеп чүгәләде:

—Тыңлыйм сезне, месье директор.

Де Ларрен мул акчадан хөр ирекне өстенрәк күргән һәм моны инде Ле Бурже аэропортындагы легендар сикерүендә бик саллы итеп раслап та күрсәткән горур холыклы татар егетенең күңел кылларын кайсы яктан тартып карарга кирәклеген инде күптән төшенеп өлгергән иде. Юк, аңа хәзер үк контрактны озынайту кирәклегенә басым ясарга ярамый. Катыга утыртырга сонрак та өлгерерсең—башта йомшак җәяргә кирәк, йомша-ак!

—Эш бит менә нәрсәдә иде, месье Нуриев,—дип башлады ул сүзен, әңгәмәдәшенә бары тик изгелек кенә теләгән әүлия кешедәй төчеләнеп.—Кышкы сезон тәгәлләнде.Үзең дә беләсең, тиздән җәйге гастрольләребез башланып китәчәк. Мин аңлыйм: инде син дә бик аргансыңдыр. Чөнки Ле Бурже аэропоротында гына түгел, аңарчы да күпме тетрәнүләрне кичерергә туры килгән бит сиңа...

Рудольф үзенең салпы ягына салам кыстыруларын әлек тә бигүк өнәп бетермәде:

—Йә, шуннан?

Раймундо де Ларрен, ниһаять, әйтеләсе төп сүзгә якынлашты:

—Әллә, минәйтәм, җәйге гастрольләргә кузгалганчы, көньяк Франциядәге атаклы Зәңгәр Яр буйларында бераз ял итеп кайтыйкмы?

Галәмәт ымсындыргыч бу тәкъдимне ишеткәч, Рудольф чүгәләгән җиреннән хәтта торып басты:

—О-о, Зәңгәр Яр!.. Лазурный Берег!! Менә бу шәп булачак, месье директор—мин дүрт куллап риза!

Хәйләкәр Раймундо де Ларрен исә, кайнар холыклы Нуриевның канын тагын да кыздырып җибәрү өчен, бераз икеләнгән булып маташты:

—Шулай дисеңме?

—Шулай, шулай... Тик кайчан һәм кемнәр белән?

—Син дә мин һәм Клара Сент!

Үзенә күптән таныш һәм якын кеше исемен ишеткәч, сабый балалар кебек куанып, Рудольф кулларын чәбәк-чәбәк китереп куйды:

—О-о... Клара Сент булгач, барам да барам инде! Ә кайчан кузгалырга?

—Иртәгә иртән үк... Чөнки, үзең дә беләсең, вакыт кыска. Ә контрактны озынайту мәсьәләсенә килгәндә, без сиңа түләнәсе хезмәт хакын хәтта бүген—менә хәзер үк кискен арттырырга әзер...

Рудольф Нуриевның да башына тай типмәгән иде. Франциянең көньягындагы атаклы Зәңгәр Яр буйлары белән ымсындырып, хөр иреккә сусаган горур җанына тагын алтын йөгән кидерергә җыенуларын ул бик тиз аңлап алды. Юк инде, авызың бер пешкәч, өреп кабарсың ди!

Тиешле җавап һаман ишетелмәгәч, түземсезләнеп, Раймундо де Ларрен тагын сорыйсы итте:

—Йә, ничек, месье Нуриев—ник дәшмисең?

—Ник дәшмимме? Чөнки мин әле бу сөйләшүгә әзер түгелмен.

—Оҗмахка төртеп кертмиләр дә бит, югыйсә...

—Беләм... Әйдәгез, иң яхшысы, бу хакта җәйге гастрольдән кайткач сөйләшик.

—Җаны теләгән—елан ите ашаган! Ярый соң, көтеп карыйк, алайса.

## 27

Җәйге гастрольләр алдыннан берничә көнлек кенә кыска ял өчен, аз булса-булсын—ләкин онытылмас-шәп булсын дип, Зәңгәр Яр буеның Больесюр-Мер дип йөртелгән төшендәге атаклы «Ля Резерв» кунакханәсен сайладылар. Итальян җиһазлары белән галәмәт затлы итеп бизәлгән мондый да зиннәтле оҗмах почмагында бары тик Раймундо де Ларрен кебек калын кесәлеләр генә ял итә ала иде.

Кемгә ничектер—мәгәр Рудольфка иң ошаганы Зәңгәр Яр үзе булды. Ул зәңгәрлек монда, ул зәңгәрлек! Бер болытсыз ап-аяз һәм зәп-зәңгәр күк. Башларын шул күккә терәгән зәңгәр түбәле таулар тезмәсе. Гәрәбәдәй сары... юк, зәңгәр комлы яр читенә шап та шоп килеп бәрелгән зәңгәр дулкыннар... Дөньяның Зәңгәр Яр дип аталган бу гүзәл почмагында, әйтерсең, бары бер—Зәңгәр Төс кенә патшалык итә иде!

Зәңгәр нур бөркелгән йомшак комлыкның ул назлы җылылыклары! Бер офыктан икенчесенә хәтле җәелгән зәңгәр келәмгә кетер-кетер басып, үзеннән-үзе зәңгәр назлы дулкыннар эченә кереп китәсе һәм алар кочагында эреп бетәсе килә башлый.

Рудольф кечкенәдән чалкан йөзәргә яратты. Болай озак арытмый. Баш очындагы зәңгәр күк йөзен, тирә-як гүзәллеген дә иркенләп күзәтергә мөмкин.

Бу минутларда Клара Сент та, чалкан ятып, иксез-чиксез күк йөзен күзәтү белән мәшгуль иде. Тик Рудольф кебек дулкыннар кочагында тирбәлеп түгел, ә кайнар комлык өстендә кинәнеп. Рудольф аны бергә коенырга, бергә йөзәргә кыстап караган иде дә, ак купальнигын киеп җибәргәч, тумыштан шоколад төсендәге тәне тагын да каралып күренгән Клара тәртәгә тибеп маташты:

—Юк, Руди—мин начар йөзәм бит.

—Ничек инде начар?! Океан читендә туып, дингез буенда үс тә!

—Ә-ә... Чили белән Францияне күздә тотасынмы?

—Сон...

—Менә шулай... Начар булгач—начар инде. Аннары, әкияти зәңгәр комлыкка чалкан ятып, бераз кызынып та аласым килә иде.

—Күпме кызынырга була инде? Кара ул тәненне—чүл гарәбенекеннән һич тә ким түгел!

Клара Сент ярым шаяртып, ярым мактап әйтелгән бу ярату сүзләренә җавап биреп тормады. Ни өчендер монсуланып киткән күз карашын очсыз-кырыйсыз күк йөзенә төбәде дә тирән уйларына күмелде.

Ә Рудольф исә, бер алдын, бер артын күрсәткән бу кырыс тормышның бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләреннән азрак бушанып тору өчен, тагын зәңгәр дулкыннар кочагына ташланды. Зәңгәр күктә ак сызык сузып, менә анын баш очыннан бер самолет очып үтте. Бик биектән бәләкәй тургай кебек кенә күренгән бу очкыч сукмагына күзе төшкәч, Рудольфның тынгысыз уйлары тагын Клара Сент тарафларына әйләнеп кайтты. Күктәге тургай хәтле генә гәүдәле бу кыз белән анын гомер сукмагы киләчәктә янәшә сузылырмы, икесе ике якка юнәлеп, әллә аймыл булырлармы—Рудольф хәзер бу турыда кистереп кенә һични әйтә алмый. Ләкин бер нәрсә ачык: Ле Бурже аэропортындагы иң хәтәр, иң куркыныч минутларда ана беренчеләрдән ярдәм кулы суза алган әлеге Чили кызы Рудольфның гомер күгендә мәңге сакланачак ак сызык булып калачак!

Тик нигә сон әле Клара бүген монсу-ямансу? Ниндидер авыр сүз әйтеп, әллә Рудольф аны үпкәләттеме? Юк кебек болай... Алайса, нигә сон әле ул Зәңгәр Ярга килгәннән бирле нидер әйтергә теләп тә, кыймыйча тел яшереп кала? Тукта!.. Раймундо де Ларренга, әле җәйге гастрольләр башланганчы ук, Рудольф Нуриев белән төзелгән ярты еллык килешүне кичекмәстән озайту кирәклеге. Чөнки гастрольдән кайтканда инде эшләр узып, туннарның исә тузып куюы да бик ихтимал бит. Турыдан барып чыкмагач, әйләнгечтән камап, әгәр елгыр эшкуар киребеткән биючене Клара Сент аша килешү җәтмәсенә эләктерергә уйлаган булса? Бик мөмкин ич!.. Мондый уй ничек монарчы Рудольфның башына килеп карамаган? Туктале, тукта!..

Зәңгәр дулкыннарга йөзтүбән әйләнеп ятты да, каз күкәе хәтле кабарган тыгыз мускуллы беләкләре белән колач салып йөзә-йөзә, Рудольф ярга таба чыгып китте. Чыкты да әле һаман зәңгәр күккә төбәлгән Кларанын янәшәсенә үк килеп басты:

—Клара, мөмкинме бер сорау бирергә?

—Рәхим ит, Руди.

—Син нигә әле бүген бик монсу-ямансу?

Клара, ниһаять, чалкан яткан җиреннән торып утырды:

—Каян белдең?

—Күзләреннән.

—Монланмассын бар...

Рудольф, аптыраудан гаҗизләнеп, көньяк кояшы инде кызарта ук башлаган кулларын як-якка җәеп җибәрде:

—Зәңгәр дингез, зәңгәр күк, зәңгәр ком!.. Мин анлый алмыйм: ничек

инде шундый гүзәллек эчендә нindидер борчулы уйларга бирелеп ятарга мөмкин? Турысын әйт, Клара: син монда ял итәргә килденме, әллә...

Кечкенәдән тигез-житешле гаиләдә яхшы тәрбия алып үскән Клара Сентнын алдашып сөйләшә торган галәте юк иде:

—Дөрес әйтәсен, Руди! Минем бөтен бәлам дә син әйткән әнә шул «әллә»дә инде.

—Ягъни, Зәнгәр Яр ожмахында ял итәбез дигән булып, мине монда контрактны озайту өчен Раймундо де Ларрен махсус алып килдеме?

—Шулай, Руди. Дингез һавасын сулап сихәтләнгәч, күнеле һичшиксез кинәеп китәчәк Нуриев бәлки әле контрактны озайтуга да риза булып куяр. Бигрәк тә, Клара, син сөйләшсән... Чөнки мин инде тырышып карадым—булмады диде.

—Менә ниче-ек?..—диде Рудольф.—Хәер, нигә аптырарга, шулайдыр дип уйлаганыем аны.

Рудольфнын кинәт кәефе төшеп китүне күреп, Клара Сент үзенә кирәкле төп сорауны биреп калырга ашыкты:

—Ә мин месье Раймундога нәрсә диярга тиеш булам инде?

—Монда килер алдыннан гына мин ана бер мәртәбә әйттем бит инде.

—Нәрсә әйттен?

—Контрактны озайту яки озайтмау турында гастрольдән кайткач сөйләшербез дип.

—Анла мине һәм үтенеп сорыйм, Руди: ул синнән мондый сүзне бүген үк—минем аша көтә!

—Алай бик көткәч, әйтерсен инде, матурым...

Клара Сент бу юлы Рудольфка яратып һәм түземсезләнеп карады:

—Нәрсә дип?

—Бөркетләрне алтын читлектә тотып булмый—алар кыяга оялый, дип.

Бәләкәй гәүдәле Клара Сент, аяк очларына басып, Рудольфнын ике як битеннән чуп итеп үбеп алды:

—Мин синен белән тулысынча килешәм, Руди! Турысын әйтүен өчен рәхмәт сина. Ә хәзергә хуш, сау булып тор, Руди...

—Хуш, Клара!

Ләкин Клара Сент белән Рудольф Нуриев бу көнне ашыгыбрак хушлашканнар булып чыкты. Кырыс язмыш сынавы бераздан аларны кабат очраштырды.

## 28

Клара Сентнын Рудольф Нуриев белән табигать кочагындагы рәсми булмаган хатын-кыз хәйләкәрлеге һәм нәзакәтлегенә исәп тотылган шартларда сөйләшүенә комачауламас өчен, Раймундо де Ларрен Зәнгәр Яр комлыгына барып тормаган иде. Ул, ике күзен дүрт итеп, аларнын тизрәк кайтып житүен көтте.

Клара Сент киткәч, Зәнгәр Яр буенын бөтен яме бетте. Бередәге зәнгәрлек акрынлап кара төсләр белән алышынды. Кара болытлар агылган карангы күк йөзе, кара сыртлы тәргәк-тәргәк дулкыннар, кара комлы яр буе... Шул комга чалкан төшеп, Рудольф азрак кызынмак булып та карады. Жанына тынгылык таба алмагач, бераздан тагын дулкыннар кочагына атылды. Юк, бу минутларда анын ашкынулы-ярсу жанына нидер житми иде. Кинәт исенә төште: шәхси милекче карамагында булгач, «Ля Резерв» вилласында жанын теләгән һәрнәрсәне, һәр шөгыльне табарга мөмкин иде. Шул исәптән моторлы көймәне дә!

Тагын берничә минуттан, мангаена сибелгән тынлаусыз чәчләрен жилгә каршы куеп, Рудольф балет чүәгенекедәй тупыйк койрыклы көймәдә дингез

эченә кереп бара иде инде. Бер кулы белән ул көймә рулен кысып тоткан, икенчесе белән исә, актарылган дулкыннар кочагына очып төшмәс өчен, үзе утырган агач эскәмия читенә ябышкан. Коточкыч зур тизлекле көймә борыны өскә күтәрелгән. Ә койрыгы исә суга тияр-тимәс бара. Колак төбендә генә ачы жил сызгырып кала. Рәхәт! Нәкъ көтүләр көтеп йөргән хафасыз балачакта иярсез ат сыртында элдерткән вакытлардагы кебек!

Тизлек хисенә бирелеп, менә инде яр читеннән шактый ук эчкә керелде. Андый-мондый хәл була калса, Зәңгәр Яр комлыгына исән-сау йөзеп чыгулар, ай-һай, икеле. Ләкин мондый гына ара ераклыгы Рудольфны һич куркытмады: исәпсез-чутсыз пируэт һәм антрашалар ясый-ясый тәмам чыныккан аяклы, биюче туташларны баш өстенә күтәреп әйләнә-әйләнә беләк мускуллары үзләрендә тупланган физик көчтән инде тыгыз туптай тәмам чынлап тора башлаган адәм балалары тагын кайда бар соң?!

Рудольфны язмыш сандалында тагын бер сынап карыйсы килгәндәй, менә ярыйсы еракта торып калган вилла-порт радиосы телгә килде:

—Месье Нуриев! Сезгә Уфадан әле генә әниегез чылтыратты—кичекмәстән вилла радиоузелына килеп житегез! Месье Нуриев!..

Гаять ашыгыч һәм күптән көтелгән галәмәт куанычлы бу хәбәрне ишеткәч, Рудольф көймә койрыгында утырып барган жиреннән ничек торып басуын да сизми калды. Тукта! Аны халыкара телефон аша сөйләшергә газиз әнкәсе чакыра икән түгелме? Тик бу хәбәргә Рудольф ни сөенергә, ни көенергә белмәде. Чөнки Уфадагы кысан фатирында хәтта өй телефоны да булмаган әнкәсе Фәридә дөньяның бер дигән, ләкин жәһәннәм тишегендәге оҗмахында ял итеп яткан улын ничек шулай тиз генә эзләп таба алсын ди инде?! Әлбәттә, могҗизалы мондый чылтыратулар артында очлы күзле, сизгер колаклы, озын куллы КГБ торуы Мәнди анасы Гөләп жиңгигә дә жиңел аңлашырлык!

Һәм мондый «хәл белешү»ләрнең хәтәр ягы шунда—алар Рудольф бар дөньясын онытып, ашыга-кабалана сәхнәгә чыгарга әзерләнгәндә яки шуңа ошашлы бүтән бер мөһим эш алдыннан гамәлгә ашырыла иде. Газиз әнкәң чакырта дигәч, бара Рудольф—бармый нишләсен? Моторлы ярсу көймәдә диңгез эченә кереп киткәч кенә ашыгыч чакырткач, инде бу юлы нинди этлек уйлап чыгардылар икән?

Менә кинәт алда як-якка су көлтәләре аттырып, зур тизлек белән ажгырып каршыга килгән катер пәйда булды. Рудольф көймәсе дә шәп элдертә. Чөнки ул, диңгез эченә кереп киткән жиреннән кире борылып, әнкәсе белән сөйләшергә ашыга! Шуңа күрә, каршыга килүче катер белән бәрелешмәс өчен, Рудольф тизлекне бераз киметә төшү яки, читкә тайпылып, аңа юл бирү турында уйлап та карамады. Ә катердагыларның авыз колакта—сөзгәк үгез кебек, һаман өскә бастырып килүләрен беләләр.

Ике көймә менә-менә маңгайга-маңгай килеп бәрелешә дигәндә, Рудольф шулай да рульне кисәк кенә унга таба борып жибәрә алды алуын. Һәм шул житте: табигатьнең инерция дигән мәңгелек канунына буйсынып, тагын бер мизгелдән аның гәүдәсе актарылган-кайнаган шомлы дулкыннар кочагына барып төште.

Катердагылар, мыскыллы елмаеп, Рудольфка тишек шлюпка ыргыттылар:

—Атлы юлчының җәяүлегә кайчан юл биргәне бар? Кая шулай ашыгасың, кыргый татар?—дип төрттерде алар.—Мә, ал—ярамаган тагын сиңа тишеклесе дә! Суга батучы саламга ябышыр ди. Син дә ябышырсың, ябышмый хәлең булмас, мескен хыянәтче!

Ачуы тынына капланган Рудольф бары тик:

—Ах, сез—Кыгыбының йомшак жәеп, катыга утырта торган зәһәр этләре!—дия генә алды.

—Су төбендә сине күптән көтәлер, месье Нуриев! Анда төшеп житкәч, телефонга чакырткан әниенә сәлам әйт...

Әйе, Рудольф дөрес шикләнгән иде: анын һәр адымын белеп торгач, болар—һичсүзсез совет шымчылары!

Тагын бер мизгелдән хәтәр катер, су көлтәләре чәчрәтеп, күздән дә юк булды. Рудольф бөтен жан ачуы белән алар артыннан теге шлюпканы томырды. Әйе, катердагылар алдашмаган иде: тишек шлюпка дулкыннар өстендә бераз чайкалгалап торды да, аскы ягыннан су тулып, тирәнгә үк төшеп китте.

Тукта! Ә көймә кайда сон, көймә?!

Юк, бәхеткә күрә, ул йөзтүбән капланмаган, ә озынча үлем элмәге ясап, Рудольф тирәсендә бертуктаусыз әйләнеп йөри иде. Выжт итеп каршы яктан узып китә дә, күз ачып йомганчы, арткы яктан тагын килеп житә! Кешегә сөйләсән—кеше ышанмаслык мондый хәлне Рудольфнын беренче мәртәбә күрүе иде әле.

Ләкин, кинәт бору сәбәпле, руль тыгылу аркасында килеп чыккан бу сәер хәлнен бөтен нечкәлекләре хакында уйлап торырга Рудольфнын вакыты юк—кичекмәстән ике мөмкинлекнен берсен сайлап алырга кирәк иде. Анын өчен әлегә анлаешсыз нindидер физик канунар буенча гажәеп түгәрәк ясап әйләнүче тилергән көймәне ташлап, еракта, инде бик еракта калган ярга йөзеп чыгаргамы, әллә котырган көймәне ничектер тынычландырып карыйсымы? Үзенен яшәве яки үлеме белән бәйле булганлыктан, һич көтмәгәндә-уйламаганда язмыш сынавы куйган бу кырыс сорауга жавапны Рудольф тиз тапты. Юк, тилергән көймәне ташлап, шомлы-дәһшәтле дулкыннар кочагында япа-ялгызын калырга һич ярамый! Бу очракта эш ярнын ерак яки якын булуына, анда йөзеп чыга алу яки алмауга гына кайтып калмый. Бу очракта эш бөтенләй башкада.

Китап корты Рудольф Нуриевнын монарчы да кайдандыр укыганы булды: әгәр адәм баласына көтмәгәндә нindидер үлем куркынычы яный башласа, анын акыл сәләте һәм физик көче кинәт кенә артып китә икән! Моны изге табигать бабабыз шулай кайгырткан. Шыксыз үлем белән күзгә-күз калгач, Рудольфнын тән буыннарына да каяндыр көч-куәт ташып керде.

Ә сәнгать кешеләренә хас образлы күзаллауга корылган акыл көченә кара син!

Рудольф бәйдән ычкынган бу көймәне никтер нәкъ менә үз язмышына охшатты. Аны да бит әле кайчан гына Ле Бурже аэропортында кырыс язмыш жиле гомер көймәсеннән дәһшәтле дулкыннар кочагына алып ташлады! Дөресрәге, аны ташланырга мәжбүр иттеләр. Ә үзе егылган—еламас, ди. Димәк, син дә бирешмәскә, әжәл белән КГБ шымчылары махсус оештырган бу якалашудан, һичшиксез, жинеп чыгарга тиеш.

КГБ дигәннән... Тукта! Суда чәбәләнгән Рудольфны нигә сон әле әзмәвердәй гәүдәле ул шымчылар үз катерларына салып, ягъни мәсәлән, урлап апкитмәделәр? Бу бит аларга берни дә тормый иде түгелме сон? Житмәсә, дулкыннар өстендә кылынган жинаятьнен эзе дә калмый...

Димәк, Ле Бурже аэропортындагы легендар сикерүе белән инде бар дөнья игътибарын үзенә жәлеп итеп өлгергән биюченен башына алай тиз генә житеп булмый, күрәсен. Димәк, дөнья жәмәгатьчелеге алдында булмаган совет демократиясе дәрәжәсен төшерүдән куркалар. Рудольф өчен монысы начар түгел, билгеле. Ләкин чит илдә яшәсән дә, КГБнын озын кулларыннан саклану өчен, киләчәктә итәк-жинне гел жыеп йөрергә туры киләчәк.

Киләчәктә?

Ә шомлы дулкыннар кочагында чәбәләнгән Рудольф өчен, гомумән, бармы сон ул киләчәк? Моны ачыклау өчен башта әле тилергән көймәне тынычландыру кирәк.

Көймә исә хуҗасына һаман буйсынырга теләмәде. Рудольф аңа теге яктан да, бу яктан да якын килмәк булып карады. Юк, нәкъ чыгымлаган ат кебек—тоттырмый гына бит кызу тизлекле көймә! Әле алай гынамы—ыжгырып өстенә килгән ул көймә, әгәр читкә тайпылып өлгермәсәң, хуҗасы булып хәтта хуҗасын да сытып үтәргә мөмкиндер кебек.

Хәзер инде ярга йөзеп чыгу турында уйларга да ярамый. Чөнки тилергән көймәне буйсындырып маташу күпме көч-егәрне алды. Аптырагач, бөтерчек кебек өскә атылып, Рудольф пируэт, антраша дигән хәрәкәтләрне дә ясап карады. Ләкин юкка гына—шома тиреле жумба балыгы кебек, буйсынмас көймә аның гәүдәсе астыннан зур тизлектә гел шуып чыгып китә торды.

Инде нишләргә? Бераздан, ниһаять, Рудольф аңына килеп өлгерде: әлегә файдасыз һәм артык хәрәкәтләр ясап, бетермә син көченне, бетермә! Иң яхшысы, суга чалкан ятарга! Аяк-кулларны аз гына селкетеп, болай байтак озак батмыйча ятарга мөмкин. Сәер-озынча түгәрәк буенча бертуктаусыз кызу тизлектә йөзгән көймә, бензины бетеп, бәлки әле үзеннән-үзе тукталып калыр. Хуҗасын шомлы дулкыннар кочагына ыргыткан куркыныч һәм йөгәнсез көймәне күреп, бәлки, кайдандыр ярдәм килеп житәр.

Калын кесәлеләр генә ял итә алырлык шәхси вилла булгач, «Ля Резерв» кунакханәсендә яшәүчеләр әлләни күп түгел иде. Шуңа күрә аларның теге яки бу минутларда кайда булуы һәмниләр кылуы гел игътибар күзендә иде. Уфадагы әнкәсе халыкара телефонга чакырткан Рудольфның ни өчен вакытында сөйләшәргә килеп житмәвен дә тиздән анлап алдылар. Анлап та алдылар һәм, уктай атылып, ресторанның диңгезгә караган тәрәзәсе каршында нәкъ менә Нуриев турында Клара Сент белән сөйләшеп утырган Рамундо де Ларрен янына кереп тә життеләр:

—Месье де Ларрен! Месье де...

—Йә... Кем яки нәрсә яна анда?—диде Раймундо, әлләни исе китмичә генә.

—Янмый яңуын... Ләкин Париждан бергә килгән иптәшегез, көймәсеннән очып төшеп, диңгездә батып ята.

—Көймәсеннән?.. Диңгездә?.. Ул ничек кергән соң әле диңгезгә?

—Прокатка көймә алып.

—Менә ничек... Йә, ярый, без уйлашырбыз...

Ләкин Клара Сент аша Рудольф Нуриевның де Куэвас театры белән ярты елга гына төзелгән контрактны бүген үк озайтырга теләмәве турындагы катгый җавабын ишеткәч, дөньяның булачак бөек биючесенә карата Раймундо де Ларрен күңеле суына да башлаган иде инде.

Клара Сентны исә, киресенчә, Раймундоның соңгы сүзләре бөтенләй ярсытып җибәрде:

—Кеше диңгездә батып ята—ә ул, уйлашырбыз, имеш!..—диде дә, эчмәгән тәмле суларын, ашамаган затлы ризыкларын калдырып, яр читендәге көймә станциясенә чыгып чапты.

Раймундо де Ларрен исә, ишкәктәй озын-нечкә кулларын болгый-болгый, аның артыннан кычкырып калды:

—Клара, кайт, борыл, зинһар! Шул тилергән Наполеон-татарионга карап, син дә акылдан язмак булдыңмы? Махсус кешеләре бар—аны синнән башка да коткарырлар. Кайт, борыл тизрәк!..

Юк, кайтмады, кире борылмады тоткан жиреннән өзә торган кызу-кайнар йөрәкле Клара Сент. Тагын берничә минуттан, кирәкле кешесенә тиешле акчасын түләп, очлы борынлы көймәсе белән көчле дулкыннарны яра-яра, ул диңгез эченә кереп тә китте.

Көймә хуҗасы исә яр читендә кычкыра-кычкыра, басып калды:

—Карагыз аны... Көймәнең бензины бетеп килә...

Клара Сент су өстендә чалкан һәм бөтенләй хәрәкәтсез диярлек яткан Рудольф янына нәкъ вакытында килеп житте. Хәер, килеп житте дисәк, дөрес үк булып бетмәс. Рудольф чәбәләнгән «Бермуд өчпочмагы»на егерме метрлап калгач, моторы сүнеп, Клара Сент көймәсе дә кинәт туктап калды. Ләкин монын сәбәпләре һәм үзенен начар йөзүе турында турында баш ватып торырга анын вакыты юк иде инде—кеше батып ята! Ул тотты да, төз-нәфис аяклары белән көймә читенә басып, шомлы дулкыннар кочагына сикерде.

Үз гомеренә янаган бу чая гамәлен кылып, Клара Сент бик дөрес эшләгән булып чыкты. Чөнки Рудольфнын жеп өзәрлек тә хәле калмаган иде инде. Ул хәтта үзенә кемнен ярдәмгә ташлануын да күрми-сизми калды бугай. Ләкин билдән кочаклаган кечкенә-йомшак, көмеш йөзекле кулларыннан танып алды: Клара бит бу, анын батыр йөрәкле һәм турылыклы дусты Клара Сент!

Янәшәсендәге ышанычлы инбашны тоюдан Рудольфнын тән буыннарына яна көч-сихәт кереп тулды:

—Рәхмәт, Клара! Синен мине инде икенче мәртәбә коткаруын!—дип пышылдады анын ничектер кан качып, агарып калган иреннәре.—Хәтерлисенме, теге...

—Ә-ә... Ле Бурже аэропортында килеп чыккан хәлләрне әйтәсенме?

—Сон...

—Рәхмәт инде, онытмагач... Ә беләсенме, Руди, минем бит әле сине өченче мәртәбә коткаруым да бик мөмкин,—диде Клара Сент, кечкенә, ләкин көчле куллары белән, моторы сүнеп, кинәт туктап калган көймәгә таба ишеп.

Рудольфка да инде тәмам хәл кереп өлгерде:

—Кемнән?.. Нәрсәдән?..—диде ул исе китеп.

—Раймундонын алтын читлегеннән!

Рудольф, яратып, Кларанын көчле гәүдәсен кысыбрак тотты:

—Менә монысы ярый торган эш.

—Шулай дисенме?

—Ә ничек итеп?

—Голландиядә яшәүче балет педагогы Вера Волкова турында ишеткәнен юкмы?

—Марго Фонтейн, Мария Толчиф, Эрик Брун кебек бию осталарынын остазымы?

—Менә-менә...

—Их! Мина да аннан осталык дәресләрен алып карыйсы иде ул!

—Алырсын, Руди, алырсын... Аз гына сабыр итик! Вера Волковага, синен хәлләрне әйтеп, мин тиз арада хат язачакмын.

## 29

Вера Волкова инде сигезенче дистәсен тутырып килгән ап-ак чәчле карчык булса да, дөнья күләмендә танылган һәм ин тәжрибәле балет педагогларыннан санала иде. Санкт-Петербург каласында туган бу ханым кайчандыр хореография училищесында атаклы Агриппина Вагановanын үзе белән бер елларда укыган һәм, инглиз кешесенә кияүгә чыгып, революциядән сон Лондонга күчеп киткән.

Туган иленнән аерылып, үзенә дә чит жирләрдә озак еллар гомер кичерергә туры килгәнгәме, Вера Волкова көнбатышта калырга мәжбүр ителгән татар биючесен бер күрүдә ошатты, газиз баласыдай кабул итте. Ул бу егеттә дөньянын булачак атаклы биючесе чаткыларын бик тиз күреп алды. Ә инде Рудольфнын хореография училищесындагы беренче укытучысы Александр Пушкин булуы ачыклангач, Вера түтәй аны өрмәгән жиргә дә утыртмый башлады. Чөнки бөек рус шагыйренен адашы белән кайчандыр, яшь чакларында алар бергә дә биегәннәр икән!

Вера Волкова канаты астына сыенгач, Рудольф Нуриев өчен чын-чынлап күк капусы ачылгандай булды. Остаз фатирында кичләрен гөр килешеп, сәнгать һәм ерак калган ил турында чөкердәшә-чөкердәшә чәй эчүләр бию күнегүләре залында туган күнел бәйләнешләрен тагын да ныгытты. Ин мөһиме: кая карама—балет сәнгате дөньясы кайчандыр Волкова мәктәбен үткән, бүген исә үзләре сәхнә йолдызларына әверелгән биючеләр белән тулган иде. Ә Рудольфка нәкъ әнә шундый мохитта кайнау кирәк иде дә!

Шулай бер көнне кичке чәй эчеп утырганда остаз фатирында сузып-сузып телефон чылтырады. Озын гудок—димәк, кемдер халыкара телефон аша чит илдән чылтырата иде.

Иреннәре турысына менеп житә язган чәйле чокырын тиз генә өстәлгә кире куеп, Вера түти коридор очындагы телефоны янына ашыкты:

—Әйе, тынлыйм...

—Лондоннан Марго Фонтейн иде әле бу. Исәнмесез, остазым!

—О-о, миссис Фонтейн! Саумысыз... Тынлыйм сезне.

—Лондон хәтле Лондоннан ашыгыч борчуымның сәбәбе шул иде: тагын бер айдан биредәге Король бию академиясе файдасына хәйрия концертым булырга тиеш. Анда катнашуларын үтенеп, күп илләрнең күренекле биючеләренә, шул исәптән Мәскәү примасы Галина Улановага да чакыру жибәрдек. Тик менә әле генә аннан хәйрия концертында катнаша алмавы турында борчулы телеграмма алдым.

—Нигә икән?

—Сәбәпләрен төгәл генә әйтмәгән... Тыйганнар булса кирәк. Ни өченме? Чөнки Советлар Союзыннан качкан бер йолдыз ачуын икенче йолдыздан алмакчылар, күрәсең. Ягъни мәсәлән, совет балетының горурлыгы булган Галина Улановадан илен алыштырган теге татар егете... Кем әле—исем-фамилиясе тел очымда гына тора...

—Рудольф Нуриевмы?

—Менә-менә... Дөрес әйтәсез!.. Ягъни мәсәлән, Уланова әнә шул Нуриев белән һичкайчан бер сәхнәдә биемәскә тиеш булып чыга.

Вера түти, маңгай сызыкларын тирәнәйтеп, авыр сулап куйды:

—Фу-у!.. Сәясәт белән сәнгатьне бутау нинди мәгънәсезлек!

—Менә шулай килеп чыга шул. Инде менә без уйлаштык-уйлаштык та, советларның Рудольф Нуриевка каршы оештырылган кызыл бойкотына җавап итеп, минем концертта Уланова урынына ул егетнең үзен биетеп булмасмы дигән фикергә килгән идек.

—Бик дөрес эшләгәнсез, миссис Фонтейн!

—Шулай дисезме?! Рәхмәт, сөекле остазым! Тик бит...

—Нәрсә тик?

—Тик бит моңарчы бер мәртәбә дә күреп карамаган ул егетнең хәзер мин хәтта кайда икәнлеген дә белмим,—диде ачыргаланып Марго Фонтейн һәм, Вера Волкованың салпы ягына салам кыстыра-кыстыра, өстәп куйды.—Дөньяның сез укытмаган, сез белмәгән һәм аралашмаган бер генә биючесе дә юктыр дип, шуның өчен нәкъ менә сезгә чылтыратуым иде, остазым!

—Дөрес эшләгәнсез! Сез эзләгән ул чибәр егет хәзерге минутларда минем каршымда утыра, миссис Фонтейн! Рәхим итегез—телефон трубкасын аңа бирәм.

Көтелмәгән бу хәбәр Марго Фонтейнга шулкадәр көчле тәэсир итте ки, ул беравык хәтта тынсыз калып торды. Телефон мембранасы аша аның бары еш-еш сулаганы гына ишетелде. Бераз тынычлана төшкәч, ниһаять, ул үз гозерен җиткерде.

Була шундый кешеләр—әле аларны күргәнче, тавышларын ишетүгә үк, күнелдә үзләренә карата җылы хис, җылы мөнәсәбәт туып өлгерә. Дөнья

балеты сәхнәсендә күптәннән һәм күпләргә мәгълүм Марго Фонтейнның йомшак-ягымлы, кайгыртучан рәхимле-мәрхәмәтле тавышы да Рудольфны бер тынлауда әсир итте. Әйе, мондый тавыш иясенә ышанырга була иде.

Рудольфның болай да ашкынулы хыялларын әнә шулай ымсындырып торгач, Марго Фонтейнның хәйрия концертында катнашу турындагы тәкъдименә ул рәхәтләнеп риза булды:

—Чакыруыгыз өчен рәхмәт, миссис Фонтейн!—диде Рудольф, үз сүзендә һичшиксез торачак ирләр тавышы белән.—Мин Лондон сәхнәсендә биергә күптәннән телимен!

—Килештек, алайса, мистер Нуриев?

—Тик ни бит, миссис Фонтейн...

—Нindидер проблемагыз бармы, мистер Нуриев?

—Виза мәсьәләсе... Англия хөкүмәте мина аны бирергә теләрме?

—Анысы өчен борчылмагыз, мистер Нуриев. Виза мәсьәләсен генә хәл итә алырбыз дип уйлыйк. Һәм бик тиз!

—Ярый, монысы шулай да булсын ди. Ә шәхси иминлек мәсьәләсе?

—Кемнән?

—Совет чекистларыннан, билгеле.

—Ә-ә... Гафу итегез... Сез бит илен алыштырган сәяси качкын да әле!..—диде Марго Фонтейн һәм, сүзсез калып, бераз дәшми торды.—Ә беләсезме, дустым: боларның берсе дә телефоннан сөйләшә торган сүзләр түгел. Сез шушы берничә көн эчендә, зинһар, Лондонга килеп китә алмассыз микән? Монда кайсы балеттан нинди бию башкарасыгыз—барысы, барысы хакында да җентекләп сөйләшер идек.

—Ә бая әйткән мәсьәләләр?

—Ә сез бу юлы гади турист булып кына, ягъни инкогнито булып килегез! Виза һәм билетлар иртәгә үк сезнең кулга тапшырылыр.

—Ярый, алайса... Мин риза, миссис Фонтейн! Тик бер үтенечем бар.

—Нинди үтенеч ул, мистер Нуриев?

—Лондонга минем беренче сәфәрем турында корреспондент яки фотохәбәрчеләрдән һичкайсы белә күрмәсен!

—Ә-ә, аңлашыла... Журналистларның белгәннәре минуты-секундында КГБ колагына да барып ирешә дигән сүз!

—Шулай, билгеле...

—Белмәсләр—борчылмагыз, мистер Нуриев.

—Хушыгыз!

Алар беренче мәртәбә әнә шулай читтән торып—халыкара телефон аша гына таныштылар.

Ләкин күзгә күренмәс ниндидер җепләр аша ике кайнар, ике ярсу йөрәк арасына утлы-рәхәт дулкыннар җибәрелгән иде инде. Һәм тиздән, бик тиздән ул ялкыннан яшәү вә бию көчен арттыручы тылсымлы сөю уты кабыначак иде. Рудольф ничектер, ә Марго исә моны күптән инде чын ярату утына сусаган бөтен җаны, бөтен бәгыре белән тойды.

Кем ул дөнья балеты күгенә балкып күтәрелгән, хөр иреккә сусаулы кыю, чын егетләрчә гамәлләре белән кызыл киртәләрне сикереп үтә-үтә, берьялгызы советчыл яшәү рәвешенә каршы килә һәм җиңеп чыга алган Рудольф исемле яшь вә яңа йолдыз? Ник алар шулай соңлап—Марго Фонтейнга инде кырык яшь тулгач очраша? Яшең житсә кырыкка—эшең китәр шырыкка, диләр бит. Балет биючеләренә бу аеруча кагыла. Нигә Мәскәү йолдызы Галина Уланова аның хәйрия кичәсендә биемәскә уйлаган? Нуриевка үч итүчеләр киңәшен тотыпмы? Нигә Лондонның Король балеты продюсерлары Улановны качкын ватандашы белән алыштыру тәкъдимен ясадылар? Язмыш шаяртуымы бу? Әллә тәкъдирме?

Марго Фонтейн киләчәк язмышына тиздән давыллы өермәдәй килеп керәчәк татар биючесе турындагы уйларыннан телефон трубкасын куйгач та озак кына аерыла алмады. Дөресрәге, теләмәде! Чөнки бу тансык уйлар, тансык хисләр дингезендә чайкалу аңа бик рәхәт тә, татлы да иде.

### 30

Скрябинның «Трагик поэма»сыннан өзекне хәйрия концертында Рудольф Нуриев нибары дүрт минут чамасы биеде. Ләкин шушы кыска гына вакыт эчендә дә кырыс язмышына галәмәт туры килеп торган үз образын тудыра алды.

Ул, хореограф Фредерик Аштон белән алдан сөйләшкәнчә, сәхнәгә кызыл плащын бөркәнеп чыкты. Юк, чыкмады—рампа читенә үк кызыл яшендәй атылды! Һәм, канатлы өермәдәй бөтерелә-бөтерелә, артыгын да тырышып җибәрде бугай—чүт-чүт кенә каршыдагы оркестр чокырына очып барып төшмәде!

Көтелмәгән бу хәлдән меңләгән тамашачы йөрәге берьюлы кысылып куйды:

—Ah -h-h! Бет -те!..

Ләкин бу хәрәкәтне инде йөзләрчә мәртәбә ясап караган шашкын биюче оркестр чокырына мәтәлмәде. Киресенчә, аның бу куркыныч хәрәкәте гаҗәеп табигый килеп чыкты. Өстәвенә, нинди образлы һәм тирән символик мәгънәгә дә ия: каршыдагы бу оркестр чокыры әле кайчан гына СССРдагы ул сикереп чыккан рухи упкын хәлләрен ничекләр искә төшереп тора!

Күпме еллар шушы рухи упкын төбендә интеккән язмышы өчен гарьләнеп, биюченең ялан тез өстендә сәхнә идәненнән шуып баруы! Һәм, ике кулын зәңгәр күккә сузып, Ходайдан ярдәм ялваруы!.. Рудольф Нуриевның нибары дүрт минут эчендә үз язмышын классик бию аша тыелгысыз көч, бетмәс-төкәнмәс дәрт-егәр белән сөйләп бирә алуы Лондон тамашачыларын тәмам тетрәндерде. Чын сәнгать, бөек сәнгать дигәннәре менә нинди була икән ул! Бу минутларда үзләре өчен дөньяның иң газиз, иң кадерле биючесенә әверелгән Рудольф Нуриевка чиксез рәхмәтләрен белдереп, кул көчләре генә җитмәгәч, идәнне аяклары белән дөбердәтә-дөбердәтә, алар бертуктаусыз алкыш яудырдылар.

Умарта күчедәй гөжләгән тамашачылар арасында Король балеты театрының директоры Нинетт де Валуа да бар иде. Рудольф Нуриевның бөтен Лондон каласын аякка бастырган тылсымлы биюенә ул да бер күрүдә гашыйк булды. Ләкин, үзе аякка бастырган, үзе күпме көч салган атаклы театрның киләчәк язмышын кайгыртып, миссис Валуа еш кына тирән уйларына күмелгәләп алды.

Фонтейнның хәйрия концертына очраклы төстә—Мәскәү йолдызы Галина Уланова килми калу сәбәпле генә чакырылган бу тылсымлы һәм могҗизави татар биючесен Англиянең Король балетына ничек кодаларга? Күпме еллар Марго янәшәсендә парлап биегән Майкл Сомсны әле шушы арада гына ялга озаттылар. Король балетының гына түгел, бөтен инглиз милләтенең чын горурлыгына әйләнгән кырык ике яшьлек Фонтейн да, сәхнәдән китәр вакытым җитте дип, соңгы көннәрдә төшенке уйларга бирелеп йөри башлады. Чөнки янәшәсенә бастырып биетергә лаек ир-зат калмады.

Юк, ашыга кебек Марго! Дөньяның инде иң якты балет йолдызына әверелгән бу гүзәл хатынның яшүсмер чагыннан алып бүгенгәчә гомере Нинетт де Валуа күзе алдында үтте. Әти-әнисе белән Шанхай каласыннан күченеп кайтып, Лондондагы Король театрының ул житәкләгән балет студиясенә йөри башлаганда, Кытай кызларыныкы төсле кысынкырак күзле, малайларныкы кебек кыска чәчле бу үсмер ундүрт яшьтә генә иде әле. Әмма, классик биюгә өйрәнә башлау чиген инде узып баруын аңлапмы, кыз

зерә дә сәләтле, сабыр-түзем акыллы һәм, иң мөһиме, галәмәт тырыш, хезмәт сөючән булып чыкты. Әнә шуна Англия генә түгел, дөньякүләм балет сәнгатенең иң якты йолдызына әверелә алды да.

Марго Фонтейнның шәхси тормышына килгәндә исә...

Юк, аны бәхетле гаилә кора алды дип әйтергә, ничектер, тел әйләнми. Дөньяның бер дигән чибәре булса да, сәхнә тормышына артык бирелгәнлектән, ул утыз алты яшьтә генә кияүгә чыга алды. Ләкин Панама президентының улы һәм илче дәрәҗәсендәге дәүләт эшлеклесе булган иренең чит хатыннар мәсьәләсендә әкәмәт тотнаксызлыгы тиз ачыкланды. Ләкин, нишләсен, инде бер мәртәбә көйләнгән һәм шактый ук иркен-бай тормышлы гаилә корабын батырмау хакына, Марго тешен кысып булса да түзде.

Матур хатыннарга күзе еш төшсә дә, ире Роберто Ариасның әллəни мактап сөйләрлек чибәрлеге юк иде. Төптән ярыйсы юан чыккан тәбәнәк-карсак гәүдә, кәкре очлы ыргак борын, каратут битендә тирән уелган кечкенә-уйнак күзләр... Ләкин кесәсе тирән... Шуна чибәр хатыннарга гына түгел, бөтен җирдә сүзе үтә. Хәтта Америка президентларына дус-таныш булган атаклы Онассис кебек миллардерлар белән эшне бик җинел йөртә Роберто Ариас абзагыз!

Шулай да, күренә ки, мәхәббәт сәхнәсендә үз бәхетенең иң югары, иң татлы ноктасына ирешә дип һич тә әйтеп булмый Маргоны. Ә моннан нәрсә килеп чыга? Димәк, балет сәхнәсендә дә ул үз сәләте, үз талантына лаеклы сәнгать үренә менеп җитә алмады кебек әле. Әгәр Марго Фонтейн чын мәхәббәт, чын сөю-ярату утында яна-яна да биегән булсамы?!

Тукта! Әгәр Марго йөрәгендә бу изге утны, шактый соңга калып, нәкъ менә Рудольф Нуриевка кабызырга язган булса? Юк! Яңа гаилә кору өчен дә булмасын, ди. Ә бит бию талантларының зурлыгы, холыкларының капма-каршылыгы ягыннан да алар бер-берләренә гаять туры килеп торалар! Әле чын мәхәббәтне татып карарга өлгермәгән ике саф, ике тугры йөрәк арасына сөю очкыннары чәчрәп төшмәсме? Бу очкыннардан, мондый сөюдән бит балет сәнгате тарихына кереп калырлык гүзәл әсәрләр дә тууы бик ихтимал!

Рудольф Нуриевны Лондонның атаклы Король балетында эшләргә ризалаштыру әллəни кыен булмастыр кебек. Чөнки аның хәзер нәкъ менә язмыш чатында торып калган чагы.

Ә менә Маргоны?

Тиздән лаеклы ялга китәргә җыенып йөри башаган Марго Фонтейн белән бу хакта иртәгә, юк—тимерне кызуында сугалар!—бүген үк сөйләшеп карарга кирәк!

Хәйрия концертында катнашкан артистлар өчен кечкенә аш мәҗлесе үткәрелде. Король балеты башлыгы Нинетт де Валуаның теләген үтәп, анда ирле-хатынлы Роберто һәм Марго белән яшь йолдыз Рудольф Нуриевның урыннары янәшә туры китерелде. Алар арасына исә ул үзе кереп утырды.

Рудольфның уң ягындагы урын буш тора иде. Мәҗлес башланып китәр алдыннан, кулыннан җитәкләп, ул шунда бер кырыйдарак нәүмизләнеп басып торган Соня Арова дигән биючене алып килеп утыртты. Дунай болгарлары җирендә туып үскән, димәк, тамырларында Рудольфныкы кебек үк төркиләр каны аккан биек-сылу гәүдәле, ләкин озынча битле карачкыл йөз-кыяфәте бүтәннәрнекеннән шактый аерылып торган урта яшьләрдәге бу балеринага, ничектер, читләтебрәк карау сизелә иде. Аны сәнгать юлына әтисенең танышы Федор Шаляпин үзе кертеп җибәргән, диләр. Әллә шуна көнләшәләрме?

Король балеты башлыгы зур уңыш белән узган хәйрия концертында катнашучыларга рәхмәт сүзен әйткәч, менә аш мәҗлесе башланып китте. Кич буе сәхнәдә чыгыш ясап арыган биючеләр, һич тартынып һәм оялып тормыйча, күптәнге гадәтләренчә, бердәм төстә тәгам-ризыкларга ябырылды.

Бәллүр савыттан көмеш кашыгы белән чумырып алып, Рудольф та Арованың өлеш тәлинкәсенә тәмле кабымлык салды:

—Аша, Сания, аша!

Арованың пешкән шомырттай кара күзләреннән сөенечле гаҗәпсенү очкыны сирпелеп узды:

—Ә ник Соня түгел?

—Чөнки төркиләрдә андый исем юк!

—Димәк, кайчандыр мин дә төрки булганмынмы?

—Әлбәттә!.. Идел буйларында яшәгән кан-кардәшләреннән аерылып, әле алтынчы гасырда ук Дунай тарафларына китеп барган Аспарух ханның ерак оныгы.

—Кызы-ы-ык... Ә ник, алайса, Дунай болгарлары хәзер төрки түгел?

—Чөнки алар, христиан динен кабул итеп, туган телләрен югалту бәрабәренә, дәүләтчелекләрен саклап кала алганнар. Ә бездә, Идел болгарларында дип әйтүем, нәкъ киресенчә килеп чыккан: тел исән—дәүләтчелек һәлак булган!

Бу турыда белгәч, Арованың ягымлы тавышы тагын да җылына төште:

—Димәк, без—бабаларыбыз уртак рухи туганнар, алайса, Рудольф?

—Шулай, Сания, шулай... Минем кадерле әнием Фәридә дә Идел болгарларының ерак оныклары яши торган бүгенге Татарстан җирендәге Төгәлбай дигән гаҗәеп матур исемле татар авылыннан булган... Тик монарчы шул авыл туфрагына кайтып баш иярга генә насыйп булмады... Татарстан дигәннән... Казан артында гына ар халкы исемен йөрткән Арча районы бар. Синең фамилияң дә әнә шул төбәк исеменә бәйле түгел микән әле?

—Менә ниче-е-ек...

—Шулай, матурым!

Шулчак Соня Арова, ничектер, чытлыкланып куясы итте:

—Юк, Рудик, миңа бүтән һич алай дип дәшмә!

—Ничек дип?

—Матурым дип.

—Ә нигә?

—Чөнки мин үземә бер дә алай матур түгелдермен кебек.

—Ничек инде алай булсын?

—Ник... Балет тәнкыйтьчесе Ричард Бакл да күптән түгел бер мәкаләсендә әнә шулай язган иде.

—Ничек язган?—дип төпченүен дәвам итте Рудольф.

—Арованың, классик балет биючесе буларак, бар яклары да килгән. Тик менә йөз-кыяфәте генә классик түгел дигән.

Рудольфның йөзе кинәт салаттагы чөгендер төсенә керде:

—Китче!.. Димәк, безнең төрки-татарлыкка төрттергән булып чыга, алайса?

—Шулай, Рудик.

—Аһ, сыбулыч!.. —дип пышылдады Рудольфның кан качкан иреннәре.

Ул бераз гына үрелә төште дә, Арова янәшәсендә утырган Ричард Баклның симез беләгеннән келәшчәдәй эләктереп алды:

—Ә хәзер минем арттан кабатлагыз, мистер Бакл!

—Йә.

—Безнең Сания Арова шундый чибәр.

—Безнең Сания Арова...

—Аның классик төрки йөзе нәкъ менә классик балет өчен яратылган!

—Аның классик төрки йөзе...

—Һәм бу хатагызны бүтән кабатлыйсы булмагыз!

—Баш өсте, мистер Нуриев!

Өстәл астыннан гына зәһәр пышылдашып һәм күз ачып йомганчы булып

алган бу сөйләшүне мәҗлестә утыручылар бөтенләй ишетми, сизми дә калды бугай. Ә менә күзләренең чите белән генә Рудольфның һәр хәрәкәтен, һәр кыланышын җиз иләк аша уздырып утырган Нинетт де Валуа игътибарыннан яшь йолдызның әле генә булып алган мактаулы гамәле читтә калмады:

—Рәхмәт, мистер Нуриев!—диде ул, янәшәдә утырган Рудольфның ике кулыннан кысып.

—Ә ни өчен, миссис Валуа?

—Кирәк чакта ярдәм хезмәттәшегез һәм үзегезне нахак гаепләрдән яклый белүегез өчен!

Король балеты башлыгының Рудольф турында бер кузгалган сүзне инде туктатып калдырасы килмәде:

—Мистер Нуриев!—диде ул җитди тавыш белән.—Безнең театр сәхнәсендә Марго Фонтейн белән киләчәктә парлашып бию мәсьәләсенә ничек карыйсыз?

—Фонтейн?.. Фонтейнның хәтта үзе белән?!—дип кабатлап сорады Рудольф, үз колакларына үзе ышанып җитмичә.—О-о... Мин моңа иң зур, иң татлы хыялларымнан берсенең тормышка ашуы диячәкмен!

—Рәхмәт... Сездән мин нәкъ менә шундый сүзләр әйтүегезне көткән идем дә.

Нинетт де Валуа, Рудольф җавабыннан канәгать калуын белдереп, инде берән-сәрән җыерчыклар төшә башлаган, ләкин әле һаман төз күренгән озын муенындагы ап-ак мәрҗәненең затлы төймәләрен төзәтеп куйды һәм, Нуриев белән киләчәктә бергәләшеп биюдә Марго Фонтейнның күңел кылын тартып карарга теләп, сул ягына борылды:

—Марго дим... Мин бүгенге концерт сәхнәсендә гел икегезнең биюен күз алдына китереп утырдым бит әле. Кем беләнме? Рудольф Нуриев белән! Әйтик, ул—принц Альберт, ә син—Жизель булып.

Бу турыда ишеткәч, әле һаман һуштан яздыргыч гүзәллеген саклый алган Марго Фонтейнның бриллиант алка җемелдәшкән нәфис колак яфракларына кызыл таплар йөгерде:

—Мин?.. Бер аягы сәхнәдә, икенчесе инде пенсиядә булган кырык ике яшьлек биюче һәм... егерме өч яшен яңа тутырган Рудольф Нуриев? Карт сарык белән аның яңа туган бәрәне биегән кебек булмасмы соң бу? Юк, юк! Әйтмәгез, үгетләмәгез дә!

Башта әнә шулай теше-тырнагы белән каршы килеп караган иде дә, театр директоры һаман үгетләүдән туктамагач, моңа өстәп, яшь йолдызның да ризалыгын белгәч, Марго Фонтейн гаҗәеп ымсындыргыч бу тәкъдимгә күнми кала алмады:

—Ярый соң, алайса... Тик бер шарт белән!

—Нинди шарт ул, Марго?

—Башта «Жизель» балетында гына биеп карыйбыз. Үзегез әйткәнчә, ике төрле холык, ике кайнар йөрәк, ике саф сөюдән дөрләп ут кабынмаса, шуның белән вәссәлам! Хуш, балет, хуш, сәхнә диясе генә калыр.

—Менә-менә... Мин нәкъ шуны теләгән идем дә! Курыкма, Марго һәм ышан миңа: әле синең күңел сандыгыңда шашып сөю, шашып ярату дигән һәм монарчы бөтенләй татып каралмаган затлы хәзинә ята! Моны сиңа мин—ундүрт яшьлек Пегги Хукхэмны атаклы Марго Фонтейнга хәтле үстерешкән Король балеты башлыгы Нинетт де Валуа әйтәм!

*Ахыры киләсе санда*



Клара Булатова

# ДӨНЬЯ ТУЛЫ, ЮКСА, УМЫРЗАЯ...

## Яз язлыгын итә

**Яз язлыгын итте.**
**Кай арада**
**Учлап кояш сипкән шикелле**
**Алтынсулар сары умырзая**
**Иңкүлекләр тулып тишелде.**

**Өзмә, өзмә, өзмә, өзә күрмә!**
**Алар шундук сула, карала.**
**Тик бер сулыш алар яши җирдә,**
**Тимә, тимә, тимә аларга.**

**Яңа шыткан бәпкә яктылыгы**
**Без—беркатлы җиһан баласын**
**Бар, дип, җирдә көннең чиста нуры**
**Хет бер язга тагын алдасын.**

**Болай да, күр, әллә кай арада**
**Җаныбызның мөһере кителде...**
**Дөнья тулы, юкса, умырзая—**
**Учлап сипкән кояш шикелле.**

***

**Куркам телевизор кузгатырга,**
**Куркам радионы ачарга:**
**Мизгел саен афәт бу гасырда,**
**Җаным белми кая качарга.**

**Көн-таң атса илдә яман хәбәр,**
**Бу дөньяга нәрсә булган соң?**
**...Без нишләдек әле моңа кадәр?**
**Без нишләрбез—инде моннан соң?**

Клара БУЛАТОВА—*шагыйрә; «Язлар алда», «Әрнү», «Яшел каләм» һ. б. китаплар авторы. «Татнефть»нең С. Сөләйманова исемендәге премиясе лауреаты. Әлмәттә яши.*

## Әй, дөнья, кая барасың?

Әй, дөнья, кая барасың?
Мин бит сине кумадым.
Әй, гомер, кая агасың?
Мин бит синнән туймадым.

Дөньяның борылышына,
Ияреп китә алмадым.
Гомерем буе менәр үргә
Менеп җитә алмадым.

Әй, заман! Мине генәме
Уртәде ялганнарың?
Мин нәрсә?—Җанны телгәли
Халыкны алдаганың.

Әй, өмет! Нигә сүнәсең?
Синең яктың югалгач,
Илһамнан берни калмас ич,
Йөрәктә җыр туа алмас.

Әй, үлем! Кемгә тиясең?—
Акылыңнымы җуйганың!
Җырымны ни дип өзәсең?
Мин бит җырлап туймадым.

Әй, гомер! Нишләп китәсең?
Уткәнеңне тоймадым.
Никләргә ашыгып үтәсең?—
Мин бит яшәп туймадым.

* * *

Данны бурычка да алып булмый,
Һәм биреп тә булмый әҗәткә.
Безгә заман шуны бирә алган,—
Түләсәк тә, түләмәсәк тә...

* * *

Кем кайлардан кайчан ни эзләгән,
Кем бөтенләй эзләп тә йөрмәгән.
Тапкан җаннар бәлки ярлырактыр
Эзли белә торган күңелләрдән?!.

* * *

Уянасы гына калмагандыр!—
Җанда төштән калган өнең әле...
Күрер төшләремдә булса да бер
Син яңадан килеп күрен әле!

## Борчулы җәй

Ялгызыма кайгы килсә
Уртаклашам мендәр белән.
...Бу бит илгә, көнгә килгән!—
Борчылмыйдыр кемнәр генә.

Гел Тукайдан алынгандай
«Кыза дөнья, сабыр җитми».
Бит сабырлык җитсә генә
Өмет сүнми, тамыр кипми.

Тамырларны корытырлык
Хата ясап куйдыкмы әллә?
Шуның белән табигатьнең
Сабырлыгын җуйдык мәллә?

***

Һичнәрсә җиңмәс газабын
Мин генә күрәм аның:
Йөзләре елмайганда да
Күзләре сүрән аның.

Маңгай күзләре коры да—
Күңеле дымлы аның.
Күзләре еламаса да
Йөрәге елый аның.

***

Эчкәйләрем тулы—чыкмый тавышым,
Яңгырый җырым уйламаганда...
Булганда да булмый кала кавышу,
Җаннар кушыла—булмаганда да...

Юкны куып күпме җан сызгандыр,
Үлчәүләргә сыймый сызланган.
Узган гомеремне, юк, кызганмыйм,
Булмас өстәмәсен кызганам:

Өстәмәдән, һай, баш тартмас идем,
Алыр идем, өстәп яз гына!..
Тартып яшим күпме йөрәк йөген—
Сыңар гомер генә аз миңа.

***

Ул чакларда син гел бүтән идең.
Итәк җилең килеп тиюдән
Фәрештәләр азып җиргә иңде,
Бөтен диндар язды дененнән.

Барысы да нидер өмет итеп
Өерелеп йөрде артыңнан.
Тота алмадылар.
Кемне көтеп
Кире кага килдең барсын да?

Бүген нәрсә?
Сүзсез буйсынасың
Ымлавына надан берәүнең.
Гаҗәпләнәм: син соң үзеңдәге
Сихри көчне кая җирләдең?

...Яшь чакларда син гел башка идең,
Охшамаган идең бүгенгә...—
Моңсу булып китте
курка-курка
Сине сөеп йөргән күңелгә.

***

Тургайлы яз, былбыллы җәй үтә,
Торналар да китәр тезелеп.
Язлар килсә тургай, җәйләр килсә
Былбыл кошлар идек без элек.

Шагыйрь җаны мәңге картаймый, дип
Шагыйранә сүзгә алданып,
Табигатькә тәңгәл яшәдек бит:
—Безнең язлар әле алда,—дип.

Без яшьлекне уйнап кына түгел,
Уен уйлап, эшләп уздырдык,
Йөрәк маен, күңел назын биреп,
Җан кузгатыр җырлар тудырдык.

... Язлар саен тургай сайрар тагын,
Җәйләр саен сайрар былбыллар,
Үзләребез калдырсак та язны,
Яшәп калсын иде бу җырлар.

Тургайлы яз, былбыллы җәй үтәр.
Торналар да китәр көзендә.
Кайберәүләр онытса да ... күпләр
Сагынырлар әле безне дә!..

***

Мәңгелектә күпме җинаять,
Мәңгелектә күпме хыянәт—
Синең гомер җирдә бер мизгел:
Ул мизгел дә олы языктан,
Гөнаһлардан һич азат түгел.

Кыска гына шушы гомердә
Күпме хата кылдың бу җирдә.
Тәүбә китер,үкен-үкенмә—
Шул көенчә керерсең гүргә.

«Бөкерене кабер төзәтә»—
Дисәләр дә, белмим, икеле.
Тураймаган, әнә, үлгәч тә,
Табутта да шайтан бөкере.



Әнәс
Хәсәнов

# ӘНИС АЛМАЛАР

ПОВЕСТЬ

*Хөрмәтле укучым!*

*Әгәр дөньяда олы мәхәббәт яшәвенә ышанмасаң, укыма син бу әсәрне... Көнеңә-төнеңә кояш бүләк итеп, җаныңа канат-куәт биреп, күңелеңә сандугач оялатып, гомер юлларыңда очып кына йөрергә көч биргән, изге, ләззәтле, шатлыклы саф мәхәббәткә ышанмасаң, якты дөньяда татлы, газаплы, җаның-тәнеңне сулкылдатып, хыял белән чынбарлык чикләрен юып, эш-гамәлеңдә рәхимлеккә, шәфкатьлелеккә, яктылыкка, югарыга өндәгән мәхәббәт булуына ышанмасаң, укыма.*

*Яшьме, картмы син, кызмы-егетме, әгәр дә кайчан да бер синең бөтен барлыгыңны кайнар сөю хисе җырлаткан, елаткан, зарыгып сагындырган, җирдән йолдызга чөйгән булса—укы.*

*Автор*

## 1

Алмагач яфраклары җылы җилдә әкрен генә тирбәлеп кыштыр-кыштыр серләшәләр. Бакчада хуш ис—өлгергән алма исе анкый. Сәрби кузаклары четердәп ярылып китә дә коры орлыклар җиргә коела. Башка вакытта кош-корт аларны чүпләп кенә торыр иде, тик балаларын канатка күтәреп, инде тынычланган кошлар тук, исләре китми, канат-йоннарын, томшыкларын чистартып яфраклар арасында үзләре генә белгән шөгыльләре белән мәшгуль.

Әнис белән Илгиз икенче курс өчен дәреслекләр алырга училище китапханәсенә килгәннәр иде. Чиста, саф һава тәэсиреннәнме, таш бинага кергәнче бераз алма бакчасындагы урындыкта утырып торырга ниятләделәр. Җылы, рәхәт. Зәп-зәңгәр күктә ап-ак болытлар йөзә.

---

Әнәс ХӘСӘНОВ (1935)—*прозаик, шагыйрь, тәрҗемәче; «Җырым—ал җилкән», «Минем сандугачларым», «Кояшлы яңгыр», һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

—Авылда бәрәнге ала башладылармы икән? Һава шулай коры торганда...
—Юктыр әле, Илгиз. Иген җыелып бетмәгәндер.
—Кайтып булышасы иде дә бит. Дәресләрне калдырырга ярамый шул. Рөхсәтсез киттенме, Сафа абый каршына барып басасыңны көт тә тор. Әнис, сагынасыңмы, малай, ә? Авылны дим.
—Быел алай ук үзәк өзелерлек түгел. Ияләшенә, күрәсең... Үткән е-ел!
—Ә мин һаман сагынам. Әле менә авыздан авылның сөтле аш тәме китеп тә бетмәгән, ә йөрәк пәрәвезгә эләккән күбәләк мени...
—Авылда кемең калды соң синең, Илгиз?
—Әни. Әнием. Күзләре бик начарланды. Әтинең үлгән хәбәре килгәннән бирле күзеннән яше кипми. Ничәмә-ничә ел бит инде.
—Бик яраткандыр, күрәсең.
—Үзе дә шулай ди.
—Бер карасаң, гаҗәпләнерлек, сокланырлык бит. Кешене кеше шулай яратсын әле, ә! Нинди була икән соң ул андый ярату?

• • •

Әнис белән Илгиз бу әңгәмәләрен хәзер еш кына искә алалар. Аннан соң бер ел вакыт узса да. Һәм нинди ел диген әле. Икесенең дә яшьлек елларын кинәт килеп чыккан давыл сыман айкаган ел. Яшь күңелләренә тәүге кайнар сөю хисе килеп тулган ул ел әнә шул кояшлы, җылы, матур, алмалы сентябрь көнендә башланды. Һич көтмәгәндә-уйламаганда онытылмас вакыйгалары белән мәңгегә хәтергә уелып калды.

## 2

Әнис тоткага кулын куйган гына иде, ишек кинәт ачылып китте дә аннан көлешә-көлешә берничә кыз килеп чыкты. Моны киного төшерүче булса, ул Әниснең артка чигенеп, кызларны уздырып җибәргәч, кинәт кенә зур итеп ачылган күзләрен, гаҗәпләнгән йөзен эре планда озак кына күрсәтеп торыр иде.

Кызлар училище капкасыннан кереп киттеләр. Әнис ишек төбендә басып торды-торды да баскычка утырды. Үзен китапханәдә Илгиз көтеп торуын да онытты. Яныннан яшь егетләр, кызлар тыз-быз килеп кереп-чыгып йөрде. Училищега яңа кергәннәр кыяр-кыймас кына, тирә-якка карана-карана сак кына уздылар. Өлкән курсныкылар шап-шоп басып, ике-өч баскычны сикереп кенә төшеп киттеләр. Әнис һаман утыра бирде. Аның күз алдында әле дә теге кызлар төркеме уртасындагы калын толымлы кызның ап-ак йөзе балкып тора иде. Ул кызның күзләре урман аланындагы күкчәчәк кебек зәп-зәңгәр булып, үзләреннән бу дөньяда яшәү бәхете, яшьлек, сәламәтлек бәхете очкыннары чәчрәп тора иде. Кызның карашы Әнис йөзеннән битараф шуып кына узды, ә менә яшь егетнең күкрәк читлегендә кайнар ут кабызырга җитә калды. Ул уттан бөтен күкрәктә әллә нинди ләззәтле, очасы, йөгерәсе килү хисе таралды. Бу хис Әнискә бераз таныш иде. Урманга, болынга баргач кып-кызыл җиләк баскан аланга килеп чыкканда нәкъ шундый хис туа, тик бу юлы ул кайнаррак, куәтлерәк, ләззәтлерәк иде. Шул көннән бирле Әнис юньләп ашау-эчүен дә онытты, йокысы качты. Дәресләрдә әллә утырды, әллә юк. Карашы каядыр еракка юнәлгән, кая карамасын, анда теге кызның ак йөзе, зәңгәр күзләре балкып торды, юан чәч толымнары чайкалды. Ул укытучыларның:

—Әнис, сиңа ни булды? Игътибарсыз утырасың. Мин әле генә нәрсә турында сөйләдем?—дип соравын да ишетми иде. Андый чакта күршесе Вәгыйз Әниснең терсәгенә төрткәч кенә, ул айнып китә дә:

—Гафу итегез, ишетмәдем шул,—дип җавап кайтара.

—Моннан соң дәрестә игътибарсыз утырма,—дип кисәткәч, Әнис чынбарлыкка әйләнеп кайта да гаҗәпләнә иде. «Мин дәрестә икән ләбаса. Тагын уйга талганмын. Тынлап утырырга кирәк ич».

Дөньяда һәр нәрсәнең чиге була. Ниһаять, Әниснен дә чәбәләнеп беткән уйлары шактый вакыттан соң гадәти эзгә төшә башлады. Күкчәчәктәй күзле, көләч йөзле бу кыз минем күнелемне юкка гына биләмидер дип уйлады ул. Аның мондый хәл турында укыганы бар иде. Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романында Галим Урманов та нәкъ шундый ук хисләр кичергән ич.

Тәнәфесләрдә Әнис ул кызны читтән генә күрә иде. Ятимнәр йортыннан килгән кызлар арасында йөргәнгә, Әнис аның да ятимә икәнлеген белә. Андый кызлар, егетләр бер үк төрле киемнән йөриләр. «Күкчәчәк күз» дә нәкъ шулай, әти-әнисе юктыр, күрәсең. Бу уй исенә төшкән саен аның йөрәге кысылып-кысылып куя. Әй, шул кызның башыннан гына сыйпыйсы иде!

Көннәрдән бер көнне Әниснең бәхете басты. Ул зәңгәр күзнең исемен белде. Училищеның бик матур алма, яшелчә бакчасында әллә ничә сортлы алма үсә, уныш җыйган көннәр училищеда үзенә бер күнелле бәйрәмгә охшап кала иде. Андагы алма исе! Баллы хуш истән башлары әйләнепмедер, умарта кортлары, шөпшәләр өерләре белән очып йөриләр. Бакча укучылар тавышыннан гөрләп тора. Ул көннәрдә яшьләр белән бергә укытучылар да эшли, кара куе бөдрә чәчле, мәһабәт гәүдәле училище директоры үзе дә алма тулы әрҗәләрне арбага төяргә булыша, шаяртып та ала, яшьләр сүзенә кушылып бәхәсләшеп тә куя. Аның шундый гадилеген укучылар да, укытучылар да ярата. Хәер, аны шәһәрдә белмәгән, ихтирам итмәгән кеше бармы икән? Алай гына түгел, район үзәгенә эш белән килгән авыл кешеләре дә аны урамда танып:

—Исәнмесез, Нәсихов абый, сау-сәламәт яшисезме?—дип, әллә каян каршына чыгалар.

Педагогия училищесының даны бөтен республикага таралган иде шул. Ә аның белән озак еллар буена мәгариф отличнигы Сафа Нәсихов житәкчелек итте.

Һәр эшкә куллары ятып торган авыл егетләре-кызларына алма җыю эшмени ул. Ә мондый күмәк эшне әйткән дә юк. Директор, укытучылар алдында бигрәк тә. Быел алма бик мул булып унган, укучылар аны әрәм-шәрәм итми, бәрми-сукмый, сак кына өзеп, әрҗәләргә тутыралар, аннары складка киштәләргә илтеп куялар. Кышка хәтле ашарга да, кышын ашханәдә компот кайнатырга да житәчәк бу кадәр алма. Әнә директор үзе шулай ди.

Ерак түгел иптәшләре белән теге кыз да баскычка менеп алма җыя. Әнис аны күзе белән генә түгел, йөрәге белән күрә. Әй, ул кызның көлүләре! Көмеш кынгыраумыни! Бу тавыш Әнис күңеленең әллә нинди почмакларына үтеп керә. Егет борылып карый да әрҗәсен күтәрергә оныта. Ул арада Илгиз:

—Әнискә бу әрҗә авыр булды, ахрысы. Әйдә, үзем җилкәнә күтәреп куйыйм әле,—дип әрҗәгә тотына.

Әнискә шушы әрҗә авырмы? Тирә-юнендәге курсташлары алдында кешедән күтәртәме! Ул әрҗәне жирдән йолкып алгандай өскә чөя, тик тигезлеген югалта, чайкалып, әрҗәсен чүт кенә төшереп җибәрми. Алмалар җиргә коела. Кемдер көлә. Кызлар «ах» дип укытучылар ягына карап алалар. Әнис башын күтәрергә оялып, жирдән алма җыя башлый. Аның бит очлары кулындагы алмалардай кызарып чыга. Башында һаман бер уй бөтерелә: теге кыз да күрдеме икән? Ә укытучылар ни әйтер?..

Тәҗрибәле рус теле укытучысы Ләйлә апалары Әниснең хәлен аңлый:

—Зарар юк, укучылар, саграк кына булырга кирәк,—дип киеренкелекне юк итә.—Алмалар бозылмас, йомшак җиргә коелды ич.—Әнис рәхмәтле елмая, аның күкрәген баскан авыр таш эреп юкка чыга.

Шул мәлне якында гына алма җыючы кызларның ачы итеп кычкырганы ишетелде. Теге күкчәчәк күз үрелеп алма алганда баскычы авып киткән икән, ә үзе ботакка асылынып калган да:

«Ярдәм итегез!»—дип кычкыра иде. Моны күргәч Әнис шул якка томырылды. Башка егетләр дә ярдәмгә йөгерделәр. Ә бакыр чәчле Идмасны гына күр әле! Барып та җитте, тиз генә баскычны торгызып та куйды. Менде, кызны күтәреп баскычка бастырды, кулыннан тотып төшәргә булышты. Кызларның кайсыдыр:

—Әнисә, кулын сыдырылган ич, әйдә, йод сөртик,—дип кызны училище медпунктына алып китте.

Әнис, дөрес ишеттемме икән дип, тирә-ягына каранды. Әнисә диделәр түгелме? Әйе шул. Исеме Әнисә икән, алайса. Ничек була соң инде бу? Ул үзе Әнис. Кызык. Әнис менә бер шатланды, бер гаҗәпләнде. Гаҗәп шул. Ничек туры килгән. Әнис—Әнисә. Хәер, бу дөньяда әти-әниләре охшаш исем кушкан кешеләр аз мени? Тик исемнәре охшаш кешеләрнең менә шулай очрашуы аңысы инде аның бер Ходай эше. Димәк, бу кыз Әниснең адашы була.

Шул ук вакытта Әниснең йөрәген әллә каян пәйда булган икенче уй тырнап өлгерде. Нишләп Әнисә янына ин алдан ул үзе түгел, ә бакыр баш Идмас барып җитте? Өлгеррәк булса, Әнисә Идмаска түгел, ә Әнискә рәхмәт әйткән булыр иде. Ә шулай да егетнең күңеле күтәренке иде. Күкчәчәк күзнең исемен белде бит ул. Әнисә диген, ә!?

### 3

Әнис Әнисәне ялгыз гына очратырга бик озак җай эзләп йөрде. Үзе бу бәхеткә ирешсә, ничек сүз кушасын, нәрсә әйтәсен дә белми иде. Шуна күрә Әнисәне ялгыз түгел, ә дус кызлары арасында күргәч, шатланып та куя.

Октябрь бәйрәменә училище ныклап әзерләнә. Укучылар демонстрациягә чыгып, райком бинасы каршыннан узалар. Анда аларга Ленин һәйкәле төбендә басып торган район җитәкчеләре кул болгый, кемдер радиодан:

—Педагогия училищесы студентларына сәлам!—дип кычкыра. Үзләрен «студент» дип атагач, горурланып, яшьләр бөтен урамны яңгыраталар:

—Ур-р-а-а!

Бәйрәм алдыннан училищеда зур концерт була. Рус бүлеге чыгышын татар бүлеге карый, татар бүлегенекен—руслар. Музыка коралларында уйнарга өйрәнүчеләр, ялгыз җырлаучылар дер-дер килеп үз чиратын көтә. Аннары биюләр. Ак кофта кигән, ак алъяпкыч япкан кызларның, галстук тагып җитдиләнеп киткән егетләрнең шау-шуыннан актлар залы гөрләп тора. Ни итсән дә бәйрәм, ни итсән дә яшьлек бит.

Быелгысы Әнискә икеләтә бәйрәм булды. Оркестрда берничә әсәр уйнап сәхнәдән төшкәч, Әнис алдагы рәтләрнең берсендәге буш урынга барып утырды. Утырган гына иде, күршесендәге кыз:

—Бу урын буш түгел,—дип пышылдады.

Әнис кызга борылып караса, янәшәсендә Әнисә иде.

—Бу минем дустым урыны. Әнә үзе килә,—диде ул.

—Егеткәй, бушатыгыз әле минем урынны,—дигәч, Әнис янында басып торган рус кызына күтәрелеп карады. Торырга гына онытты.

—Нәрсә, егеткәй, күргәнең юкмы әллә? Шул кадәр текәлеп торасың?—

Әнисә Әнискә карап көлеп җибәрде. Әнис шунда урынлы-урынсыз:

—Син Әнисә бит. Ә мин Әнис,—дип пышылдады да, торып китте.

Бу көннән соң ул шактый вакыт канатланып, ниндидер эчке рәхәтлек тоеп, әллә нинди үзгәрешләр көтеп йөрде. Әйтте бит ул үз исемен күкчәчәккә, әйтте. Димәк, таныштылар. Тик үзгәреш кенә булмады. Әнисә иптәш кызлары белән әле китапханәдә, әле коридорда сирәк кенә очраштыргаласа да битараф кына уза бирде. Әниснең андый көннәрдә бигрәк тә җаны кыйналды. Ничек инде танышканнан соң да ул аңа борылып та карамый? Әллә бар аңа Әнис, әллә юк. Хәер, ул хаклыдыр да. Шундый матур кыз игътибар итәрлек кем соң ул? Кием-салымы ташка үлчим. Училищеда Сафа абый урнаштырган нык тәртип хөкем сөрә. Ямаулы киеменне тулай торакта кисәң ки, ә училищеда гади генә булса да үтүкләнгән костюм-чалбардан йөр. Күлмәгең һәрчак чиста, юылган булсын. Муеныңа галстук—мәҗбүри. Аяк киеме турында әйткән дә юк. Ул һәрвакыт чиста булырга тиеш. Вакыт-вакыт директор яз дими, көз дими, ишек төбендә үзе басып тора, өс-башыңны, аяк киеменне тикшерә. Бар теләге—булачак укытучыны пөхтә киенеп, чиста йөрергә өйрәтү.

Балалар йортыннан килгән ятимнәрне училище ашата-эчертә, киендерә. Моны тәрбиячеләр игътибар үзәгендә тота. Аларның киемнәре әнә нинди матур. Җылы йон свитерлары гына да ни тора.Тererәк егетләр тәрбиячеләрдән өс-башларын яңартып торуны үзләре үк таләп итә. Тиешме—бирегез! Ә Әниснең нәрсә? Узган ел яз көне юл өзегендә ул училище коридоры буйлап кызыл эчле зур галош сөйрәп йөрде. Тула оегын салгач моны күргән кызлар бик мәгънәле итеп бер-берсенә карап калалар иде.

Ярый әле, быел аңа әти-әнисе зур авырлык белән ботинка, яңа чалбар, күлмәк алып бирә алдылар, сарыкларын сатып. Юк инде, юк, аның өс-башы ятимнәрнекеннән бик калыша. Житмәсә, кара куе чәче түбәсендә тырпайган. Сулап тарасаң да һаман шул. Озынрак йөртсәң ята ятуын, тик рөхсәт юк. Син—булачак укытучы!

Соңгы вакытта Әнис үзенең куе кара кашларын башкаларныкы белән чагыштыра да кәефе кырыла. Башкаларның әнә сызып куйганмыни! Ә аның тоташып үскән диярсең. Дөрес, тешләре тип-тигез, ялт иткән. Бу борын тагын. Нәкъ кызларныкы. Ир кеше борыны тотрыклы, күзгә бәрелеп торырга тиеш диләр. Ә ияген чокырлы булырга. Бугаз төене нинди калку житмәсә. Ашаганда аска-өскә уйнаклап тора. Күзләргә килгәндә—гел мәсхәрә! Әле соры, әле яшькелт төскә керә. Ир буласы кешедә шундый күз булсын инде, әй! Әнисә ана игътибар итәме соң. Аның күзләре—күкчәчәкләр. Эх!

Кая гына бармасын, ни генә эшләмәсен, аның күз алдында һаман Әнисә. Алтынсу толымлы күкчәчәк күзле Әнисә. Аңа игътибарсыз чибәр Әнисә. Йә, күпме йөрергә була инде болай? Юк, ничек тә күрергә, сүз катып карарга кирәк үзенә. Менә шул!

## 4

Күрде ул аны, күрде. Күрмәсә яхшырак та буласы икән. Училищеның физкультура залы янынннан үтешли, Әнис анда шау-гөр килгән тавышка игътибар итте. Егетләр, кызлар көлешә-көлешә нидер сөйләшә иде. Әнис ишекне ачып залга күз салды. Анда... анда... трусик-майка гына кигән бер төркем егетләр, кызлар Әнисәнең калын чәч толымнарын башына чорнап маташалар иде. Берсе:

—Бәйләргә кирәк, бәйләргә. Чәчең сиңа сикерергә дә, мәтәлчек атарга да комачау итә,—ди. Икенчесе:

—Бәлки, кистерергәдер. Ярышлар житә. Ә безнең әле һаман ике-өч күнегү өйрәнеп бетергәнебез юк,—ди.

Әниснең курсташы Марс аның ишектән карап торганын күргәч:

—Әнис, әллә син дә безнең акробатика түгәрәгенә керәсеңме? Уз, әйдә,—диде.

Барысы да Әнискә борылып карадылар. Әнисә дә.

—Юк, юк!—Әнис каушап тиз-тиз ишекне япты да китапханәгә менеп китте. Кирәкле китаплар алып, уку залына кереп утырды. Укыса укыды, укымаса—юк. Аның күз алдында һаман баягы күренеш иде: егетләр, кызлар Әнисәне сарып алганнар да бөтерелепме бөтереләләр. Тукта, нишләп ул укуга бирелеп шундый эшләрдән, түгәрәкләрдән читтә йөри соң әле. Дөрес, училище оркестрына язылып, альтта, контрабаста ару гына уйнарга өйрәнде. Бәйрәм кичәләрендә әнә ничек шәп уйныйлар. Юк, болай булмый бу! Аны бит чаңгы түгәрәгенә язылырга чакырганнар иде. Тик анда күнекмәләр еш кына ял көненә туры килгәнгә ул риза булмады. Язылса да йөри ул моннан соң. Күнекмәләргә дәрестән соң, кичләрен дә чыгарга була ич. Авылга да чаңгыда кайтып-килеп була. Бу да күнекмә ләбаса. Нинди генә әле.

## 5

Ул елны май бик җылы килде. Егетләр бушрак вакыт табып, Бизнә елгасына су коенырга баргаладылар. Елга училищедан ерак түгел матур бөдрә таллыкларны аралап ага иде. Егетләр аның тирән урынын беләләр, шактый биек басмадан сикереп чумалар, кайчакта су астыннан йөзү буенча үзара ярышып та алалар иде. Вакыт-вакыт монда шәһәр балалары да килеп су керә, аларның чыр да чу килеп коенуларын, уйнауларын карап тору үзе бер күңелле иде.

Көннәрнең берендә Әнисләр комда кызынып, шәһәр малайларының басмадан сикереп уйнаганын карап ятканда кием-салымы белән ун-унике яшьлек бер малай суга егылып төште. Ул сикерергә җыенган иптәшен сизмәгәндә артыннан килеп этеп төшерәм дигәндә генә тегесе алданрак сикерде. Шаян малай туктала алмыйча аның артыннан ук үзе дә суга чумды да куркуыннан бата башлады. Аның тончыга-тончыга: «Ярдәм итегез»,—дип кычкыруына Әнис суга ташланды. Авырлык белән булса да коты алынган малайны тирәннән алып чыгып, сай җиргә бастырды.

Берничә көннән училищеда иртәнге музыкаль зарядка беткәч, барлык укучылар алдында директор Әнискә рәхмәт әйтте, чын егетлек менә шундый була ул дип мактап алды. Бу эш директорга ничек мәгълүм булгандыр, Әнис моны белмәде. Ул шунысына шатланды, инде училище кызлары ана елмаеп уза башладылар. Әнисәнең күкчәчәк күзләре белән елмаюы Әнисне аеруча куандыра иде.

Май аеның соңгы матур көннәрендә училище укучыларын Чулман култыгы яры буена бик зур баржадан утын бушатырга алып чыктылар. Училище утын белән җылытыла иде.

Баржаны бушатырга бер генә көн бирелгән икән. Чулманга каләр алты-җиде километр юл барасы, ана чаклы шәһәр кырыеннан ук аккан Бизнәне кичәргә кирәк иде. Менә шунда инде Әнискә бәхет кояшы елмайды. Ул көймәдә йөри белә, биш-алты кешене утырта да елганың аргы ягына чыгарып куя. Аннары кире килә. Әнискә шул хәтле рәхәт, чөнки чират көтүчеләр арасында Әнисә дә бар. Кызлар чыр-чу килеп сөйләшәләр, Әнис бар көченә ишә дә ишә. Бу бәхетле минутларның ул озакка сузылуын теләи. Күкчәчәк аның бу якка чыгып җитәр алдыннан көймәне зырылдатып борып, яр кырыена койрыгы белән оста итеп китереп туктатканын күрә. Яшьләр кереп утыргач, көймәне берәрсе этеп җибәргәнне дә көтми, Әнис янә ишә башлый.

Егет Әнисәнең яр кырыенда озаграк торуын теләи: менә күреп торсын әле Әниснең осталыгын! Ниһаять, Әнисә дә иптәш кызлары белән көймәгә кереп утырды. Әнис янә ишкәкләргә ябышты.

—Әнис, сине егетләрнең берәрсе алыштырсын иде. Тирләп-пешеп чыккансың бит. Арыгансыңдыр. Ишә белүчеләр бардыр бит!

Укытучы апаларының бу сүзенә Әнис:

—Юк-юк, Ләйлә апа, арымадым,—дип ишүен тагын кызулата төште. Аннары көймәдән чыгучыларга ярдәм итте. Әнисә ярга чыгарга гына торганда аннан алдан сикергән кыз көймәне чайкалдырып җибәрде. Әнисә «әни!!!» дип куркып калды. Әнис сикереп торып аңа кулын сузды, ярга чыгарга булышты. Әнисә, елмаеп, рәхмәт әйтте. Күкчәчәк күзнең кул җылылыгыннан рухланып Әнис тагын иште дә иште. Соңгы укучыларны көймәдән төшергәндә ул уч төпләренең кызып әрнегәнен тойды. Аның ике кулы да берничә урында чикләвек зурлыгында кабарып чыккан иде.

Укучылар көне буе эшләп баржаны кичкә бушатып бетерделәр. Ул арада кара төтеп бөркеп килгән буксир баржаны алып та китте. Яр буенда әрдәнә-әрдәнә утын өелеп калды. Алгебрадан имтиханга ике көн кала Әниснең кулы бик каты сызлый башлады. Кабарган урыннарын каләм очы белән тишеп агызгач, сызлау тынып торган сыман булды, ләкин бераздан уң кул кызарып шешә башлады.

Авыртуга түзә алмыйча Әнис ишекле-түрле йөрде. Ятты, торды, стаканга салкын су салып, бармакларын шунда тыгып җиңеллек эзләп карады. Төннәрен аңа аеруча авыр булды. Малайлар йоклый, ә аны йокы алмады. Шулай бимазаланган бер көнне кичен вакытлы-вакытсыз йокыга талды. Шул чакны тулай торак бүлмәсенә профсоюз бюросы әгъзалары килеп керде. Йоклап яткан Әнисне күргәч алар гаҗәпкә калды. Арадан берсе:

—Нишләп әле ул бу вакытта йокы симертә?—дип, кашын җыерып, аның янына ук барып басты. Малайлар хәлне аңлатып бирделәр. Бюро әгъзалары моны ишеткәч табибка күрсәтергә кирәк дип Әнисне уятырга тотындылар. Әнис аңгы-миңге килеп торып утырды да берни аңламый кызларга текәлде. Алар арасында читтәрәк басып торган Әнисәгә күзе төшкәч, сикереп тормакчы иде, кулы караватк кырыена бәрелде. Аның күзләреннән утлар чәчрәде, күпереп шешкән кулның авыртуына түзә алмыйча бөгелеп төште. Кызлар аһ итеп аны сарып алдылар.

—Кая, күрсәт әле!

—Нишләп табибка бармадың?

—Малайлар, ә сез ни карадыгыз?

—Җаныкаем гына, ничек түзәсең, ә?

Монысын Әнисә әйтте. Ул Әниснең кулын әйләндереп-әйләндереп карады. Хәзер үк шәһәр хастаханәсеннән табиб чакырырга кирәк иде. Ул арада Илгиз чыгып йөгерде.

Нечкә күңелле Әнисә һаман такмаклады:

—Миленький, ничек болай булды соң бу? Ничек түзәсең?

Әнисне дәваланырга хастаханәгә салдылар. Егетләр, кызлар хәл белергә аның янына еш килеп йөрделәр. Уколлар, дарулар ярдәм итте, Әнис савыгып чыкты.

Егетнең күңеле көрәйде. Бердән, савыкты, икенчедән, килгән кызлар арасында Әнисә дә бар иде. Авырып алгебрадан бирә алмый калган имтиханы өчен ут йотып ятканда укытучы Халидә Хәкимовна аңа ел барышында алган билгеләре буенча «4» билгесе чыгаруын әйтеп китте. Димәк, Әнис стипендиядән төшеп калмады. Ә иң куанычлысы—Әнисәнең «миленький», «җаныкаем» дигән сүзләре колак төбендә һаман яңгырап тора иде.

## 6

Булачак укытучылар училищедан йөз төрле эшкә өйрәнеп чыгарга тиеш. Аларга училищеның яшелчә, җиләк-җимеш участогында «Авыл хуҗалыгы нигезләре» буенча практика узу да мәҗбүри эш. Анда һәр укучы яшелчә

үстерергә өйрәнә. Жанын кайсын тели. Эш кораллары, төрле-төрле ашламалар бирелә, биология укытучысы кинәшләре белән ярдәм итә.

Әнис үз участогында помидор үстерде. Һәм нормадан өч мәртәбә артыграк уныш алды. Моны ул һич көтмәгән иде.

Шатлык өстенә шатлык: аны Мәскәүдәге Бөтенсоюз халык хужалыгы казанышлары күргәзмәсенә юллама белән бүләкләделәр. Ә иң куандырганы—шундый ук юлламага кыярдан югары уныш алган Әнисә дә лаек булды. Юлламада «Павел Бажов» пароходында Горький шәһәреннән Мәскәүгә хәтле барып, шул ук маршрут белән кире кайтырга диелгән иде. 20 августта алар Горькийга чыгып киттеләр. Көтмәгәндә килгән бу бәхеттән түбәсе күккә ашкан Әнис кызга бик игътибарлы булды, чемоданын күтәреп йөрде, иртәкичен ашханәгә чакырды. Әнисә баштарак читләшебрәк йөрсә дә тора-бара экскурсияләрдә күбрәк аның белән булды. Бу Әниснең иң бәхетле көннәре иде. Ниһаять, ул Әнисә белән гел янәшә, күрешә-сөйләшә ала. Идел буе шәһәрләре Ярославль, Кострома, Кинешма, Углич, Владимирда алар бергәләп фотога төштеләр. Әнис жае чыккан саен кызны туңдырма белән сыйлады, әле дә ярый жәйге айлар өчен стипендия биргәннәр иде.

Мәскәү ай-һай зур шәһәр икән! Андагы машиналар тагын! Күргәзмәдәге экспонатлар, халыклар дуслыгына багышланган алтынсу скульптур композицияләрнең матурлыгы дисеңме! Яңа төзелә торган Мәскәү университетының мәһабәтлеге, зурлыгы дисеңме! Аның студентлар өчен унайлыклары! Университет диварындагы сәгать эченә ике катлы йорт сыя икән ләбаса. Сталинга бирелгән бүләкләр музее турында сөйләп тә торасы юк. Андагы нәни генә дөге бөртегенә язылган хат, әллә ничә төрле агач кисәкләреннән ясалган шахмат тактасы, алтын йөгертелгән вазалар, юлбашчының шәхси әйберләре, ана чит ил житәкчеләре биргән бүләкләр Әнис белән Әнисәнең хәтеренә уелып калды.

Пароходта булган ике вакыйга аларны шактый якынайтты. Әнисәнең чибәрлегенә тасраеп карауччылар монда да күп очрады. Шуларның берсе пароходта эшләүче матрос иде. Әнисләр утырганның икенче көнендә үк ул бик матур формасын киеп йөри башлады. Әнисәне күргән саен: «Сәлам, гүзәлем!»—дип кычкырып узды. Биюләр, концертлар оештырылган көннәрдә гел Әнисә янында бөтерелергә, кино залында якынрак утырырга тырышты. Ә бер көнне вахтасыннан буш чагында аны үз каютасына кунакка килергә кыстады. Моны күреп, Әнис ачуыннан нишләргә белми йөрде. Хәер, Әнисәнең тапкырлыгы мәсьәләне тиз хәл итте. Бер көнне алар палубада матур Идел ярларын карап барганда теге матрос тагын килеп бәйләнде, Әнисәне жилкәсеннән кочаклап:

—Моя красавица! Мин бит сезгә гашыйк булдым. Сез игътибар да итмисез. Мин фәкыйрегезне кызганыгыз,—дип үбәргә үрелде. Әнисә аның кочагыннан житез генә ычкынып:

—Отстаньте! Менә минем боксер егетем!—диде, сикереп торган Әнисне күрсәтеп.—Югыйсә... Мин капитаныгызга барып әйтергә дә күп алмам.

Син күр дә мин күр, матростан жилләр исте. Моннан соң ул аларны очратса да күрмәмешкә салышты.

—Егетем дигәнгә ачуланмыйсынмы, Әнис?—диде күкчәчәк күз.—Тозсыз күзләрен акайта да килә, акайта да килә бит.

—Егетең булырга мин бик тә шат булыр идем бит,—диде Әнис, тик тукталып калды. Аның колагында теге матроска әйтелгән «отстаньте» сүзе янгырый иде. Әнисә моңа елмаеп куйды.

Ә бер көнне Әнис парикмахерскийга кереп жәй буена «под польку»га үстергән чәчен кыска гына «под бокс» итеп алдырырга теләде. Чәч алучы кыз каршы килде:

—Шаяртасызмы әллә? Шундый матур чәчнеме? Юк-юк, мин аны бозмыйм.

—Тагын үсә лә ул. Алыгыз!—диде Әнис.

—Әллә чәчегезне картада оттырдыгызмы, ә? Ял итүчеләр бездә әллә ниләр китереп чыгаралар.

—Юк, юк, сез ни сөйлисез. Әйдә, алыгыз инде.—Әнис үз сүзендә торды.

—Юк,—дип киреләнде чәч алучы кыз.—Сезне мин монда калын толымлы, матур күзле бер кыз белән күрәм.—Кызыгыз ни әйтер?

Әнискә бу кызык тоелды. Дөрестән дә, Әнисә ни әйтер икән?

—Үзен алып килимме әллә?

—Алып килегез.

Әнис Әнисәне каютадан чакырып чыгарды да парикмахерскийга алып китте. Чәч алучы кыз аңа да зарланды:

—Менә егетегез чәчен боздырырга тели. Ни диярсез? Нинди чәч бит, нинди чәч!

Әнисәнең көмеш кыңгыравы бүлмәне яңгыратты. Училищедагы тәртипне белә иң ул.

—«Егетемнен» теләгенә мин каршы килә алмыйм. Бу аның үз эше,—диде ул. Ә үзе Әнискә сынаулы караш ташлады.

Кыз, ризасызлыгын чыраена чыгарып, чәчне ала башлады. Үзе һаман ах та ух килде. Шунысы кызык, Әнисә чыгып китмәде, карап утырды. Эш беткәч:

—Менә хәзер чын авыл малае булдың,—дип көлеп куйды.

—Авыл малае булгач нишлисең инде.

Авыл малае искиткеч шат иде. Менә Әнисә тагын «егетегез» дигән сүзгә битараф калды. Әллә ишетмәде, әллә ишетеп тә игътибар итмәде. Егетем түгел, димәде. Моңа тикле ул Әнисәгә авылдагыча әйдә дус булыйк, дип тәкъдим итәргә ниятләп йөргән иде. Хәзер аңлады, алай кирәкми икән иң. Әйтмичә дә дуслашып була икән.

## 7

Бу күңелле сәяхәттән тәэсирләргә бик баеп кайттылар. Укулар башлангач, аларга сораулар күбәйгәннән күбәйде:

—Башкала матурмы? Метрода йөрдегезме?

—Сталинны күрмәдегезме?

—Мәскәүлеләрнең өс-башлары нинди?

—Шлюзлар «Яшь сталинчы»да язганча матурмы?

—Мәскәүдә татарлар яшиме?—дип аптыратып бетерделәр.

Сәяхәтчеләр, алып кайткан открыткаларын күрсәтеп, белгән-күргәннәрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр.

Бер көнне Әнисне Сафа абыйлары кабинетына чакырып алды. Үзе бик яхшы белеп торса да аннан ничек укуын, әти-әнисе хәлләрен сораштырды. Аннары:

—Әнис, сез Әнисә белән бик дуслашып киттегез бугай. Син аның ятимә кыз икәнен беләсеңме?—диде.—Беркеме дә юк бит.

—Беләм, Сафа абый.—Сөйләде. Күңеле китек чакларын да чамалый башладым.

—Шул-шул. Сиңа артык ияләшеп, егет белән кыз арасындагы чикне уза күрмәгез. Бу бигрәк тә сиңа, егет кешегә кагыла. Аңлыйсыңмы?

Аңлады Әнис, аңлады. Кызарып, оялып китте.

—Мин аның кулыннан тотарга да оялам бит, Сафа Гыйлаҗетдинович,—диде ул.—Честное комсомольское. Ул үзе дә бик тыйнак. Борчылмагыз.

Бу сөйләшүдән соң күп тә үтмәде, Әнис күкчәчәкнең үзенә карата мөнәсәбәтен чынлап белде.

Авыл малайларын кем биергә өйрәтә соң инде. Училищеда биюләр оештырганда Әнис танцыларда читтәрәк йөри, «краковяк» шикелле җиңелрәк биюләргә генә катнашкалый иде. Башта малайлардан күреп, ул да батырчылык итеп, училищеда укучы Людмила исемле кыздан биергә өйрәтүен үтенде. Кыз риза булды, дәресләрдән соң калып, Әнисне биергә өйрәтә башлады. Беркөнне алар буш класста вальс әйләнергә өйрәнеп торганда ишектә Әнисә күренде. Аның йөзе үзгәреп китте, ул ишекне япты да китеп барды. Шул көннән соң ул Әнискә күренмәскә тырышты, чакырса да чыкмады. Әнис, ниһаять, аның акробатика түгәрәгеннән бушаганын көтеп алды да:

—Әнисә, сиңа ни булды? Теге көнне киногa билет алып килгән идем. Шәһәрдә «Чал чәчле кыз» исемле кытай фильмы бара. Син чыкмадың да,— диде.

—Киногa йөрергә кеше тапкансың бит инде. Людмилаң ни дияр?—Әнисәнең тавышы калтыранып чыкты.

—Ул бит мине биергә генә өйрәтә. Үзем үтендем.

—Ә мин өйрәтә алмас идемме?—Әнисә шундый караш ташлады, Әнис барын да аңлады.

—Гафу ит, бетте. Син өйрәт, алайса. Минем бит сине борчыйсым килмәде. Людадан мин гафу үтенермен,—диде ул.

Көз көне күрше колхозга бәрәңге алырга булышырга баргач, Идмас белән Әнис арасында низаг килеп чыкты. Әнискә ат җигеп бәрәңге тутырган капчыкларны авылның ындыр табагына ташырга кушылды. Бер-ике көннән соң Идмас Әнискә:

—Син эштән качып йөрисең!—дип бәйләнде.—Безнең кебек син дә бәрәңге чүплә. Ат белән кем дә ташый аны. Бүгеннән мин!—дип дилбегәгә килеп ябышты.

—Бригадир миңа кушты, сиңа түгел,—дип Әнис каршы килде. Гадәтенчә Идмас мәсьәләне йодрык белән чишмәкче булды. Алар бәргәләшә башлаганнар иде, бригадир килеп аерды.

—Юкка чәпәли чуак булмагыз,—диде ул.—Килешми. Бу нинди тәмсезләнү. Капчыклар авыр, аларны төяү дә, ындыр табагына илтеп бушату да майлы ботка ашау түгел.

Бу хәл директорга ук ишетелде. Ул Әнисне ачуланып ташлады, чөнки Идмас низаг шаһиты булган малайларны куркытып куйганга күрә, алар Әнис гаепле дигәннәр иде.

Шуннан бирле Идмас Әнискә гел кырын карап йөрде. Аның Әнисә белән дуслыгы да Идмасның эчен пошыра иде. Бер мәртәбә ул аксыл керфекләрен кысып:

—Син юкка гына Әнисә янында буталып йөрисең. Без бит бер балалар йортыннан килдек. Аның артыннан йөрүчеләр булгалады,—диде.—Ул кемгә дә шаккатмады. Укуын белде.

—Әллә үзеңә дә исе китмәдеме? Шуңа борчыласыңмы? Бәлкем, сине карт дип уйлагандыр, ә?

Бәхәс кызасын алдан ук сизенгән кебек бу тирәгә малайлар җыела башлады. Идмасның күзләре урынында нечкә ярыклар гына калды:

—Телим икән, Әнисәне мин синнән бик тиз биздереп, үземнеке итә алам. Мин аны алмагачтан күтәреп алган көннән бирле күпме вакыт узган дип беләсең? Ә ул миңа күргән саен елмаеп китә.

—Син, Идмас, куык очырма әле.—Әнис масаючан кешеләрне яратмый иде.—Син Илгиз белән Сәлимә арасына да чөй кагарга маташтың түгелме? Бик исләре китте!

Идмас күзләрен як-якка атты:

—Бәхәсме? Менә күрерсең! Раймагта матур пәке күргән идекме? Оттырган

кеше шуны алып бирә. Килештекме?

—Юк, бәхәсләшмим дә, нитмим дә. Борынынны белеп тарт, яме. Син безнең араны боза алмыйсың. Сәбәбен әйтеп тормыйм.

Шул көннән Идмас Әнисә артыннан калмаска тырышты. Билет алып кинога чакырды. Бүләккә китаплар алды. Кирәксә-кирәкмәсә дә, физика, биология кабинетларында ярдәм итимме дип, янына барып утырды. Тик Әнисә аның ярдәмен кире какты, бүләкләрен алмады. Кинога чакыргач, бер барды да бүтән бармады. Бер көнне ул Әнискә:

—Син күрәсеңме? Юкмы? Идмас күзләрен тозландырып янымда бөтерелергә генә тора. Ник дәшмисен?—диде.

—Зиночкасы белән ачуланышса, ул шулай бүтәннәргә бәйләнергә ярата. Сине дә үзенә каратам дип үнәч киерә,—диде ана Әнис.

—Мин аны якын да җибәрмим...

—Йөрер-йөрер дә туктар... Бер дә борчылма. Үзен бик чибәр, теләсә кайсы кызны карата алам дип белә, күрәсең. Әйткән сүзе бар аның...

—Нинди сүз?

Бу күнелсез әңгәмәне Әнис икенчегә борырга теләде:

—Ярар ла, игътибар итмә. Физика кабинетына керәбезме? Оптика кагыйдәләрен кабатлыйсым бар дигән идең.

Әнис кабинетка кереп, озак кына көтеп утырса да Әнисә күренмәде. Әнис аны эзләп тулай торакка барып килде, кыз анда да юк иде. Бүлмәдәш кызлары: Идмас чакырып чыгарды да алар каядыр китеп бардылар бугай, диде. Бу Әнис өчен шаккатыргыч яңалык иде. Ул аптырап калды. Ничек инде? Үзе Идмасны якын да җибәрмим диде, ә үзе... Әнис кызны кичкә кадәр булса да көтәргә, хәлне ачыкларга ниятләде. Хәер, Әнисә озак та үтми училище капкасыннан кайтып керде.

—Әнисә, мин сине кабинетта да, инде менә монда да көтә-көтә арып беттем,—дип аның каршына чыкты.

—Хәлдән таймадыңмы?—Әнисәнең сүзләре бик кырыс яңгырады.

—Син кайда булдың соң? Кызлар сине Идмас белән чыгып китте диделәр.

Әнисә җавап бирергә ашыкмады.

—Әйе, аның белән булдым. Ә нәрсә? Арып беткәнсең икән, бар, кайтып ятып йокла инде, хәл керер.—Кыз китәргә дип борылды.

—Әнисә, мин берни аңламыйм. Нинди чебен тешләде сине, ә?

—Мин дә сине аңламыйм. Теләмим дә. Их, син!—Әнисә күзләренә мөлдерәмә тулган яшьләрен яулыгы белән сөртеп, йөгереп диярлек тулай торакка китеп барды.

Әнис балтасы суга төшкән кеше кебек берничә көн кара көеп йөрде. Нәрсә булды соң инде бу? Күкчәчәк күз шул көннән бирле очрашырга да теләми. Әнис су буенда алар икесе генә яраткан каен янына барып көтеп тә утыргалады. Юк, күренмәде.

Димәк, Идмас сүзе өстен чыкты. Әнә ич ул ничек елмаеп йөри. Дөрес, теге көннән соң Әнисә аның янына да чыкмый икән. Әнискә моны Лилия әйтте. Алайса, сәбәп нәрсәдә? Тагын берничә көн узды. Алар Әнискә айлар булып тоелды. Бер көнне егетләр тулай торакта дәрескә әзерләнеп утырганда бүлмә ишеген бик каты итеп шакыдылар.

—Керегез, кер, бикле түгел ич.

Ишектән бүлмәгә Әнисә белән Лилия килеп керде.

—Хәерле кич, егетләр.—Әнисә кыю гына атлап Әнис кырына килеп басты. —Идмас өйдә юкмыни? Мин икегезне дә туры китерермен дип өмет иткән идем. Менә ал, син оттың,—диде дә Әнис кулына сөяк саплы авыр пәке салды. Әниснең бу ун җәпле пәкене раймагта кызыгып карап торганын ул белә иде.

—Нәрсә оттым? Бу нинди пәке? Һични анламыйм.—Әниснен аптыравы йөзенә чыкты.

—Сез Идмас белән пәкегә бәхәсләшкәнсез икән. Син жинден. Мә! Ал!—Кызнын ирен кырыйлары тартышып-тартышып куйды.

—Тукта әле, Әнисә. Бернинди бәхәс тә булмады. Сина моны кем әйтте? Идмасмы?! Улмы?—Әнис кызны кулыннан алды.

—Сүз иясе белән йөрми.

—Бернинди бәхәс тә булмады. Киресенчә, Әнисәнне үземнеке итәм, дип бакыр баш масайды. Ә мин ул сина борылып та карамаячак, дидем. Дөрес әйттемме?

—Ә ул башкача сөйләде. Бәхәсләштек, жинелгән кеше пәке сатып ала дип килештек, ди. Мин оттырдым, ди.

—Теләгенә ирешә алмаганын анлый икән әле үзе. Тик бернинди килешү дә булмады. Анысы ялган. Ышанма! Комсомолец, имеш! Малайлар, менә сез әйтегез әле. Шундый килешү булдымы, юкмы? Сез дә анын мактанганын ишеттегез ич.

Шунда Игълам сикереп торды:

—Ялганлый ул! Андый сүз булмады. Әнисә, Лилия, ышанмагыз.

Бүтән малайлар да бер-берсенен сүзен жөпләделәр.

—Ә мин сина рәнжегән идем. Мин бит таш курчак түгел. Бу бит мине мәсхәрәләү дип уйладым.—Әнисәнен йөзе ачылып китте.

—Син мина шуна гына үпкәләп йөрден инде, алайса, иеме?—Әнис күнелсезлекнен бетүенә сөенә иде.

—«Шуна гына». Пәке отар өчен дус булып кыланып йөрү кешедән көлү түгелмени?

—Ярар инде, Әнисә. Анлаштык бит. Бүтән сәбәп юк.

—Ә син үзен ничек уйлыйсын? Анын шулай мактанып йөрүен белә торып, синен читтән генә күзәтүен егетлекме?

Әнис моны көтмәгән иде. Дөрестән дә, нишләп ул мона юл куйды сон әле?

—Менә монысы өчен мин гаепле. Гафу ит. Чыннан да. Сина ышанганга күрәдер, уйламаганмын да,—диде ул.—Йә, беттеме?

—Бетте.

—Алайса, мә бу пәкене Идмаска кире бир.—Әнис кулын пешереп торган матур пәкене Әнисәгә сузды.

—Бирде ди, хәзер. Алмыйм. Минеке ул, аныкы түгел. Сина бүләгем булыр. Кызыгып йөргәненне беләм ич.

Идмас теге чакта кәпрәйсә дә, Әнисәне үзенә карата алмавына бик гарьләнеп, эчтән тынды. Әнискә ник бер сүз әйтсен.

## 8

Өченче курс тәмамлангач, жәен укучыларны район буенча экскурсиягә алып чыктылар. Александр II патша крепостное правоны бетерү хакында манифест чыгаргач, ул чакта Рус Бизнәсе дигән авылда Антон Петров исемле крестьян житәкчелегендә крестьяннарнын баш күтәрүләре, монын өчен нинди жәзага тартылулары хакында бик күп яналык ишеттеләр. Патша залимнәре тарафыннан жаны кыелган Антон Петров каберенә чәчәкләр салдылар. Никольское авылында данлыклы ат заводында, Куйбышев исемендәге затонда пароходлар ремонтлау заводында булдылар. Борынгы Болгар шәһәрендә тетрәндергеч тарихи хәрабәләрне карап йөрделәр.

Укучыларны жирле экскурсоводлар Болгарда матур бер күл янына алып бардылар, анын ни өчен изге Рабига күле дип аталуы хакында халкыбызнын буыннан-буынга күчеп йөргән риваятен сөйләп тан калдырдылар.

Менә шунда инде Әнисә дә Әнискә күнеленең иң ерак түрендә йөрткән хисләрен тәүге кат ачып салды. Болгар хәрабәләрен карап йөргәндә ул үзен бөтен барлыгы белән болгар кызы итеп тойды.

...Хан кызы Рабига Иделдә дус кызлары белән ял итеп көймәдә йөргәндә ялгыш суга егылып төшә, бата башлый. Моны күргәч, камышлар арасында балык тотып утырган Гомәр исемле яшь егет ана ярдәмгә ташлана, коткарып кала. Ике яшь йөрәкнең танышуы әнә шундый фаҗигале вакыйгадан башлана. Әле мыегы тибеп кенә чыккан горур кыяфәтле, үткен күзле, житез хәрәкәтле яшь егет берничә елдан чибәр, гайрәтле, унган батырга әйләнә. Рабига да буйга тартыла, кызларның багалма кебек гүзәл чорына керә. Бер-берсенә гашыйк булган егет белән кыз Ага базар урамнарында, Идел буенда, хан сарае янында очрашканда мәхәббәтләрен яшермиләр.

Аксак Тимер сувар халкына яу белән чыккач, Гомәр батыр ярдәмгә ашыга һәм сугыш кырында һәлак була. Биләр, Сувар, Жүкәтау калаларын яндырып көлгә әйләндергәч, Аксак Тимер Болгарны камап ала. Болгар халкы үз-үзен аямыйча басып алучыларга каршы сугыша, ләкин көчләрнең тигез булмавы сәбәпле, шәһәр дөрләп яна, мәчетләр, китапханәләр көлгә әйләнә. Хан үзе дә яраланып фани дөнья белән хушлаша. Ләкин шәһәр халкы бирелми.

Аксак Тимернең гаскәр башлыгы Болгар халкына соңгы әмерен житкерә:

—Хан кызы Рабиганы миңа тотып бирсәгез, мин моннан ары сезгә тимәскә сүз бирәм, ди.

Туган халкын кырылып бетүдән саклап калу өчен гүзәл Рабига риза була, тик гаскәр башлыгына бер шарт куя.

—Бертуган абыем белән энемә ике юртак китерт. Шунда гына мин синеке булырмын, ди.

Шарт үтәлә, юртаклар китерелә. Рабига туганнарына:

—Барыгыз, сөекле туганнарым, качып котылыгыз. Аннары халыкны жыеп, шушы Аксак Тимер этләрен дөмектерегез,—ди.

Егетләр юртакларга атланып, күздән югалалар.

Рабига Таш пулат түбәсенә менеп туган шәһәренә күз сала. Күрә, кая карама—ут, янгын, кайгы-хәсрәт, үлем. Инде аның беркеме дә калмаган, туганнары да, әти-әнисе дә, сөекле Гомәре дә.

—Юк инде,—ди ул.—Явыз дошман минем намусымны пычрата алмас. Ана бирелгәнче үлүең яхшырак.

Рабига Таш пулат түбәсеннән ут эченә ташлана, ләкин исән кала. Болгарлылар савыктырырга дип аны изге күл янына күтәреп баралар, яраларын юып, дәваларга телиләр. Чибәр Рабига, аңына килгәч, куе каенлык ышыгында жәелеп яткан күлгә ташлана да юк була. Дошман аны бик озак эзләсә дә таба алмый. Туган халкы аның явыз басып алучылардан качып, яшерен юл белән Иделгә агып чыккан да аннары сөйгәне Гомәр кабере янына барып вафат булган, дип ышана. Шуннан соң бу күлне Рабига күле дип йөртә башлыйлар.

Боларны ишеткән Әнисә ул көнне үзен исеме риваятьләргә, халык күңеленә сеңеп калган Рабига итеп сизде. Мәхәббәт кешене нинди биеклекләргә күтәрә, жир, күк белән бер бөтен ясый ала. Күлдә йөзеп йөргән ике аккошны күргәч, аның күңеле тулды. Янәшәсендә аның үз аккошы бар лабаса. Ә ул аккош чыннан да янында гына, күз карашы белән иркәләп, сөюеннән очып кына йөргән Әнис иде. Аның Әнискә бик тә мөһим, менә шушында, Болгарда, Рабига күленең чирәмле матур ярында күңелен ташытып, аеруча дулкынландырып туган тәүге хисен әйтәсе килде.

—Әнис,—диде ул,—мин янәшәмдә гомерем буена синең генә булуыңны телим. Бары син генә.

Кояш нурларында коенып яткан зәңгәр күл өстеннән жылы жил исте, ул

йөрәкләренә бөек хис тулган яшьләрнең башларыннан сыйпап узды. Ирennәр иреннәргә кушылды.

9

...Пароход тавышы сискәндереп җибәрде. Ул Идел өстеннән еракка, каршы яктагы ярларга барып бәрелде, аннан кире кайтып бөтен урманлыкка, пристаньга кереп тулды. Әнис белән Әнисә кочаклашып һаман аерыла алмый басып тордылар. Инде аларга аерылышырга кирәк иде. Тик көчләреннән килмәде. Басманы алырга җыенган кин җилкәле ачык йөзле матрос:

—Сез утырасызмы, юкмы?—дигәч кенә егет кызны кочагыннан чыгарды.

—Хуш, җаным. Йә, елама инде... Сөйләштек бит инде. Бер ел күп вакыт түгел ул. Мина да синнән аерылып китү бик авыр. Тик нишләмәк кирәк. Училище тәмам. Әрәм булма, укуыңны дәвам итә күр, диделәр. Беләсең ич. Син дә училищены тәмамла, аннан минем янга килерсең. Мин университетны бетергәч, бергәләп эшкә китәрбез. Хыялыбызны тормышка ашырып балалар укытырбыз. Йә-йә, пароход кузгала ич.

—Мин сине хәзер үк сагына башладым,—диде Әнисә.—Хәтерлисеңме, син миңа роза бүләк иткән идең. Ул исән. Кипсә дә хуш исе аңкып тора. Мин аны синең төсең итеп саклармын.

—Алла бирсә, безнең тормышта андый розалар күп булыр әле, матурым.

Алар пароход басмасына кадәр янә кочаклашып бардылар. Әнис пароходка кергәч борылды да:

—Хуш инде, Әнисә,—диде.—Пароход төнлә генә килә, озатып йөрмә дип күпме әйттем. Инде караңгы төште. Җил көчәя. Болыт та килә, яңгыр булыр, ахрысы. Шәһәргә бер ялгызың ничек кайтырсың. Бар инде, бар. Хатларыңны еш яз. Яме-е!

Пароходның көпчәк калаклары ләп-ләп итеп инде суга бәрә иде. Ул акрынлап борылды да кап-кара суны икегә ярып, Идел уртасына таба юл алды. Пристань лампалары тоныкланып артка шуды, пароход елга култыгын узып инде күренмәс булды. Пристаньда яулык болгап басып торган ак күлмәкле кыз Әнисмең йөрәген әрнетеп калды...

Әнисәнең күз яшьләре кибә төште. Аның Әнисеннән соң бушап калган шәһәр ягына борылып китәсе килми, аягы тартмый иде. Сөйгәненең китүенә ул әллә ышанмый идеме соң? Ышанадыр ла, әнә ич, егете пароходка кергәч, аяк астында шыксыз шыгырдап торган басманы тартып алдылар. Әнә ич, Әнисе ана, хуш, диде, Казанга килерсең, диде. Җил, яңгыр, диде. Ә шулай да Әнис менә хәзер кинәт кенә әллә каян пәйда булыр да, гадәтенчә арттан килеп аның күзен томалар, Әнисә танымаган булыр, ә егете шуңа шатланып көлеп җибәрер дә, кысып кочаклап алыр сыман тоела иде.

Әнисә үз хыялына үзе ышанып, кинәт кенә борылып карады. Юк шул, Әнис инде еракта, ул күптәннән пароходның җылы төтен бөркегән торбасына сөялеп, күзләрен авырттыра-авырттыра караңгыга чумып калган пристань ягына карап китеп бара иде.

Кинәт көчәеп киткән җил пристаньның калай түбәсен шаулатып алды. Әнисә айнып китте. Төнне монда үткәреп булмый, кайтырга кирәк иде. Тулай торактагы дус кызлары әллә кайчан пошаманга төшкәннәрдер. Хәер, аның кая киткәнен беләләр белүен. Тәрбияче Ксения апасы да белә. Шулай уйлана-уйлана Әнисә кайтыр юлга чыкты. Ана әле кап-караңгы юлдан алты-җиде километрлап ара узасы бар иде.

Караңгыда юл кырыендагы һәр куак, һәр түмгәк әллә нинди албасты, җен, бүре булып күренә. Кыз куркуын җиңәргә тырышып атлый да атлый. Ә үзе һич булмаса, берәр кеше очраса, болай ук куркыныч булмас иде, дип өметләнә. Җил көчәйгәннән-көчәя, инде әнә Идел ягыннан беренче тамчылар

да куып килә бугай. Әледән-әле күзне яшен камаштырып ала. Шөкер, инде шәһәр утлары да күренә башлады. Кыз адымнарын тагын да тизләтә төште.

—Йа, Ходаем, яңгыр коя башлаганчы кайтып кына җитәсе иде.

Юл кырыена якын ук килеп үскән куаклар яныннан узганда Әнисәгә анда кемдер посып торган кебек күренде. Кинәт ялтырап киткән яшеннән куркып, кыз чигенеп куйды. Шул мәлне кемдер аны арттан муенын бик каты кысып, учы белән авызын-борынын томалады. Әнисә тыны бетеп, сыгылып төшкәч, аны куак арасына сөйрәп алып керделәр. Күлмәк сәдәпләренең чытырдап өзелеп төшкәнен ул ишетә алмады. Кемдер кызның өстенә авып, аның гәүдәсен тупас капшый иде. Бик нык авыртудан Әнисә кинәт айнып киткәндәй булды. Аның өстендә сасы хәмер, әче тир исе аңкытып битен яшергән берәү мыш-мыш килеп, ашык-пошык үзенең хайвани теләген үти иде...

## 10

Иптәш кызлары аны тулай торак баскычында елап утырган жиреннән бүлмәгә алып керделәр. Тулай торак ду килде. Кызлар бер-берсен бүлдерә-бүлдерә сораша башладылар. Әнисә күлмәгенең изүе ертылган, әчке киемнәре дә пычранып беткән иде. Үзе бертуктаусыз сулкылдап-сулкылдап елый, бер генә сорауга да җавап бирми утыра бирде.

Фаҗига иртән директорга мәгълүм булды. Сафа Нәсихов та гаҗиз калды. Мондый вәхшилекне кем эшләвен ул Әнисәдән сорашуны хатын-кыз укытучыларга йөкләде, әмма мәсхәрәләнгән кыз, телсез калган кешедәй, һаман берни дә әйтмәде, елавын белде. Кызлар директорга Әнисәнең Әнисне озатырга барганын әйткәч, Нәсихов тетрәнеп китте. Мондый эшне Әнис ничек эшли алды икән? Мин аны бик яратам, кочакларга да оялып йөрим бит, дигән иде ләбаса. Нинди явыз, кара эчле кеше булып чыкты бит бу тәти егет. Өстәвенә—юләр! Болай булгач, башы бетә бит инде аның. Хәзер менә аңа университетның башкасында укырга туры килер, дип уйлады, ачынып, директор. Егетнең юлдан язганын алар ничек күрми, сизми калдылар икән соң? Фаҗига турында Сафа Нәсихов прокуратурага, милициягә җиткерми кала алмады.

Бер-ике көн узды. Әнисә тынычлана төшкән шикелле булды. Тамагына каба башлады. Сорауларга кыска итеп: йә «әйе», йә «юк» дип җавап бирсә дә, шуннан артык узмады. Тик Әнис турында сорашырга керешкәндә ул кабат үксеп-үксеп еларга тотына да үз эченә кереп бикләнә иде.

Укучы егетләр чибәр Әнисәне шушы хәлгә төшергән кешене изеп ташларга әзер иделәр.

—Мин ул Әнисне Казанда барыбер эзләп табам!—диде Идмас.—Моның үчен барыбер алам, болай гына калдырмыйм!

Берничә көн шулай шау-шу килеп кайнап торган училищеда Әнис исеме һаман ешрак кабатланды. Әнисәнең дус кызлары беркөнне җыелышып директор кабинетына килеп керделәр.

—Сафа абый! Без бик нык гаҗәпләнәбез!—диде бик актив Камәрия.—Әнисне эзләп табарга да җавапка тартырга кирәк. Ә Сез берниндн чара күрмисез! Бу ничек була инде, ә?

—Укучылар, мин тиешле органнарга хәбәр иттем инде. Алар тикшерү эшләре башлап җибәрделәр. Тик менә Әнисә үзе генә берни әйтми бит. Мондый явызлыкны кем эшләде, дигәч, белмим дип елап тик тора. Ә Әнисне табабыз аны, табабыз. Ул үзенә тиешлесен алыр. Дуслык, мәхәббәт, имеш. Мәхәббәт шундый буламыни?!

Директор чыннан да аптыраган иде. Ул бит яшьләрнең мөнәсәбәте чындыр дип ышана иде.

Менә сина мә! Уйлый торгач, ул бер нәтиҗәгә килде. Органнарга кадәр Әнисне ул үзе барып тапсын әле. Нинди йөз белән каршылар икән. Әнис инде училищены тәмамлаган кеше булса да дипломын әле генә алды бит. Анын бер аягы әле һаман училищеда диярга була. Анын өчен дә җаваплылык шул ук директорга төшә ләбаса. Министрлыкта, райкомда ни диярләр! Башын әйләнерлек тә шул. Әнә бит, күрше Тәтеш училищесы директорын эшеннән азат иттеләр. Әлләни гаебе булмаса да. Анда шундыйрак бер «ЧП» өчен директор җаваплы булып калды. Әйе, барырга кирәк Казанга, күрергә кирәк ул оятсызны!

Ул арада училище тагын ду килә башлады. Әниснен Әнисәгә ике хаты килеп төште. Килеп төште дә кабат училищенын астын-өскә китерде. Әнисәдән хатны ялына-ялына алып укыгач, барысы да шаккатты.

«Әнисәм, күз нурым! Сагынып үләм бит мин сине. Күз алдымда һаман кул болгап басып торасын, бәгърем. Ник хат язмыйсын? Бер атна узды бит инде. Вәгъдәне шулай үтиләрмени? Бер-ике көн эчендә хатын килмәсә, нишләргә дә белмим. Имтиханнарга да әзерләнә алмый башладым...»

Анын икенче хаты тагын шөбһәләнергә мәҗбүр итте. «...Мин үзем гаепле. Син мина рәнҗегәнсендер дип уйлыйм. Сине елатып, кап-кара төндә ялгызынны калдырып киттем бит... Ник хат язмыйсын, матурым...»

Эшләр болайга киткәч, Нәсихов Әнисәне үз янына чакыртты.

—Сенлем, мин барын да төпченмим... Бер генә сүз әйт. Сез бит бик матур пар идегез. Әйт әле, Әнис гаеплеме? Син бәлки яшерәсендер?

Әнисә әле генә анга килгән кешедәй яшь тулы күзләре белән директорга карап торгач:

—Сафа абый! Ул түгел... Ул мине ярата. Мин дә аны... Әнис гаепле түгел,—диде дә әкрен генә торып чыгып китте.

Директор:

—Алайса кем сон?—дип сорарга өлгерсә дә коридорда бәхетсез кызнын аяк тавышлары гына янгырап калды.

Бу хәл директорны янә тирән уйга батырды. Кем сон алайса? Кем? Бу органнар да ник шулай озак кыймылдый икән сон? Училищеда кылны кырыкка ярыр чаклар, ә кул эшкә бармый. Нәсихов прокуратурага кереп, берәр нәрсә ачыклап булмасмы дигән уйга килде. Кызнын Әнисне гаепләмәвен дә әйтергә кирәк иде.

Олы яшьтәге тикшерүче ана күптәннән таныш булса да шешенке күз кабакларын өстәлгә төбәп, бик ачылып китмәде, директорны сабыр гына тынлап торды. Аннары:

—Сез мина яналык әйтмәдегез. Ул кыз белән сөйләшеп, без анын егетен гаепләмәгәнен белдек инде,—диде.—Бик ярата икән ул аны. Яраткан кешесен җавапка тартылуын теләр микән сон ул, дигән сорау туа.

—Сез чыннан да Әнис гаепле дип уйлыйсызмы? Әнә бит хатында ул Әнисәгә өзелеп яратам, дигән. Хат язмый торсан, кайтам, дигән. Сөйгән кызын мәсхәрә кылса, ул шундый хат язар иде микән?

—Шунысы сәер дә шул анын.

—Менә-менә. Ә икенче хатында: мин үзем гаепле. Рәнҗегәнсендер. Сине елатып, калдырып киттем, дигән. Бу үз гаебенне тану түгелме?

—Ә кыз анын гаебе юк ди ләбаса. Һич анламассын. Кыскасы, безнен хезмәткәр Казанга китте инде. Әнисне эзләп табарга тиеш. Калганы шуннан сон ачыкланыр.

—Ярар, рәхмәт сезгә. Һөнәри сер булмаса, мина хәбәр итә торыгыз инде, зинһар.

—Карарбыз, Сафа Гыйлаҗетдинович. Мин анлыйм. Мондый хәлләр өчен беркемнен дә башыннан сыйпамыйлар. Үзегез беләсез.

Сафа Нәсиховның тикшерүче кабинетыннан чыкканда кәефе тагын да бозыла төште. Нәрсә соң инде бу?! Ятимнәр йортыннан килгән кыз бала өчен, әлбәттә, ул үзе җаваплы. Ул бит җитәкче. Тәрбия эше начар куелган димәк. Нәрсә карадың диячәкләр. Ул республикада ятим балаларны укыта торган бердәнбер училище директоры. Шуңа күрә ана игътибар зур, җаваплылыгы тагын да зуррак. Балаларның тамагы да тук булсын, өс-башлары да бөтен булсын. Дөрес, министрлык ярдәм итә, тик тормыш тормыш бит ул. Кием-салым да туза, ертыла, продуктлар белән тәэмин итүдә дә өзеклек чыгарга гына тора.

Шундый уйлардан башы каткан директор үз кабинетына кайтып кергән генә иде, телефон чылтырады. Чыбыкның теге башында әле генә сөйләшеп торган тикшерүче иде.

—Кайтып җиттегезме, иптәш Нәсихов. Монда тагын бер катлаулык чыгып тора әле. Казаннан безнең хезмәткәр хәбәр итте. Теге Әнис юкка чыккан бит. Университетта да, тулай торакта да таба алмаган ул аны,—диде.—Үз гаебеннән куркып качып йөри микән әллә? Әти-әнисенә сиздермичә, борчымыйча гына белешәсе иде, авылына кайтмады микән?

Сафа Нәсихов лып итеп кәнәфигә утырды. Димәк, тәти егет гаепле. Югыйсә качып йөрмәс иде. Чүп өстенә чүмәлә була түгелме соң әле бу? Йомгак тагын да чуала лабаса.

Директорның көндәлек эшләре җыелып тора. Әллә ничә приказ язасы, читтән торып укучылардан имтиханнар алуны оештырып җибәрәсе, тагын бакчада җәйге эшләр планын карап чыгасы, тагын әллә ниләр эшлисе бар лабаса.

Директор авыл хуҗалыгы нигезләрен укытучы Вера Кузнецованы чакырып алды, җәйге эшләр көндәлеген төгәлләргә кушты. Ана теле укытучысы яшь Илсөяр белән каникулда Казанга экскурсиягә баручы укучылар исемлеген ачыклады, моңа кирәк-яракларны табарга булышты. Физика укытучысы Гыйльман Әхәтов белән лабораториягә яңа уку елына нинди әсбаплар сатып алу кирәклеген ачыклады... Ләкин ни генә эшләмәсен, миен һаман борчулы уйлары бораулады: кайда, кайчан, ничек, нәрсәне күрми калдылар соң алар? Тәрбиячеләр ничек кыз баланы кемгәдер ияртеп җибәрә алганнар? Кемгәдер дисәң... Сөйгән егетенә лабаса. Алайса, бу фаҗигагә кем гаепле? Кайда, ник югалып йөри ул Әнис. Дөрестән дә, аның дусты Илгизәрне мотоциклга гына утыртып авылга җибәрергә кирәк. Әнис анда кайтмадымы икән? Тик моны әти-әнисенә берни әйтми, сиздерми генә эшлисе иде.

Кичен өенә кайткач та аны шушы уйлары борчыды. Хатыны Гәүһәриянең:

—Син алай ук бетеренмә әле. Ашаудан калып барасың ич,—диюенә кәефе кырылды.

—Синең шул булыр инде... Ашау-ашау!—дип бер дә юкка хатынының хәтерен калдырды.

Ә иртәгәсен аны тагын да борчулырак хәлләр көтә иде.

## 11

Әнисә шушы берничә көн эчендә нык суырылып, ябыгып калды. Тамагына капса капты, капмаса онытты. Тәрбиячеләр, иптәш кызлары, бигрәк тә Лилия, Фирдәвес гел аның белән бергә булдылар. Әлбәттә, күбесенең башында үз-үзенә кул гына сала күрмәсен, дигән уй бөтерелде. Кызлар үзләрен Әнисә урынына куеп карыйлар да йөрәкләре җу итеп китә иде. Әнисәнең күкчәчәктәй күзләренең тонып, тоныкланып, алсу битләренең саргылт-көрәнсу төскә керүен күрү аларга бик авыр иде.

Кайвакыт Әнисә иптәшләреннән, зинһар, ялгызымны гына калдырыгыз әле, дип үтенсә дә аңа күз-колак булырга тырыштылар. Әнисә исә төннәрен,

бүлмәдәге кызлар йоклап беткәч, торып утыра, аннары кием-салымын барлый торган булып китте. Тагын уйга талып утыра-утыра да кинәт аның борынына теге хәмер, ачы тир исе кабат бәрелеп киткәндәй тоела. Ул хәтта укшый ук башлый. Тешләнеп, кара янып беткән күкрәкләре янә сулык-сулык итә. Үзе һаман кабат-кабат бер нәрсәне уйлый: кем соң аны шулай рисвай итте? Кем соң аның исемен шулай пычратты, бөтен шәһәргә фаш итте? Инде хәзер ана нишләргә? Бу хәлне белгән-ишеткән һәр кеше ана бармак белән төртеп күрсәтәчәкләр бит. Ана кызыгып йөргән шәһәр егетләре күзен дә ачырмаячак хәзер. Йа, Хода, әнкәсе исән булса, кайтып ана сыеныр иде. Аның бит беркеме дә юк. Шушы явыз, миһербансыз дөньяда ул берүзе калды. Хәзер ана бәхетсез башын кайларга илтеп ташларга соң?

Сафа Нәсихов училищега килгәнче тагын прокуратурага сугылды, тик ана анда бернинди яналык әйтмәделәр. Ә яналык аны училищеның үзендә көтә иде. Ул кабинетына кергән генә иде, училищеның озын коридор башындагы ишек шапылдап ябылды да ир балалар тавышы янгырый башлады:

—Әйдә-әйдә, батыррак атла, кияү егете! Башта директорга күрен.—Тавыш Идмас Фәсхетдиновныкы иде.

—Җибәр! Җибәр диләр сина! Сугыш чукмары! Синнән башка да юлны беләм. Җибәр!

Йа, Хода! Бусы Әнис тавышы түгелме соң? Нәсихов идәндәге паласка сөрлегә-сөрлегә ишеккә ташланды. Кинәт ишек ачылып китте, ә анда Әнис күренде. Җилкәсеннән төртеп җибәргәнгә ул Сафа абыйсына килеп бәреләязды. Әнис артыннан Идмас Фәсхетдинов пәйда булды.

—Исәнмесез, Сафа Гыйлаҗетдинович! Кызлар тулай торагына барган җирдән мине менә бу сугыш чукмары сезнең янга сөйрәп килде, гафу итегез!—дип Әнис директор каршына басты.—Әйтерсең, мин үзем юлны белмим!—Кара инде, күлмәгемнең изүен умырып төшерде.

Нәсихов бераз үз күзенә ышанмый торгач:

—Син Әнисме?—дип урынсыз сорап куйды.—Син каян килеп чыктың? Кайчан? Сине бит милиция, прокуратура эзли.

—Прокуратура? Милиция? Мин нәрсәгә кирәк булдым аларга?—Әнис агарынып китте.—Нәрсә булды? Һич аңламыйм. Менә училище ишек алдында күренүем булды, Идмас килеп ябышты.

—Син берни дә белмисеңмени?

—Нәрсәне? Әнисә мина хат язармын дип калды. Ә үзе язмый. Күнелем нидәндер шикләнде дә менә кайтып белим дидем.

—Алай икән.

Идмас кулларын бутарга керешге:

—Кара син аны, ә! Берни белмәгән булып кылана! Юк инде, тәти егет, җаваплылыктан котыла алмассың хәзер.

Директор инде үз-үзен кулга алып өлгерде, ул Идмасны тынычландыра башлады:

—Тукта әле, Фәсхетдинов. Сабыр ит.

—Сез сабыр ит дисез.—Идмас йөзен җыерды.—Ә кем ана йөргән кызын мәсхәрәләргә ирек биргән. Әнисәне яраткан булып кына йөргән икән. Ике йөзле! Сталин үлгәч тә еламаган иде ул. Мин яхшы хәтерлим!

Боларны ишеткәч, Әнис шаккатты.

—Сафа абый, нәрсә сөйли ул?! Кем мәсхәрәләгән? Әнисәнеме?

—Туктагыз әле, егетләр. Әйдәгез, тәртип белән генә... Әнис, сине Әнисә пароходка озатырга бардымы?

—Барды, барды. Озатып калды. Нәрсә булды, Сафа абый? Әйтегез инде.

—Пристаньда син киткәндә тагын кемнәр бар иде? Араларында танышлар юк идеме?

—Кеше бик әз иде. Танышлар юк иде. Йә, әйтегез инде, нәрсә булган Әнисәгә?

—Һе, белмәгән булып кылана! Нәрсә булсын, син аны көчләгәнсең ич!—Идмас төкерекләрен чәчеп сүзгә кысылды.—Белмәгәнгә сабыша!

—Көчләгән! Минме! Син ни сөйлисең, бакыр баш!

—Туктагыз әле, дим, егетләр. Һм-м... Сине, Әнис, эзлиләр бит. Шик сиңа төшә...

—Мина? Әнисә кайда? Ул исәнме? Әйтәм аны, хаты юк!

Әнис кинәт сикереп торып, ишеккә ташланды. Ана каршы төшәргә теләгән Идмас өлгерә алмый калды. Әнис чыгып йөгерде. Аның артыннан Идмас та йөгерде. Нәсихов коридорга чыккач, аларның кызлар тулай торагына кереп киткәннәрен күреп калды. Үзе дә шунда ашыкты. Нәсихов Әнисә яшәгән бүлмә ишеген шакыганда анда инде давыл купкан, кызлар Әнисне сарып алганнар, теткәләп ташларга җыенган кебек, кызарып-бүртенеп аңа ябырылалар иде. Директор килеп кергәч тә алар тынычлана алмадылар, кычкыруларын дәвам иттеләр.

—Син нишләдең?

—Ничек шуңа намусың җитте, ә?!

—Ярата, имеш!

—Сине бит ул өзелеп ярата иде, ә син! Их!

Әнис кызларның әле берсенә, әле икенчесенә борылып карый, нәрсәдер әйтергә тели иде, тик кызлар һаман ду киләләр, аңа авыз ачарга да ирек бирмиләр.

Нәсихов кызларны тынычландыра башлады:

—Сабыр итегез, кызлар! Сабыр итегез. Әнискә дә сүз әйтергә ирек бирегез.

Әнис тирә-ягына каранып, маңгаендагы тир тамчыларын сөртеп алды.

—Нәрсә соң инде бу? Минем бер гаебем дә юк, кызлар, Сафа абый. Ышаныгыз. Честное комсомольское. Ул мине озатып калды. Әйттем мин аңарга—озатма, дидем. Инде караңгы төшкән иде. Болытлы төн иде.

—Болытлы булгандыр шул. Сиңа ярдәмгә.—Моны Идмас кыстырып куйды.

—Син теленне тыясыңмы, юкмы? Нинди ярдәм! Әйтегез әле, Әнисә үзе кайда соң? Больницадамы? Кайсында? Мин барып күрим әле. Әйтәм, хаты юк. Көтәм-көтәм, җавап язмый.

Кызлар тынычлана төштеләр булса кирәк, Әнисә караватына карап куйдылар.

—Әнисә үзе кайда соң?

Кайсыдыр:

—Чыннан да? Ул кайда соң әле? Туалетта түгелме?—дип шунда йөгерде.

Әнисә анда да юк иде. Нәсихов тагын шөбһәләнә калды:

—Лилия, Фирдәвес, сез белмисезме? Сез ничек соң аны күздән югалттыгыз? Аңа игътибарлы булырга дип кат-кат әйткән идем ләбаса. Барыгыз, эзләп табыгыз,—диде ул.—Ә син, Әнис, әйдә минем белән. Училище классларын карап килик.

Кызлар дәррәү коридорга, тулай торак бүлмәләренә сибелделәр. Әнисәне беркайда таба алмагач, аның урын-җирен актара башладылар. Бәхетсез кызның әйберләре үз урынында, тик бер-ике күлмәге, җылы йон кофтасы, плащы юклыгы беленде. Тәрбияче Ксения Юрьева йөгереп кенә сестра-хозяйка янына барып килде. Әнисәнең чемоданы үз урынында иде. Яңа хәбәрне ишеткән егетләр, кызлар бик тиз генә училище бүлмәләрен, чарлакны тикшереп чыктылар. Әнисә беркайда да юк иде.

Хәбәр бик тиз милициягә барып җитте. Кызны инде милиция хезмәткәрләре эзли башлады. Егетләр белән көне буе анда-монда чапкан, әлсерәгән Әнисне кичен кулга алдылар.

## 12

Ә Әнисә бу чакта Тәтеш ягына баручы очраклы машинага утырып Идел янына килеп житкән иде. Кулындагы төенчеген алып машина әржәсеннән төшкәч, ул кабинадагы шофер янына килде дә ана ике сум акча сузды.

—Рәхмәт сезгә,—диде ул.—Ике сум житәдер бит?

Шофер кызга текәлеп карап торганнан сон:

—Шундый чибәр кыздан акча алсан, жир йотар. Кирәкмәс, сал кесәнә. Кая юл тотуын, матурым?—диде.—Йөзеннән күреп торам, бик борчылгансын. Бирешмә син, бирешмә. Дөньяда матурлык яшәмәсә, анын мәгънәсе калмый. Ярый, хуш иттек.

Машина тузаны таралгач, Әнисә Иделнен аръягына пристаньга чыгучылар арасына кереп басты. Ул әле кая китәсен белми, бары тик үзен пычракка батырган район үзәгеннән, анын гүзәл мәхәббәтен изгән, яшьлегеннән мәхрүм иткән урыннан тизрәк китәргә, качарга гына тели иде. Үзен эзләргә ташланачакларын чамалаганга, Әнисә Переволоки пристанена түгел, Тәтеш пристанена китәргә карар кылды. Пристаньда эзләми аны каян эзләсеннәр тагын. Ә Тәтешкә эзләп килгәндә, ул инде киткән булачак. Тик менә кая китсен икән ул? Казанга барырга һич ярамый, анда анын Әнисе, анын бу дөньяда ин яраткан, ин якын кешесе укырга керергә йөри. Ин якын? Их, йөрәккә ин якын да бит, ә менә хәзер аларнын аралары! Эштән чыгарылып, мәсхәрәләнеп, исеме бөтен дөньяга таралгач, Әнисенен күзенә ул беркайчан да күренә алмаячак. Әнис белән алар бер-берсе өчен үләргә дә әзер иде. Бер-берсен мәнге ташламаска антлар эчтеләр, вәгъдәләр бирештеләр. Ә кем белгән аларнын гүзәл мәхәббәте менә шулай көтмәгәндә чәлпәрәмә киләсен. Их, Әнис, Әнисем, бәгърем, мәхәббәтем, күз нурым, хуш мәнгегә. Мәхәббәтебез хакына син мине гафу итәрсен, тора-бара онытырсын. Ә мин сина гомерем буе турылыклы булып калырмын.

Уйлана торгач, Красный Бор районынын Кырынгы авылында әнисенен сенлесе—Сәрия апасы яшәгәне исенә төште. Башта шунда барып чыксын әле ул. Аннары күз күрер. Ин яхшысы йә Себер, йә Урта Азия якларына юл алу. Аннан аны беркем дә эзләп таба алмас. Әнисә булган акчасын барлап, Красный Бор пристанена тикле билет алды. Дөрес, ана Кама Тамагында икенче пароходка күчеп утырасы бар, диделәр. Бусы әйбәт тә иде. Димәк, анын эзе тагын да чуалачак.

Пароходнын Переволокида туктап торачагын Әнисә уйлап бетермәгән иде. Пароход кузгалып киткәч кенә анын башына уй килеп төште: әгәр аны пристаньда эзләп йөрсәләр? Ярый әле бу уй вакытында башына килде. Димәк, ничек тә качып калырга кирәк. Кыз «Джамбул» пароходынын трюмында ин ерак, яктылык саран гына төшә торган почмак идәненә кайсы ятып, кайсы утырып баручылар арасына кереп урнашты. Косынкасын мангаена ук төшереп бәйләде. Ул Әнисе утырып киткән пристаньнын тизрәк артта калуын теләде.

Әнисә дөрес уйлаган, аны чыннан да пристаньда эзләп йөриләр иде. Эзләүчеләр арасында училище кызлары, егетләре дә, милиция хезмәткәрләре дә бар иде. Алар пароходка утырырга килгән кешеләргә Әнисәнен фотосурәтен күрсәтеп сораштылар, кассир хатынны аптыратып бетерделәр. Кассир хатын, юк, андый кыз миннән билет алмады дип әйттем ләбаса инде, дип тегеләрнен өметен бөтенләй кисеп куйды.

Бер мәлне трюм халкы гөжли башлады, карана-карана, кесәләрен актарырга керештеләр. Әнисәнен йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Шулай итеп, аны танып, алып калачаклар микәнни. Юк икән лә, контролерлар билет тикшереп йөриләр икән. Шулай итеп, Әнисә куркыныч пристаньны узып китте. Узуын узды, ләкин шушы пристаньнан ерак түгел үзенен тормыш юлы кискен борылыш

алуын искә төшерүгә аның йөрәге әрнеп-әрнеп сулкылдады. Кем соң аны шулай мәсхәрә кылды? Нинди явызы бәхетсез итте, мәхәббәтеннән аерды? Әнисә ул бәндәгә ләгънәт укыды.

Бәхеткә каршы, Кама Тамагы пристанендә ана күп көтәргә туры килмәде. Красный Борга кадәр йөрүче пароходка күчеп утыргач, ул бераз тынычлангандай булды. Тынчу трюм идәнендә аунап төн уздыргач, Әнисә һава суларга пароход койрыгына чыкты. Күбекләнеп артка йөгергән Чулман суына карап бара-бара аны тагын тирән уйлар басып алды. Бүгенге кебек үк бу су көннәр, айлар, еллар буена аккан да аккан. Кемнәрне генә күрмәгән, кемнәрне генә күкрәгендә йөртмәгән ошбу гүзәл елга... Аның әле сөзәк, әле текә ярлары буенда кемнәр генә ял итмәгән, хәл жыймаган, бөдрә таллар, биек-биек өянкеләр баскан култыкларына карап кемнәр генә хозурланмаган. Офыкларга тоташкан хуш исле куе үлән баскан болыннарында кемнәр генә тезелешеп-тезелешеп тирләп-пешеп печән чапмаган да, тәненең һәр күзәнәгенә иксез-чиксез ләззәт биргән шифалы суында коенмаган, колач җәеп йөзеп йөрмәгән. Кемнәр генә шушы изге елга буенда матур айлы кичләрдә сандугачлар җырына кушылып, йөрәктән дулаган табигый хискә бирелеп, сөйгәненә иң изге, иң саф мәхәббәтен ачмаган.

Үзенең бүгенге аяныч хәле исенә төшкән саен Әнисәнең йөрәге әрнеп, сыкрап, тырнап тибә. Мәхәббәтне иң татлы, ләззәтле, канатландыргыч хис диләр дә, ник соң ул газаплы, әрнүле сулышын өрде? Бөтен табигать шау чәчәктә гөрләп утырган, һәр җан иясе яшәргә ашкынып торган бу көннәрдә мондый рухи газап кешегә каян килә? Ник җаныңны тегермән ташыдай авырлыгы белән баса, тынынны кыса...

Әнисә кергәндә кешеләр уянып, аннан-моннан юынгалап, тамак ялгарга керешкәннәр иде. Кайсы йомырка белән ипи кисәге капкалый, кайсы кипкән балык суыра, сохари кимерә. Әнисәнең бернинди ризыгы юк иде, булган акчасын ул билетка тотып бетерде. Күршеләренә карамаска тырышып, һаман йокымсырап утырган булды. Юлдаш абыйлар, апалар да әнә капчыкларын баш астына салып черем итәләр, уянып дөнья хәлләрен сөйләшеп алалар, тагын яталар, торып, йөреп керәләр. Ни генә дисәң дә аларның азмы-күпме тамаклары тук шул, ә менә Әнисәнең...

Аның каршында утыручы, бумази күлмәк өстеннән иске халат кигән хатын кесәсеннән «Свобода» дигән нәни генә түгәрәк калай савытны алды да яргаланып, каралып беткән куллары белән ачып азаплана башлады. Калай савыт бирешмәде.

—Бирегез, үзем ачыйм әле,—диде Әнисә. Ул тырнакларын авырттыра-авырттыра ачып хатынга кире бирде. Трюмга вазелин исе таралды. Хатын бармак очы белән вазелин алып кулларына сөртте. Әнисәнең сораулы карашын күргәч:

—Әйе, наныем... Авыл хатынының куллары ярылмый нишләсен,—диде.—Чүп утарга да, сыер саварга да, бәрәнге әрчергә дә, кер уарга да, бүтән мең төрле эшкә дә шул бер кул бит инде ул.

Әнисәнең әнисе дә нәкъ шундый иде ләбаса! Ул чиста ак яулыгын арттан бәйләгән бу ягымлы хатынның тиресе яргаланып беткән кулларын үз кулларына алып күкрәгенә кысудан чак кына тыелып калды.

Бу пароход дигән нәрсә ник шулай әкрен сөйрәлә икән? Агымга каршы бару авыр инде, анысы. Ник пристаньнарда шулай озак тора? Ашыйсы килүне ничек басарга соң? Әллә үзе каршында Әнисәгә ягымлы күзләре белән карап барган ападан ипи катысы булса да сораргамы? Әнисә кичкә кадәр түзәрлек кебек иде, ләкин ашказанының сулык-сулык итүенә чыдый алмый башлагач, теге апайга сүз катты.

—Апа, ачуланмагыз әле. Сезгә үтенечем бар. Минем акчам бетте. Мең

төенчектә күлмәкләрем бар. Берәрсен сатып алмассынмы?—диде.

—Кичәдән бирле сина карап барам, кызым. Бу балага нидер булган дип уйлыйм, ә сүз кушарга унайсызланам. Укымышлы кешегә охшыйсын, андыйлар тик-томалдан сүз катуны өнәмиләр. Кил якынрак. Менә кружкага чәй ясап бирим. Ипи кисәгем дә бар. Икебезгә дә житәр, кил әле, кил.—дип бу апай ачык чырай күрсәтте.

—Мин бит бушлай түгел, апа. Менә шушы күлмәкне сезгә бирәм.

—Әй, бала-бала. Минем дә синен шикелле кызым бар. Ул да шулай дөнья жаен белми. Кирәкми мина синен күлмәген. Үзен киярсен. Нинди таза, матур, кер күтәрә торган икән.

Ягымлы караштан, жылы сүздән Әнисәнен күнеле тулып китте.

—Рәхмәт инде, апа,—диде ул.

—Син сон кая барасын болай? Бер ялгызын, кыз бала?

—Кырынгы дигән авылга баруым иде. Эшем төште. Бик тиз чыгып китәргә туры килде.

—Кырынгыгамыни? Мин үзем Чишмәледән. Якташлар икәнбез. Ә Кырынгыда кемен бар?

—Әнинен сенлесе Сәрия апа. Ул почтада эшли иде.

—Ә-ә, алай икән. Мин аны әз-мәз беләм бугай. Теге күп балалы Сәрия инде ул, алайса. Анын ире фронттан контузия алып, бик холыксызланып кайткан дигәннәр иде. Шул инде, шул, алайса.

Кайнар чәй белән ипи кисәге капкач, Әнисәгә хәл кереп китте. Юлдаш хатын сүзләрен ишеткәч, Әнисә сүзне артык сузарга теләмәде, рәхмәт әйтеп үз урынына барып утырды. Авыр уйлар анын жанын тагын тегермән ташыдай баса башлады. Әнис хат язмаганга үпкәлидер инде. Ничек яза ала идем сон мин ана?! Караңгы төндә юлда тотып көчләделәр дипме? Сүзенне тынламыйча сине озата барып шушы хәлгә төштем дипме? Әй, Әнис, Әнисем, син хәзер кайларда нәрсәләр уйлап йөрисен икән?

## 13

Әнисне прокуратурага алып килделәр. Ул үз хәлен әле дә анламый иде бугай. Ничек инде аны, Әнисәне үлеп яраткан кешене шундый пычрак эштә гаепли алалар?! Вәхши кеше эше ич ул! Ә Әнисә кайда икән сон? Ул ачыклык кертә ала лабаса. Аны таптыlармы икән, юкмы икән? Көчләделәр дип үзенә-үзе кул сала күрмәсен, Ходаем. Бик тә тәэсирләнүчән, эмоциональ кеше бит.

—Тиктомалдан кешене кулга алырга сезнен ни хакыгыз бар? Минем бер гаебем дә юк. Чишегез кулны!—дип Әнис һаман ачулануын баса алмады. Тикшерүче ләм-мим сүз әйтми бик озаклап анын кулын чиште дә йөзенә текәлеп торды. Тып-тын бүлмәдә стена сәгате тавышы буш мичкәгә чүкеч белән суккан кебек янгырый башлады. Шактый вакыт торганнан сон тикшерүче:

—Син, егет, монда тавыш күтәрмә. Шуны бел. Син менә әйт әле, Әнисә Әхмәдуллина дигән гражданканы беләсенме? Йә?—диде.

—Белмәскә! Бергә укыдык. Минем яраткан кызым ул. Сез аны таптыгызмы, юкмы?

—Алайса, бик әйбәт.—Тикшерүче сорауны жавапсыз калдырды.—Сөйгән кызын икән. Син аны сонгы кат кайчан күрден?

—Кайчан дип. Моннан бер атна элек. 20 июньдә ул мине пристаньда озатып калды. Мин Казанга киткәндә.

—Сәгать ничәдә?

—Сез пароход ничәдә килә дип беләсез? 11 сәгать 20 минутта килә ул.

—Әхмәдуллина нинди киемнән иде?

—Анысы нәрсәгә инде?

—Сорауны монда мин бирәм. Җавап бирегез.

Тикшерүче астындагы урындык ямьсез итеп шыгырдап куйды.

—Чәчәкле кыска җинле җинел күлмәктән иде.

—Күлмәге чиста идеме?

—Сез нәрсә инде? Кыз кеше пычрак күлмәк киеп йөри ди мени?

—Ул төнне яңгыр яуды. Сез яңгырга эләктегезме?

—Юк. Мин пароходка утырганда яшен яшьнәп, яңгыр килә иде. Мин әле Әнисәгә: юкка гына озата килдең. Яңгыр килә, ничек кенә кайтырсың, дидем.

—Ә аның күлмәк изүен син ерттыңмы?—Урындык күсе тавышлары чыгарып тагын шыгырдады.

—Нишләп мин ертыйм ди. Аның күлмәге ертылганмыни?

—Сез пристаньга барганда берәр җирдә туктап тормадыгызмы?

—Туктадык. Әнисә чәчәк ярата. Бер-ике урында туктап чәчәкләр өзгәләде.

—Утырып та тордыгызмы?

—Юк, утырмадык. Арымадык без. Икебез дә спортчылар. Ул акробатика белән шөгыльләнә, ә мин икенче разрядлы чаңгычы. Җиде-сигез километр юл безгә нәрсә инде ул.

—Ярар, мактанма. Син монда кайчан кайттың?

—Бүген, иртәнге пароход белән.

—Ник кайттың?

—Без көн саен хат язышырга сөйләшкән идек. Мин яздым. Ә җавап юк.

—Шуннан?

—Мин бик борчылдым. Күңелем нидер сизгән кебек булды. Белергә дип кайттым.

—Нәрсәне?

—Сезнең кайчан да булса яратканыгыз бармы? Булса, мондый сорау бирмәс идегез.

—Син сорауга җавап бир. Йә җаваптан баш тартам, диген.

—Бу сорауга җаваптан мин баш тартам. Яраткан кеше күңелен яраткан кеше генә аңлый, күрәсең.

—Яхшы. «Баш тартам». Шулай дип язып куйыйк.

—Языгыз. Минем Әнисәгә тимәгәнемне, аның өчен үләргә әзер торуымны да язып куегыз.

—Һе-е. Шушы хәлендәдәме?

—Әйе. Әгәр аны мәсхәрәләгән кешенең кем икәнен белсәм, үтерер идем.

—Әһә-ә. Димәк, үч алыр идең...

—Алыр идем. Ә сез?

—Син кайда икәнеңне онытма.

Стена сәгате тавышы тагын көчәйде.

—Сез миннән шикләнәсезме? Соң аның үзеннән сорагыз.

—Сорадык, сорадык. Син аны бик каты куркыткансың, ахрысы. Көчләүче син түгел диде.

—Алайса, ник мине монда алып килдегез. Җибәрегез.

—Менә бусы тиз булмас шикелле. Бик күп нәрсәләр ачыклыйсы бар әле,—диде тикшерүче кәгазьләрен кыштырдатып.

—Ачыклагыз. Ә мине җибәрегез. Без Әнисә белән икәү килеп барын да аңлатырбыз. Күрештерегез безне.

—Әнисәң югалды шул, таба алмыйбыз... Ярый, син әлегә утырып тор. Уйла, бәлки кайбер нәрсәләрне искә төшерерсең.

Тикшерүче рәшәткәле тәрәзәгә карап бераз уйланып торды да:

—Петров, алып кит!—дип кычкырды.

Ишектә кобурасын бил каешына таккан милиционер күренде, куе зәңгәр гимнастеркасын тарткалап, Әнис янына килде дә авыр кулын анын җилкәсенә куйды:

—Киттек.

Урамга чыгуга каршыларына тупыллардан юмарт коелган мамыкларны тирә-якка очырып, ашыга-ашыга килүче Сафа Нәсихов, курсташлары Илгиз Сәләхетдинов, Идмас Фәсхетдинов, Вәгыйз Миннуллин, тагын берничә егет очрады. Әнис:

—Сафа абый, бу нәрсә соң инде? Минем бер гаебем дә юк бит! Ярдәм итегез. Моны карт әти-әни ишетсә, авырып егылачаклар. Аларга ишеттерә күрмәсеннәр, зинһар,—дип туктап калды. Директор:

—Гаебен булмаса, бары да ачыкланыр, Әнис. Син артык борчылма,—диде.

—Сөйләшергә ярамый. Киттек, киттек.—Милиционер Әнисне КПЗ га алып китте. Әнис:

—Әнисәне һаман тапмадыгызмыни? Ул кайда икән соң?—дип сорарга өлгерде.

—Юк шул әле. Беркайда юк.

Әнис директор белән килгән егетләргә берни әйтергә өлгерә алмады. Анын күз алдыннан Идмасның мыскыллы карашы гына чагылып китте. Ул арада Илгиз ияреп килеп:

—Әнис, кайгырма. Без сезнең Әнисә белән нинди дус йөрүегезне аңлатырбыз. Сине озак тотмаслар, кайгырма!—дип кычкырып калды.

## 14

Икенче көнне дә Әнистән шул ук тикшерүче сорау алды. Әнис бүген аның йөзендә нindидер үзгәреш барын шәйләде.

—Йә, егет, инде барын да сөйләп бирергә булдыңмы, юкмы?—диде ул.—Әллә һаман үз сүзеңдә торасыңмы?

Төне буе йоклый алмыйча пычрак, караңгы камерада аунаган Әнис бик йончыган, хәлсезләнгән иде. Күз кабакларын көчкә күтәреп, ул тикшерүченең йөгерек күзләренә текәлде.

—Гражданин Лотфуллин, син сорауны ишеттеңме?

—Ишеттем. Мин кабат шуны гына әйтә алам. Мин Әнисә Әхмәдуллинага кагылмадым. Мин аны яратам. Ул да мине ярата. Әнисә мине пристаньда озатып калганнан бирле мин аны күргәнем юк. Безне аның белән очраштырыгыз, ул табылдымы?—диде дә Әнис сыгылып төште. Ул әле дә сасы камера исеннән айный алмый иде.

—Син гаебеңне танып, үзеңә хөкемне җинеләйтә аласың. Йә, ярар... Син миңа бу әйберне танышыңмы?—Хәйләкәр елмаеп, тикшерүче Әнис йөзенә текәлде.

—Минем югалган пәкем ич бу. Сез аны каян алдыгыз?

—Димәк, пәке синеке.—Урындык тагын күсе тавышлары чыгарып куйды.—Яхшы. Шулай дип язып куйыйк. Югалган иде, дисең инде. Ә кайчан, кайда югалтуыңны беләсеңме?

—Каян белим? Белсәм, шуннан гына табып алган булыр идем,—диде көлемсерәп Әнис.

—Димәк, белмисең. Ә мин беләм. Җинаять урынында югалткансың син аны.—Тикшерүче күз кырые белән генә үз сүзләренең Әниска тәэсирен күзәтте.

—Тагын «җинаять»... Мин беркемгә дә җинаять ясамадым.

—Син пәкене кайчан югалттым дисең әле?

—Әллә кайчан... Яз башында ук инде.

—Ә җинаять урынына ул ничек барып чыкты икән, ә? Үз аягы беләнме?

—Пәкем югалгач, тулай торакның бүлмәсен егетләр белән кат-кат актарып чыктык без. Таба гына алмадык.

Тикшерүченең йөзенә карангылык йөгерде. Аның ышанасы килмәве күренеп тора иде:

—Бу кайчан булды дидең әле? Кышынмы?

—Яз көне дидем ич инде.

—Моны кем раслый ала?

—Классташ, бүлмәдәш егетләрнең күбесе. Илгиз Сәләхетдинов, Хәтмулла Кәримов, Идмас Фәсхетдинов. Бүтәннәр дә. Ул пәке мина Әнисә бүләге.

—Ә пәкегә «Ә.Л.» дип үзең тамга салган идең ме?—дип дәвам итте тикшерүче.

—Ничек? Нинди «Ә.Л.»? Кая карыйм әле.

—Кагылма. Урыныңда гына утыр.

—Мин бернинди тамга да төшермәдем. Шундый матур пәкенең сөяк сабын бозалар ди мени?

—Ә яратып йөргән кызыңның сафлыгын бозсаң да ярыймы? Йә, бар, кайтып тор.

—Әллә мине чыгарасызмы?—Әнис шатланып китте.

—Һәй, нинди өлгер син. Ашыккан ашка пешкән.

—Уф... үләм...

—Үлмисең әле, үлмисең...

Әнисне тагын камерага алып киттеләр. Ул гаебем юк дип әйтеп тора бит инде. Нишләп соң аны һаман ябып тоталар? Бу мәхшәр кайчан бетәр? Хәзер аның бөтен тормышының асты өскә килде. Менә сиңа университет. Әле кайчан гына алар Әнисә белән киләчәккә нинди матур планнар корганнар иде. Бергә тормыш итәргә вәгъдәләшкәннәр иде. Шулай итеп бу хыялларның барысы да күккә очты микәнни? Аның хәзер бар өмете дә киселде микәнни...

## 15

Күптәннән аралашмаган Әнисә хәбәр бирми-нитми Кырынгыга кайтып төшкәч, Сәрия апасы гаҗәпләнә калды. Әнисәнең йончыган кыяфәтенә, соргылт йөзенә карап, пошаманга бирелеп сораша башлады: нәрсә булды, ник кайттың, каникулгамы, укуыңнан кумаганнардыр ич, әйберләрең кайда?..

—Мин берничә көнгә генә. Шаршудыга барып әнием кабере белән саубуллашам да китәм,—диде Әнисә.

—Тукта әле, тукта. Гомер эчендә бер күрешеп дигәндәй... Кая ашыгасың? Ишле гаилә булганга бездә әллә ни сый булмас инде ул. Хәлдә барынча кунак итәрбез. Әнә җизнәң дә шулай ди.—Сәрия апасы иренә сораулы караш ташлады. Тегесе:

—Дим, дим,—диде төксе генә.

—Мин кунак булырга кайтмадым, апа. Ачуланма, артыгын сорама да. Аңлатырмын әле бер. Йомышымны соңрак әйтермен.

Сәрия Әнисәнең йотлыгып катык ашаганын күреп, аның ачыкканын аңлады. Туганының артык ачыласы килмәгәнен чамалагач, төпченеп тормады. Йомышымны соңрак әйтермен диде ич. Төнлә Әнисәнең авыр ыңгырашканын ишеткәч, янына барып озаклап карап торды. Саташа да, ахрысы. Берәр бәхетсезлеккә юлыкканмы икән әллә?

Кайтканның икенче көнендә Әнисә апасына мунча ягарга булышты, сеңелләрен юып чыгарды. Үзе дә чабынып юынып чыкты.

Балалар белән мәш килгәч, тәне генә түгел, җаны да җиңеләйгәндәй булды. Матур күзләрендә аз-маз нурлар кабынып китте. Янына сарылып йөргән кызларга шифалы үләннәр хакында сөйләп алды.

Шаршудыга барып кайтыйм дигәч, Сәрия апасы ана ике йомырка, бәрәңге

кушып пешергән кабартмалар төйнәде. Нәни Рәхимҗан бу вакытта әнисе янында бөтерелде. Аның:

—Мина да йомырка бир. Әни дим, минем дә йомырка ашыйсым килә,—дигәнен ишеткәч, Әнисә тетрәнеп куйды. Йомыркаларның берсен Рәхимҗанга тоттырды. Бу йортта мин артык кашык лабаса. Тизрәк китәргә кирәк.

Шаршуды зиратына ул арт урамнан гына барып керде, аның беркем белән дә очрашасы килмәде. Хәер, аны танырлык кеше монда калдымы икән соң? Ул бит бик яшьли ятимнәр йортына эләкте. Шактый эзләгәч кенә ул әнисе каберен тапты. Кабер янындагы куе үләнгә утырып уйга талды.

—Әнием, бәгърем, син минем хәлемне беләсеңме икән?! Менә хәзер мина нишләргә инде. Син ничек кинәш итәр идең?

Тик ана кем генә җавап бирсен соң?

Зиратта тын гына басып торган каеннарның җинелчә җилдән лепелдәгән яфраклар тавышыннан башка бернинди тавыш та юк иде. Монда килгәч Әнисә тагын елармын дип белгән иде. Тик еламады. Елый алмады. Әллә инде күз яшьләре беткән, әллә аның иңнәренә ишелгән авыр хәлен сизенгән туган җире Әнисә җанына тынычлык индергән иде.

Әнисә кечкенәдән үк әбисеннән өйрәнгән бер-ике доганы укыды да хушлашырга дип башын кабергә куйды. Шул мизгелдә аның күңелендә моңа кадәр таныш булмаган хис уянды. Кыз талпынып куйды. Аның әнисе ана булып дөньядан китте. Ә ул? Беркайчан да ана булмаячакмыни? Дөньяның нинди зур галәмәте бит бу! Миһербансыз бер адәм аны пычратты, мәхәббәтеннән аерды. Баланы бит аны сөйгән кешеннән генә табалар. Югыйсә баланны ничек сөясең? Димәк, ул беркайчан да бәхетсез бала тапмаячак. Беркайчан да ана булмаячак. Кинәт аның башына коточкыч бер уй килеп, миен бораулый башлады. Әйтерсең лә Әнисәне баштан аяк кайнар су белән коендырдылар, ул хәтта бөтен тәне кызыша башлаганын тойды. Теге хайван соң пычрак кешедән балага узган булса! Үз хәленең тагын да хәтәррәк икәнен ул менә әле генә төшенде. Нишләрмен, кая барып егылырмын, кеше күзенә ничек күренермен? Мондый хурлыкка түзеп яшәгәнче яшәмәвең хәерлерәк түгелме?

Авыр уйларына бирелеп Әнисә шулай шактый утырды. Инде көн сүрелеп бара, кайтырга кирәк иде. Алда бары авыр билгесезлек, бәхетсез көннәр дәвамы. Юлда ана кемнәрдер очрады, нидер әйтте, сорашты, тик ул боларны төштә күргән кебек шунда ук онытты. Аны бер генә уй биләде—каядыр барырга, нидер кылырга кирәк, тик нәрсә—Әнисә моны тәгаен белми иде. Бер мәлне кылт итеп аның күз алдына Әнис килеп басты, әмма бу аның хәлен тагын да авырайта төште. Әнис инде еракта, бик еракта, бәхетле, мәхәббәтле тормышта, томан эчендә калды. Ана хәзер юл өзелгән иде.

## 16

Әнисненң үтенечен тыңлап, аны машинага утыртып пристаньга алып киттеләр. Куаклар юлга якын үскән бер урында туктап машинадан төшерделәр. Әнисненң йөзен, үз-үзен тотышын җентекләп күзәтеп торган тикшерүче бу куаклар янында аның тынычсызлануын көткән иде. Ләкин Әнис башын игән килеш уйга талып тик басып торды. Йә тикшерүченең, йә машина йөртүченең куаклар арасына кереп хаҗәт үтисе килгәндер дип кенә уйлады. Куе кара кашлы тикшерүче беразданн:

—Бу куакларны таныйсыңмы?—дип сорады.

Әнис гаҗәпләнде:

—Юл кырыендагы үскән барча агач, куакны ник танырга тиеш соң әле мин? Моның нәрсәгә кирәге бар?

—Ярар, танымасаң, киттек, алайса. Әнисәң менә шушында көчләделәр дигән иде.

Пристаньга килеп җиткәч, Әнисне пассажирлар залына алып керделәр.

Залда беркем дә юк иде. Яшь кенә милиционерны сакта калдырып, тикшерүче каядыр чыгып китте. Егетнең йөрәге тагын әрнеп-әрнеп тибә башлады. Әле кайчан гына алар Әнисә белән бергә пароход көтеп, вак дулкыннарның чупылт-чупылт пристаньга бәрелеп күбекләнеп торуларын озак-озак карап тордылар. Кояшның кызарып, зураеп, аргы як яр артына төшеп китүен күзәттеләр. Шул чакта Әнис:

—Менә, Жир шарының түгәрәклеген исбат иткән бер мисалны үз күзебез белән күзәттек,—дип сөйгәненең көлдереп алган иде. Ә менә бүген! Кем уйлаган мондый хәлләрне. Ничек килеп чыкты соң бу... Әнисненң җылы су, суүсемнәр исеннән тагын башы әйләнә башлады.

Зал ишеге сискәндереп кинәт ачылып китте, аннан тикшерүчегә ике ир-ат ияреп керде. Әнис аларны шунда ук танып алды. Болар теге көнне пристань тросына бәреләзып килеп туктаган балыкчылар иде. Алар зал уртасына уздылар да Әнискә текәлделәр. Әнис үз хәленнән уңайсызланып, оялып читкә борылды. Ә шулай да миеннән боларның ярдәме тимәс микән дигән уй узып китте.

—Йә,—диде, тикшерүче ирләргә карап.

—Шул бит,—диде тегеләрнең берсе иптәшенә карап.

—Әйе, шул егет, шул.—Икенчесе дә иптәшенең сүзен җөпләде.—Бу егет бик боевой бер кыз белән пароход килгәнне көтеп торды.

—Кайсы көнне инде ул?

—Исендәме, Коля, ул көнне без бик зур чуртан каптырган иек. Менә шуның хәтле.—Балыкчы кулларын җәеп, тикшерүчегә борылды.—Мин спинингны ыргытуым булды, кинәт леска бик нык тартылып читкә атылды. Мин әле Коляга әйтеп куйдым. Бу ике-өч килолы боевой чуртан булса, мин әйтәм, бер ярты алабыз инде, дим. Шулай булды да. Коля белән без ул чуртанны көчкә тартып чыгардык, әйе. Аны күрүгә минем хатын...

—Туктагыз әле. Анысы соныннан...

—Соныннан дип... Өч килолы боевой чуртан бит ул көн саен эләкми, парин. Хет елап утыр... көне буе...

—Аңлашылды, аңлашылды... Әйтегез әле, бу егет үзе генә идеме?

—Әллә шаяртасыз инде, иптәш тикшерүче! Нишләп үзе генә булсын. Аның янында бик чибәр боевой бер кыз да бар ие, дим ич.

—Әйе, әйе. Алар гел кочаклашып басып тордылар. Без кирәк-яракны, балыклы чиләкне көймәдән алып чыкканны карап калдылар. Үзләре гел елмаялар, безгә карап нидер сөйләшеп алалар.

Боларны ишеткәч, Әнисненң эченә җылы йөгерде. Ул торып басты. Милиционер аны җилкәсеннән этеп кабат урынына утыртты.

—Әйе шул. Мин әле Степанга әйтеп куйдым. Их, мин әйтәм, нинди матур чаклары боларның...—Ирләрнең Коля дигәне кабат сүзгә кушылды.

—Ә ул кыз нинди күлмәктән иде?

—Кыска җиңле җәйге, көнбагыш чәчәге төшерелгән җинел күлмәк кигән ие. Без әле аның күлмәге үзенә бик төс килгән икән, дип сөйләшеп тә кайттык.

—Чибәр кыз, бик чибәр кыз иде, әйе.

—Күлмәге ертылмаган, чиста идеме?

—Ну инде...

—Сез аларны якыннан күрдегезме?

—Алар белән безнең ара 5—6 метрлап булгандыр инде.

—Әйе, шуннан артык түгел. Без көймәне пристань тросына бәйләп, йозакка бикләп калдырабыз.

—Алайса, сез инде бернинди дә шикле нәрсә күрмәдегез.—Тикшерүче һаман үз ягына каерды.

—Нинди шик инде ул. Без киткәндә дә алар кочаклашып басып карап калдылар, дим ич.

—Ярар, инде китсәгез дә ярый. Файдагыз тимәде. Кирәк була калсагыз, чакыртып алырбыз.—Тикшерүче канәгатьсезлеген яшерергә кирәк тапмады.

Балыкчылар Әнискә борылып карый-карый чыгып киттеләр. Берсе ишек төбендә туктап, Әнискә күз кысты. Тикшерүче моны күреп калды. Анын башына берәр уй килде бугай, ул тиз генә ишекне ачып:

—Сез сәгать ничәләрдә кайтып киттегез?—дип кычкырды.

—Сигез, тугызынчы яртылар булгандыр. Кояш әле баемаган ие,—дигән җавапны ишеткәч, тикшерүче Әнискә төбәлде.

Әниснең йөзенә алсулык йөгерде, ул еш-еш сулыш алып, торып басты.

—Менә күрдегезме,—диде ул.—Минем гаепсез икәнемне хәзер аңладыгызмы инде, ә? Җибәрегез мине. Мин дә сезгә Әнисәне табарга булышыйм.

—Ашыккан ашка пешкән дип әйткән идем инде мин сина. Боларның сүзе берни дә расламый әле.

—Ничек инде? Алар кочаклашып тордылар диделәрме? Көчләнгән кыз кочаклашып торыр идеме?

—Алар сезне сәгать сигезләрдә, тугызынчы яртыларда күргәннәр. Шулаймы?

—Шулай. Йә, шуннан?

—Әйтик, тугыздан соң пароход килгәнче күпме вакыт бар?

Әнис лып итеп урындыкка утырды. Эш тагын кире якка борылды, күнелендә туган өмет чаткысы кабат сүнде. Күз алдына ниндидер кара шәүлә килеп басты.

—Беләсезме, нәрсә!—диде Әнис кинәт кенә.—Без пароход килгәнне көтик.

—Ни пычагыма?—Инде үзе дә йончый төшкән тикшерүче тагын усал карашы белән Әнискә текәлде.

—Бәлки мине «Свирьстрой»нын капитаны, йә берәр матросы таныр. Мин Казанга шул пароходка утырып бардым бит.

—Юк инде, егетем. Башка вакытта...

—Сез тәҗрибәле кеше ләбаса. Башка вакыт булмаска да мөмкин. Күргән кешеләрнең безне онытуы, эшләрен ташлап китүе ихтимал. Үтенеп сорыйм, зинһар, пароходны көтеп алыйк без.

Тикшерүче икеләнә калды:

—Һе... Безнең дә начальство бар. Кинәшеп алыйм әле, булмаса.

Ул телефонлы бүлмә эзләп чыгып китте. Анын кире килүен көтә-көтә Әнис гаҗиз булды. Анын өчен хәзер бердәнбер өмет булып пароход кешеләре калды. Әгәр алар Әнисне танып, Әнисәнен яулык болгый-болгый озатып калганы расланса, котылачак бит ул. Котылачак. Тикшерүче, сыра исе анкытып, авызын сөртә-сөртә кире килгәнче Әниснең күнелендәге өмет йөз мәртәбә кабынып, йөз мәртәбә сүнеп өлгерде.

—Ярар, синенчә булсын. Начальство каршы түгел. Көтик, алайса,—диде тикшерүче.

...Ниһаять, тирә-юньне яктыртып пристаньга пароход килеп туктады. Шыгырдатып басманы пристаньга сузганны көткәндә Әниснең йөрәге ярылырга җитеп кага иде.

Анын колагына тагын тикшерүче бүлмәсендәге теге сәгатьнең ярсып-ярсып типкән тавышы ишетелеп китте. Пароходтан чыгучылар да, керүчеләр дә әз иде. Тикшерүче Әнисне милиционер карамагында калдырып чыгып китте дә бераздан пароход капитанын ияртеп кире керде. Ул эшне аңлаткан булган, күрәсен, капитан бүлмәгә керүгә, Әнискә карап:

—Шушымы?—дип сорады. Тикшерүче баш какты.

Капитан бер якынрак, бер ераграк китеп Әнискә карап торгач:

—Әллә тагын... Пароходка утырган кешеләрне каян танып бетерәсең. Пассажирлар пароходка кергәндә бер-берсен чүт кенә таптамыйлар. Юк, әйтә алмыйм, гафу итегез, мин эштә,—дип чыгып китте. Әнис өнсез калды. Инде бөтен өмет матроста иде.

Егерме-егерме биш яшьлек куе кара чәчле, шомырттай кара күзле, беләкләре бүлтәеп чыккан матрос егет, бүлмәгә килеп кергәч, башта аптырабрак торды.

—Минем милиция, прокуратура белән беркайчан да эш иткәнем юк. Аллам сакласын,—диде ул.

—Ярар, алайса, бик әйбәт,—диде тикшерүче.—Сез менә бу егетне танымыйсызмы?

Әнис торып басты да аңа ялварулы караш ташлады.

—Һо! Бәхетле егет, бу синме? Ни булды?

Тикшерүче:

—Танýйсызмы, юкмы?—диде коры гына.

—Кәнишне, таныйм.

—Кайда күрдегез? Сез аның белән таныштмы?

—Таныш түгел түгелен. Берәр атна булыр, аны бик чибәр кыз елый-елый озатып калды. Ну чибәр иде, первый класс. Шуңа күрә без әле бер-ике пассажир белән бу егетне нинди бәхетле дип сөйләшеп алдык. Сина нәрсә булды соң, егет. Милиция...

—Әйе, бәхетем минем хәзер ташып тора менә.

—Ул кыз елый иде дисез инде?—Тикшерүче үз ягын каера бирде.

—Егете дә нинди бит аның! Еларлык шул. Алар бер-берсенә шулкадәр пар килгәннәр, әй. Кара син аның дулкынланып торган чәчләрен! Кашларын!

—Бәлки, ул үпкәләп, йә берәр башка сәбәптән елагандыр?

—Анысын белмим. Бәлкем, аерылып калу авыр булгандыр. Пароход киткәнче кочаклашып басып тордылар. Мин басманы алам бит, дигәч кенә менә бу бәхетле егет кереп утырды. Мин әле соңыннан да күз салгаладым. Ул кыз бик озак яулык селкеп, кул изәп калды. Кереп утырыр алдыннан егетне үпте дә бугай. Вәт шул.

—Тагын берәр шикле нәрсәгә игътибар итмәдегезме? Киемендә, әйтик.

—Иттем. Матур күлмәген кабартып торган матур имиләренә. Ну, егет, син чыннан да бәхетле икәнсең. Йә, ярар, беттеме? Кул куясы түгелме? Йөгерим, безнең капитан ул коры кеше. Кстати, ул төнне яшенле яңгыр булды.

—Ярар, рәхмәт, хушыгыз.

—Хушыгыз. Егет, хуш. Кызың бик чибәр синең, саклый күр син аны.

Матрос йөгереп диярлек чыгып китте. Ул арада «Свирьстрой» өченче сигналын биреп яңа туып килгән айның су өстендәге алтын күперенә юл тотты.

...Ике көннән Әнисне иреккә чыгардылар. Ә аның Әнисәсе суга төшкән кебек юк булды.

## 17

Чарджуй шәһәрендә ул көнне бик көчле җил чыкты. Күкне тузан болыты каплады, хәтта кояш та тузан аша күренмәс булды. Әнисә яши торган йорт каршындагы тупыл тамырлары белән кубып, гөрселдәп юлга ауды. Ачы тозлы тузан тәрәзәләрдән, ишекләрдән бүлмәләргә тулды, шкафларга, өстәлурындыкларга калын катлам булып ятты, кешеләрнең күзләренә керде, тешләрендә чытырдады.

Әнисәнең биредә мондый көчле туфанны беркайчан да күргәне юк иде.

Жил котырынып-котырынып исә башлагач, ул ишек-тәрәзәләрне япты, аннары йорт хуҗасы Саҗидә янына икенче бүлмәгә чыкты да ана сыенды.

—Курка калдынмы әллә, Әнисәкәй?—диде апасы.—Була ул мондый хәлләр бездә, була. Көньяктан эссе жил исә дә чүлдән әллә нинди тузан өермәләре алып килә. Мәхшәр! Без чүл уртасында яшибез ләбаса. Чарджуй Ташкент та, Ашхабад та түгел шул. Асфальт аз, тузан оясы инде бер карасаң.

Әнисә моның шулай икәнен ел ярым элек килеп урнашуга ук белде. Ул тимер юл вокзалына килеп төшкәч, Сәрия биргән адрес белән Саҗидәләрне эзләп йөргәндә малай-шалайның ялан аяк йөрүенә игътибар иткән иде.

Урамда калын булып яткан тузанны сөреп кенә баралар! Соныннан моны Саҗидәгә сөйләгәч, апасы:

—Әй, сенелкәй, без мона ияләнгән инде,—диде.—Ничек кенә сакланып йөрмә, берәр җиргә барырга чыксаң, тездән тузанга батып кайтасың. Кая инде монда аяк киемен чисталыгы!

Ләкин ничек кенә булмасын, Әнисә үзе укыткан класс укучыларын—төрекмән, рус балаларын чисталыкка өйрәтергә тырышты. Балалар мәктәпкә керер алдыннан җәй булса, аяк киемнәрен селкеп, кагып, башка вакыт булса, кырып юып, яхшылап сөртеп, чистартып керә торган булдылар. Училищеда өйрәнгән гадәт монда бик ярап куйды.

Давыл котырынды-котырынды, ә янгыр яумады. Җил басылгач, Әнисә бүлмәләргә кереп тулган тузанны сөртте, идәннәрне юып чыгарды. Саҗидә:

—Рәхмәт, сина, Әнисәкәй. Менә Низам абыен кайтканчы ялт иттерден,—диде.—Әнә гомере озын булыр, кайтты да бугай.

—Ул түгелдер. Ул булса, капка кагып тормас иде. Кемдер кечкенә капканы кага ич анда,—диде Әнисә.—Кая, чыгып ачыйм әле.

—Юк, үзем ачам. Ә син табын көйли башла.

Саҗидә кечкенә капка келәсен ачкач, анда бер ят кеше пәйда булды.

—Сәмәрканд урамы, 13нче йорт шушы буладыр инде,—диде бу ир-ат, тирә-ягына каранып.—Тәки таптым бит.

—Сез кем буласыз соң? Бер дә күзгә-башка күренгәнегез юк шикелле иде?

—Мин ерактан, Татарстаннан килдем, апа.

Апа дигәч, Саҗидә ир кешегә төбәлебрәк карап алды. Әйе, дөрестән дә, апа диярлеге бар икән, дип уйлады Саҗидә. Башта гына олырак булып күренгән икән. Бакырсыман чәчле. Күзләре ничектер сәер карый. Әле изүгә, әле чәч-башка карашы төшә, гәүдәмне дә тиз генә күзе белән сыпырып алды.

—Татарстаннан укмыни?

—Әйе. Мина менә шушы адресны биргәннәр ие. Әхмәдуллина Әнисә монда яшиме?

—Монда, монда. Әйдә, узыгыз, уз. Әнисәү, менә монда бер егет сине сорый, карале.

Ишек шыгырдап ачылып китте. Анын уемында изүен яба-яба Әнисә күренде.

—Әнисә! Таптым бит, таптым!—дип егет шатлыгыннан нишләргә белмичә анын янына ашыкты.

—Абау!—Әнисә аптырап хәтта чигенеп куйды.—Идмас, димме? Каян, ничек болай? Әллә сине давыл китереп ташладымы?

Әнисә кинәт очынып барып, Идмасның муенына сарылды.

—Каян килеп чыктың син? Каян?!

—Әнисә, кунакны йортка алып керик. Болай ярамый инде.—Саҗидә Әнисәнең кунак муенына сарылуын ошатмады, бугай.—Әйдәгез, узыгыз. Хәзер хуҗа абыегыз да кайтып җитәр.

Әнисә Идмас куенынннан чыкты да шатлыклы күз яшьләрен сөртә-сөртә ишеккә юнәлде. Идмас ана ияде. Кызның алсуланып киткән янаклары, төз, матур аяклары, сылу гәүдәсе, муенына килеп асылынганда тиеп киткән йомры күкрәкләре анарда күптәнге хисләрен уятып җибәрде. Ләкин егет үзенең соклануын яшерергә тырышты.

—Димәк, син шушында качып ятасың икән,—диде ул.—Без сине эзли-эзли аптырап беттек.

Әнисә һаман ни әйтергә дә белмәде, ул каушаган иде.

—Качып, дип. Юк, тик...

—Ә мин кичә төнлә килеп төштем. Чемоданымны саклык камерасына тапшырдым да вокзалда кундым. Урындыкта озак йокланылган. Адресың белән эзләргә чыгарга дип торганда давыл купты. Инде менә... килеп таптым.

—Ярар... йә, сөйлә, Идмас, анда ниләр бар? Утыр, утыр. Кайда яшисең, кайда эшлисең? Бергә укыган кызлар, егетләр кайларга таралып бетте? Аралашасызмы? Монда ник киләсе иттең?

Әнисә сорау артыннан сорау яудыра башлады. Бу анын каушап калуын яшерергә тырышуы булды, күрәсең. Һич көтмәгәндә бөтенләй чит-ят җирләрдә Хөзер Ильяс шикелле кинәт шулай килеп чыксыннар әле. Икенчедән, ул бит киткәннән бирле Сәрия апасыннан башка беркем белән аралашмады, хат та алышмады. Анда да сирәк кенә... Аның Төрекмәнстанда икәнлеген бары тик Сәрия апасы гына белә иде. Бары ул гына. Идмас аның адресын Сәрия апасыннан алган микәнни? Нәрсәгә? Ә апасы ник биргән инде? Әнисә бит аңа адресымны беркемгә дә бирмә дигән иде. Әнис исемле егет сорап килсә, бигрәк тә.

—Әнисә, Әнисә дим, аннары, аннары... Кунак кеше шундый ерак юл килеп арыгандыр, әйдә, башта чәй эчерик. Әйдә, табынга килегез,—дип Сажидә яшьләрне чәйгә өндәде.

—Апа, мин сезне Сажидә апа дип беләм. Дөресме? Димәк, дөрес әйткәннәр, алдамаганнар. Ә мин ышанмаган да идем. Туктагыз әле, мин башта чемоданымны алып килим. Чәйне аннары эчәрбез. Анда күчтәнәчләрем дә бар ич.

Идмас йөгереп диярлек чыгып китте. Ул авыр чемоданын күтәреп вокзалдан кайтканда Низам да өйдә иде инде.

—Алайса, син безнең Әнисәне эзләп килдең инде. Мин шулай дип беләм,—диде ул Идмаска чәй эчкәндә.—Эзләрлек тә шул. Чибәрлеге белән тан калдыра кызый. Монда әнә сөлек шикелле төрекмән егетләре дә ул килгәннән бирле безнең урамны үз иттеләр.

Болай туры бәреп сөйләшүдән Идмас бераз каушабрак калды.

—Эзләп дип... Без бит... бер училищеда укыдык...

—Шуның өчен генә дөнья читенә килеп чыкмыйлар, егетем. Бергә укыган кеше күп булыр ул, иеме, Сажидә?

—Йә инде, Низам, кунак кешегә бәйләнеп утырма. Менә ул алып килгән кетерманне кимер. Арыш икмәге сохарие. Без инде аның тәмен дә оныткан идек. Монда бит лаваш та лаваш.

Хуҗаның йөзе яктырып китте:

—Менә анысы өчен рәхмәт, Идмас энем. Рәхмәт. Үпкәли күрмә, мин үз балаларымны да туры юлдан гына йөрергә, дөресен генә сөйләргә өйрәттем. Аллага шөкер. Менә дигән кеше булып үсеп җиттеләр. Улыбыз Мәскәүдә зур бер хәрби институтта эшли. Кызыбыз нефть институтында Казакъстанда укыта. Вәт шулай.—Низам горур иде.

—Сез бик бәхетле ата-ана икәнсез. Ә монда ничек килеп чыктыгыз соң?

—Без бала чакта ук әти-әниләребез монда күчеп килгәннәр, ие. Сажидә апаның да, минем дә.

—Әйе, әти-әниләр туган як дип өзелеп сөйлиләр иде.—Сажидә дә сүзгә кушылды.—Күрә генә алмый вафат булдылар. Бик сагыналар ие шул.

—Ник кайтмаганнар соң?

—Дөнья бит, аның мәшәкатьләре... Колхозлашу, кулакларны сөрү. Туганнарыбызны Себергә сөргәннәр... Анда ничек кайтасың?

—Әйе... Булган шул андый хәлләр, булган.

—Йә, ярар. Бүгенгә житеп торыр. Син безгә туган яклар турында бәйнә-бәйнә сөйләрсең. Озакка килдеңме соң?

—Белмим әле. Бәлкем, монда торып та калырмын... Әйеме, Әнисә? Әнисә менә нәрсә дияр.

—Әйттем бит юкка килмәгәнсең дип. Әнисә шикелле багалма йөгертә ул. Тик кара аны, мотри!—Низам шаярып Идмаска бармак селкеде.

—Низам абый, син нәрсә инде,—Әнисәнең бит очлары алланып китте.—Каламы, юкмы, аның үз эше. Биштән үткән, бишектән чыккан диләрме әле. Минем мона ни катнашым бар... Дөнья иркен.

—Ярар, ярар. Болай гына әйтүем. Яшьләр эшенә борын тыгуым түгел. Ходай язганча булыр.

## 18

Яшьләр көннәр буе сөйләшеп туя алмадылар. Бигрәк тә Әнисә кунактан барын да бәйнә-бәйнә сөйләтте. Татарстанда нәрсәләр бар? Халык һаман шулай авыр яшиме? Классташларның кайсы кайда эшли? Куйбышев сусаклагычы төзелү сәбәпле шәһәрне дә, педучилищены да бүтән урынга күчерү турында карар чыккан иде, ул эшләр ничек бара? Минем классташлар кайда икән? Лилия? Фирдәвес?

—Әйе, шәһәр күчenә. Училищены Арчага күчерделәр дә инде. Классташларың кайсы кая юллама алып, эшкә урнашып бетте,—диде Идмас.—Ник син Әнис турында сорамыйсың әле? Ул Казанда. Университетка кергән. Укып йөри, ди. Тажсыз патша булырга. Имеш, өйләнергә дә исәбе бар икән... Илгизәр дусы Сәлимәгә өйләнгән.

Боларны ишеткәч, Әнисә тетрәнеп китте. Дулкынлануын яшерергә тырышып әле чәйнеккә, әле чәшкегә сузылды. Идмас моны сизде, карашын стенада текелдәгән сәгатькә күчергән булып, Әнисәне күзәтте. Чибәр шул, чибәр. Хәзер тагын да тулыланып, матураеп киткән. Йөзе дә көньяк кешеләренеке кебек каралып тора.

—Әнис тә, уку еллары да артта калды шул инде. Истәлек булып, әрнүле истәлек булып, Идмас,—диде Әнисә.—Ярар, син үзең бит бездән ике-өч яшькә олырак идең. Армиядә түгелмени соң?

—Юк, алмадылар. Күздән гаеп тапкан булдылар. Мин мона бер дә гарьләнмим лә. Өч-дүрт ел вакыт әрәм иткәнче берәр вузга керермен дип торам. Син рөхсәт итсәң.

Идмас сүзен уенга санаган булып, көлеп куйды, ә үзе Әнисә йөзенең кинәт житдиләнүенә игътибар итте.

—Минем синең тормышыңа бер катнашым да юк. Синең үзеңнеке, минем үземнеке,—диде Әнисә.

—Икебез дә ятимнәр, беркемебез дә юк. Бергә укыдык, бергә тәрбияләндек,—дип кенә әйтүем. Гел чит кешеләр түгел ләбаса. Кинәш итүем дип бел.

—Синең Зинаидаң бар иде ич. Ул кайда хәзер? Сез ник бергә түгел?

—Ул никтер миннән йөз чөерде. Хәзер бер ир бала үстерә дип ишеттем.—Идмас жавабын теш арасыннан кысып чыгарды.

—Бик дус йөрдегез ич. Ничек инде?

—Ярар ла. Рус кызының татар малае белән нинди уртаклыгы булсын...

Менә син үзең турында берни сөйләмисең. Нишләп училищены ташлап киттең? Бөтен шәһәрне аякка бастырып. Сине кайдан гына эзләмәдек без. Сулардан, урман-болыннан. Училище, тулай торак чарлакларын әйтеп тә торасы юк. Милиция дә эзли-эзли аяксыз калды. Ә син монда качкансың икән.

—Качмадым мин... Ни дип әйтим... Шулай килеп чыкты инде. Син менә мине ничек таптың?

—Сәрия апаң документларыңны, әйберләреңне сорап язганые, училищега. Шуннан соң синең адресны сорап кат-кат хат язып, аптыратып бетердек без аны. Җавабы бер булды—юк, белмим. Эзләгез, табыгыз, мин аның бердәнбер туганы, дип тукыды. Аптырагач, Сәрия апаннарга үзем бардым. Ире салгаларга ярата икән. Эчкән кешенең ихтыяры слабый була инде ул! Сандыкларыннан синең хатларны эзләп тапты. Башкасы инде аның, кем әйтмешли, дело техники. Хи-хи-хи.

Идмас Әниснең дә Сәрияләргә берничә хат язуын белә иде, тик әйтмәде. Әнис тә: «Әнисәнең кайда икәнлеген белмисезме? Белсәгез, зинһар өчен, миңа аның адресын бирегез әле»,—дип язган иде. Әнисә үзе беркемгә дә берни әйтмәскә кушкач, Сәрияләр серне ачмадылар. Әнис исемле егет кызыксынса, бигрәк тә диган иде ич...

—Дело техники, дисең инде.—Әнисәнең күзләрендә ачулы очкыннар уйнап алды.—Алай икән... Син шуннан соң Әнисне бөтенләй күрмәдеңме?

—Әйттем ич инде. Юк. Укырга кергән, өйләнергә йөри ди.

—Анысын ишеттем. Мин югалгач, ул шулай тыныч кына яшәде дип әйтмәкче буласың инде син, әйеме?

—Сине көчләгән дип аны кулга алдылар ул чакта.

—Әнекәем! Миленький!—Әнисәнең йөзе ап-ак булды.

—Курыкма, курыкма... Озак тотмадылар. Чыгардылар. Гаепсез булган, имеш. Кем белә инде сезнең хәлләрне... Бик дус булып йөрдегез бит. Син, бәлкем, аны үзең йолып калгансыңдыр әле. Кагылмады, дип. Шулаймы?

—Ул шундый әшәкелеккә бара алыр дип уйлыйсыңмы син?

—Алайса, син ник безне шундый борчуга салдың? Аны да, мине дә. Барыбызны да.

—Миңа нишләргә кирәк иде, ничек итеп аның йөзенә күренергә кирәк иде соң? Шундый мәсхәрәгә калып... Шундый антлар эчкәннән соң... Әгәр мин аны кулга аласыларын белгән булсаммы?

—Нишләр идең?

—Нишләргә белер идем. Анысы аның сиңа кагылмый ла...

Идмасның йөзе үзгәреп китте. Ирен почмакларына мәсхәрәле елмаю кунды.

—Ачуланма, сиңа бер сорау бирим әле,—диде ул.—Өйләнергә йөргәнен белә торып, син һаман аның турында уйлыйсыңмы? Шушы хәлеңдә дәме?

—Уйлыйм. Берни өмет итмәсәм дә. Ул минем бердәнберем. Яшьлекне—тәүге хисләрне онытып буламыни?

Идмас көлә башлады:

—Син китапча сөйлисең түгелме?

—Ә бәлки китап безнеңчә сөйлидер.

—Акыллы син, Әнисә. Молодец та инде үзең. Тик...

—Нәрсә «тик?» Әйтеп бетер.—Әнисәнең таләпчән карашыннан Идмас читкә борылды:

—Тормыш китаптагыча гына бармый бит, диюем.

## 19

Бер-ике атна узгач, Идмас Әнисәне гаҗәпкә калдырды. Күренми торды-торды да килеп керүенә ярып салды:

—Мине котлый аласың, Әнисәкәй. Эшкә урнаштым. Унбишенче мәктәпкә. Математика укытачакмын, физкультура дәресләрен дә мина йөкләделәр. Мин тагын бер нәрсә белдем әле—монда каракүл арзан икән. Татарстанга алып кайтып сатсаң, шәп файда ясыйсың дигән сүз. Яшәргә була монда, шулаймы?

—Һәркем үзе белгәнчә яши. Бернинди кинәш тә бирә алмыйм,—диде Әнисә.—Алайса, син монда төпләнергә уйладың инде?

—Шулай килеп чыга. Син үзең дә менә монда качып килгәнсең ич.

Әнисәнең күкрәк читлегенең кайсыдыр почмагында бу кешегә ачу кебек нәрсәләр кузгалды. Үзенең монда килеп чыгу сәбәбен аңа кат-кат аңлатты бит инде. Тәне мәсхәрәләнгән, рухы җәрәхәтләнгән Әнисә Әниснең пакьлегенә каршы нәрсә куя ала иде соң? Идмас һаман шуны аңламыймыни? Ә үзе монда нишләп йөри ул? Бәлкем, үзе качып йөридер әле. Әнисә катгый бер карарга килеп, хисенә юл куйды.

—Син һаман мине качып килгән дип уйлыйсың инде? Ә син үзең качып йөрмисеңме икән? Алиментлан дим. Зинаидан бер ир бала үстерә, дигән... Синеке түгелме?

Идмас һич тә мондый туры сүзне көтмәгән иде. Ачуташ капкан кебек йөзе җыерылды. Бер агарды, бер кызарды, ыкы-мыкы килде:

—Син... бигрәк инде! Нишләп качып йөрим ди?.. Каян килеп минеке булсын... Аны кем исбат иткән?

—Ул кыз артыннан калмый йөрдең ич.

—Аның артыннан кем генә йөрмәде. Беләсең килсә, синең Әнис тә аның янына баргалаган иде—юмарт икән дип кайтты.

Әнисә дулкынлануыннан калтыранып аны бүлдерде:

—Ялган! Ялган бу! Үтерсәң дә ышанмыйм. Зинһар, бар кит. Күрәсем дә, ишетәсем дә килми. Ничек телең барадыр?

—Ярар, Әнисә, гафу ит. Үзең дә инде... Тиктомалдан кешегә шундый гаеп ташларга... Хуш,—Идмас ашык-пошык киенеп Сәҗидәләрдән чыгып китте. Үзен-үзе әрләп, юл буена төкеренеп кайтты, квартир хуҗасының, нишләп болай күңелсез, диюенә салкын гына җавап биреп, бүлмәсендәге караватка барып ауды. Артыгын ычкындырды шул, артыгын ычкындырды.

## 20

Әнисә соңгы көннәрдә суырылып калды. Идмас сүзләре аның җанын телгәләде, болай да әрнегән ярасына тоз салды. Әнис тә Зиночка янына барып йөргән, имеш. Ярар, шулай да булсын ди. Ә син—аны яратып йөргән егет, моңа ничек карадың, ничек түздең? Ничек күз йомдың? Бөтен училище алдында ачыктан-ачык яратышып йөр-йөр дә, дус кызын янына пычрак уй белән барган егетләргә күз йом, имеш. Юк, алай булмый ул. Юләр сату бу!..

Ә Әнис? Шул арада Әнисәсен онытып, бүтәннәр белән чуала аламы? Моның беркайчан да булуы мөмкин түгел. Ул мине үлеп-үлеп ярата иде. Тик мәңге ялгыз калмас ич инде. Үзе шундый чибәр, эчкерсез, кешелекле, тырыш егеткә күз ташлаучылар күптер. Тора-бара мине онытыр, хисе дә сүрелер. Бу табигый хәл. Әнисә үзе шулай тели.

Алайса, Идмаска мондый ялган нигә кирәк булды икән соң?

Әнисәнең боегып калуын Идмасның соңгы вакытта күзгә-башка күренми йөрүеннән дип уйлап, Сәҗидә белән Низамның егеткә җен ачулары килде. Тиктомалдан кыз баланың күңелен кузгатсын да юкка чыксын, имеш. Шул да булдымы егетлек.

Сәҗидә белән Низам юллама алып, ике атнага гына булса да дип «Фирүзә» дигән бик матур урындагы ял йортына киттеләр. Ялгыз калгач, Әнисәнең эче поша башлады. Уйлары белән ул торган саен үскән, укыган җирләренә кайтты. Дус кызларым хәзер кайларда йөри икән? Тормышларын ничек

кордылар, ничек эшлиләр икән? Лилия бик нечкә күнелле иде. Минем югалуымны ничек кичергәндер инде. Аңа берни әйтми юкка чыгу—шушы да буламы дуслык! Әнис!..

Егет исенә төшүгә Әнисәнен йөрәге күкрәк читлегеннән чыгарга җыенгандай ярсып тибә башлый. Менә тагын. Ул каршыга килеп баса да, гадәтенчә күзләренә карап елмаеп тора.

—Синең күзләрең гаҗәп матур. Болындагы күкчәчәк төсле,—дия иде ул. Ә пристаньда Казанга китәргә торганда нәрсә диде!

—Мин рәссам булсам, зур итеп синең сурәтенне ясар идем. Чәчәкле болын уртасына бастырып, кояш көнләшерлек итеп ясар идем. Чәчәкләрне кояшка түгел, сиңа каратып. Менә, ичмаса, сурәт булыр иде бу, ә? Кулына роза тоттырып.

Әнисә ярый әле сөйгәне биргән розаны саклый алды. Туган якларын, Әнисне үлеп сагынганда ул нәни тартмадан бүләк розаны сак кына ала да исни. Иснәве була, училище бакчасындагы гөлҗимешләр, сәрби куаклары уртасындагы урындыкка очып кайта, колагында дус кызларынын шатлыклы тавышлары янгырый башлый. Тавыш-тынсыз гына каяндыр Әнис килеп чыга, кып-кызыл, зур роза чәчәге суза, карап басып тора-тора да, башын иеп китеп бара. Нинди каһәрле көн аерды соң аларны... Шәфкатьсез, рәхимсез көн... Ә көннең монда ни гаебе бар? Кояшлы матур җәйге көн иде ләбаса. Кара болыт килеп кенә бозылды ул. Әнисәнең уйлары әле тегендә, әле монда сикерә, ул торып йөреп китә, тагын барып утыра. Гомер буе шулай мәсхәрәләнгән, узасы узган, тузаны тузган кыз булып калачакмыни соң инде ул? Ә алда нинди матур хыяллар, планнар бар иде. Нинди явыз бәндә аны шушы хәлгә төшерде соң...

Уйларына бирелеп, Әнисә капка шакыганны ишетми калды. Инде тәрәзә шакый башладылар.

—Кем булыр бу?—дип Әнисә тәрәзә янына килде.

Анда Идмас басып тора, капканы ач дип кул изи иде. Әнисә чыгып, капканы ачты.

—Син икәнсең әле. Куркытып җибәрдең,—диде ул.—Өйдә ялгызым гына идем. Сәҗидә апалар ялга китте.

—Шулаймыни? Шулайрактыр дип уйлаган идем үзем дә. Күпме килми тордым, сагынып та беткәнсеңдер, иеме?—диде Идмас шаяру рәвешендә. Әнисәнең дәшмәвен үзенчә юрады булса кирәк, теле белән төлке тотарга ниятләде:

—Сиңа каракүл жакет тектерергә дип районнарга чыгып кердем әле. Тиреләр сатып алдым. Сине куандырырга исәп. Туган көненә.

—Миңа берни дә кирәкми, Идмас. Син бар, кайт. Ялгыз хатын-кыз янына ир-ат килүне беркем хупламый монда.

—Йә инде, Әнисә. Син дә, мин дә тиле яшьләр түгел бит. Килсәм, аның ни ояты бар?—Идмас кулларын сузып, Әнисәгә тәмам якынайды.—Без бит инде синең белән дистә еллар бергә.

Әнисәнен борынына тәмсез хәмер исе килеп киткәндәй булды:

—Әллә син... эчкән димме?!

—Чүт кенә... Унышлы сәфәрне юып кына. Әнисә, Әнисә, кил әле яныма. Шундый сагындым үзенне. Мин ялгыз бит бу чит җирдә. Икебез дә ялгыз.

—Юкны сөйләмә, Идмас. Бар кайт. Эчкән кешене җенем сөйми. Кит, дим.

—Җә инде, матуркаем. Кума инде... Кыз чагың түгел ләбаса инде.—Идмас Әнисәне биленнән кочып, үзенә тартып китерде дә үбәргә сузылды. Әнисәнен борынына хәмер исенә кушылган ачы тир исе килеп бәрелде. Ул укшый ук башлады. Бу сасы ис аңа таныш иде.

Әнисәнен күзләре зур булып ачылды, таштай каткан сыны калтырый башлады. Элек җәрәхәтләнгән әгъзалары нәкъ элеккечә сулкылдап әрнергә кереште.

—Син!

Идмас, кыршаудай кулларын ычкындырып, берни анламый кызга текәлде.

—Син!—Әнисә кинәт очынып Идмасны уңлап-суллап янаклый башлады. Ул үзен-үзе белештерми иде.

—Син икәнсең, кабахәт! Син булгансың!

Идмас Әнисәнең кулларын тотарга маташты, иелде-бөгелде, тик соңгы чиккә җитеп ярсыган Әнисәне туктата алмады.

—Минем мәхәббәтемне, тормышымны җимерүче син булгансың, пычрак җан! Син, син, ублюдок! Югал, югал күз алдымнан! Мә сиңа, мә!

—Әнисә, Әнисә дим, тынычлан, җә, тынычлан инде. Узган эшкә салават диләр бит.

—Узган э-э-эш! Оятсыз, җир бит! Ничек монда килергә иттең! Нәрсә кирәк сиңа, ә?

—Минем ниятем чын иде бит, җә инде. Бәлки торып китәрбез дигән идем.—Идмас челт-челт күзен йомгалады.

Әнисә читлектәге капландай, арлы-бирле сугылды, аннары кәнәфигә сыгылып төшеп, яшь баладай сулкылдый, үксеп-үксеп елый башлады.

—Әнисә, ярар инде, тынычлан, зинһар, тынычлан... Бер утырып барын да сөйләшербез, икебез дә ятимнәр ләбаса...—Идмас Әнисә елап тынычланыр да аннан соң аны үз ягыма аударырмын дип уйлый иде.

—«Сөйләшербез!» «Торып китәрбез!» Синең белән торганчы гүргә керүең хәерлерәк. Кит, чыгып китәсеңме, юкмы? Югыйсә мин хәзер күршеләрне чакырам.

Әнисә чыннан да сикереп торып ишеккә юнәлде. Идмас моны көтмәгән иде, Әнисәне узып ишек тоткасына ябышты.

—Ярар, ярар, киттем.—Ул кабалана-кабалана ишекне ачты да яшеннән качкан шайтан кебек йөгерә-атлый капкага ташланды.

Шул мәлне бу якларда җәен шактый сирәк була торган хәл—калай түбәләрне яңгыратып күктән эре тамчылар коела башлады. Яңгыр көчәйгәннән көчәйде. Ишек алдындагы берданбер алмагач яфраклары калын тузан япмасыннан арынып ямь-яшел төскә керде. Әнисә коеп яуган яңгыр астына чыгып озак кына басып торды. Чәчләре, киеме, бөтен тәне чыланганын ул сизми иде. Аның күз яшьләрен яңгыр юып ташлады. Ничек кинәт башланса, яңгыр кинәт бетеп тә китте. Әнисә өйгә кереп ут кабызды да караватка барып ятты. Ул бик-бик арыган иде.

## 21

Картлар йорты матур гына бакча эчендә урнашкан. Янында яшелчә бакчасы да бар. Теләгән кеше шунда чыгып казына, төрле-төрле чәчәк, укроп, суган утырта. Кирәгеннән бигрәк шөгыль булсын дип. Дәрте-дәрманы беткәннәр җылы, кояшлы көннәрдә йорт янындагы урындыкларга тезелешеп салмак кына гәп коралар, изрәп, черем итәләр. Шылт иткән тавышка да уянып, капканы күзәтәләр. Картларның берсе көн саен бакчаның аргы, аулак почмагындагы урындыкка ялгыз гына сенә дә уйларына бирелә. Шәлперәйгән иске эшләпәсен агарган кашларына тикле батырып кия, инде тонган, төсен җуйган, һәрвакыт яшьле күзләрен бер ноктага төбәп карлы-бозлы яңгырлар җилләткән таш балбал шикелле сәгатьләр буе тын гына утыра бирә. Янынннан узган кешеләр аның вакыт-вакыт кулларын болгап үз алдына ниләрдер сөйләгәненә сәерсенеп карап китәләр. Карт үпкәләрен гыжылдатып авыр сулый, көрсенә, тик беркемгә берни әйтми утыра да утыра. Арыгач, кузгала,

бер аягын сөйрәп диярлек бинага юнәлә, керә. Коридорда бүлмә ишеге янында туктап, тынлап тора. Аннан бүлмәдәше Гаяз тавышы янгырый:

—Их, син! Адәм мәсхәрәсе! Шундый козырен була торып нәрсә карап утырдың, тирес тутырмасы! Жә әйләндереп җибәрермен!

Картлар йортына караучысыз, тәрәксез калган колмак сабагыдай карткоры гына түгел, гомеренең күп өлешен төрмәләрдә уздырып, башын кая куярга белмәгән пенсия яшендәге сукбайлар да эләгә. Гаяз шуларның берсе. Андыйлар пенсия алган көннәрдә үзләренә күрә бәйрәм ясыйлар. Елгыррагы кибеткә барып килә. Хәзер анда утлы суга кытлык юк, акчаң гына булсын. Интернатка түләгәннән калган акча шул ябалак сөтенә тотыла. Дөрес, монда балаларым килеп чыкса, күчтәнәчкә, бүләккә дип акчаларын тиенләп җыючы карт-коры да бар. Аларга мондый көннәрдә бигрәк тә авыр. Хәмер яратучыларның авызларына шайтан төкреге кердеме, тавыш-гауга чыгуын көт тә тор. Монда инде алдынгылар рәтендә шул ук тәүбә капкалары ябылган Гаязлар, йә кайчандыр дөнья кендеге булып йөреп, җил-давыл китереп ташлаган зур бавырлы «акыл иясләре».

Тагын «төшереп» алалар да һаман карта сугалар. Күпме мөмкин инде... Ахмаклар. Эт сугарып көннәр буе йөриләр дә бер уен табалар. Карт, рәнҗеп, башын чайкап ала, борылып кире китәргә исәпли, ләкин сул аягы карыша. Бүлмәдән яңгыраган тавышлардан аның бөкрәйгән гәүдәсе тагын да сыгыла төшә. Ул кыяр-кыймас кына ишекне ача. Балта элеп куярлык тәмәке төтененә кушылган хәмер, балык, суган исе борынны ярып керә. Карт чыдый алмый:

—Тагын бүлмәне сасыткансыз,—дип мыгырдый-мыгырдый ятагына юнәлә. Анда ачы тир исе сеңгән, кыршылып беткән кун куртка, полиэтилен пакет, ипи валчыклары, газета ертыклары аунап ята. Ул аларны Гаяз караватына илтеп ташлый.

—Бүлмәдә тартырга, эчәргә ярамый дип күпме тукыйлар... Ә сез колагыгызга да элмисез... Бүлмәдән дуңгыз абзары ясыйсыз...

Гаяз кызгылт күзләрен акайтып, йодрыкларын йомарлый. Теле тупсанынннан ычкына. Хәмер исе аңкыткан авыр сулышын картның йөзенә бәрә:

—Үлә дә белмәдең, корчангы! Имгә яраксыз нәстә! Мыгырдаган була тагын! Синең яшьтәшләрең теге дөньяда әллә кайчан инде миллионынчы төшен күреп ята. Анаң төчкергәндә төшеп калган мәхлук.

Карта уйнаучылар бүлмәне генә түгел, бөтен коридорны янгыратып кешниләр:

—Миллионынчы төш, ә? Ха-ха-ха!

—Ну, әйтәсең үзең! «Төчкергәндә төшеп калган». Ха-ха!

—Сун, һаман мыгырдана! Мин бит аның төне буе бүлмәне пыскытып, сөрсеп ятканына зарланмыйм. Ә ул, паршивый, һаман—«сасыткансыз»! Әле «тәрәзәне ач», әле «яп»!

Карт бүтән эндәшми, ни генә әйтсә дә файдасы тимәсен белә. Эшләпәсен тумбочка өстенә ыргытып, стенага борылып ята. Бу карт—Идмас Фәсхетдинов. Сиксәнгә якынлашып килгән бәхетсез карт туган якларына Төрекмәнстаннан берничә ел элек кайтып егылды. СССР таркалгач, анда Рәсәйдән килгәннәргә көн бетте. Алар берәм-берәм дә, гаиләләре белән дә фатирларын, мал-мөлкәтен әрәм-шәрәм итеп, туган илләренә кайтырга мәҗбүр булдылар. Төрекмән телен белмәгән кешеләр эштән азат ителде, төрле кыенлыклар алдында калды. Идмас, гомеренең күп өлешен шунда уздырса да, ул телне өйрәнә алмады. Гомумән, аның гуманитар фәннәрдә яшьтән үк рәте булмады. Училищеда укыганда нишләп «феодал» сүзендә «е» язылa, «фиолетовый» дигәндә «и» язылa дип рус теле укытучысы белән чатыр-чатыр бәхәсләшә иде. Фәсхетдинов күптән инде пенсиядә. Эшләгәндә әле коллективта, кешеләр арасында ялгызлык ул хәтле үзәккә үтмәде. Тик менә ялга чыккач... Янына кереп

хәлен белүче дә, кибеттән ризык-мазар алып кайтып бирүче дә калмады. Яман холкы, хөсетлеге аркасында гаилә кора алмады, тирә-юньдәгеләрнен дә гайрәтен кайтарып бетерде.

Көннәрдән бер көнне ул туган илдә чыпчык та үлми дигән уйга килде дә булган әйберләрен, бер бүлмәле квартирасын арзанга гына сатып, бик авырлык белән Татарстанга кайтып китте. Баштарак елларда хат алышкан, каракүл тиреләре, җиләк-җимеш сатарга булышкан әшнәләре инде картайган, ана ярдәм итәрлекләре калмаган иде. Шулай да аз-маз акчасына, алып кайткан каракүл тиреләренә кызыгучы бирәү табылды, төрле юллар белән аны картлар йортына урнаштырды. Ана да Идмас Фәсхетдинов бөтен акчамны алдап-йолдап алып бетерде, дип рәнҗеп йөрде.

Моннан бернечә ел элек анын янына карт кына бер маржа килеп киткән дип сөйлиләр. Зур, матур күзләре төсен инде җуйса да, ул хатын шактый чибәр булган, имеш. Аны алып килгән илле яшьләрендәге ир читтән генә картларнын сөйләшеп бетергәнен көтеп торган, якын бармаган. Аннары теге хатынны сак кына җитәкләп, машинасына утыртып алып та киткән. Шул көннән сон Идмас бернечә ай авырып яткан, сул аягы начар йөри башлаган.

Еш кына Идмас Фәсхетдинов үз язмышынын кайчан, ничек, ник кителгәне турында чигәләре чынлаганчы уйланып ята. Әтисе яна төзелгән колхоз милкен әрәм-шәрәм итүдә бер дә юкка гаепләнеп Себердә югалу вакытыннан ук башланганмы анын кара бәхете. Әллә әнисенен Идмасны карт әби кулына калдырып кайгыдан бик яшьли вафат булгачмы? Әллә бик ашыйсы килгән бер мәлне кеше базын басып тотылгачмы? Шуннан өелде дә өелде инде. Олылардан ишетеп «бакыр комган базга чумган», «ата шайтан» дип үртәгән малайларны тотып «яра» башлагачмы... Үзе дә кимен куймады. Үз тиннәренә көче җитмәсә, аларнын эне-сенелләрен кыерсытты. Кемгә балта мае ялатты, кемнен изүенә бака тотып салды, мәк дип тиле бәрән орлыгы ашатты. Бигрәк тә ачуын чыгаралар, гарьләндерәләр иде шул.

Яшьтән үк эшкә кулы ятып тора иде бит анын. Кешедән ким җире юк иде. Дөрес, башка малайлардан гел өстен чыгарга теләде. Шуна сугышырга, кырлышырга хәзер иде. Үзеннән әйбәтрәк укыганнарны, инде сонрак яхшырак эшләгәннәрне ул гел яратмады. Берәрсенен унышын күрсә, нишләп анын урынында мин түгел, мин кемнән ким, дигән сорау да аны гомере буе ээзләрлекләде, тормышынын ямен алды, җанын кыйнады, ялгышларга этәрде. Үзенә каршылардан ул астыртын гына үч алырга да өйрәнде. Ярылырга җиткән чаклары да аз булмады. Хәмер капкаларга иялэшеп китүе тагын. Әйе, анын, кем әйтмешли, балта сабы кыска иде. Ялгышларын төзәтергә теләгән чаклары да булмады түгел, булды. Әмма терсәк якын да тешләп кенә булмый.

Ник дип ул Әнисәгә барып бәйләнде инде, йә? Үзе кебек үк ятимә Әнисәгә? Ярый әле теге чакта гөнаһынны белмәделәр. Белсәләр, төрмәдән башын чыкмый иде ләбаса. Ә Әнисә күпме вакытлар үткәч минем гаепне каян, ничек белә алды икән сон? Шөкер, эш күптән узган инде... Әнистән көнләшүдән генә туган бу эш фаҗигагә әйләнә язды бит...

Янагыннан чакма кабызып куып чыгарганына карамастан, Идмас Әнисә янына тагын бер барып карады. Бу юлы аны Әнисә генә түгел, Низам белән Сәҗидә дә якын җибәрмәде.

Шулай уйланып ята-ята, күнелсез хәлләр кылт итеп исенә төшкән саен карт сискәнеп китә. Менә тагын... Әнисә белән аралары бөтенләйгә өзелгәч, ул сәүдә эшләре белән Казанга бер кайтуында һич көтмәгәндә базарда Әнисне очратты. Аз-маз хәл-әхвәл сорашып китеп кенә барырга иде дә кана. Юк, ул Әнискә синен Әнисән бер төрекмәнгә кияүгә чыккан икән дип ычкындырды. Бу ялган ана нәрсәгә кирәк булды, Идмас моны үзе дә белми, аңламый

калды. Алар да минем шикелле үк каңгырап йөрсеннәр дип уйлагандыр инде.

## 22

Ул көнне Әнис базарга аяк киеме эзләп чыккан иде. Ларекларга кергәләп, сатучылар кулындагы ботинкаларны караштырып йөргәч, ул олы яшьтәге бер хатын янында тукталды. Тегенең кулында микропор аслы, матур гына сары ботинкалар күргәч, аларны әйләндереп-әйләндереп карады. Шул арада шау-гөр килгән халык арасында бакыр баш чалынып китте. Тукта, бу Идмас түгелме соң?

—Апа, мин хәзер әйләнеп киләм, яме?—дип Әнис теге кеше артыннан китеп барды. Әйе, бу Идмас иде.

Әнисне күргәч, ул күрмәмешкә салышмакчы иде дә, карашлары очрашты. Нишләмәк кирәк, чит кеше сыман узып китеп булмый инде.

—Нихәл, Әнис,—диде ул, кулын сузып.—Нишләп йөреш?

Әнис артык ачылып китмәде:

—Вак-төяк мәшәкать белән йөрим шунда. Син каралып киткәнсен. Кояшта күп буласың, ахрысы.

—Туры килә шул, йә, укып буламы? Все же университетка керден бугай...

—Укыйм. Классташларны очратканың бармы? Кемнәр кайда икән?

Идмас ихахайлап көлде:

—Тел төбендә Әнисә турында берәр нәрсә белмисеңме дигән сорау инде. Юк, белмим мин аны. Кая китеп югалгандыр. Дөрес булса, бер төрекмән егетенә кияүгә чыккан дип ишеткән идем.—Идмас үзгәреш көтеп Әнис йөзенә кадалды. Әнә чыннан да ул агарып китте.

—Төрекмән егетенә?

Идмас көтмәгәндә артыграк ычкындырганын шәйләде:

—Белеп әйтүем түгел. Каян чыккан сүздер. Һаман яратасыңмыни соң? Йөзеңнән кан качты.

—Яратам. Таба гына алмыйм.

—Шул хәлендәдәме? Каймагы алынган килештәме?

—Их, син... Шуны да аңламыйсыңмы? Ниндидер бер явызы аны шул хәлгә төшергәч ул, бәлкем, Әнис минем белән булырга хурлана дип, эзен югалтырга теләгәндер. Аның кебек чиста күңелле кызны табарга кирәк әле.

—Чиста хатын диген инде?

—Чиста кыз. Яраткан кызым.

—Төрекмән белән яшәсә дәме?

—Каян алдың соң син шул сүзне: төрекмән, төрекмән?!—Әнис ачуы кабарганын басарга тырышты.

—Әйттем ич инде. Шундый сүз чыккан дип. Утсыз төтен булмый, диләрме әле.

—Синең фәлсәфә, Идмас, бер дә үзгәрми, ахрысы. Теге чакта да шулай дип мине гаепләргә йөргән идең. Тик хаклык жинде.

Идмасның күзләре гадәтенчә ярык кына булып калды:

—Яратып йөргән кызыңнан колак кагу да җиңү буламы?

—Син сүзне борма. Минем гаепсезлегем ачыкланды. Ә менә синең Зинаида белән мөнәсәбәтләрең ничек?

Мондый сорауны көтмәгән Идмас йөзен читкә борды:

—Ничек, ничек... Берничек тә түгел. Борчак пешмәде. Кемнәндер бала тапкан, диләр.

—Кемнәндер? Бала? Синнән түгелме икән?

Идмасның ачуы йөзенә чыкты. Бу сүзне аңа кемнәр генә әйтмәде инде. Ярый әле аның бәхетенә Зинаида нык торып, баланы Идмаска такмады.

Шунын өчен генә булса да рәхмәт үзенә. Ә бу неудачникка нәрсә диярга, ничек авызын томаларга? Мин син түгел диярге̃ме әллә? Алай дисән, ул бит минем Зиночка белән ничек йөргәнне белә. Аранын ничек өзелгәнен генә белми. Белмәсен дә.

—Үзем ятим үскәч, ятимлек мина яхшы таныш. Баласы минеке булса, ике дә уйлап тормый Зинаидага өйләнер идем.

—Сон?

—Нәрсәгәдер кәжәләнде... Күптән инде анын үз тормышы, минем үземнеке. Ялгыз башым, тыныч колагым.

—Ә Хәлимә?

—Нинди Хәлимә? Сары пошлакмы? Анын монда ни катнашы бар?

—Сина мәхәббәтен күпме генә яшерергә тырышса да күрә идек бит. «Сары пошлак», имеш. Хәер, син...

—Нәрсә мин? Әйтеп бетер!

—Мәхәббәт белән уйнамыйлар. Ахыргы әтәч булуын ихтимал.

—Бабайлар сүзе. Сафсата...

—Бабайларны юкка гына «аксакал», ягъни акыл иясе димиләрдер. Ярар, ни эш бетереп йөрисен сон әле?—Әнис Идмас кулындагы төенчектән күренеп торган каракүл тиресенә игътибар итте.—Әллә тире сатасынмы?

—Нишләп сатыйм? Сатып алам!

—Шулай күп итепме?

Идмас сатып алам дигәндә мондый сорау булыр дип уйламаган иде. Анын куллары кыбырсый башлады.

—Күп дип... Күп түгел лә... Ни... Бүрек тектерергә исәп.

Әнис анын аптырабрак җавап бирүеннән дөресен әйтмәгәнен анлады. Идмас авыр хәлдән чыгарга теләп, үзе дә көтмәстән тәкъдим ясады:

—Әллә чәйханәгә кереп берәр йөз грамм төшереп алыйкмы? Синен кайгыны юып? Элеккеге дуслык хакына, ә?

—Без дус идек мени? Кем сон, алайса, мине төрмәгә утыртырга атлыгып йөрде?

—Мин бит ялгышып, син гаепле дип уйлаган идем. Узган эшкә салават диләр ләбаса.

Әниснен йөрәге кысылып куйды:

—«Салават!» Минем урында үзен булсан, нишләр иден икән?

—Ярар, әйдә, берәр йөз грамм кабыйк та, үпкәләрне онытыйк инде. Бу дөньяда дүрт аяклы ат та абына.

—Мин эчмим.

Ул арада болар янына халык арасыннан кара тутлы бер хатын килеп басты да ярым татарча:

—Булмады, Идмас, алмыйлар. Фарт килми. Карыйлар да кыйммәт дип китәләр,—дип кулындагы тиреләргә ымлады.—Әйдәле, Чарджуйдан тагын килгәннәр анда.—Идмаснын йөзе чалшаеп китте. Ул аннан-моннан саубуллашып таю ягын карады:

—Ярар, хуш... Арытты, кайтып ятыйм әле. Бергә укыганнарны очратсан, сәлам диген.Араларында Сөләйман йөзеген табучылар бармы икән, ай-һай...

Әниснен җавабын да көтми, Идмас халык арасына кереп китте. Кара тутлы хатын да ана иярде. Әнис алар артыннан карап, уйланып калды. Димәк, болар каракүл сатып йөриләр. Тик каян алалар икән сон аны? Каракүл бәрәннәрен бездә үрчетмиләр. Урта Азия тирәсеннән микәнни? Кызык. Теге хатыннын сөйләме дә сәер. Сүзләре татарча сыман, тик безненчә үк түгел... Кайда яши, кайда эшли икән сон бу Идмас. Үзеннән сорарга кирәк булган икән. Хәер, нәрсәгә инде ул анарга?

## 23

Көтмәгәндә бу очрашудан соң Әнис җанын авыр хисләр янә бәләкли башлады. Азмы-күпме басыла төшкән йөрәге янә урыныннан купты. Әнисә аны нииндидер төрекмәнгә алыштырсын инде, ә? Ничек инде? Ышаныргамы, ышанмаскамы? Алар бит үлгәнче бергә булырга сүз куештылар. Беткән баш беткән дип әллә чыннан да шундый адым ясап аттымы икән? Кайда соң ул? Кемнәр арасында йөри? Күреп сөйләшәсе иде үзен! Бер генә дә сагынмый микәнни соң ул! Минем Казанда, университетта укыганымны белә ләбаса...

Уйлана Әнис, уйлана. Һәм һаман шул Идмасның төрекмән дигән сүзенә барып төртелә. Төрекмән... Тукта әле, теге чакта Идмас янына килеп чыккан хатын да төрекмән хатыны булмадымы икән? Теле бик сәер иде, ни татарча, ни урысча. Чарджуй дигәнен ничек аңларга тагын. Бергәләп китеп тә бардылар. Хәер, ул хатын нишләп үзбәк йә казакъ, йә каракалпак булмаска тиеш? Һәрхәлдә, нәрсәдер бар монда...

Лекциядә булсынмы, университетка барышлый-кайтышлый юлдамы, уйлана торгач, Әнис бер карарга килде. Менә дүртенче курсның соңгы имтиханнарын биреп бетерсен дә Әнисәне тагын да ныклап эзләргә керешәчәк ул. Аның дәүләт органнарына мөрәҗәгате барып чыкмады. Эзләтергә дип гариза язып милициягә баргач:

—Әнисә Әхмәдуллина сиңа кем була соң ул?—дип сорадылар. Ул нәрсә дисең инде, сөйгән кызым, диде. Биек фуражкалы капитан көлемсерәп кенә:

—Тапкансың эш. Һәркем йөргән кызын эзләтә башласа, үләргә кирәк монда,—диде.—Сугыш вакытында югалганнарны эзләү эшләре дә муеннан... Так что, егетем, без бу эшкә тотына алмыйбыз. Бик яратышсагыз, табышырсыз.

Әнис бергә укыган егетләр, кызларның кайберләрен эзләп табып, алардан кат-кат сорашып карады. Нәтиҗәсе генә булмады. Аның каравы үз вакытында училищеда рус теле укыткан укытучы Нинель Чепурнова Әнискә бер киңәш бирде.

—Мин барын да беләм, Әнис,—диде ул.—Синең бер гаепсез икәнеңә дә ышанам. Сезнең шундый матур дуслыгыгызга соклана идем. Әллә күз тидеме шунда. Әнисә югалгач, аның бер туганы училищеда калган документларын, әйберләрен соратып алган иде бит. Тап син ул апаны. Ул белми калмас.

—Нинель Ивановна, таптым ла мин аны. Хат артыннан хат яздым. Белсәгез, Әнисәнең адресын миңа әйтегез әле дип...

—Шуннан?

—Җавап килмәде.—Әнис авыр көрсенеп куйды.

—Их син, егет. «Җавап килмәде», имеш. Шуннан тынычланып калдыңмы?—Укытучы тавышында шелтә төсмерләре яңгырады.—Ә ник ул апаның үзен эзләп тапмадың? Янына барып сорашырга иде.

Укытучының бу сүзләре егетнең күңелен айкады. Чыннан да! Имтиханнары бетүгә ул, җәйге айлар өчен стипендия алып, Кырыйнгыга барырга ниятләде.

## 24

Сәрияләр аны күтәреп алмадылар. Сиңа нәрсәгә ул? Син кем соң? Ник безне бимазалап йөрисез, киләсез, хат язып теңкәгә тиясез. Без аның кайда икәнен белмибез... аптыратмагыз кебек сүзләр Әниснең бар өметен кисеп ташлады. Сәриянең ире Гыйбадулла исә утка керосин сипкәндәй итте. Кызарынып-бүртенеп тыңлап торды-торды да:

—Йөрисез шунда! Җан көекләре! Әле берсе, әле берсе килә дә: Әнисә кайда? Әнисә кайда? Тү-тү Әнисә, тү-тү!—диде.—Таба алмыйсың син аны, тәти егет. Берегезне дә күрәсе килмәгәч, эзләвегезнең нәмәгә хаҗәте бар? Ә?

—Гыйбадулла абзый, сез әле берсе, әле берсе килә дидегез. Тагын кем сорап йөрде соң аны?

—Һәй!—Гыйбадулла кулларын селкеп өйдән үк чыгып китте.

Булмады. Бер кире килсә, гел шулай була бит. Монда да барып чыкмады. Әнис бирегә нинди өметләр баглап килгән иде. Биштәрен аркасына асып капкадан чыккач, өй каршындагы кайрылары әллә кайчан кубып, шомарып беткән юан бүрәнә өстенә барып утырды. Озак утырды. Тәрәзәдән үзенә текәлгән карашларны да күрде. Шулай шактый бөгелеп төшеп утырганнан соң капкадан Сәрия килеп чыкты да:

—Энем, исеменне Әнис диденме әле? Әнис... Әнис... Һем. Туры килеп тора икән. Күреп торам, бик кайгырып утырасын. Буш кеше түгел, күрәмсен. Ул бит кая киткәнен беркемгә дә әйтмәскә кушты,—диде.

Әнис күнеленда тагын өмет чаткысы уянды:

—Сәрия апа, алайса, сез анын кайда яшәгәнен беләсез?

—Ай, Алла, нәрсә генә дим соң инде.—Хатын тавышында икеләнү сизелде.

—Бая ирегез әле берегез, әле берегез килә, диде. Үзегез дә аптыратып килеп йөрисез, дигән идегез. Аны сорап тагын берәр кеше килгән идемени?

—Жирән чәчле, аксыл керфекле юан гына берәү килгән ие шул. Идмас диде ме шунда, Ильяс дидеме.

Әнис тетрәнеп китте. Идмас! Очрашканда ул бит бу хакта ләм-мим берни әйтмәде. Ничек була соң инде бу? Ул да килеп йөргән икән. Менә тагын ребус. Димәк, анын да ниндидер уе бар.

—Алай икән... Сез Әнисә адресын ана әйттегезме соң?

—Юк-юк.

—Алайса, ул Әнисәнен бер төрекмәнгә кияүгә чыкканын каян белә икән?

Инде Сәрия аптырап калды:

—Син ул Идмасны каян беләсен соң?

—Бергә укыдык. Мин университетка кердем. Ул юллама алып эшкә китте. Берәр ай чамасы элек анын белән базарда очраштык.

—Нәрсә, Әнисә төрекмәнгә кияүгә чыккан дип ул әйттеме?

—Ул.

—Ул каян белгән?—Үз соравына үзе аптырап, Сәрия уйга талды. Әллә... Гыйбадулла ычкындырдымы икән...»

—Әнис, синен Әнисә белән бергә укыганынны белдем инде. Ник эзлисен соң син аны? Ник шулай өзгәләнәсен? Бергә укыганнар азмыни?

—Мин бик яратам аны. Ул да мине ярата иде. Кинәт кенә тотты да юк булды... Их! Бәлкем, ул, көчләнгәч минем Әнискә кирәгем калмады дип уйлагандыр. Шуна күзгә күренмәс булгандыр...

—?!

Сәриянен тыны кысылды. Битләренә тимгел-тимгел таплар бәреп чыкты.

—Көч... Көчләнгән... диденме?

—Әйе. Мине Казанга пристаньга озатканнан сон, кайтып барганда көчләгәннәр бит аны. Мине гаепләп кулга алганнар иде. Гаебем булмагач, чыгардылар.

—Әстәгъфирулла! Син, энем, ни сөйлисен, ә?

—Сез белмәдегезмени? Үзе әйтмәдемени?—Шунда гына Әнис үзенен ярамаган сүз ычкындырганын сизеп алды...

—Алай... Анлый башладым, бугай. Ах, бичара, бичара... Кара әле, башларым ук әйләнеп китте. Әйтәм жирле, минем кайда икәнемне беркемгә белдерә күрмә, диде. Бигрәк тә Әнис исемле егет эзләсә, диде. Син буласын икән инде, алайса... Бик яратасынмыни сон?

Сәриянен тавышы йомшап, икеләнеп калуын чамалап, Әнис дулкынлануыннан торып ук басты.

—Бик! Без бит вәгъдәләр дә бирешкән идек. Планнар кордык. Ә чынында менә нәрсә килеп чыкты.

Әнисненең сүзләрендә хатын-кыз йөрәге ихласлык сиздe бугай, Сәрия үзе дә көтмәстән анын жилкәсенә кулын куйды да өйгә чакырды.

—Әйдә, энем, өйгә керик әле, әйдә әле.

Әнис Сәриягә ияреп кабат капкага юнәлде. Бая гына чылбырына буылып-буылып өргән эт бу юлы тыныч кына карап калды. Кергәч, Сәрия самавырын янартып жибәрде, башын чайкый-чайкый уйланып, ипи турады, эремчек, сөт чыгарып куйды. Бакчада бәрәнге төбенә өеп йөргән Гыйбадулланы чакырып кертте. Шау-гөр килеп уйнап йөргән балаларын урамга чыгарып жибәргәч, иренә:

—Гыйбадулла, монда без белмәгән зур хикмәт бар икән. Тынла әле,— диде.—Ә син, Әнис энем, менә Гыйбадулла абыена барын да сөйләп бир. Ул ир кеше, ул ничек әйтсә, шулай булыр. Йә!

Әнис Сәриягә сөйләгәннәрен кабатлады. Гыйбадулла бүлдермәде, сикереп торып, йөргәләп алса да, тынлап бетерде. Аннары хатынына:

—Әйттем бит мин сиңа! Тикмәгә түгел бу, дип. Әйттемме? Әйттем. Ә син—юк, юк! Ярамый! Бир адресын! Бир!—дип ярсый ук башлады.—Тикмәгә шулай эзләмиләрдер. Берсенә биргәч, икенчесенә ник бирмәскә!

Гыйбадулла сулыш юлына су эләккәндәй, кинәт «ык» итеп туктап, йөткерә башлады. Үзе дә сизмәстән теге чакта кызмача баштан Идмаска адрес биргүен ычкындырды бит. Күзләре түм-түгәрәк булды.

—Син ни сөйлисең? Мин беркемгә берни бирмәдем. Әллә... үзен?

Гыйбадулла, борылып-сарылып тормады, беткән баш беткән дигән сыман, кулын селтәде:

—Ярар сана... Булды инде андый гөнаһ. Теге Идмас дигәне коньяк чыгарып күңелне йомшатты бит, каналья.

Бу кадәр яңалыкны башка сыйдырырга кирәк иде. Әнис бер шатланды, бер кайгырды. Менә, ниһаять, анын кулында Әнисә адресы. Әйе, ул Төрекмәнстанда икән шул. Болай булгач, анын кияүгә чыгуы дөрес икән. Янына барсаң йә хат салсаң, гаиләләрен бозып куюың мөмкин. Нишләргә соң? Тагын бер башваткыч. Сәрия апасы да анын кияүдәме-юкмы икәнен әйтә алмады. Үзе бу хакта берни язмагач, белмим шул дип кенә җавап бирде. Ә шулай да Әнис күңелендә нәни генә өмет чаткысы һаман сүнмәде. Шул чаткы аны Сәриягә рәхмәтләр укый-укый Казанга йөгертте. Уйлана-уйлана, үз-үзе белән көрәшә торгач, Әнис хәл итте: ул Чарджоуга барачак. Әнисәсен... Әнисәнен үзен күреп, барын да ачыклаячак.

## 25

Ай-яй бу Казакъстан далалары! Кая карама соры кинлек. Иртәдән кичкә хәтле горизонтта рәшә уйный. Кояш үләннәрне көйдереп бетергән дә бу бәндәләрнең тагын нәрсәсен корытыйм икән дигәндәй күк гөмбәзендә эленеп тора. Вагонда чыдап булмаслык эссе. Почта-пассажир поезды көчкә-көчкә сөйрәлә. Һәрхәлдә Әнискә шулай тоела. Анын башында уйлар өермәсе. Тизрәк, тизрәк Ташкентка барып житеп, Чарджоу поездына утырырга кирәк. Чарджоу шул Чарджуй икән инде ул. Төрекмәнчә. Менә тиздән Әнис Чарджоуга барып житәчәк тә югалган Әнисәне күрәчәк. Башта читтән генә. Ире белән булса, ялгыз гына чыккан чагын көтеп алачак. Бер көн, ике, өч көн, бер атна, бер ай көтәчәк ул. Бәлкем әле кияүдә дә түгелдер. И-и, ул чагында...

Сәрия Әнисәгә хат салыйм әле дип калды. Яздымы икән, юкмы икән?

Поезд эсседән әлсерәгән станцияләргә килә дә бик озак тора. Әнисненең төшеп йөгерәселәре килә. Помидор-кыяр, кавын-карбыз сатып торучылар рәтләре буйлап узганда да, лаваш сатучыларга акча түләгәндә дә ул жирле

халыкның мондый коры җирләрдә тормыш итә алуына гаҗәпләнә. Урмансыз, елгасыз ничек яшәргә мөмкин дип уйлый.

Юлда яшеллек шактый мул үскән зур станцияләр дә очрап куя. Тиздән шундыйларның берсе Кызыл Орда була, анда поезд озак торачак. Каршыга килә торган поездны көтәчәк, диделәр. Поезд килеп туктады, пассажирлар төшеп, кирәк-ярак ала башладылар. Казакъ егетләре, кызлары аларга балык, җиләк-җимеш, кипкән кавын кебек әйберләр тәкъдим итеп шау-гөр килделәр. Менә станциягә әкрен генә Ташкент поезды да килеп керде. Юл өстеннән салган күпер аша бу якка аның пассажирлары да төшә башлады.

Төрле милләт кешеләренен төрле телләрдә сөйләшә-сөйләшә күләгәдәге урындыкларга һава суларга утырганын шактый карап торгач, туеп, Әнис үз вагоны янына китәргә дип торганда күпер аша төшеп килгән ике кызның берсе таныш кебек тоелды. Хәер, мондый эсседә күзенә әллә нәрсәләр күренер. Ләкин шул секундта теге таныш гәүдәле кыз килә-килә... Әнисәгә әйләнде. Ул кысык кына күзле үзбәк кызы белән елмаеп сөйләшә-сөйләшә якын ук килеп җитте дә һични аңламый аптырап торган Әнискә текәлде. Аның төпсез күкчәчәктәй күзләрендә чиксез гаҗәпләнү чаткылары чагылды. Ул тетрәнеп туктап калды.

—Әнис?!!

—Әнисә?!!

Яшьләр бер-берсенең кочагына ташландылар:

—Синме бу, сөеклем?!

—Мин, мин, бәгърем!

—Ә бу синме, кояшым?!

—Әйе, мин! Мин! Күкчәчәгем!

Шуны гына көткәндәй, якындагы куаклар арасында кошлар чутылдады, вагоннарның берсеннән тирә-якны тутырып «Сагыну» җыры яңгырый башлады. Яшьләр бер-берсен кысып кочаклаган хәлдә әле һаман сокланышып басып торалар иде. Аларны хәзер ике поезд ике якка тартса да аера алмас иде. Беренче булып Әнис анга килде:

—Син кая барасың, әнис алмам?

—Синең янга. Кабул итсән. Ә син?

—Ә мин синең янга.

—Әнисәм!

Төрле милләт кешеләре—ирләр, хатыннар, кызлар, егетләр кочаклашып торган егет белән кыз янынннан елмаеп уздылар.

Ярты юлдан борылып Әнис Казанга билет алды. Тимер юл станцияләре бер-бер артлы бии-бии артка шуды. Кайтыр юл булгангамы, әллә бүтән сәбәптәнме поезд ямь-яшел урманнар, сусыл үләнле болыннар аша туган якка тиз элдертте. Сөйләшеп, куанып, сөешеп туя алмаячак әнис алмаларны киң кочагын җәеп гүзәл Казан, мәхәббәтле, бәхетле-сәгадәтле тормыш көтә, ә алларында, өстәл өстендә әллә кайчан Әнис Әнисәгә бүләк иткән, әле дә хуш исе аңкып торган роза чәчәге ята иде.



Рөстәм
Зәкуанов

# ЧАТЫРТАУГА МЕНӘМ...

## Яшәү—мизгел

Кеше гомере, карасаң—
Бары очкын чаткысы:
Яшәү-үлем арасыннан
Бик аз гына атлыйсы...

Кемгә күпме язылганын
Белми адәм баласы...
(Яшәгәндә бу дөньяда
Изге эшем калсачы!)

Кылган эшләр, эзләр калсын!—
Үтәр, китәр бу гомер...
Бу галәмдә безнең яшәү—
Кыска гына мизгел бер.

## Кем гаепле?

Төркиядә булдым күп мәртәбә,
Хөрмәтлиләр безнең халыкны,
Татар каберләре—чәчәк тулы,
Югалтмыйлар уртак тарихны.

Күпне күрдем ерак Себерләрдә:
Карурманда татар эзләре.
Тубыл, Төмән, Якут шәһәрендә
Горур яңгырый татар сүзләре.

Күпме мактау ява Әләзәнгә—
Бердәм яши мишәр туганым.
Укыла биш вакыт намаз анда,
Иртәләрен яңгырый азаны.

Мари Иле, Чуаш авыллары...—
Татар анда әйтә үз сүзен.
Фин җирендә, хәтта Штатларда
Саклый татар газиз үз телен...

Ә без монда—милләт мәркәзендә,
Кыерсытып рухын анамның,
Башка телдә нотык тотабыз ич,
«Саклыйк, диеп, телен татарның»...

Акыллылар булып сөйләшәбез,
Гаепләне читтән эзлибез.
Рәнҗетүдә туган телебезне
Гаепле тик бары үзебез!

## Зыялы мокыт

Зыялысы, дибез, халкыбызның —
Зур урында түрә булганны:
Туган телдә сүз катарга курка,
Сәламләми хәтта туганны...

Үз телендә сөйләшүләр кая!—
Татарлыктан хәтта ул кача.
Мулла кушкан газиз исемен дә
Яздырган ул инде башкача.

---

Рөстәм ЗӘКУНОВ (1957)—*шагыйрь; «Яшәү мәгънәсе» исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.*

Тукаемны, Такташымны сөйми,
Имеш, алар—авыл җырчысы.
Мода өчен затлы китап җыя,
Тик опера, имеш, «моңлы»сы;

Балетларга йөргән була... Милли
Театрга тапмый вакытны...
Бу адәмме бөек татарымның
Зыялысы? Әллә мокыты?

## Табыну

Күктән иңә бар да җиргә—
Яңгырлары, карлары...
Күкне тишеп боздык мәллә,
Ник күбәйде зарлары?

Афәт Җирдә—көн-таң атса,
Сәбәпсез кан коела.

Үз туганы—туганына!—
Җирдә каршы куела.

Шуңадырмы, юк тынычлык,
Иман бетте җаннарда.
Үзең якла, күр чара дип,
Ялварыйкмы Аллага?!

## Акыл кирәк

Гомерең үткән, вакытың җиткән,
Заман башка, чоры бүтән.
Горурлыкны югалтмыйча
Китә белү кирәк икән...

Матур итеп китү кирәк,
Андыйлар ник җирдә сирәк?
...Кәнәфигә килергә дә,
Китәргә дә... акыл кирәк!

## Азнакайның чал бабасы

Туган якка кайтып килгән саен
Чатыртауга меңәм сагынып.
Кылган чәчен тарый җилләр аның,
Болытлары ага сарылып.

Иңнәрендә имәннәре сакта,
Тарих ята һәрбер тарафта.
Балаларын көткән ана кебек,—
Каеннары моңнар тарата.

Азнакайның рухы—чал бабасы
Тирә якка баглый карашын:
(Байбаклары карый күзен кысып...)
Җилләр исә сыйпап чал башын...

Ак әбиләр безне озатып кала,
Күңелләре һәрчак догада...
Сагынабыз изге Чатыртауны,
Гомер юлы кайда узса да.



Әлфия
Ситдыйкова

# МӘҢГЕЛЕК ЯМЬ ЭЗЛӘП

***

Тормыш кырыслыгын тоеп,
Кайчак елый ирләр дә,
Ил күтәрмәс авыр йөкләр
Баскан чакта иңнәргә.

Күрсәтмиләр күз яшьләрен,
Агарса да чәчләре.
Күздән түгел, йөрәгеннән
Тама канлы яшьләре.

Гомер елгасын кичкәндә
Сынса нык лы ишкәге,
Чиксезлеккә аннан алда
Күчсә җанга иштәше,

Сүзсез генә әрнеп, сызлап
Кайчак елый ирләр дә...
Сыгылмыйлар: дөнья йөген
Илтәсе бар үрләргә.

***

Рухи дөньям Шигъри Күккә баккан,
Мәңгелек ямь эзли дөньядан.
Әйтерсең лә җиргә миңа кадәр
Бер шагыйрь дә әле тумаган.

Әйтерсең лә дөнья күзен ачкан
Минем белән генә бергәләп.
Минем белән бергә ал кояш та
Әйләнә бит җирне тирәләп.

Йолдызлар да, гүя, бүген генә
Җемелдәшә, җиргә күз кысып.
Якын төсле ара, бәхетне дә
Алып булыр кебек кул сузып.

Шагыйрь күңеле—кайтавазы язның
Һәм чәчәкле җәйнең дәвамы.
Рухи дөньям—Шигъри Күккә баккан,
Якынайтып ике араны.

Күкләр миңа кулын сузып тора...
Чиксезлекнең серле карашы.
Шигырь юлларына түгелә-түгелә
Сафлык илен эзләп барасы...
Мәңгелек Ямь эзләп табасы...

Әлфия СИТДЫЙКОВА—*шагыйрә, радиожурналист; берничә китап авторы. Чаллыда яши.*

***

«Тәнкәең ак, түшкәйләрең киң яраткан...»—
Шигырь язган икән Дәрдмәнд кайсы елда?!
Гыйшкы көчле. Ут-ялкынга төренә-төренә
Энҗе сүзләр ятып калган шул дүрт юлга.

«Ак тәнемә, түшкәемә» башың салдың,
Иреннәрең назлап үпте күкрәгемне.
Тансык назга төрә-төрә тирбәттең дә,
Тоташ утка салдың горур йөрәгемне.

Шул мизгелдән ялкын теле белән бергә
Әллә инде күккә аша җаным-тәнем?!
«Тәнкәең ак, түшкәйләрең киң яраткан...»—
Бары Дәрдмәнд аңлар мени минем хәлем?!

***

*Бәйрәмнәр күп... Сабантуйга*
*җитә сирәге...*

Р. Фәйзуллин

Татар даны—сабантуйлар белән...
Каз өмәсе, авыл җыены...
Кеше җаны өчен көрәш бара,
Дәвам итә тормыш дуены.

Ир-егетлек таныла мәйданнарда,
Бил алышып җиңгән мизгелдә.
Җиде буын бабаларын белеп
Яшәү дәвам иткән нигездә.

Көрәшчеләр белән данлы илем,
Бил бирми ул татар көрәштә.
Гасырларны кичеп, Идегәйләр
Идел-Йортны барлап эндәшә.

Җир пакьлеге, Ил аклыгы өчен
Дәвам итә көрәш бүген дә.
Хакыйкать һәм Хөрлек, Гаделлек, Моң
Мәйдан тота Татар илендә.

## Сандугач

Тал-тирәккә кунып сайрый
Бер кош һәркөн таң тугач.
Әйтерсең лә һәр күңелдә
Сайрый сары сандугач.

Һәр йөрәкнең үз ярасы,
Һәр кошның бар үз моңы.
Һәр кешенең язмышында
Тәкъдир язган үз юлы.

Кошка—тирәк, җанга—йөрәк
Кирәк гомер үтәргә.
Сусаганда чишмә булсын
Ятып суын эчәргә.

Кем ярасын кем дәвалар,
Җанга тоташ моң тулгач?
...Җиргә килгән һәрбер кеше
Ул—яралы сандугач.

Айгөл
Әхмәтгалиева

## ӨЗЕЛГӘН ГӨЛ

Суга сәҗдә кылган таллар арасыннан сыкрап-сыктап бер кош аваз салды.
—И-и-ик! И-и-ик!

«Таллар да картая икән». Нигәдер хатынның уе кош тавышы артыннан иярмәде. Аның күз карашы чаларган таллар өстеннән йөгереп үтте.

—Таллар да картая икән.—Үзе дә сизмәстән әлеге уен кычкырып кабатлыйсы итте.

Кулындагы дилбегәсен җай гына кагып барган малай, атны тыя төшеп, җилкәсе аша хатынга борылып карады.

—Бу сиңа келтер-келтер барган трамвай түгел шул,—диде ул үзен бөтенләй зурларча һәм хуҗаларча хис итеп.—На-а, малкай, кая басканыңны карабрак атла әле.

Апасының юл сикертмәләреннән зарлануы дип уйлады булса кирәк, малайның йөзләгән нәни кояш сибелгән сөйкемле йөзе бөтенләй җитдиләнеп китте. Ул, атын тагын да саграк атлатырга тырышып, юлның чирәмле ягына әйдәкләде. Хатын, бөкләнгән аякларының ойый башлавын тоеп, аларны арба читенә салындырып утырды. Янәшәдәге саегып, нәүмизләнеп калган инешнең ишетә белгәннәргә генә ишетелгән челтер тавышына арба тәгәрмәчләренең келтерәве кушылды. Шулкадәр тансык, җанга якын, сагындырган тавыш иде бу. Болай да түгелергә генә торган күңеле тагын да нечкәреп киттеме, хатынның керфек төпләренә яшь бәреп чыкты.

—Матай белән генә җилдертеп барасы ие. Шәһәрдән кайтып кем инде ат арбасында калтырап йөрсен. Һе...—Малай, үзенә аркасын куеп барган хатынга күз кырые белән карап алды. Сәеррәк кунак булды шул туган апасы. Иртән, таң йокысының иң татлы мәлендә уяткан әнкәсе дә колагына кат-кат киртләде:

—Теленә салынып, апаңны бимазалама. Күңеле тулган чак бугай. Иртә таңнан «зиратка менеп төшик», ди. Бар, җәлт кенә атыңны җик, улым, бакча артлатып кына аппарырсың. Ишетсен колагың, күп сүләнмә!

Һе... Сүләнмә, имеш. Болай да инде, су капкандай... Тау бите буйлап зиратка күтәрелгәндә дә, чардуганы эчендә миләш үсеп утырган кабердән чүп утаганда да тел тибрәтеп сүз әйтү булмады. Апасы кап-кара бөдрә чәчләрен яулыгы астына яшерде дә, кыңгырау гөл төсен урлаган күзләреннән тып-тып тамган яшьләрен сөртүне дә кирәксенмичә, әле соры ташны сыйпап алды, әле туфракка йөзен терәп, авыз эченнән генә нидер сөйләнде. Малай белә: бу кабердә кунак апасының әнкәсе ята. Зөлфия апасы ерак шәһәреннән

кайткан саен бирегә килмичә калмый. Аннан соң үзләренең иске йортларына юл тота.

Бу юлы да шулай булды.

—Мин төшеп калыйм, энем, син иплэп кенә кайта тор,—диде ул малайның аркасыннан кагып.—Бәхетең булсын берүк,—дип тә өстәп куйды.

Малай ат-арбасы белән күздән югалуга, уйлары белән ялгыз калган хатын инеш ярына таба атлады. Галушларын салып, кулына тотты. Инешнең үтә күренмәле суына яланаяк кереп басуга, үзәкләрен өзеп, сабый чагы, шушы суда әнкәсе белән кер чайкаган мәлләре исенә төште. Бит очларын әчеттереп, янә күз яшьләре тәгәрәде.

Такыр сукмакта юеш эзләр калдыра-калдыра, тыкрык буйлап үз нигезләренә юл алды. Шәһәрдәге иркен фатирында, гаиләсе белән бөтенлектә гомер кичерсә дә, вакыт-вакыт аңа менә шушы күрешү—ташландыкка калып кына жанга газиз булудан туктамаган туган йорт белән очрашу житми иде.

Келәнең асылмалы бавын тартуга, агач капка авыр сулап ачылырга итте дә, нәрсәгәдер төртелеп, туктап калды. Хатын, ике куллап этә торгач, үзе сыярлык арадан ишек алдына үтә алды. Кеше биеклеге булып үскән кычытканнарны, тигәнәкләрне аягы белән аудара-аудара, болдыр буена атлады. Тәрәзә кашагасындагы төсе уңган бизәкләрне, йортның каралган бүрәнәләрен сыйпап үтте. Элеккечә баскыч астыннан ачкычны эзләп алды, әмма йозакны ачып өйгә керергә ашыкмады. Кунак көткәндәй, нигәдер ашыга-кабалана ишек алдын рәткә китерергә уйлады. Бакча почмагындагы иске келәттә эш кораллары, вак-төяк, кирәк-яраклар саклана иде—шунда юнәлде. Келәтнең йозагы суырылган, ишеге салынып төшкән—кемдер нәрсәдер кирәксенгән ахрысы. Хатын көрсенеп эчкә үтте. Кояш нурларында биегән тузан пәрдәсе аша тирә-якка күз ташлады. Ике ябе сынган кыска сәнәктән гайре «кыйммәтле» әйбер күренмәде. Әнкәсенең иске самавырына кадәр аякланган иде. Эзләнә торгач, алама булса да халат табылды, ишек кашагасы өстендә киндер бияләйләр дә «исән» иде. Хатын кара жирлеккә ак борчаклар төшкән күлмәге өстеннән буяу таплары белән чуарланган иске халатны киеп куйды. Кешегә кереп чалгы сорап йөрүне кирәксенмәде: бияләй киеп, ишегалдындагы үләннәрне кул белән йолкырга булды. Йолкып, бер өемгә өя барды, аннан, сәнәкнең ярым-йорты ябенә эләктереп, өемне абзар янына ташый башлады. Эш белән мавыгып, капкадан килеп керүчене дә абайламаган икән.

—Әссәламегаләйкем, әйбәт кенәме, кызым?

Хатын, каршысында таякка таянып басып торган йомры гәүдәле, кәжә сакаллы картны кем диярга дә белмичә, бермәлгә аптырап калды. Чуар күлмәгенең чабуларын чалбар өстенә чыгарып салган, кара түбәтәен күзенә үк төшереп кигән, камзулына галәмәт зур сәдәфләр тезелгән карт таныш та, түгел дә кебек. Песи битедәй кечкенә йөзендә туктаусыз йөгереп торган күксел күзләре, сакал астыннан да очлаеп, алга чыгып күренгән ияге, үтмәс чалгы белән чабылган жирдә тырпаеп калган үлән сабакларыдай берән-сәрән утырган чәч бөртекләре аның кигән киеменә нишләптер һич кенә дә ятышмый иде.

—Мин әйтәм, Жамалның ихатасына күптәннән берәүнен дә аяк басканы юк иде дим, явыз ниятле бәндәләр була күрмәсен, дим, кердем әле менә, әйе.

Хатын аның бөердән чыккан тавыш белән «әйе» диюен ишеткәч, үзалдына ачы елмаеп куйды. Әнкәсе бу кешене урамда очрата калса да бер чакрымнан урап үтә иде. Колхоз рәисе булып эшләгән елларында авыл хатын-кызларының желегенә төшкән Тимер Хәсән бүген мөгътәбәр карт кыяфәтендә басып тора түгелме?

—Исәнмесез.—Шулай дию белән чикләнде Зөлфия.

Картның мондый корылыкка керфеге дә селкенмәде, ул җайлап кына баскыч тактасына килеп утырды.

—Дога кылып алыйк. Әйе.—Учларын йөзенә терәп диярлек нидер укыгандай иткәч, ашыгып кына битен сыпырды, сәнәген коймага сөяп, үз-үзен кочаклап торган Зөлфиягә сынаулы караш ташлады:

—Хәзерге яшьләрне игә китергәнче әле...—дип мыгырданып алды.—Авыл халкы да мәчеттән ерак йөри, югыйсә улым үз акчасына гүрнәчәдәй итеп салдырган иде. Кермиләр, урап үтәләр. «Кеше талап җыйган акчага салган»,—дип сөйләнүләрен әйт син. Кем кемнекен талаган, кем күргән... Мине мулла дип санамыйлар, йөз чөергән булалар. Алланың кашка тәкәсе кирәктер аларга.—Хәсәннең эчен бушатып зарлануы идеме, сүз юктан сүз булсын дип сөйләнүе идеме, хатын аңа әлләни әһәмият бирмәде. «Зар елатуларынны оныта алмыйлардыр». Уен кычкырып әйтмәде. Шулай да:

—Элек дин юлында йөрмәдегез бугай,—димичә булдыра алмады.

Карт, берән-сәрән калган сары тешләрен күрсәтеп, кош тоткандай сөенеп куйды:

—Элек җир йөзендәге оҗмахта яшәп алдык инде. Әйе. Выдруг тегендә дә бар дигәннәре дөрес булса, ә? Әзрәк итәк-җиңне җыеп куйсаң, мужыт безгә дә тәтер.—Тимер Хәсән янә авызын колагына кадәр җәеп көлде.—Шуларны уйлап, савaплы юлда йөрү әле менә, әйе.

Зөлфия аңа, чиркануын яшермичә, туп-туры карады. Йә Хода, намаз юлына басып та, үзен-үзе алдарга маташа түгелме бу мескен? Хатын, карт белән сөйләшер сүзе юклыгын белдереп, үлән өстенә ташлаган бияләйләрен алып киде, баскыч буеннан читкәрәк китеп, янә тигәнәкләргә барып ябышты.

—Синең дә бөтенләйгә кайтуыңмы?—Хәсәннең тавышы нигәдер калтырабрак чыкты.

Чүгәләп, халат итәген тез арасына җыя төшеп чүп йолкыган хатын бер мизгелгә сәерсенеп китте. Гаҗәп, бөтенләйгә кайтты ди ул монда, вакытлыча гына ди, Тимер Хәсән ни өчен борчылырга тиеш? Тагын кемнең кайтуы турында сүз бара? Гомумән, нәрсә калган аңа, нишләп йөри бу карт аларның ишегалдында?

—Атаңны шушы нигездә төпләнер дип уйлыйсыңмы?

Зөлфиянең кычытканга үрелгән кулы һавада асылынып калды. Нинди ата турында сөйли бу саташкан карт? Бөтен авыл халкы белә ләбаса, юк Зөлфиянең атасы, юк. Кем ул, нинди ул—бу серне әнисе үзе белән мәңгелеккә алып китте. Кимсетелүләр, авырлыклар белән үткән балачагында да, акыл утыртып, буй җиткергән елларында да әнисеннән әти таптырган мәлләре булмады түгел, булды. Җамал җил ашап яргалап бетергән иреннәрен дерелдәтеп, инәлүле тавыш белән: «Сорама, кызым», дияр иде. «Сиңа әти тигән кешенең мыскал да гаебе юк, кызым. Тик сорама, исемен дә, кемлеген дә сорама. Гаепләсәң, бары мине гаеплә». Гаепләмәде ул әнисен. Бәлки кайчан да булса үзе әйтер дигән сүзсез өмет белән, елларга бәйләнеп еллар үтте.«Әтиең читтән килгән кеше иде. Син туганчы ук суга батып үлде». Бетте. Күпме яшәп тә, әти кеше турында бүтән сүз ишетә алмады Зөлфия. Шулай да әнкәсенә бер тамчы да рәнҗү сакламады. Ана кешенең болай да ут йотып, һәрчак үзен кемдер алдында гаепле тоеп яшәгәнен күрмәдеме әллә, аңламадымы? Йөрәгенә төйнәлгән җан газабы шулай иртә гүргә кертте дә инде әнисен.

Зөлфия бернәрсәне ачык белә: әнисе белән Тимер Хәсән арасында күзгә күренмәс җеп булып гомер буе ниндидер нәфрәт хисе яшәде.

—Аның белән каберең якын булмасын!—ди торган иде Җамал.

—Беспартийный башың белән персидәтелгә каршы дәшмәкче буласыңмы әллә? Әйткәннәр сиңа дуңгыз фермасына эшкә төшәсең дип, и вчу. Пнимаешь,

партия кушканны үтәмәскә итә. Әйе.—Тимер Хәсәннең чыңгылдап торган тавышы ерак еллар аша кабат аларның капка төбендә яңгырый түгелме?

Уе үткәннәр белән бүгенге арасында бер мизгелгә адашып алган Зөлфияне:

—Әле кайтып күзгә күренмәгән, халык үзен мәчеткә имам итеп сайлау турында хыялллана. Имеш, нәселләре затлы—муллалар нәселе,—дигән сүзләр чынбарлыкка кайтарды.

Юкәдә икән чикләвек. Нинди кысыр хәсрәт белән көя дисәң, мәчет тирәсендәге урынын югалтудан куркып өтәләнә икән Тимер Хәсән.

Зөлфия, синең эшләреңдә минем катнашым юк дигәндәй, җилкәсен генә сикертте дә йолкынган кычытканны сәнәк белән абзар ишеге төбенә ташуын белде.

—Җамалны әйтәм, авыр туфрагы җинел булсын, һай, тәккәбер иде дә соң! Әйе. Син дә анаңа охшагансың.—Хәсән каш астыннан туктаусыз йөгереп торган күзләрен Зөлфиягә төбәргә тырышты.—Ә бит сине минем кыз дип тә авыз пычратучылар күп булды, he-he-he.—Картның көләргә маташуы күңел кайтаргыч иде.—Әле ярый Җамалның үз авызыннан атаңның кем икәнен әйттерә алдым.

Аның тагын нидер әйткәнен хатын ишетмәде, ишетсә дә аңламады. Ул аяк астындагы җирнең, тирә-яктагы үләннәрнең салмак кына әйләнүен тойды. Егылып китмим тагын дигән сыман, аркасы белән болдыр тактасына терәлде. Уң кулы тактадан тырпаеп торган кечкенә кадакка тап булды—бердәнбер котылу чарасына юлыккандай, калтыранган бармаклары белән бар көченә шул кадакны кысты. Бу адәм аның әтисенең кем икәнен белә! Зөлфиянең тез буыннарына әйтеп бетергесез хәлсезлек йөгерде. Шул ук мизгелдә әллә каян ингән көч белән ул Хәсән янына ыргылды. Кәҗә сакалын уң кулы белән учлап, битараф кыяфәттә утырган карт:

—Әстәгъфирулла!—дип читкә тартылды.

—Кем ул? Кем ул минем әти тиешле кеше?

Хәсән карт, бу сүзләрне ишетеп, гаҗәпләнүдән салынып төшкән иреннәрен җыя алмыйча, берара тынсыз калды. Хәтта күзләре дә бер мизгелгә йөгерүдән туктады кебек. Димәк, Җамал үз кызына берни дә әйтмәгән!

—Кһым. Алай икән. Әйе.—Сәбәпсез йөткерә-йөткерә, Хәсән карт утырган җиреннән аягүрә басты, йорт бүрәнәсенә сөягән таягына үрелеп, гаҗәеп мөһим нәрсәне күзәткәндәй, бик бирелеп таякның һәр сызыгын өйрәнеп чыкты. Оекбаш кунычына кыстырган чалбар балагына бер хәерсез чүп эләккән икән—иелеп, озаклап, шуны кагып маташты.

—«А»сын әйткәч, «б»сын да әйт.—«Тимер Хәсән» дигән сүзләр тел очында йомарланып калды.—Зөлфия, сабырсызланып, аның сүз катуын көтте. Карт исә киресенчә, күңелендәге ләззәтне—кемнеңдер үзе каршында ялварып, баш иеп тору мизгелен озаккарак сузарга теләгән иде.

—Җамал әйтмәгән икән, димәк, кирәксенмәгән. Әйе. Ярар, искегә тисәң, исең китәр ди. Кузгалыйм мин.—Хәсән, хәйләкәр елмаюын яшерергә тырышып, түбәтәе белән йөзен сыпырып алды.

Янә тиен җитезлеге белән картның каршысына ташланган Зөлфия үз ярсуын тыяр хәлдә түгел иде. Ул, чүп өеменә кадап куйган сәнәгене күтәреп, картның күкрәгенә терәде.

—Әйтәсеңме, юкмы? Ике дә уйламыйм, китереп кадыйм. Әнкәемнең күз яшьләре өчен булыр ичмаса.—Күзләре сәер ялтыраган хатын бу минутта тәмам куркыныч кыяфәткә кергән иде.

«Менә үз башыма бәла! Шайтан телемнән тарттымы... Билләһи, кадар да бу тиле. Анасы сынары...» Үз дәверендә әшнәләре җилкәсенә һәм утырган кәнәфие артына ышыкланып күпләрне дер селкетеп торган ир заты, ябык кына гәүдәле шушы хатын алдында көчсезләгән тоеп, артка чигенде. Һава

житмәгәндәй, камзул төймәләрен чишеп ташлады, аптыраган чырай белән түбәтәен баш артынарак шудырып куйды.

—Туктале, кызым, олы кеше белән шулай шаяралар димени?! Алла сакласын, уеннан уймак диләр. Әйе.

—Әйтәсеңме, юкмы?—Зөлфия инде гаҗәеп тыныч тавыш белән баягы соравын кабатлады.

—Менә, Алла бәндәсе. Әйттем бит, Сабирҗан дидем. Бүген-иртәгә авылга кайтыр дип көтәләр үзен. Шул инде сиңа әти тиешле кеше.

—Син моны каян беләсен, Тимер Хәсән?

—Ананның үз авызыннан чыккан сүзләр. Миңа ни, кеше эшенә кысылмыйм.

—Ялганлама.—Зөлфия, сәнәкне әле дә булса кулыннан ычкындырмыйча, һөҗүмгә ташланырга әзер кыяфәттә басып тора иде.—Кемгә, кемгә—сиңа барып эч серен уртаклаша торган кеше идеме әнкәй?

—Сон, үзем әйттердем. Алайса авылда сүз таралган ие, имеш Җамалның кызы Хәсәннән икән, фәлән-төгән. Кая, күпме үгетләп-куркытып та якын китермәде анаң. Кһым...—Карт, артык сүздән ачылган авызын томаларга теләгән шикелле, учы белән янә сакалын сыпыргалады.—Кич белән ферманың каравыл йортына сөйрәп дигәндәй алып кердем Җамалны. Син, мәйтәм, партийный кешенең, намуслы персидәтелнең абруен төшереп, гаиләсен бозып нинди сүз таратасың анда, дидем. Кызың миннән булырга җиң очына да кагылдырганың юк бит, дидем. Тешләк иде бит Җамал, минем күзгә караган да каткан. Чыгырдан чыкканмындыр инде, кулдагы йөгән белән китереп сыладым шулчак. Артыкка киткәнен беләм инде, нишлисең, ачу килгән чак бит. «Кызыңның атасы кем? » дим. Авыз ачарга исәбе юк иде, синең белән куркыттым. «Әйтмәсәң, үзең үкенерсең. Кызыңның пешеп килгән чагы, алай-болай харап итеп ташласалар, гаепне үзеннән эзлә», дидем. Кая барсын, әйтте. Ну үземне дә кисәтте, малай, «мин исән чагында бу исемне берәрсенә ычкындырсаң, йә кызыма бер-бер-бер хәл кылсаң, сәнәк белән кадап үтерәм», диде. Синдә дә анаң каны ага... Вәт шул. Сабирҗан читтә иде бит, әлерәк кенә силсәвиткә хат язган. Мөмкин булса, туган авылыма бөтенләйгә кайтыр идем дигән. Мондагыларга нәрсә, бик әйбәт булыр, йорт та табарбыз дип җавап язып салганнар инде. Имеш, балаларга дин сабагы да укытыр... Әйтерсең, мин укыта алмыйм! Әйе. Улым салдырган мәчеткә шул килмешәкне генә кертеп утыртасы калды. Әзергә бәзер, җайлы шул...—Әңгәмәнең ни белән башланганын бөтенләй исеннән чыгарган Тимер Хәсән, төн йокыларын качырган көндәшен искә төшерүгә, ярсуына чыдый алмыйча, җәлт кенә торып басты; сәнәгенә таянып тораташ урынына катып калган Зөлфиянен дөньяда барлыгын онытып, капкага юнәлде.

Каккан казык урынына күпме басып торгандыр, хатын вакыт исәбен югалтты. Күз алдыннан әнкәсенең аркасын ярып үткән кып-кызыл яра эзе, ананың «егылып төштем» дип шул канлы җәрәкәткә киндер сөлге ябып йөрүләре; «балам син, бәхетем син» дип Зөлфияне күз яшьләре белән иркәләп сөюләре сызылып китте. Моңарчы язмыш белән ризалашып, дөньяда әти дигән сүз дә барлыгын онытырга тырышып яшәгән хатын кинәт пәйда булган хакыйкатьтән куркып калды. Күкрәк түрен ят бер тойгы әрнетергә тотынды.

***

Тормыш тоташ кайту-китүләрдән генә тора кебек... Ул чакта да Сабирҗан туган авылына кайткан иде. Юк, юк, бөтенләйгә түгел. Бер генә, бары бер генә тапкыр балачак эзләре буйлап үтәр өчен, тирәннән-тирән сагыну дәрьяларының дулавын басар өчен... Ни хәл итәсең, туган авылы аны үгисетте,

әткәсен-әнкәсен кан-яшь түктереп, җиде ятлар арасына озатты. Чишәргә теләп тә, мәңге чишелмәс төеннәр дә була икән шул көнелдә... Кайтып төшүгә тау башыннан шактый озак карап торды. Хәтерли әле, аның бала чагы иде: йөзеннән төсе качкан әтисе, тал кебек сыгылып төшкән әнисе һәм ул, Йолдыз Кашкага тагылган как арбага утырып, нигездән кубарылганда, дөресрәге, аларның гаиләсен «кулак» дип авылдан сөргәндә, барысы да башкача иде. Ул чордан соң шактый сулар аккан диген... Кара бөдрә чәчле, томраеп торган зәңгәр күзле, какча гәүдәле малай түгел, чигә буйларына иртә чал кунган, тормыш сынауларыннан чыныккан, киң җилкәле, мәһабәт гәүдәле өрлектәй ир-егет кайтты әйләнеп.

Менә бу яшь наратлар ул киткәндә бөтенләй нарасыйлар кебек иде, нәзберекләр иде... Ә хәзер, күрче, наратлык тәмам олы урманга әверелгән. Әнә теге, уртадагы Ялан тау элек, Сабирҗан бала чакларда, коточкыч зур, биек булып күренә иде,—тәбәнәкләнгән, чүгә төшкән... Салкын чишмә наратлык янындагы таулар кочагында җырлап ага торган иде—аны да авылга күчергәннәр, ахыры, инешнең аръягына таба калын торба сузганнар, шул тирәдә көянтә-чиләк күтәргән хатын-кызларның кайнашканы күренә.

Ул, юл сумкасын бер кулыннан икенчесенә күчерә-күчерә, туган тиешле абыйсы Каюмның йортына юнәлде. Авыл белән араны бәйләп торган, еллар шаукымыннан да курыкмыйча, алар белән элемтәсен өзмәгән бердәнбер туган иде Каюм агасы.

Сабирҗан килеп кергәндә, Фәйрүзә җиңгәчәсе коштабак тотып ишегалдында чебиләр ашатып йөри иде.

—Чеп-чеп-чеп, и үләмәт нәмәрсә, тагын болдырдагы таска кереп чыккансың бугай, лычма булгансың...—Капкадан кемнеңдер кереп килүен күргәч, сүзеннән бүленде, кулын каш өстенә куеп, беравык керүчегә төбәлеп торды. Алай гына танымагач, табагын чирәмгә утыртып, кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә Сабирҗанга таба атлады.

—Кем дип әйтим, күзләрем дәген юньләп аерып бетерми...

—Соң, мине танымаска инде, җиңгәчә-ә-ә-әй...

—Әллә? Әллә, Сабирҗан, син инде, апаем?! И-и, сине күрер көннәр дә бар икән...—Фәйрүзә, Сабирҗанны кочаклап алган шәйгә, аркасыннан сөя-сөя такмакларга кереште:

—Кайтмаска дип антлар эчеп киткәнсеңдер, бөтенләй, агай. Аталарың да, үзең дә хатлар, посылкалар салгалап тордыгыз, онытмадыгыз үзебезне. Менә агай, менә агай. Бер хәбәрсез дигәндәй... Абзаң шаккатыр инде... Киленне алып кайтмагансың бугай?

—Юк... юк, җиңгәчәй. Кайтам димәде, ярар инде. Өй эчендә дә көчкә йөри, кая инде болай ерак юлга чыгу. Көне-төне күмер тузаны сулап, комбинатта эшләп йөрүнекедер—хастага калганына ничә ел... Мин инде, бер булса да күреп килим дип, кыймылдадым әле менә. Их, җиңгәчәй, белсәң иде: сагындыра, төшләргә кереп интектерә авыл!

—Шулайдыр, шулайдыр, җаным. Туган туфрагыңнан, рисвай итеп, аерып китсеннәр әле... Әткән-әнкән изге җаннар иде, урыннары оҗмах түрендәдер инде,—дип, Фәйрүзә җиңгәчәсе тагын балавыз сыгып алды. Аннан, тынычлана төшеп:

—Һаман икегез генә яшәп ятышмы? Килен белән дип әйтүем?

Сабирҗан җан әрнүе белән кулын гына селтәде:

—Булмады инде, җиңгәчәй, бала дигәннәренә тиенеп булмады. Менә туа, менә туа дип көткәннәре дә дөньяга килә алмадылар. Кем гаепле, Алла белсен.

—Менәтрәк, кем гаепле дип торасың, дөньясыннан эзлә инде син гаепне, шулкадәр бредный җирдә эшләп нинди саулык калсын ди кешедә. Үлсеннәр,

бетсеннәр, тамырлары корысын дип җүрикәйләр эшләтә торганнардыр, адәм ыстырамы. Бөтен җүнле кешене токымнары белән ду китереп бетермәсләр ие. И-и, заманакайлар диген... Ниләр генә кыланмай адәм балалары белән...— Фәйрүзә, артыграк әйтеп ташладым дигән шикелле, сүзеннән кырт туктап, яулык чите белән авызын каплады.

Каюм абыйсы әле дә булса тимерче алачыгында эшли икән, кайтканын көтеп тормастан, Сабирҗан да шунда юнәлде.

Сагындырган шул. Барысы-барысы да. Мөмкин булса, күгелҗемләнеп торган наратлыкны да, инде чыпчык тезеннән калып, ярларын тал басып бетергән инешне дә кысып-кысып кочаклар иде Сабирҗан... Әтисе белән әнисе, авыл туфраккайларына кайтып күмелсәк иде, дип, әй, хыялланганнар иде. Кая инде... Урал таулары артында, адәм балаларының күз яшьләреннән төзелгән таш каланың ялан кырында булды мәңгелек йортлары.

Хатыны дә кайта алса, Сабирҗан ана Олы елга буендагы су тегермәнен— әтисе Сәфәргали мулланың мактанычын күрсәтер иде. Өй нигезләрен, гөрләп торган умарталарын күрсәтер иде. Бакчада күкрәп үскән алмагачлар күләгәсенә алып чыгар иде, күкрәк киереп, кин сулыш белән җырлап җибәрер иде. Иде... «Иде» шул. Су тегермәне ташландыкка калган, умарталар таланган, ботарланган, алмагачларны салкын кышта утынга турап бетергәннәр. Ябык кына гәүдәле Сәфәргали мулла берүзе кулында тоткан дәүләтне «мәгърур» Совет хөкүмәтенең җилкәсе күтәрә алмаган.

Уйларына чумып, тау итәгендәге алачыкка килеп җитүен дә искәрмәгән икән. Сабирҗан, һәр почмактан күзләп торган балачак хатирәләрен яңартып, нәкъ элеккечә, Каюм абыйсы янына ялан тәпи йөгереп төшкән чактагыча, ике учын авыз турысына китереп:

—Каюм абзыка-а-ай!—дип сөрән салды.

Алачыкның ишеге ачык иде. Менә анда куе зәңгәр күлмәгенең җиңнәрен беләгенә кадәр сызганган, искереп, төсе аералмаслык хәлгә кигән алъяпкыч бугaн, бөкрәя төшкән ябык гәүдәле, яше алтмышлар тирәсендәге ир заты күренде. Ул берара кунакка шаккатып текәлеп торды.

—Әй, энекәш, җан түзмәде диген, ә?—Кап-кара кулларын алъяпкыч итәгенә сөрткәләгәч, Каюм Сабирҗанны каты итеп кочаклап алды. Берара икесе дә сүзсез тордылар. Исәнлек-саулык сорашуны бу мизгелдә кирәксенмәделәр. Бугазга килеп тыгылган төер сүз башларга комачаулый иде. Күз яшьләрен ирләрчә эчкә йотып, бер-берсенең күзләренә текәлделәр. Кайчандыр төз нараттай булган Каюмны авыл тормышының авырлыгы ярыйсы бөккән: инсәләр салынган, маңгай сырлары берсеннән берсе тирәнәйгән. Күзләренең җетелеге шактый кимегән.

Бу очрашуда шатлыгы да, сагышы да җитәрлек булды. Туганнарның икесенең дә күнелен «язмышларның пыран-заран килүендә кем гаепле соң» дигән сүзсез сорау тырный иде.

...Сабирҗан, өйдә тик ятып булмас дип, көн дә Каюм абыйсы белән алачыкка йөрде. Беркөнне ишек төбенә чүгәләгән килеш икәүләп тәмәке көйрәтеп утыралар иде, җиз самавыр күтәреп, алачыкка күрер күзгә күркәм генә булган, утыз яшьләр тирәсендәге бер хатын килеп керде. Ояла төшеп сәлам бирде дә шунда ук чаяланып:

—Бәрәч, Каюм абый, кунагыңны да эшкә йөртмәсәң инде,—дип әйтеп куйды. Каюм да:

—Ничава, кунак дип бушка ашатып яткырмам инде. Укасы коелмас әле,— дип шаяртып алды.

Хатын, Сабирҗан ягына күз сирпеп карады да, үз карашыннан үзе тартынгандай, тиз генә Каюмга таба борылды.

—Карале, Каюм абый, самавырымның борыны агып интектерә, тиз генә

рәтләп бирчәле шуны.

—Әллә салкын тигәнме, борыны ага дисен.—Каюм, самавырны әйләндереп-тулгандырып карады да:—Ярар, Жамал, иртәгә, син килүгә Сабиржан абыен ялт иттереп ясап куйган булыр үзен,—диде.

—Китчәле, иртәгә кадәр чәй эчмичә торыйммыни? Сина сон инде ул ике-өч минутлык эштер, кулыннан гөл коя торган кешегә,—Жамал, елмая-елмая салпы ягына салам кыстырып куйды.

—Сон, безнен янга кызлар көн саен килеп йөрми бит. Иртәгәгә бер сәбәп булыр иде диюем... Ярар инде, бик ашыккач, карап карыйк.

Эшне төгәлләгәннән сон Сабиржанның Жамал артыннан күз алмыйча карап калуын күргән Каюм:

—Әллә, энекәш, күзен төште инде, әнә бит, ияреп китеп бара,—дип төрттерәсе итте. Аннан, кинәт кенә житдиләнеп:—Шәп кеше ул Жамал, мировойын! Түлке бәхете генә юк. Персидәтел Тимер Хәсән харап итеп ташлады да үзен, шуннан бирле ир-ат халкын жен урынына күрә,—дип өстәп куйды.

—Нәрсә, көчләгән идемени, Тимер Хәсәнне әйтәм.

—Сон, апаем, персидәтел кеше көчли мени инде. Үз «ирегеп» белән мәжбүр генә итә бит. Каршы килеп кара!.. Жамал гына нәрсә, ирле хатыннарны да читкә куймый, итәк колы.

—Белә торып, шул хатыннарның ирләре ни карый? Жыйнаулашып бер бәргәләп атсалар да...

—Бәргәләрсен, бар... Иртәгесен авылын белән Себер сөрерләр—шул булыр. Районндагы бөтен түрә монын кулыннан ашый.

Сабиржан, «да-а-а», дип сузып кына куйды да, бүтән сүз дәшмәде. Тимер Хәсән дигән исемне ишеткәч, бер вакыйга хәтерендә янарды. Теге чакта, сабый бала килеш авылдан кубарылганда, шушы Хәсәннен сөенечтән әрле-бирле йөгергән күксел күзләре озатып калган иде аны... «Сөрелгәннәргә» бер кабым ризык, бер чүпрәк заты алырга рөхсәт итмәделәр. Сабиржан, риясыз сабыйлыгы белән, өстенә яна бишмәтен киеп утырган иде. Үзләренә чапырыш күрше булган Тимерхан агай, моны күреп, жәнлек аулаган аучы комарлыгы белән малайның өстенә ташланды.

—Сал жәтрәк, нәселегезне корытасы нәрсә,—дия-дия, бишмәтне малайның өстеннән йолкып диярлек салдырды. Кулында әйләндереп-тулгандырып караганнан сон, табышны арба читендә басып торган улы Хәсәнгә тоттырды. Тегесе, сөенеченнән авызын колагына кадәр ерып, Сабиржанга тел күрсәтте дә бишмәтне кочаклап өйләренә таба йөгерде.

Ул чактагы гарьлектән арба төбенә капланып үксүләре Сабиржанның бүгенгедәй күз алдында иде.

***

Жамал, алачыктан чыкты да, бермәлгә аяк астына төбәлеп тын гына басып торды. Өйгә кайтырга ашыкмады ул. Аяклары үзеннән-үзе инеш буена—бөдрә таллар белән каймаланган Кызыл ярга атлады. Яр читенә чүгәләде дә, болай да ялт итеп торган самавырын ком белән ышкырга керешә. Аннары, эшен ташлап, сабый бала кебек тезләрен кочаклады, сулыгып-сулыгып еларга тотынды. Бар авыр уйларны, хәсрәтләрне, әрнүләрне, рәнжүләрне шушы инеш суларына салып агызасы иде. Болай таллар кебек бөгелмәс иде Жамал.

Гомеренен заяга үтүенә әрнеп, елады да елады. Анын да башка кызлар кебек сөясе, сөеләсе, иркәләсе, иркәләнәсе килмиме? "Ямьсез бит мин, кем карасын мина" дип үз-үзен ышандырып йөргән көннәре кире кайтсамы? Терсәк якын, тешләп кенә булмый... Инде яшьтәшләренен балалары буй житкереп килә, ә ул һаман сынар канат. Сүз катучылар булмады түгел,

булды, кайберләренә кызның тәне генә кирәк иде, кайберләрен исә Җамал үзе якын итә алмады. Авылдашларының үзе артында кызганулы яки көлемсерәүле карашларын тойса да, җаны илергән, телем-телем телгәләнгән мәлләре күп булса да, дәшмәде Җамал. "Сатылмадым мин Тимер Хәсәнгә, сафлыгымны таптатмадым. Йөзенә төкерер өчен генә бардым янына!" дип кеше саен аңлатып йөрсенме? Илнең авызын тегеп буламы?

Шашып-шашып бала сөясе килә аның. Урамнан берәрсенең бала җитәкләп үткәнен күрсә, томырылып-томырылып карап кала. Фермага менгәч, хатыннарның аһ та ваһ килеп балаларының шуклыгыннан зарланулары, уңышларына сөенүләре, гамәлләрен сөйләп көлешүләре йөрәген мең пычак белән телгәләгәндәй итә. Колакларын томалап чыгып чабасы, югаласы килә андый мәлләрдә. Төннәре дә мең газап белән үтә: төшләрендә ап-ак тәнле, тупырдап торган бала сөя Җамал. Сабыйның калач кебек күпереп торган кул аркаларын, буынтык-буынтык тәпиләрен үбә. Баланың, чырык-чырык килеп, йомшак куллары белән муенына сарылуыннан гәүдә буйлап искиткеч җылы ләззәтле дулкын таралуын тоя. Уянып китүгә исә—кочагына сыенган чигүле мендәрдән кала, янәшәдә берни дә, беркем дә юк.

Берничә көннән Җамал тагын алачыкка килде. Янә шул самавырын күтәреп. Каюмның көндез районга киткәнен дә, әле тиз генә кайтып җитмәсен дә яхшы белеп килде ул.

Сабирҗан әллә Җамалны, әллә таныш самавырны күрүдән бераз аптырабрак калды. Өч көн эчендә тагын борыны ага башламагандыр бит моның, шәт...

—Ага, ага шул, Сабирҗан абый, рәтләп кенә бир инде. Тагын купкан бит.

—Кит, берәрсе йолкыса да болай куптарып булмас, җен кагылгандыр моңа.

Җамал тавыш-тынсыз гына Сабирҗанның эшләп бетергәнен көтеп утырды.

—Менә, булды,—дип самавырны сузгач та, алырга ашыкмады. Бит очларының кызышып януына игътибар итмәскә тырышып, Сабирҗанга күтәрелеп карады һәм кисәк кенә аның күкрәгенә килеп капланды.

—Сабирҗан абый... зинһар дим, дөрес аңлый күр мине. Минем... минем бала табасым килә. Ямьсез дисәң, йөземә карама, тик бер генә, бер генә ярат әле мине... Җирәнмә, җирәнмә миннән... Бер генә бардым Тимер Хәсән янына—әткәй-әнкәйнең, үземнең яшәрлегемне калдырмаячагын аңласам да бардым... Күңелен күрер өчен дип уйлый күрмә, бары тик ыштыр битенә төкерер өчен генә бардым... Белеп торам, ул адәм актыгы мине барыбер тынычлыкта калдырмаячак. Хатын-кызны яклардай кыю ирләр бар дисеңме авылда.—Җамал кайнар күз яшьләре белән Сабирҗанның күкрәген пешерә-пешерә, ашыгып пышылдарга кереште.—Ялгызлыкта гомерем үтеп китә бит, ичмаса тупырдатып сөярдәй куанычым булыр иде. Исемеңне телемә дә, исемә дә алмас идем. Син бит читтәге кеше, үзеңне эзләр, бәйләнер дип уйлый күрмә. Тик... бала гына бүләк ит миңа. Беләм, гөнаһка чакырам сине, тик ни хәлләр итим, авылдагы кемгә барып шулай дип ялварыйм—җүләргә санаячаклар бит үземне... Сине кайтканыңнан бирле күзәтәм, сабыр, ипле кешегә охшагансың, Сабирҗан абый...—Җамал үкси-үкси ирнең иңбашларына сарылды.

Ике ут арасында калды Сабирҗан. Кайнарлык, яшьлек ташып торган хатынның кулларын үзенең иңбашыннан сыпырып кына төшерер иде—соңгы елларда, хатыны авырганнан бирле мондый дәртне тоя алмаган ир уртасы Сабирҗанның да тәнендә җаны бар лабаса... Куып та чыгармас иде үзен—күзгә күренмәгән билгесезлектән хатынының моңсу карашы, сары сарган сагышлы йөзе эзәрлекләп тора кебек...

Гомерендә беренче тапкыр аны хыянәткә әйдиләр. Кул изәп, ачы да, шул

ук вакытта татлы да елмаеп, хыянәткә чакыралар... Тән акылга буйсынмады. Куллар үзләреннән-үзләре Жамалны сыгылмалы биленнән күтәрергә үрелде, аяклар үзеннән-үзе алачыкның алгы ягындагы как сәкегә юнәлде...

Бераздан Жамал, күзләрен йомган килеш тагын Сабиржанның күкрәгенә башын салды да, бик әкрен тавыш белән:

—Кыз балам тусын иде. Кыз кешене әтисенә охшаса бәхетле була диләр: синеке кебек кап-кара бөдрә чәчле, зәңгәр күзле кызым тусын иде. Зөлфия дип исем кушар идем үзенә.

—Ә нигә, нигә Зөлфия?—Әле генә булып узганнан аңына килеп бетә алмаган Сабиржан үз тавышын үзе танымады.

—Зөлфия—бөдрә чәчле кыз дигәнне аңлата...

***

—Черт- черт. Черт-черт...

Жиләк өзгәндәй, үзе дә сизмичә, бер-бер артлы кычыткан яфракларын йолыккалый икән—Зөлфия, бармак очларының әчетеп кызышуын тоеп, тәүге тапкыр күргән кебек, кулларына текәлде. Сабый чагында шушы кулларын әтисенең киң учына яшереп, авыл урамын хыялында ничә кат әйләнгән иде ул! Артыннан көлеп, кимсетеп түгел, көнләшеп карап калдылар. Әнисе дә башын югары чөеп, горур кыяфәттә янәшәдән атлый иде... Бала йөрәген кичләрен татлы хисләргә күмгән ак хыял иртәләрен эреп юкка чыга, таң пәрдәсе эленгән тәрәзәдән ачы чынбарлык үрелеп карый. Инде йөрәкне учка кысып, барысы белән—әнкәсен мәңгелеккә югалту хәсрәте белән дә, ачылмас серләрнең барлыгы белән дә килешкән иде бит. Ә бүген... Гүя ул, кара бөдрә чәчләрен жилгә таратып, балачакның ак хыялына таба йөгерә. Тик ара якынайган саен күңелне сөенеч түгел, киресенчә, ниндидер шом били. Хыялын кулга төшерүгә, шушы аклык кар бөртегедәй эреп юкка чыгар күк тоела.

Бу минутта бүтән һичбер чарасы калмагандай, Зөлфия үзе буе үләннәрне ялан кул белән ярсып-ярсып өзгәләргә кереште. Жан әрнүе бу юлы яшьләр булып түгелмәде. Уйсыз, хиссез калган хатын, дөньясын онытып, жир тырмый-тырмый кычыткан, тигәнәк йолкый иде—әйтерсең лә кеше язмышлары белән шулар уйный, әйтерсең лә алар гаепле...

Зөлфия, чүп үләне арасында чык тамчысын да эчеп бетерергә өлгермәгән зәп-зәңгәр чәчәкне күргәч, кинәт айнып киткәндәй булды. Кыңгырау гөл, «мине өзмә, ни гаебем бар?» дигәндәй, мөлдерәмә тулы караш белән хатынның күзләренә текәлгән иде...



Ләйсән Якупова

## ЯШЕНЛЕ ТӨНДӘ...

***

**Караңгы төн.**
**Якты күзләр.**
**Дөньяга моң сибелгән.**
**Ташкын булып**
**Аккан хистән**
**Күңел бүген исергән.**

**Караңгы төн.**
**Җан—күбәләк.**
**Күңел дөньяны коча.**
**Йөрәгең—ут,**
**Ялкынына**
**Күбәләк-җаным оча...**

***

**«Кайгырсаң-кайгырмасаң да**
**Ахырыбыз бер инде.**
**Өч тиенлек бу дөньяга**
**Төкереп бирдем инде».—**

**Кыен чакта яшь аралаш**
**Елмаеп шулай димен.**

**Тик кайсы вакыт бөтенләй**
**Башка шул сүзем минем:**

**«Бар күңелем, җаным белән**
**Бөеклегеңне тоям,**
**Яшәгәнем өчен синдә**
**Мең-мең рәхмәт, и, Дөньям!»**

***

**Нәни яфрак агач-анасыннан**
**Аерылмаска һаман тырыша.**
**Кар каплаган горур бу яфракка**
**Күңелемнән мин дә булышам.**

**Карлы җилләр күңелемә бәрә,**
**Мин дә еламаска тырышам.**
**Соңгы хисләремне җылытырга**
**Беренче кар миңа булыша...**

***

**Яңгырдан түгел,**
**Күзләрем**
**Яшьләремнән яшьләнде.**
**Яшенле төндә**
**Яшенме,**
**Яшьлегемме яшьнәде?!.**

*Ләйсән ЯКУПОВА—шагыйрә; «Яшенле төндә» исемле китап авторы. Уфада яши.*

***

Китәм инде,
Хуш, Хыялым,
Калдырам сине...
Һәм башкача үз дөньяңа
Чакырма мине.
Күптән инде минем өчен
Зәңгәр түгелсең.
Зәңгәр дөньяңа башканы
Алып керерсең.

Миннән дә беркатлырагы
Табылыр әле.
Ул да сиңа минем кебек
Табыныр әле...

***

Ак, саф Бәхет!
Әгәр килә калсаң,
Мин көткәнчә,
Теләгәнчә кил.
Кабул итәм сине
Олы килеш,
Вакланмаган килеш кенә,
Бел!

***

Мин һаман да көләм әле,
Мин һаман да елмаям.
Минем башым һаман горур,
Күзләрем һаман шаян.

Мин һаман да көләм әле...
Син аптырыйсың, беләм.
Аңламыйсың, мин бит бары
Еламас өчен көләм...

***

Бүген килеп тезләндеңме,
Калдырма диюеңме?
Сөрт яшьләрең, соң уяндың,
Мин җирлим Сөюемне.

Мәхәббәтем үлде инде,
Белмәдең лә кадерен.
Гөлләргә күм—шул кечкенә
Безнең сөю каберен...

## Кош һәм кешеләр

«Кош буласым килә, диде егет,—
Булыр идем көчле, горур бөркет!»
«Туган булсам иде былбыл булып!»—
Диде кызый, егетенә сыенып.

Җәйге кичне шулай утырдылар,
Сөйләштеләр... Тамак ялгадылар...
...Иртән шунда бер кош килеп кунды.
Көнбагышлар калган... Әй, куанды!

«Балаларым өчен булды азык!
Көннәр буе очам, эзләп ризык...
Туган булсам иде кеше булып...»
Шулай уйлап китте кошчык очып...

*«Ватаным Татарстан»га—90*

# УНӨЧЕНЧЕ ӨМЕТ

*«Эш»... Татар газетасы өчен бик килешле исем.*

*Хезмәт—ул татар кешесенең ихтыяҗы, яшәү рәвеше. Урта Азиядәге кардәшләребез хезмәт сүзен «Михнәт» дип тәрҗемә итә. Туксан яшьлек газета язмышына төшкән михнәт юбилей мәкаләләренә, фәнни язмаларга, истәлек һәм альбомнарга гына сыймас.*

*Әле, Татарстанны Автономияле республика итү турындагы декретка В.И.Ленинның кулы куелмаган килеш, Октябрь инкыйлабыннан соң нибарысы дүрт ай вакыт үтүгә, рәсми Татар газетасы чыга башлый. Газета хәрби интервенцияләр, гражданнар сугышы, колхозлашу, шәхес культы елларын, Бөек Ватан сугышын, торгынлык чорын һәм, ниһаять, базар мөнәсәбәтләре илә социализм казанышларын сату кебек михнәтләрне исән-имин кичеп, яналык хәбәрчесе буларак яшәп калган. Әйе, аның исеме сигез тапкыр алышынган, әйе, бүгенге баш мөхәррир дә инде унөченче... өмет.*



*«Кызыл Татарстан» (1924—1951) редакциясе. Сулдан уңга: Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Гали, редактор урынбасары Г. Толымбайский, редактор Г. Нигъмәти, К. Тинчурин.*

«Ватаным Татарстан» газетасының унөченче баш мөхәррире Минназыйм Сәфәров белән кара-каршы сөйләшеп утырабыз.

**—Миңназыйм әфәнде, әгәр кичәге 90 еллык тарихны күзалласак, сезнең газета белән безнең журнал бик якын туганнар булып чыга. Ник дигәндә, матбагаларыбызның нигез салучылары һәм даими авторлары шул ук шәхесләр бит.**

—Әлбәттә шулай. Татар журналистикасының тарихы йөзәр еллап кына исәпләнә, ә матур әдәбият борынгыдан килә. Шуна күрә дә һәр иҗтимагый янарышның башында әдипләр торган. Г.Камал, Ф. Бурнаш, Г.Нигъмәти, Ф. Сәйфи-Казанлы, Ф.Әмирхан, Һ. Такташ, Х. Туфан, М.Җәлил, М.Әмир, И.Гази, Ш.Мөдәррис кебек бик күпләр безне туганлаштырган.

**—Туган димәктән, заманыбызга күрә хөсетлектәнме, хәзер бит туган белән туганның арасында да ышанычлы гына дуслык юк. Ә «Ватаным Татарстан» белән «Казан утлары» арасында бу дуслыкның традицияләре дә бар.**

—Әйе. Әйтик без «Казан утлары» журналын редакциябезгә почта аша яздырып алып укыйбыз.

**—Без дә сезнең әбүнәче. «Ватаным Татарстан» безгә дә килә. «Казан утлары»ның һәр яңа санына күзәтү ясап барасыз.**

—«Казан утлары»нда чыгарга тиешле күләмле әсәрләрнең өзекләрен үзебездә бастырып укучыларны алдан ук сөендерә торабыз.

**—Миңназыйм әфәнде, газетагызның һәр саны хикәя, публицистика, тәнкыйть мәкаләсе белән тулы, хәтта, башка газеталардан аермалы буларак, шигырьләрне дә юллап кына түгел, ә полосалап—бит тутырып бирәсез. Сезнең бүгенге оештыручыгыз республиканың Министрлар Кабинеты. Алар әдәби язмаларга бирелгән мәйданны күпсенмиләрме?**

—«Ватаным Татарстан»га баш мөхәррир булып расланганда Президентыбыз М.Ш.Шәймиев, мине сынар өченме: «Алга таба газетаны нишләтергә уйлыйсың?»—дигән иде.

**—Ил Башының нинди җавап ишетергә теләгәнен сизенгәнсездер, шәт?**

—Әйе. Иске өйне кемдер сипләп котыла, кемдер яңаны сала,—дидем. «Сипләү—

ялкаулар, булдыксызлар эше, янаны салырга кирәк»,—диде Минтимер Шәрипович.

**—Һәм шулай булды дамы?**

—Үземә каршы эшләгәнем юк. Планеркаларда ни уйлап, ни кинәшсәк—безнеңчә бара. Шуңа күрә эшкә сөенә-сөенә киләм.

**—Димәк, «Ватаным Татарстан» әдәбият-сәнгатькә булган игътибарын киметмәячәк? Хикәя-повестьлар, романнан өзекләр, тәнкыйть мәкаләләре дә, шигырьләр дә элеккечә күпләп басылачак?**



*«Социалистик Татарстан»да чыккан фоторәсем. Казанның Спорт сарае. Беренче космонавт Юрий Гагарин. Р. К. Беляев белән. 1967 ел.*

—Әлбәттә. Газетагызда әдәби әсәрләрне киметегез дип берәүгә дә югарыдан Указ төшми. Кайбер газеталар шигырь басудан бөтенләй баш тарталар икән—бу аларның эчке сәясәтләре генә. Халык хәзер шигырь укымый дип халык исеменнән хөкем карары чыгарып утырырга ярамый. Заманында мәчет манараларын да халык исеменнән кисканнәр. Аны райком секретарьлары егып йөрмәгән. Һәр авылның берәр денсезе табылган. Тиражлар бетә, халык укымый, татар китаплары нәрсәгә ул дип йөрүчеләр—денсезләр алар.

**—Димәк, Миңназыйм әфәнде, һәр явызлыкның нигезендә финанс кытлыгы түгел, ә «кеше факторы» тора.**

—Алар бер-берсенә тыгыз бәйләнгән... 90 яшьлек газетабызны традицияле, сыйфатлы, зәвыклы итеп саклап 100 яшенәчә житкерәсебез килә. Эстрада тирәсенә укмашкан «сары матбугат» белән уртаклыгыбыз юк. Алар бит тираж арттыру өчен бүгенге эстраданың үзе кебек «арзанлы», оятсыз, тозсыз гайбәтләр язып халыкны матур әдәбияттән, зәвыклы сәнгатьтән аералар.



*«Социалистик Татарстан»ның (1960–92)редколлегия утырышы. Сулдан уңга: Ш. Зәбиров, Г. Шәрәфетдинов, А. Әхмәтов, М. Мостафин, З. Төхфәтуллин, Ш. Хамматов (редактор), Р. Тимергалин, Ф. Әгъзәмов, З. Габитов, З. Хөснетдинов, З. Шәфигуллин. 1968 ел.*

**—Сезнең үз кызыгыз Гөлназ да шул эстрада тирәсендә эшли. Ул да «сары прессага» иярмәсме?**

—Без аның белән күп саен шушы темага сөйләшәбез. Гаиләбез табын артына жыелгач чәй эчүләр еш кына «планерка»га әверелә. Бәхәс туа, ләкин туган тел дигәндә арабызда конфликт юк.

**—Тәрбиягез бик кырыс күренә—сезнең Гөлназ татарчаны әлифба телендә сөйләшә. Ни дисәң дә ул бит шәһәрдә туып-үскән «безнең көннәр герое».**

—Беләсез бит, мин Чуашстаннан килгән татар. Татарстаннан читтә яшәүче диаспора ана телен сезгә караганда хөрмәтләбрәк саклый. Яшермим, мин үзем дә шагыйрь булырга хыялланган кеше. Якташым Р.Зәйдулла белән шигырьләребезнең бер полосаларда басылганы бар, Г.Сәбитов кереш сүз язган иде. Хәер, кайсы гына татар баласы шигырь язып карамагандыр.

**—Кызыгыз Гөлназ да кечкенәдән шигырь яздымы?**

—Ул VI сыйныфта укыганда, хәер сорап торучы бер әбине кызганып, аның

турында «Сабантуй»га язып җибәргән иде... Һәм студент елларында «Татарстан яшьләре»ндә И.Шәрәфидә практика үтте. Радио-телевидение аның стихиясе ул.

**—Ярый, без тагын газетагызның 90 еллык юбилеена әйләнеп кайтыйк әле... Белгәнемчә, «Ватаным Татарстан» милли матбагалар арасында тираж буенча ел рекорды номинациясендә өч ел рәттән «Ника» статуэткасы алган, дүрт төбәктә махсус хәбәрче тоткан, ике-өч хезмәткәрле әдәбият һәм сәнгать бүлеген саклап калган, китапханәле-музейлы олуг газета... Язылу чоры башлангач, районнардагы хакимият җитәкчеләре сезгә бик теләп булыша торгандыр.**

—Демократия бит хәзер—ни телибез, шуңа язылабыз дип теге «сары пресса»га ябышып яталар. Матбугат бетә диген бик җайлы ишарә уйлап таптылар да... Йә безнең хакимияткә хәзер зыялылар кирәкми, йә алар моны махсус шулай эшли! Җитәкчеләребез укымый икән, димәк, аларга ияреп гади халык та укымаячак.

**—Бәлки министрлык һәм тармакларның матбугат үзәкләре ярдәм итәләрдер?**



*2008 ел, 7 февраль. «Ватаным Татарстан» газетасының яңа саны әзерләнә (сулда—баш мөхәррир Миңназыйм Сәфәров).*

—Матбугат үзәкләре, миңа калса, эчке яңалыкларны читкә чыгармас өчен махсус оештырыла...

**—Бәлки, тәнкыйть язмаларын күбәйтергәдер?**

—Әйе! Урындагы берәр җитәкчене «борычласаң», бүген «Ватаным Татарстан» чыкмады дип бөтен районында тиражны «югалталар». Язылу чорында куралэтә аяк чалулар башлана. Татар түрәләренең серкәсе су күтәрми. Алай да тәнкыйть язмалары чыга тора... Без күбрәк укучылар белән эш итәбез, почтага үзе барып языла торган әбүнәчеләребезгә таянабыз. Алардан көн саен кочак-кочак хат килә. Бөтенесе ярдәм сорый...

**—Укучылар белән элемтәгез гел хат аша гынамы?**

—Юк, нишләп хат кына булсын?! Иллегә якын хәбәрчебез гел юлда. Интернеттан да шактый яңалык керә. Премьер министр Рөстәм Миннеханов махсус күрсәтмә биргәч, министрлар, ведомство җитәкчеләре белән турыдан-туры элемтә оештыра башладык. Казан шәһәре мэры да килде. Газета укучыларының сорауларына өчәр сәгать буе җавап биргәнебез бар.

**—Миңназыйм әфәнде, укучыларыгыз олыгаямы?**

—Киресенчә, яшәрә. Анкеталар үткәргәч, без моңа ышандык. Инде яшьләр өчен «Яшелчә» дигән кушымта да чыгарабыз: яшь, яшел, яшьләрчә, ягъни... Редакция хезмәткәрләре дә яшәрә, күбесе—үземнең шәкертләрем. Журналистика факультетында унбиш ел укытуымның тагын бер нәтиҗәсе бу.

**—Миңназыйм әфәнде, газетабызның исеме сигез тапкыр үзгәргән дидегез. Монысы яшәрме?**

—Исем дигәннән, газета тарихында баш мөхәррирләрнең берсе Фәтхи Бурнаш та минем якташ булган, ул да Чуашстанның Батыр районыннан («Чаян» журналына исемне ул тапкан). Безнең газетаның җисеме дә, исеме дә табылган. Әгәр беренче көннәреннән үк «Ватаным Татарстан» дип оеша алса—ул монарчы сигез кат исем дә алыштырмаган булыр иде.

**—«Эш» турында сөйләшеп башланган әңгәмәбез бик бәрәкәтле үтте. Газетагызның 100 еллыгында тагын бер кат очрашырга язсын.**

**Камил КӘРИМОВ**

# МӘҖИТ ГАФУРИ ИҖАТЫНДАГЫ МӨҺИМ БАСКЫЧ

Март аенда Башкортстанда татар телендә нәшер ителүче «Кызыл тан» газетасының дөнья күрә башлавына 90 ел тула. Гасырга якын шушы вакыт аралыгы эчендә басма бай һәм матбугат тарихында мәңгегә сакланырлык үзенчәлекле юл үткән. Рәсми мәгълүматларга караганда, аның беренче саны 1918 елның 1 мартында чыга. Оренбург шәһәрендә «Башкортстан» исеме белән татар телендә нәшер ителүче газета Башкортстан Вакытлы Революцион Советы карары нигезендә оештырыла. Март ахырында Оренбург Дутов гаскәрләре тарафыннан басып алыну сәбәпле, «Башкортстан»ның биш саны гына дөнья күреп өлгерә. 1919 елның 14 сентябрендә газета Кече Башкортстанның башкаласы Стәрлетамак шәһәренә күчерелә һәм анда «Башкортстан хәбәрләре» исеме белән чыга башлый.

1922 елның 14 июлендә «Автономияле Башкортстан Совет Социалистик Республикасының чикләрен киңәйтү турында» ВЦИКның декреты чыга. Ана ярашлы рәвештә республиканың башкаласы да, һәм, әлбәттә, «Башкортстан хәбәрләре» редакциясе дә Уфага күчерелә.



*Сулдан уңга: Галимҗан Ибраһимов, Мәҗит Гафури һәм «Коммуна» газетасы редакторы Мөхәммәт Бикбулатов.*

Бу вакытта башкорт әдәби телен формалаштыру буенча эшчәнлек тә киң колач җәя. Моның нәтиҗәсе буларак, 1923 елның 29 декабрендә РКП(б) өлкә комитеты президиумы «Башкорт телен гамәлгә ашыру буенча практик эшләр турында» карар кабул итә. 1924 елның 22 августыннан республикада башкорт телендә—«Башкортостан», татар телендә «Яна авыл» газеталары чыга башлый.

«Яна авыл»ның төп максаты—әлегәчә иске, начар хуҗалыгы белән сөйрәлеп килгән фәкыйрь, надан авыл урынына ничек итеп яхшы хуҗалыклы, бай һәм анбелемле яна авыл төзергә өйрәтү була. «Шунын белән бергә, эшчеләр тормышына да гәзит зур урын бирәчәк»,—дип яза «Яна авыл» 1924 елның 22 августында шушы исемдә беренче тапкыр аерым газета булып чыккан санындагы мәкаләдә. Чыннан да, редакция коллективы бу мәсьәләгә тугры булып кала. Арытаба, заман сулышы белән бергә аның исеме «Коммуна»га үзгәртелә. Һәм, ниһаять, Бөек Ватан сугышы елларында өч елга якын тукталып торганнан соң, 1944 елның 12 мартында «Коммуна»ның законлы варисы—«Кызыл тан» газетасының беренче саны дөнья күрә. Бүген ул үзенең күпсанлы укучыларына нәкъ шушы исем белән таныш. Әмма нинди генә авыр елларда һәм нинди генә исем белән чыгарылмасын, «Кызыл тан» дәүләт пропагандасы коралы булып кына түгел, милли традицияләрне, мәдәниятне саклау һәм үстерү, халыкны рухи яктан баету үзәге булып та калган. Бирегә һәрвакыт иҗади интеллигенция, зыялылар тартылган. Редакцияне хәтта Башкортстанда яшәүче әдипләрнең иҗади һәм әдәби Мәккәсе дип атарга буладыр. Газетаның беренче саны дөнья күргәннән алып бүгенге көнгә кадәр анда эшләп киткән һәм әлеге вакытта эшләүче журналистларның алтмыштан артыгы әдәби иҗат белән шөгыльләнгән, үзебезнең милли әдәбиятны төрле жанрлардагы әсәрләр белән баеткан. Татар-башкорт дөньясында киң билгеле иҗат ияләре бар алар арасында.

Башкортстанның халык шагыйрьләре Мәҗит Гафури, Сәйфи Кудаш, Әнгам Атнабаев, Башкортстанның халык язучысы Нәҗип Асанбаев, Салават Юлаев исемендәге премия лауреатлары Әнвәр Бикчәнтәев, Әсгать Мирзаһитов, Абдулхак Игебаев, Гыйлемдар Рамазановларның исеме «Кызыл таң» тарихында алтын хәрефләр белән язылган. Шулай ук Таһир Ахунжанов, Гариф Гомәр, Динис Исламов, Гайнан Әмири, Хәсән Сарьян, Рәис Габдрахманов, Вазих Исхаков, Фәнил Әсәнов, Якуп Колмый кебек күренекле язучыларны да телгә алмыйча мөмкин түгел. Галимҗан Ибраһимовның да газетага язышуы, журналистлар белән аралашуы билгеле...

«Кызыл таң» редакциясендә төрле елларда эшләп киткән кешеләр исемлегендә Мәҗит Гафури исеменең беренче итеп язылуы һич тә очраклы түгел. Ул бүгенге «Кызыл таң»ның башында торучыларның берсе. Мәгълүм булуынча, Мәҗит Гафури журналистлык эшчәнлеген 1919 елда «Кызыл юл» газетасында башлап җибәрә. «Шәрекъ ярлылары» һәм аның дәвамы булган «Урал» газетасында үткен каләм остасы булып танылган Гафури 1922 елда Уфада чыга башлаган «Башкортстан» газетасына эшкә күчә. Бу редакциядә эшләгәндә 1923 елда аңа «Башкортстанның халык шагыйре» дигән исем бирелә. Газета икегә—татарчага һәм башкортчага бүленгәч, Гафури 1924 елның августыннан «Яңа авыл»ның хатлар бүлеге мөдире эшен зур кинәнеч белән башкара. Хәбәрчеләр хатларын эшкәртергә, алар белән хат алышырга ярата, шул эшләрдән ямь таба һәм яшьрәк каләмдәшләренә үрнәк булып тора. Һәм, әйтергә кирәк, шагыйрь газетаның идея-әдәби ягын яхшыртуда, аны халык арасында популярлаштыруда да мөһим роль уйный. «Кызыл таң»ның 1968 елдагы 18 март санында чыккан мәкаләсендә Үзбәк Гыймадиев билгеләвенчә, революциягә кадәр үк әдәби иҗат эшен публицистика белән тыгыз бәйләп алып барган атаклы язучының журналистлык эшчәнлеге «Яңа авыл»да аеруча киң ачыла. Ул 1928 елга, ягъни сәламәтлеге начарланып киткәнгә кадәр редакция аппаратында эшләвен дәвам итә, төрле бүлекләргә җитәкчелек итә, акыллы киңәшләре һәм ярдәме белән күп кенә талантлы яшьләрнең иҗатына юнәлеш бирә. Бу унайдан С. Кудаш, Г. Әмири, Г. Гозәеров һәм башка әдипләрнең истәлекләре Мәҗит Гафуриның «Яңа авыл»дагы эшчәнлеге турында бик күп җылы хатирәләр саклый.

Гафури матбугат эшенә ил тормышындагы иң авыр вакытларда тотына. Сәяси формацияләрнең алышыну вакыты була ул. Бу елларның үзенчәлекләре тарихтан һәркемгә мәгълүм. Язучы шушы чорда илдә барган үзгәрешләрне үз иҗатында актив яктырта башлый. Аның шигырьләренә яңа заман геройлары, башта инкыйлабчылар һәм ялкынлы көрәшчеләр, соңрак—социализм төзүчеләр, эшчеләр образлары килеп керә. Әмма Гафуриның идеаллары үзгәрми. Әдәбиятка мәгърифәтче, халыкны анбелемгә өндәүче, аның киләчәк тормышын кайгыртучы буларак килеп кергән әдип шушы идеяләр системасына тугры булып кала. Шуңа да аның егерменче гасыр башы революцияләрен җанланып кабул итүе һич тә очраклы түгел. Алардан соң илдә башланачак үзгәрешләр халык тормышына һичшиксез яхшылык кына китерәчәк дип ышана ул. Һәм язучының бу чорда язылган һәр шигырендә, әсәрендә диярлек, шушы ышану чагылыш таба. Ә инде Мәҗит Гафури журналистлык эшенә ныклап тотынгач, идеяләр аның мәкаләләренең дә нигезенә ята. Шунысы кызыклы, әдәбияттагы юлының башлангыч этапларындагы кебек үк язучының иҗатында да, журналистлык хезмәтендә дә антитезаларга, ягъни күренешләрне, вакыйгаларны капма-каршы куеп чагыштыруга шактый зур урын бирелә. Бу алым аның байтак мәкаләсе һәм әсәренә хас.

1925-29 еллар арасында «Яңа авыл»да Мәҗит Гафуриның утызга якын мәкаләсе, «Ике күренеш», «Дәртле егетләр», «Басулар арасында» дигән очерклары, «Болар да пролетарийлар имеш» дигән фельетоны чыга. Алар арасында ярлы крестьян хуҗалыкларын аякка бастыру мәсьәләләренә багышланганнары да, мәдәният һәм көнкүреш проблемаларын күтәргәннәре дә, совет матбугаты тарихын һәм бурычларын яктыртканнары да, татар эмигрантларының пычрак эшләрен фаш иткәннәре дә, истәлекләр һәм сорауларга җаваплар да бар.

Алдарак әйтеп үтелүенчә, матбугат белән әдәбият бер-берсе белән берегеп үсә. Мәҗит Гафуриның газета эшчәнлеге дә аның иҗатында чагылыш тапмый калмаган. Язучының бу чорда язган шигырьләренең күпчелеге «Яңа авыл»да дөнья күрә...

Мәҗит Гафуриның «Тормыш баскычлары» дигән күләмле повесте дә әүвәл «Яңа авыл»да басыла. Ул 1927 елның 16 октябреннән 1928 елның 14 февраленә кадәр дүрт ай буена саннан-санга бирелеп бара. Гомумән, бу чорда газета битләрендә әдәби

әсәрләргә урын шактый күбрәк бирелә башлый. Электән язышкан шагыйрьләргә Гайнан Әмири, Йосыф Гәрәй, Бәдрүш Мокамай кебек яңа исемнәр өстәлә. Замандашы Хәлил Маннанов Мәҗит Гафуриның редакциягә бу әсәрне алып килүен болайрак хәтерли: «Редакциягә килгәндә, Гафуриның кулында бер папка бар иде. Гариф Гомәр белән сөйләшеп киттеләр. Ул соңгы елларда гына язган «Тормыш баскычлары» повестен гәзиттә бастыру турында сөйләшү өчен килгән булып чыкты. Алар икәүләп редакторга кереп киттеләр. Соныннан редактор «Тормыш баскычлары»н басарга әзерләү өчен Гариф абыйга чыгарып биргәч, аның башлап безнең гәзиттә басыласын белдек. Гафуриның үткән беренче Бөтендөнья сугышын чагылдырган бу зур повесте гәзиттә бүлеп-бүлеп басылды һәм байтак номерга сузылды. Аны басканда, ул үзе көн дә диярлек редакциягә һәм типографиягә килеп йөрде. Материалның әдәби бүлектән ничек чыгуы, корректурасының ничек укылуы, типография хаталарын булдырмау мәсьәләләре белән якыннан кызыксынды. Шулай ук повестьның яхшы чыгуын тәэмин итү өчен Г. Гомәр, Г. Әмири, Б. Баян, мин һәм башкалар аны күзәтеп бардык һәм корректураларын үзебез кат-кат укып чыктык...»



*Уңнан сулга (утырганнар): Мәҗит Гафури, Ризван Алушев, Сафа Борһан, Муса Йосыпов, Рәхмәт Чурагулов. Басып торалар: Гайса Габбасов, Сәйфи Кудаш, Гариф Гомәр һәм Мортаза Якупов. «Яңа авыл» коллективы. 1924 ел.*

Бу истәлектән күренүенчә, Мәҗит Гафури повестен «Яңа авыл»да басу тәкъдимен үзе ясаган. Бу исә газетаның аңа бик якын булуы, язучының аны укучыларны хөрмәт итүе турында сөйли.

«Яңа авыл» редакциясе әсәр турында фикер алышу оештырган. Укучылардан килгән хатлар 1928 елгы 14 февраль санында урнаштырылган. Аларда әсәрне аерым китап итеп чыгару кирәклеге әйтелә, повестьны яхшырту буенча тәкъдимнәр дә бирелә...

Тормышының ахырына кадәр Мәҗит Гафури «Яңа авыл», арытаба «Коммуна» газетасы белән бәйләнешен өзми. 1930 елның 15 сентябрендә ул «Коммуна»ның хәбәрчесе сыйфатында Новосибирск шәһәрендә үтүче авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсенә бара. Бирелә шагыйрь Себер эшчеләре белән очраша, алар арасында Башкортстаннан һәм Татарстаннан килүчеләрнең байтак булуын күрә. Гафури шәһәрдә татар телендә чыгучы «Азат Себер» газетасы редакциясендә дә була...

«Кызыл таң»ның туксан еллыгы уңаеннан Мәҗит Гафурины искә алу һич тә очраклы түгел. Алдарак әйтелүенчә, ул бүгенге көндә меңләгән кеше яратып укыган басманың нигезен салучыларның һәм аның ныклап үсеп китүенә зур өлеш кертүчеләрнең берсе. Мәҗит Гафуриның «Яңа авыл» да эшләве газетаның халык арасында популярлашуында мөһим роль уйный. Шул рәвешле, «Кызыл таң» туксан ел буена үз абруен төшермичә халыкка хезмәт итә икән, монда Мәҗит Гафуриның өлеше гаять зур. Шуңа да аның исеме газета тарихына алтын хәрефләр белән язылган.

**Камил ЮЛАЕВ,**
*Уфа*

Фәрит
ХАТИПОВ

# ТЫНГЫСЫЗ ҖАН

## Батулланың иҗатханәсендә

Әдип Рабит Батулла, үзенең күп замандашлары кебек, кыйбла югалтырдай катлаулы, тиз үзгәрүчән елларның шаһиты булды. Ул 1938елда—Сталин золымының кайнаган чорында—дөньяга аваз салып, Хрущев, Брежнев, Черненко, Андропов, Горбачев, Ельцин, Путин чорларын узып, 70 яшенә җиткән шәхес. Житмеш ел аз гомер түгел, яшьли йөрәк авырулы кешегә бигрәк тә.



Яшь Батулла—житез чаңгычы, мәктәптә алдынгы, төбәктә алдынгы спортчы. Татарстан беренчелегенә Яна Писмән (хәзерге Лениногорск) ягында уза торган чаңгы ярышларында (1955) 10 чакрым арада беренче булып килгәндә финишка житәрәк аңын жуеп егыла һәм гомерлеккә йөрәге киңәеп-имгәнеп кала. Шактый катлаулы иҗат тормышы кичереп, илле сигез яшенә житкәндә (1996) аның йөрәгенә берничә операция ясыйлар. Дүрт тамырын алыштыралар һәм аорта клапанын кисеп, протез (тимер) капкач куялар. Язучы гомерлеккә икенче группа инвалид булып кала һәм яшьтәшләреннән иртәрәк пенсиягә чыга. Ләкин Батулла чирләшкәләр исемлегенә керергә теләми, бик үҗәт эшли, яза, концертлар алып бара, сәнгать кешеләренең иҗат кичәләрен оештыра, спектакльләр куя, Коръән аятьләренең татарча мәгънәләрен әзерли (ун еллык хезмәт), ике углын тәрбияли.

Катлаулы операцияләрдән соң Батулла күбрәк тә эшләп ташлады бугай. Ул 34 китап чыгарган. Аның 15 томлыкка житәрлек әсәрләре бар, шуларның күп өлешен пенсиягә чыккач башкарды ул.

Бу әсәрләрнең күбесе аерым китап булып та, вакытлы матбугатта да басылган һәм аларның кайберләре тиешле бәяләрен алган. Безнең вазифабыз—әнә шул абруйлы фикерләрне дә файдаланып, Батулла әдипнең олы иҗаты турында сүз әйтү.

Мәгълүмдер ки, язучы белән әдип арасында бераз аерма бар. Без барыбыз да язучы, журналист та, хәбәрче дә, бер-ике хикәя бастырган кеше дә язучы... Алга таба шушы язучы кантарлы иҗаты белән әдип икәнен исбат итәргә тиеш. Әдипләр—халык язмышын кайгыртучы, милләте өчен азатлык таләп көрәшүче абруйлы иҗатчы шәхес ул. Яшәеше, иҗаты белән Батулла бу таләпләрнең барысына да туры килә. Шулар өстенә ул драматург та, артист та, режиссер да, телевизион тапшырулар остасы да, кичәләр оештыручы да, укытучы да. Ул Казан театр училищесында һәм сәнгать академиясендә озак еллар укытып, шәкертләр тәрбияләгән остаз. Кайчак «Кем соң ул Батулла?» дигән сорау туарга мөмкин: күбрәк артистмы ул, режиссермы, укытучымы, әллә язучымы? Бу сорауга мин Батулланың 60 яшьлек бәйрәмендә сәхнәдән Илһам Шакиров әйткән сүз белән җавап бирәм:

Батулланы аны әкиятче дә, хикәяче дә, мәзәкче дә, драматург та, укытучы да, режиссер да диләр. Мин үзем аны бер генә сүз белән әйтер идем: Батулла ул безне, халыкны, агартырга тырыша, ан-белем тарата. Ул—мәгърифәтче!

## Серле хикәяләр

Кин тармаклы иҗатын Батулла хикәяләр язудан башлап җибәрә. Кече күләмле бу жанрда ул яшәешнең, кешеләр арасындагы төрле мөнәсәбәтләрнең күп якларына туктала. Аның бу өлкәдәге эшчәнлегенә бәя биреп, Фатих Хөсни болай дип язды: "Батулланың кыска һәм характерлы табылган диалоглар аша хикәяләргә тырышуы һәм шуның өстенә тагын сатирик сәләте игътибарны үзенә җәлеп итә." *(Татарстан яшьләре, 12, декабрь, 1967.)*

Гаҗәеп житезлек һәм үҗәтлек, әйтерсең лә Батулла өчен бөтен юллар ачык: яз да яз! Батулла яза да яза, ләкин житмешенче елдан соң кинәт тынлык, Батулла өч ел китап чыгара алмый. Моның сәбәпләрен тәфсилләп тикшереп тормыйк, гаеп Батулланың үзендә дә, «өстәгеләрдә» дә бардыр, һәрхәлдә монда Батулланың тиктормас холкы, тиктормас теле сәбәпчедер, мөгаен. Татар кошы тартар теленнән табар!

Хәер, тиктормас тел генә гаепләме икән, бәлки Батулланың әсәрләре гаепледер?

"Мираж" исемле хикәя *("Казан утлары", 1968, 1 сан)* аерым сөйләшүгә лаек әсәр. Татар әдәбияты өчен бу хикәя типик әсәр түгел иде. Астарлы хикәя, кинаяле әсәр иде ул. Батулланың иҗат йөзен билгели торган программ хикәя иде. Әйтергә кирәк, Батулланың иҗатында андый хикәяләр берничә; шушы юлдан тайпылмыйча алга киткән булса, Батулла кинаяле әсәрләрне күпләп язган булыр иде. Ләкин Батулла тәнкыйтьләрдән каушап калдымы, алга таба "сарыклар да исән, бүреләр дә тук" дигән ысулларак иҗат итә башлады.

Хикәя күп кенә укучыларны аптырашта калдырды. Хикәядә вакыйга да, сюжет та, фикер дә юк кебек.

Ике шофер, әйләнеч юлдан йөрергә иренеп, туры юлдан, чүл аша бораулау скважиналарына таба китәләр. Юл уртасында бензиннары бетә, запас бензин бакларын Исәнгол гаражда онытып калдырган була. Кояш көйдерә, су бетә, ризык бетә, җәяү китсәләр, барып житә алмаслар. Аларны эзли чыкканчы өч көн узар. Исәнгол җәяү китик ди. Рәуф машина астында көтик ди. Шулай берничә көн узып китә. Офыкта мираж уйный башлый, анда шәһәр, гөлбакчалар шәүләләнә. Яшь шофер ялган шәһәргә таба китә. Рәуф аның үлем чиренә кереп киткәнен аңлап, аны саклар өчен, һәлакәткә барасын белсә дә, дусты артыннан ялган бәхеткә таба барырга мәҗбүр була. Икесенең дә хәле бетә. Рәуф авыр булса да, дөрес юлга төшәргә тырыша. Исәнгол аерылып китә, акылдан яза. Рәуфне хәлсез килеш кышлакка йөзе белән борылган хәлдә табалар, ул исән кала.

Хикәя бетте. Мин монда хикәянең тел төбен ачып салдым бугай, хикәяне укыганда игътибарсыз кешегә бу тел төбе, кинаяя ачылып бетми. Тора-бара гына укучы авторның ни әйтергә теләгәнен аңлый башлый. Хәйләле әсәре белән автор читләтеп "Коммунизм—ул мираж, ул матур ялган, ул һәлакәткә илтә", ди түгелме? Романнарына торырлык хикәя иҗат иткән Батулла. Шушы хикәясе белән генә дә яшь язучы Батулланы шул чакта ук "әдип" дип атарга була иде.

"Мираж" хикәясе кайбер житди оешмаларның игътибарын тиз җәлеп итте.

Аның "Фасил белән Василә" хикәясе дә *("Печать", Советская Татария, 1970, 4 ноябрь; "Мөһер", Татарстан яшьләре, 1980, 1 гыйнвар; "Йылдыз", кырым-татар журналы, 1981, № 3.)* астарлы, кинаяле, хәйләкәр әсәр.

Фасил исемле ир табиплар киңәше белән хатыны Василәне Кырымга алып китә. Ләкин аларга кунакханәләрдә урын юк, шәхси фатирга урнашырга мәҗбүр булалар. Фасил кинәт шушы каралты-кураны таный, кайда нинди агач үскәнен әйтеп бирә, каршы йортларны да кайчандыр күргән кебек хис итә. Фатир хуҗасы Ксенья Тарасовна аларны фатирдан куып чыгара, имеш, аларның паспортында ЗАГС мөһере юк. Татар авылында никах белән дә гаилә корып яшәгәннәре турында, аларның дүрт баласы барлыгын, фотокарточкаларын күрсәтеп сөйләсәләр дә, Тарасовна каты тора, авыру хатыны белән Фасил урамда кала.

Шулай итеп, бичара Фасилне икенче тапкыр үз йортыннан, үз ватанынннан куалар. Әсәр оста кул белән, хәйләле язылган.

Батулланың астарлы әсәрләреннән, мөгаен, иң кызыклылары, иң

үзенчәлекләре "Кияү" (1991); "Яшенле янгыр көткәндә" (1980), "Башлана" (1980),"Соңгы чабыш" (1969), "Мон" (1971) хикәяләредер. Бу әсәрләр Батулла иҗатына хас серлелек белән уранган.

## Көлкеханә

Бериш хикәяләргә сатирик янгыраш хас. Аның "Бер юлда" әсәре коммунистлар режимына әче сатира буларак язылган. "Айлар Хлам" *("Ләңгелдек" исеме белән басылды, "Шәһри Казан" 2006, 3 март)*—булдыксыз бәндәләрнең ничек итеп үзләреннән өстен һәм талантлы кешеләрне кимсетергә, каралтырга тырышулары турында эпиграмма, каһкаһәле көлү әсәре.

Батулланың "Мираж" хикәясе шөпшә оясына таяк тыгып болгаткан кебек, сатира өлкәсендә дә Батулла "шөпшә оясы"на таяк тыккалады.

"Хәвефле өч көн" хикәясен *(Шәһри Казан, 1991, 14 сентябрь; Мәдәни җомга, 1995, 3 ноябрь,)* мин каһкаһә хикәясе дип атар идем. Ленин мавзолееның ишеге төбендә сакта торучы каравылчыларның берсе мавзолей эчендә кеше йөргәнен ишетеп ала. Каравылда торганда сөйләшергә ярамаса да, ул иптәшенә бу турыда әйтә. Чыннан да, эчтә кемдер бар. Бу кеше Ленин тавышы белән "р" авазын сакаулап сөйләшә, йомыш белән мавзолейдан чыгаруларын үтенә, чыгармаган очракта ул йомышын мавзолей идәненә башкару белән яный. Каравыл алыштырырга килгән офицер да Ленин тавышын ишетә. Офицер—ҮКга, ҮК КГБга шылтыратып, теге кешене наряд килеп җиткәнче ачып чыгарып, бәдрәфкә кертергә рөхсәт ала. Чыннан да, мавзолей эченнән тач Ленинга охшаш кеше килеп чыга, КГБчылар Ленин табуты торган катка менеп карыйлар, Ленин урыны буш, димәк Ленин терелеп чыккан. Ленинга охшаш әлеге зат, бәдрәфкә керәм дип, каравылны алдалап качып китә. ҮКда паника: һич кичекмәстән Ленинны табып, урынына яткызырга боералар. Ленинны таба алмыйлар, мавзолейны ремонтка, дип өч көнгә ябып куялар. Өч көн эчендә Ленинны табып, табылмаса, Ленинга охшаган кешенең мәетен буш урынга салырга, дигән карар чыгарыла. Шулай кылалар да, Себер шәһәрләренең берсендә Ленин ролен уйный торгач, исереп үлгән артистның мәетен мавзолейга куялар, ләкин каравылны алдап качкан Ленин да табыла. Анысын кая куярга? Мавзолейда урын буш түгел. Беренче Ленинны "шизофреник" дип акылсызлар хастаханәсенә ябып куялар. Анда өч Наполеон, ике Христос, биш Маркс, ун Сталин "Мин—Ленин" дип әйткәннәрне тотып ашыйлар икән, Ленинны шулар янына ябалар.

Хикәя 1987 елда язылган булса да еллар буе басылмыйча ята.

"Хәвефле өч көн" әсәре—әдип Батулланың сатира өлкәсендәге иң зур уңышларыннан берсе.

## Тарих чоңгылларында ниләр бар?

Әдипнең җыйнак әсәрләренең бер тармагы ерак үткәннәрне яктырта. Батулла аларда тарихи вакыйгаларны заман язучысы буларак күзәтми, урта гасырларда бара торган вакыйгалар арасыннан торып безгә мәгълүмат бирә кебек. Шуңа күрә, аның тарихи хикәяләре ышандыру көченә ия. Холыклар куе буяулар белән сурәтләнә. Батулланың тарихи әсәрләренең теле турында шактый язылды, ул язмаларның барысы да Батулла әсәрләрендәге телнең шигърилеге, сурәтлелеге, байлыгы, гүзәллеге турында сөйли. Тарихны белмичә дә шәп тарихи әсәр язучылар бар, тарихны белеп тә кеше ышандырмый торган әсәр язучылар бар. Ә Батулла тарихны белә, ышандырырлык иҗат көченә дә ия.

Батулланың үзе әйтүенә караганда, тәҗрибә буларак, 1971 елда ул тарихи темага беренче тапкыр каләмен сынап карый: "Мортаза" исемле хикәясен яза (Идел, 1989, 5 сан). Күреп торасыз, хикәянең язылу вакыты белән басылуы арасында 18 ел гомер узып киткән.

Әсәрдә Казан егылгач (1552), дошман гаскәрләре татар авылларында чукындыру эшен башлап җибәрәләр. Мортаза хәлфә халыкны дошманнарга каршы күтәрә, халык чукынырга теләми, дошманнарның һөҗүмен уңышлы гына кире кагып тора. Ләкин дошманнар туплар алып килеп, авыл өйләрен тупка тота башлагач, капкалар җимерелгәч, дошманнар ургылып авылга керә, мөселманнарны суялар, талыйлар, көчлиләр. Йортларын урап алгач, Мортазаның хатыны кяферләр кулына төшмәс

өчен, үзен кыектан ташлап һәлак була. Шушы сугышта Мортаза батыр каты яралана. Анын ансыз гәүдәсен дуслары сугыш кырыннан алып чыгып, урманга алып китәләр. Исән калганнар шунда карурман уртасына жыела. Мортаза анына килә, кайдадыр бала жылый, аны кемдер юата, кемдер акрын гына борынгы көйне шыншый, барысы да үлеп бетмәгән икән дип шөкрана кыла. Көрәш әле дәвам итәчәк.

Әсәр өйрәнчек кул белән язылган, ләкин анын тәэсире гаять куәтле. Ул көчле эмоциональ дулкында иҗат ителгән. Батулла бу әсәрендә әле тарихи нечкәлекләрне белеп бетерми, ул сюжетка ныграк игътибар бирә. Шулай да бу хикәя авторнын башка тарихи әсәрләреннән аерылып калырга тиеш түгел, анын үз урыны, үз дәрәҗәсе бар. Автор бу хикәясен университетнын тулай торагында студентлар алдында укый. Әсәр зур уныш казана һәм... яшерен агентлар тарафыннан кара исемлеккә кертелә.

Анын "Сонгы сөннәт" әсәре *(Идел, 2005, 2 сан)* Казан дәүләтенен жимерелгән көннәрен сурәтли. Анда тарихи шәхесләр Сафа Гәрәй хан, Үтәмеш Гәрәй ханзадә, Сөембикәләр күз алдында терелә. Батулланын серле каләме аларга жан өргән. Автор шул чорнын каралты-курасын, ат дирбияләрен, кием-салымын тәфсилләп сурәтли. Монарчы татар әдәбиятында булмаган "йөзенчегә—кыл " йоласы хикәягә килеп керә. Бу йола инде онытылган. Ләкин Яна Бистәдә һәм Башкортстан татарлары бу йоланы әле дә булса хәтерлиләр икән. Сөннәтче һөнәре буыннан буынга бик борынгы заманнардан килә. Сөннәтчеләрнен беркемгә дә әйтми торган серләре була ди. Һәр сөннәтче йөзенче оланга сөннәт ясагач, назик жиренә ат кылы сала, ягъни оланнын жанжирен кыл белән буып куя. Жанжир шешә, берничә минуттан сон кыл аста кала, ул кылны берничек тә алып булмый икән. Бала сия алмыйча үлә. Балага кыл салмаса, Тәнре сөннәтченен үзен ала яки ана котчыккыч афәт китерә икән. Исламны кабул иткәнебезгә дә 1180 елдан артык, элеккеге мәҗүси, тәнречелек заманасыннан калган бу йоланы Ислам да кысрыклап чыгара алмаган. Бу рәхимсез, кыргый йола турында ишетә белүчеләр дә сирәк. Ләкин Батулланын үзенә мөрәҗәгать итик:

—Улым Нурбәк тугач,—дип башлады әдип хикәясен.—Мин Мәржани мәчетенә сөннәтче баба эзләп киттем. Мина бер бабайны күрсәттеләр. Ул Яна Бистәдә, Иске Бистәдә, Бишбалталарда сөннәт ясап гомер кичергән бабай иде. Бабай белән күрешеп, килешергә дип торганда янымa бер танышым—Сәлим абзый килде, ул театрда декорацияләр цехында эшли иде. Ул мина: син улына сөннәт ясатырга йөрисен икән, сак бул—йөзенче кылга эләкмә. Ул бабайнын йөзенче кыл салырга вакыты житкән булырга тиеш, диде. Һәм йөзенче оланга кыл салу йоласы турында сөйләп бирде. Мин мона ышанмадым. Ләкин Рәсим Сәлахов авызыннан да ишеткәч, курка калдым һәм улымны хастаханәдә табиптан сөннәтләттердем. Рәсим Сәлаховка сөннәтче баба кыл сала, сөннәтче баба капкадан чыгып барганда Рәсимнен абыйсы кайтып керә, эшне сизенеп баланы күтәреп, якындагы хастаханәгә йөгерә һәм табиплар Рәсимнен жанжиреннән кылны алып, баланы коткарып калалар.

Хикәядәге сөннәтче баба да ике ут арасында кала. Казаннын мәшһүр ханы Сафа Гәрәй үзенен Сөембикәдән туган улы Үтәмеш Гәрәй ханзадәгә сөннәт ясарга Торсын бабага куша. Үтәмеш ханзадә Сөембикәнен күптәннән көтеп алган бердән-бер улы була, Сөембикә кабат бала табалмаячак. Торсын баба шул баланы үлемгә мәхкүм итәргә тиеш. Кыл салмаса, бабанын үзенә афәт киләчәк. Әллә онытa, әллә юри, Торсын бабанын әзерләнгән кылы юкка чыга, Үтәмеш ханзадәгә сөннәт ясала, кыл салынмый кала. Шушы вакыйгадан сон ил өстенә, Торсын баба нәселенен өстенә, һәлакәт ябырыла. Озак та узмый, Сафа Гәрәй ханны үтерәләр. Казанга дошман яулары басып керә, Сөембикә белән улы Үтәмеш әсир алына, Сөембикәне дошман ягында җәзалап үтерәләр, Үтәмеш чукындырыла, озакламый ул да сәер шартларда үлеп китә. Торсын бабанын бөтен нәселе кырылып бетә, ул берүзе исән кала, сөннәт пәкесен үткенләп баскычтан төшеп барганда ул абынып, чалкан егыла, егылганда кулындагы пычак ялгыш анын муенын кисә.

Искиткеч әсәр, шомлы, мистика тулы әсәр. Романнарына торырлык хикәя. 2005 елда "Идел" журналы оештырган тарихи хикәяләр ярышында бу әсәр үзенен асыл бәясен алды, ул беренче урынга чыкты.

"Бәдәлче" хикәясе дә *(Ватаным Татарстан, 2005, 9 сентябрь)* Мөхәммәд Әмин—Әҗем ханлык иткән чорны сурәтли. Хөкемдар Әҗем хан белән шагыйрь Мөхәммәдьяр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне бәян итә әсәр. Батулла тарих

дингезендә колач салып, иркен йөзә ала торган әдип.

Атаклы карачы бәк, мәшһүр шагыйрь Мөхәммәдьяр астыртын эш йөртүчеләр аркасында хан тарафыннан сарайдан куыла. Тора-бара Әҗем хан да тәхетсез кала, ханны дошманнар эзәрлекләгәндә Мөхәммәдьяр үзен сарайдан мәсхәрәләп куган ханны яшереп, саклап кала. Әҗем хан янадан тәхетне кире кайтара, ләкин шагыйрь Мөхәммәдьярга сарай тагын тар була, ул янә куыла. Дошманнар тарафыннан агулангач, үлем түшәгендә ятканда Әҗем хан баш очына Мөхәммәдьярны чакыртып ала, аннан гафу сорый һәм үзе өчен Мөхәммәдьярга хаҗ сәфәре кылуын үтенә. Мөхәммәдъяр бәдәлче булып хажга китә, ул хаждан кайтканда инде Әҗем хан гүр иясе була.

"Шәһидлек" әсәре *("Кол Шәрифнең соңгы вәгазе", Мәдәни жомга, 1998, октябрь.)* һәм тарихилык һәм заманча янгырашы белән Батулла ижатының кыйммәтле асыл ташы—җәүһәре булып тора. Вакыйга 1552 елнын 2 октябре көнне бара. Монарчы шәкертләренә гел игелек, гел миһербан турында гына вәгазь укыган имам Кол Шәриф бүген шәкертләрен кылычка тотынырга, ватанны дошманнан саклап, шәһид китәргә чакыра. Аһ, көчле вәгазь!

"... Казанны җимерерләр, яугирләр кырылып бетәр. Ләкин узар заманнар, шушы урында безнең кан коелган жирдә рухыбыз, манараларыбыз янә калкыр. Инанамын, торыннарым, менә шушы жирдә, без шәһид киткән урында Кол Шәрифнең рухы сезгә вәгазь укыр. Әнә, чакыру быргысы уйный. Бу—безгә хәбәр. Балаларым, кулыгызга алыгыз кылыч, изге сугышка, Жиһадка китәбез!

Аллаһу әкбәр!"

Батулла әфәнде якынрак тарих турында да әсәрләр язды. Анын Тукайның бала чагы турындагы бер цикл хикәяләре *(Ялкын, 2006, 4 сан, Сабантуй, 2006, 5 апрель)* жанга жылы өрә торган әсәрләр. Сабый Тукайның табигатьне күзәтүләре, гаиләдән гаиләгә күчеп йөргәндәге бимазалары—барысы да ышандыра.

Кыскасы, әдип Батулланың хикәяләү остасы, сатира остасы, сюжет кору остасы булуы, психологик һәм тарихи темаларны әсәрләрендә сурәт чаралары аша ышандырырлык итеп күрсәтә белүе—татар әдәбиятының соңгы еллардагы казанышы ул.

## Әкиятче Батулла

«Баланың әдәбият белән, гомумән, китап белән танышуы әкияттән башланганлыгын һәм шигъри фантазияне үстерүдә, баланын характерын тәрбияләүдә әкиятнең әһәмияте чиксез зур икәнлеген искә төшерсәк, Батулланың бу изге эше турында мактаудан башка берни әйтеп булмый», дип язган иде Нурихан Фәттах 1972 елда.

Әйе, хикәя мәйданында Батулла ничек аерым, затлы урын биләп торса, әкият өлкәсендә дә ул нәкъ шундый ук сыйфатта. Һәм жае чыккач әйтим: Батулла әфәнденең әкиятләре һәм күләм ягыннан, һәм сыйфат ягыннан, һәм оригинальлеге ягыннан әлегә кадәр тикшерелмәгән, анын әкиятләре турында фәнни хезмәтләр язылмаган. Юкса Батулланың ижаты яшь тәнкыйтьчеләргә менә дигән алыш мәйданы булыр иде.

Батулла каләменнән мавыктыргыч, мажаралы, тирән мәгънәле әкиятләр, чишмәдән чыккан кебек, 23 ел буе чылтырап агып тора. Шушы вакыт аралыгында Батулла тарафыннан 100 дән артык әкият, 12 әкият китабы чыгарылган.

«Әкият язган язучы беркайчан да онытылмаячак. Чөнки әкиятне балалар укый, алар үскәннән соң үз балаларына шул әкиятләрне сөйләячәк. Һәм шулай мәңгегә әкият яшәячәк. Колхоз, совхоз, КамАЗ, нефть турындагы әсәрләрнең күбесе инде искерде, әкиятләр искермәячәк.

Язучы буласы килгән кеше «һичшиксез» татар халык әкиятләре аша килергә тиеш. Аннан соң башка халык әкиятләрен һәм әдипләр ижат иткән әкиятләрне укып-өйрәнгән кеше, шөбһәсез, бай рухлы кеше булачак.

Мин Батулланың «Алып батыр мажаралары» һәм башка әкиятләрен кибернетика, фәлсәфә дәресләрендә студентларга мисал буларак кулланам».Бу сүзләрне шагыйрь һәм кибернетик Жәүдәт Сөләйман язган.

1966 елда Батулла "Колакчын Тафи" исемле әкиятен яза. Ләкин ул әкиятне редакторлар кабул итми. Редакторлар алмашынган саен, Батулла шул әкиятен

тотып керә, ләкин тагын кире боралар. Ниһаять, 1976 ел килеп җитә, партия өлкә комитетының иң абруйлы органы "Социалистик Татарстан" газитендә әле яңа гына эшкә алынган Әхәт Гаффар әкиятне бастырып чыгара.

Әкият бик кыска, нибары ике бит чамасы. Сюжеты да бик гади.

Урман уртасында төлке гаиләсендә туган Тафи исемле бер нәни төлке этка охшаган була. Аучылар башка төлкеләрне атканда, бу төлке көчегән эт баласы дип атмый калдыралар. Шуннан соң Тафи эт булып китә, төлкеләрнең яшерен сукмакларын аучыларга күрсәтә һәм бу батырлыгы өчен аучылар Тафиның муенына зур калай асып куялар. Соңыннан ауларга төлкеләр калмагач, Тафины аучы атып үтерә дә, колакчынлы бүрек тектереп кия.

Әкият бетте. Бу әкиятне бастырып, Әхәт Гаффар башына бәла ала. Бүлек мөдире Рәшит Гариповка, Әхәт Гаффарга кемнәрдер:

—Сез нәрсә анда шул сакалның пасквилен бастырып ятасыз? Партиянең өлкә комитеты секретаре Фикрәт Табиевнең авторитетына кизәнергә сезгә кем кушты!— дип гелән шылтыратып, редакторның котын ала башлыйлар.

Әхәт эштән китә. Рәшит каушап кала. Шул чак редакциягә Батулла килеп керә, Рәшит хәлләрне сөйләп бирә. Батулла шаркылдап көлә дә Рәшиткә әйтә:

—Шулай шылтыручыларга син әйт: сез үз халкын сатып, күкрәгенә калай аскан төлке баласы Тафины Табиев дип уйлыйсызмыни, Табиев та татар халкының мәнфәгатьләрен сатып орден алдымыни? Без алай уйламыйбыз, бу гап-гади бер әкият кенә!—диген.

Рәшит шулай эшли дә, шуннан соң ник берсе шылтыратсын!

Батулла бу әкиятен бик ярата, ахрысы, ул аны еш бастырып килә. Шәп әкият, мавыктыргыч, мәгънәле әкият. Бу әкиятче Батулла иҗатының йөзек кашы булып тора.

«Талантлы әкиятче Батулланың диапазоны киң, мөмкинлеге зур, әдәбиятыбызда ана көндәшләр юк, димәк, яз да яз гына!»Бусы—Аяз Гыйләҗев фикере.

Шушы урында без Батулла әкиятләренең хронологик тәртибен бозып, 2005 елда чыккан бер томлык әкиятләренә күз төшерик.

"Елантау" (2005) китабына Батулланың иң саллы, иң күләмле, иң мәгънәле әкиятләре тупланган. Авторның сандыгында тагын бер томлык запас әкиятләре чират көтеп ята. Китап Казан каласының 1000 еллык бәйрәменә багышлана. Китапның исеме дә Казан каласына нигез салыну турындагы риваятькә бәйләнгән. Саин хан жыланнарны куып, шул калкулыкка шәһәр салдыра башлый. Халык арасында киң таралган риваятьне Батулла киңәйтә, яңа каһарманнар кертеп, кыйссага әверелдерә. Бу кыйссаны балалар да, олылар да йотлыгып укырлык.

Әкиятләр турында сүз чыккач, шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер: Батулла һәр жанрның күп юнәлешләрендә иҗат итә, хикәяләренең сатирик, психологик, тарихи, кинаяле булуы турында әйттек. Аның әкиятләре дә күп төрле. Хәреф танымаган ике яшьлек сабыйлар өчен дә, үсмерләр өчен дә, олылар өчен дә ул әкиятләр яза. Шушы юнәлешләрдә Батулла "аш төрләндерә", әйтик, аның җәнлек-җанварлар турындагы мавыктыргыч әкиятләре дә, тылсымлы әкиятләре дә, мажаралы әкиятләре дә бар. Бу китап нәкъ шулай төзелгән дә. Аның беренче өлешен могҗизалы- тылсымлы әкиятләр алып тора, икенче өлешенә җәнлекләр турындагы мажаралар кертелгән.

*Бу бер томлыктагы һәр әкият үз эчендә сер, сихри куәт, тылсым көче саклый.* Татар халык әкияте "Акҗылан"ның дәвамы буларак иҗат ителгән әсәр каһарманы үзенә яхшылык кылган Акҗыланны җәлладларга сата. Акҗыланны саткан кеше үлә алмыйча интегә икән. Шахрам баба да үлемсез була. Ул үлемсезлектән туя, ләкин үлә алмый интегә, якын дустын саткан бәндә өстендә үлемсезлек каһәре эленеп тора. Мең елдан соң Акҗыланның тылсымы аның өстендәге бу каһәрне— үлемсезлекне ала, Шахрам ләззәтле елмайган хәлдә җан бирә.

Әгәр дә "реаль әкиятләр" дигән термин булса, мин иң башта Батулланың "Акбүре" кыйссасын атар идем. Без барыбыз да татар халык әкиятләре китабында "Ак бүре" әкият-романын укып үстек. Батулланың "Акбүре"сендә вакыйгалар бүгенге татар авылында бара. Акбүре—шул ук, ул үлемсез, ул теләсә нинди хайванга, теләсә нинди агачка, кешегә әверелә ала торган тылсым иясе. Халык әкиятендә Акбүре табигать сакчысы. Бүгенге экологияне саклаучы оешмаларның диварларында, рекламаларында Акбүре сурәте булырга тиеш. Урманга кереп,

печәнне таптап, кошларны атып, атлары белән матур аланнарны бозып йөргән йөз браконьерны (Гыйфрит урлап алып киткән анасын эзләргә чыккан шаһзадә белән аның сугышчыларын) Акбүре торараташларга әвереллерә. Ә төпчек шаһзадә шул урманга килеп кергәч, атын бәйләп куя, кошларны атмый, юлга алган ризыгын гына утырып ашый, шулчак аның каршысында мәһабәт егет пәйда була, бу кешегә әверелгән Акбүре булып чыга, Акбүре миһербанлы шаһзадәгә анасын коллыктан азат итәргә булыша. Шәп әкият уйлап чыгарган татар милләте. Гомумән, татар халкының риваятьләрендә бүре хайваны мәкерле, усал түгел, татар халкы үзенең борынгы бабасы дип бүрене хисаплый, гасырлар буе төрк халыкларына мифик Акбүре юл күрсәткән, ана бүре ике шаһзадәне имезеп үстергән, икенче ана бүре яраланган ир баланы үлемнән коткарып, аннан ун бала тапкан, шул ун баланың берсе безнең борынгы атабыз.

Батулла боларның барысын яхшы белә, аның әкиятләрендә дә бүреләр кешеләргә корткычлык кылмый. "Акбүре" кыйссасында ул төп каһарман, унай каһарман. Әсәр реаль тормыштан башлана, балалар, укучылар, колхозчылар, житәкчеләр, аучылар-сунарчылар, карурмандагы җәнлекләрнең язмышы... Шушы гап-гади генә агып бара торган тормышта могҗизалар башлана. Аучы Сыртакның юлында Акбүре очрый. Алагаем олы гәүдәле, мәһабәт Акбүре—урман хуҗасы, чирүләр башлыгы, акыллы, хәйләкәр җәнлек. Сыртак исә оста сунарчы, бүреләргә кистән белән бара торган куәтле шәхес. Әсәр шушы ике куәт арасындагы көрәшне сурәтләүгә корылган. Табигать сакчысы Акбүреме, әллә акча өчен, дан өчен җәнлекләрне, бүреләрне кырырга алынган Сыртакмы җиңәчәк? Бик зур мәсьәлә күтәрелә әсәрдә. Сунарчы Сыртакның сурәте әйтерсең лә автор тарафыннан ясалмаган, әйтерсең лә Сыртак үзе шулай җанлы-тере булып туган. Гап-гади көнкүреш, урак уру, утын яру кебек ябай гамәлләр арасында искитәрлек сихри көчләр яши. Бүреләрнең чирүдәге тормышы да, бүреләрнең үзара аңлашуы да реаль.

Батулла әкиятләрен укыганда шул мажараларның, тылсымнарның дөньяда булганына ышана башлыйсың.

Батулланың әдип буларак, фәйләсүф буларак, зиһен иясе буларак һәм, ниһаять, милли каһарман буларак, холкы шушы әсәрендә ныграк ачыла кебек.

"Алып Батыр мажаралары" каһарманның оятка калуыннан башланып китә. Аждаһа белән сугышырга киткән батыр адашып, үз авылына кайтып керә. Монда юмор да, сатира да бар, ләкин тора-бара әсәрдәге Алып Батыр трагик образга әверелеп бетә. Әйе, ул Сервантесның "Дон Кихоты", Гераклның унике батырлыгы, Синдбадның җиде сәяхәте белән бераз аваздаш, ләкин Батулла татар халык авыз иҗатының җәүһәрләрен кулланып, аны нәкъ менә милли, татарныкы иткән, татар каһарманының батырлыгы коры мажараларга гына төзелмәгән, аның һәр сәяхәте аерым, саллы фәлсәфи фикер алып килә.

Алып батыр ул коеп куйган уңай образ түгел, ул ялгыша, кыйнала, көлке хәлләргә, аяныч хәлләргә тара, куәтен кая куярга белми йөргәндә ул каш ясыйм дип күз чыгара, файда эшлим дип зарар кылып ташлый.

«Бу әсәр («Алып Батыр мажаралары») Батулла иҗатында аерым, мөһим урын алып тора, аның зур уңышларыннан берсе дип уйлыйм... Бу әсәрне укыганда үзеңне Ана телебезнең, халкыбызның тарих бәйрәмендә йөргән кебек хис итәсең»,—дип язды шагыйрь Рәниф Шәрипов. *(Казан утлары, 1987, 2 сан)*

Чыннан да, әсәрнең теле үзе заманча да, үзе урта гасырлар теле дә кебек. Әнә шул тел әсәрне кабул итәргә ярдәмләшә, син урта гасыр кешеләренең тавышларын ишетә башлыйсың.

Бу роман аерым бер игътибарга лаек. Ул—татар халкының йолалары, көн күреше, кием-салымы, азык-ризыгы, сугыш кораллары, Ана телебезнең энциклопедиясе. Мин бу әсәрне "роман" дип ялгыш атамадым, аның мажаралары, һәр бүлекнең камил, мөстәкыйль әсәр булуы, һәр бүлекнең үз максаты, үз фәлсәфәсенә ия булуы, әсәр каһарманы Алып Батырның дөнья халыкларына ярдәмгә атылуы һәм халыклар бәхете өчен көрәшеп йөргәндә сөйгәненнән коры калуы—барысы да әсәрне роман дәрәҗәсенә күтәрә. Нигә моңарчы бу әсәр башка телләргә тәрҗемә ителмәгән дә, нигә аның нигезендә кино, мультфильм төшерелмәгән икән дип хәйран каласың! Бу бит татар әдәбияты өчен генә түгел, дөнья әдәбиятлары өчен дә кирәкле әсәр.

## Романнар авторы Батулла

«Юл буенда зәңгәр чәчәк»—безнең татар әдәбиятының зур уңышы. Безнең әдәбиятта шундый төгәл такт, югары культура һәм искиткеч көчле ихласлылык белән язылган әсәрләр сирәк... Бу әсәр Батулланы татар әдәбиятының иң беренче сафында баручы язучылар рәтенә бастырды»,—дип язды Миргазиян Юныс 1991 елда.

Чыннан да, поэтик яңгырашлы, югары сәнгатьле прозага Рабит Батулла "Юл буенда зәңгәр чәчәк" дигән (1990) саллы роман белән килеп керде, һәм аның бу өлкәдәге күркәм таланты тагын да ачылып китте. Әдип биредә сугыш чорын һәм аннан соңгы кырыс елларны бәян итә. Әсәрнең исемендә үк шигъри аһәң һәм тирән мәгънә төсмерләнә. Зәңгәр чәчәк—гүзәллек билгесе. Ләкин аның урыны—юл читендә, шактый кадерсез җирдә. Дөресен әйткәндә, юл буендагы зәңгәр чәчәк—ул романның баш каһарманы Ярмөхәммәт һәм башка гади игенчеләр символы. Алар тырыш, сабыр холыклы, күңелләре саф. Шул ук вакытта социаль-психологик басым астында яшәргә дучар ителгәннәр. Шул җирлектә әсәр сюжетында уңганлык белән булдыксызлык, зирәклек белән мокытлык, әхлаклылык белән миһербансызлык, йолаларны кадерләү белән санга сукмау гел бәрелешеп тора, анда бик гыйбрәтле хәлләр тасвирлана.

«Батулла, күрәсең, бу зур китабы белән («Юл буенда зәңгәр чәчәк») илле еллык юбилеена килә һәм шушы китап, ниһаять, әдәбиятта аның урынын беркетеп куя инде. Бу беркетелгән урыннан ул инде төшмәячәк, аннан күтәрелеп кенә булачак»,—дип яза Мөхәммәт Мәһдиев 1987 елда.

Әсәр безнең прозага нык куллы, зур максатлар куеп иҗат итүче әдип килүе турында хәбәр итте. Ул игътибар белән өйрәнүгә, шәрехләп тикшерүгә лаек.

Сугыштан соңгы татар авылы турында романнар да, повестьлар да, хикәяләр дә байтак язылды, шөкер. Аларны уртак тема—тылдагы авыр тормыш берләштерә һәм, дөресен әйтергә кирәк, аларны бер-берләренә охшаш итә. Ләкин охшаш әсәрләрдән аермалы буларак, ("Юл буенда зәңгәр чәчәк"—исеменнән үк шигырь һәм нәфислек аңкып тора) авыр тормышта авторның күңел күзе башкалар күрмәгән матурлыкны күрә, шул гүзәллекне байрак итеп күтәрә. Юл буенда үскән һиндиба (цикорий) чәчәген кешеләр күрми, күрсәләр дә, игътибарсыз узып китәләр, ул чүп үләннәре рәтендә, аны юлдан узган арбалар да дегеткә буяп китә, аны өзеп сулы савытка да утыртмыйлар. Әсәрнең каһарманы Ярмөхәммәт шул чүпкә дә саналмаган чәчәкнең матурлыгын күрә. Бу—күчермә мәгънәсендәге чәчәк. Әсәр агышында ямьсез саналган Рәйсә Ярмөхәммәтнең күңел күзендә гүзәлләрнең гүзәленә әверелә. Икенчедән, башка әсәрдән аермалы буларак, шушы гади тормышта могҗизалар, тылсымнар пәйда булып тора.

Соңгы елларда татар язучыларының кайберләре ике гашыйк арасындагы җенси мөнәсәбәтләрне тәфсилләп язарга алындылар, янәсе ике кеше генә белергә тиешле ул серне язгач китапны күбрәк кеше укыячак. Татарның яшәү рәвеше Көнбатыш илләренең (шул хисаптан рус халкының да) яшәү рәвешеннән дә нык аерылып тора, кайберәүләр ачык секс ягында булса да, күпчелек укучы ул әләпсезлеккә тиң күренешләрне кабул итә алмый. Батулланың бу әсәрендә дә андый күренешләр бар. Ләкин шул җенси мөнәсәбәтләрне башкаларга күрсәтергә тырышучы әсәрләрдән аермалы буларак, Батулла бу өлкәдә бик сак эш итә, шул ук мөнәсәбәтләр шигъри югарылыкта, әдәп кысаларында күрсәтелә.

Тышкы ялтыравыклы гүзәллекне маңгай күзләре сау булганнарның барысы да күрә, ә менә эчкә яшерелгән гүзәллекне күрү өчен маңгай күзе генә җитми, аның өчен күңел күзенең ачык булуы, эчке тәрбия, затлылык булу шарт. Ярмөхәммәткә әнә шундый сәләт бирелгән.

Әсәр гап-гади әйберләрдә дә, гап-гади кешеләрдә дә булган гүзәллекне күрергә чакыра. Шул сәбәпле "Юл буенда зәңгәр чәчәк" кыйссасы кат-кат укысаң да туйдырмый, аның гүзәллеге ачыла бара.

Батулла шушы әсәре өчен бер тавыштан Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый бүләген алды.

Күптән түгел генә "Мәйдан"да чыккан *(2006, 10 сан)* "Җимерелгән бәхет" әсәре дә нәкъ шул өслүбтә иҗат ителгән. Анда Заһидә Тинчурина сөйләвендә узган гасырда яшәгән татар зыялыларының тормышы, көрәше, уңышлары, фаҗигаләре бәян ителә. "Җимерелгән бәхет" ул—татар милләтенең узган гасырдагы язмышы

турындагы милли әсәр, дип әйтер идем мин. Театрыбыз, әдәбиятыбызга бәһаләп бетергесез зур өлеш керткән Гаяз Исхакыйлар, Фатих Әмирханнар, Кәрим Тинчуриннар, Фатыйма Ильскаялар, Гөлсем Болгарскаялар, Габдулла Кариевлар, Әшрәф Синяеваларның образлары укучы күз алдында балкыйлар да гомерлеккә хәтердә калалар. Мондый әсәрләрне иҗат итәр өчен тарихи документларны өйрәнүнең никадәр катлаулы, авыр һәм кирәкле эш икәнен сөйләп тормастан, шуны гына әйтәм: шул документларга, тарихи чыганакларга авторның олы таланты, сәнгати күзаллавы килеп кушылгач, ул документларның әдәби әсәргә әверелүе һәр кешене куандыра, һәр кешегә тирән мәгълүмат та бирә. Әдәби чаралар аша автор безгә тирән тарихны сөйли.

Батулланың тагын бер киң эшчәнлеге турында да әйтми калырга тиеш түгелбез. Ул еллар буе радио-телевидениедә тарихыбыз, олуг шәхесләребез турында сөйли. Бу популяр тапшыруларны миллионлаган тамашачы карый, тыңлый. Аның тарихи миниатюралары аерым китап булып чыкты *(Тузга язмаган хәлләр. Татарстан китап нәшрияты, 1997.)* Бу тарихи шәхесләребез турында бәһаләп бетергесез кыйммәтле мәгълүмат туплаган кечек энциклопедия дияр идем мин. Ун кеше еллар буе җыя торган фактик материалны Батулла берүзе башкарган.

"Сөембикә" кыйссасы турында инде байтак язылды (*Сөембикә. Татар. китап нәшр., 1992.*) Мәсәлән, шагыйрә Лена Шагыйрьҗанның мондый сүзләре бар:

«...Кадерле китапның *(Сүз «Сөембикә» романы хакында бара.—Ф. Х.)* сәхифәләрен актарам... Әсәрне әсәр иткән, укучыны әсир иткән аның теле, әлбәттә. Батулланың теле искиткеч!.. Ә инде Сөембикәнең ханнар төрбәләре янында елап, инрәве—бу үзе бер поэма... Кыскасы, бу—милләт китабы. Һәрбер татар кешесе—карты да, яше дә, ире дә, хатыны да бу китапны укып чыгарга бурычлы хәтта...»

Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗев әйтмешли, шушы әсәрен язып «...Батулла Сөембикә ханбикә белән янәшә Сафа Гәрәй ханга да һәйкәл куйды. Романның күп тармаклы унышларының берсе һәм иң әһәмиятлесе әнә шулдыр».

Бу бөек зат бездә күптәннән инде үзенең талантлы әдибен, аның дикъкатьле карашын, күнел җылысын көтә иде. Ул бөтен барлыгы, кешелек сыйфатлары белән зур сәнгатьнең түрендә булырга лаек. Сөембикә язмышы, бер үк вакытта, милләтебезнең йөзен һәм драматик тарихын да гәүдәләндерә. Аның яшәешендә гүзәллек, мәһабәтлек белән ачы фаҗига аралаша.

Сөембикә—татар халкының йөзек кашы, сөекле кызы, ихлас горурлыгы, шул ук вакытта йөрәгенең төзәлмәс ярасы да ул. Татар халкы Сөембикәне дүрт ярым гасыр буенча хөрмәт белән күнелендә саклап килгән, поэтик иҗатында, бәет, риваятьләрендә тасвирлаган. Язма әдәбиятта исә 1917 елга кадәр Һади Атласи белән Ризаэддин Фәхретдиннең хезмәтләре, Фатих Әмирханның «Сөембикә» хикәясе басылды.

Әмма большевистик режим вакытында безнең әдәбиятта ханбикә турында бер генә әсәр дә дөнья күрмәде. Әйтерсең, милләткә нинди дә булса зыян салган берәр гөнаһлы бәндә турында сүз бара! Шулай итеп, Сөембикә образы әүвәл үз илендә түгел, чит илдә иҗат ителде. Төрек әдибе мөхтәрәм Нәүрүзхан аның хакында тарихи роман язды.

Ниһаять, үзебездә дә тарихыбыз битләрен актарып карау мөмкинлеге ачылды. Ханбикә турында пьеса, шигырь, поэмалар иҗат ителде. Сөембикә хакында Батулла зур күләмле роман язды.

Әдип Сөембикә тормышын, башка әсәрләрдән үзгә буларак, дөньяга килгәннән алып соңгы көннәренә кадәр тасвирлый, гаҗәп үзенчәлекле хәятын җанлы, мавыктыргыч итеп күз алдына китереп бастыра. Тагын шунысы да бар—әдип бу затның гадәтилектән югары торуына басым ясый, гүзәлләрнең гүзәле, чаяларның чаясы, батырларның батыры, тапкырларның тапкыры итеп күрсәтә, милләтебезнең үсеше, алга китеше, азатлыгы, тигезлеге өчен җан атып яшәүче патриот, кешелекле, миһербанлы зирәк фикер иясе булуын раслый. Әдип бу реаль шәхесне еш кына борынгы күренекле әдәби образларга илтеп тоташтыра. Ул, мәсәлән, Сөембикәнең сылулыгын Зөләйха, Ләйлә, Зөһрәләр матурлыгына тинли, аны көнчыгыш поэзиясендәге каһарманнар белән бер сафка куя. Бу җәһәттән хәзерге әсәрләр белән дә билгеле бер уртаклык, якынлык сизелә.

Батулла романының дәвер төпкелләрендәге әсәрләр белән бәйләнеше сюжет оештыруның кайбер элементларында да күренеп кала. Безнең борынгы поэзиядә еш кына сөеклене төштә күреп гашыйк булу очраклары тасвирлана. Кол Гали

кыйссасында Йосыф һәм Зөләйха төштә табышып кына калмыйлар, төш аркылы гәпләшәләр, аңлашалар, ниятләрен уртаклашалар, үзара кинәшләр бирешәләр— әсәрдә, шулай итеп, төштәге диалог яктыртыла. Сөем туташның яшьлек хыялларын, эзләнү-омтылышларын хикәяләгәндә дә автор шушы алымга мөрәҗәгать итә. Сөем туташ төшендә гаҗәп матур бакча, шул бакчада, ап-ак аргамак өстендә, шәм кебек төз гәүдәле Шәддад патшаны күрә, чакырып дәшкәнен ишеткәндәй була.

Борынгы әдәбиятыбыздагы кебек, әдип Сөем туташны да мәхәббәтенә ирешүдә актив табигатьле итеп гәүдәләндерә. Ул дус кызлары белән әлеге бакчаны һәм Шәддад патшаны эзләп ерак сәфәргә китә һәм, байтак каршылык, кыенлыклар күреп, ахырда Кабул шәһәренә барып чыга. Монда ул төштәгедән дә матуррак бакча күрә, Бабур патша һәм улы Хумаюн солтан белән очраша, алар хозурында әңгәмәгә катнаша, фикер алыша һәм аларны, әдип сурәтләвенчә, гүзәллеге, чибәрлеге белән генә түгел, акыл иясе, философ булуы белән дә таңга калдыра, алар алдында хөрмәт казана. Патша белән солтан: «Атаклы фәйләсуфләр, мәшһүр суфилар берлә бәхәс кылырдай мәгълүматлы кыз үстергән ләбаса төрки-татар даласы»,—дигән нәтиҗәгә киләләр *(185 б.)*.

Кыйссадан күренүенчә, Хумаюн солтан Сөем туташка гашыйк була, никахлашырга тәкъдим ясый. Ләкин кыз аның бу теләген кабул итә алмый, үз мәмләкәтенә кайтырга, ырулар арасындагы ызгыш-талашларны, сугышларны бетерү, татулык, бердәмлек урнаштыру өчен тырышырга үзен бурычлы дип саный. Нугайга кайткач та ул байтак ханзадәләрнең, абруйлы мирзаларның яучыларын борып җибәрә. Ахырда Казан ханы Җан Галигә чыгарга ризалык бирә.

Әсәрдән Сөембикәнең гаилә тормышы, мәхәббәте үтә каршылыклы, чуалчык булганлыгы күренә. Җан Гали—Касыйм ханы Шаһ Галинең энесе, гомере буе Мәскәүдә яшәп, рус тәрбиясе алган, Казан тәхетенә дә Мәскәү кулы белән утыртылган хан. Аның бөтен теләге—русларга ярау, шулар мәнфәгатен кайгырту, бар нияте—русларга аркалану, аларның тирәгән тою. Кешелек сыйфатлары белән ул бик булдыксыз, буынсыз, ихтыярсыз булып чыга. Кемгә килеп юлыкканын белгәч, Сөембикә ачы күз яшьләрен түгә. Ләкин шулай да хәсрәтен читләргә сиздерми, көнчеләргә, хөсетлеләргә авыз чайкарга җай бирми, язмышына буйсынып, иренә тугрылыклы булып кала. Җан Галигә йогынты ясап, казнаны ныгыту, гүзәл бакча, бай китапханә булдыру хәстәренә керешә, бер үк вакытта ханга дәүләтнең бәйсезлеге, мөстәкыйльлеге, куәтле булуын кайгыртырга киңәш итә. Ханның да күз карашында мәгънә чаткылары ялтырап китә, кулы катылана башлый. Ләкин нәкъ менә шушы үзгәреш рус тәлинкәсен ялаучы Булат бәк Ширин ишеләргә ошамый. Алар Җан Галине ауга чыккан җирдә үтерәләр.

Батулла сурәтләвендә исә, Җан Галинең еллыгын үткәргәч, Сөембикә Нугайга, әтисе Йосыф әмир йортына кайтып китә. Казанга икенче тапкыр хан булып Сафа Гәрәй кайта. Батулла аны Казан халкының зур шатлык, ихлас куаныч белән каршы алуын, Хансарайга, кулдан төшермичә, күтәреп баруын сурәтли. Сафа Гәрәй хан егерме ике яшьлек тол Сөембикәне дүртенче хатын итеп ала. Әдип тасвирлавынча, Сөембикә Сафа Гәрәйне төшендәге Шәддад патша, Кабулдагы Бабур падишаһ, Хумаюн солтан белән чагыштыра һәм Сафа Гәрәй барысыннан да мәһабәтрәк икән дигән нәтиҗәгә килә: «Менә шушы икән бит аның беренче һәм соңгы мәхәббәте, Сафа Гәрәй хан икән!..» Сафа Гәрәй дә аны бөтен күңеле белән сөя.

Батулла бәяләвенчә, Сафа Гәрәй Казанның соңгы ханнары арасында иң батыры, булдыклысы, каты рухлысы була. Аның Мәскәү белән тынычлыкта, тату яшәргә омтылуы, ләкин Иванның һич тә тынгылык бирмәве, Сафа Гәрәйнең моңа кыюлык, зирәклек белән җавап кайтаруы, патшаның алты тапкыр ишле гаскәрен пыр туздырып ташлавы, күп җиңүләргә ирешүе, явыз Иванның чәчен йолкый-йолкый елап үз йортына чигенүе барлык әсәрләрдә дә, нигездә, бертөрле бәян ителә. Әмма Сафа Гәрәйнең икенче тапкыр Казаннан чыгып китүе Нәүрүзханда үзгәрәк—Шаһ Галине тозакка эләктерү уены кебегрәк аңлатыла. Батулла исә моның үтә драматик хасиятен төшендерүгә басым ясый. Аның хикәяләвенчә, Сөембикә һәм Сафа Гәрәй улы Үтәмеш Гәрәйнең исем туенда Мәскәү куштаннары, Булат бәк Ширин өере Сафа Гәрәй яклыларның һәммәсен дә кылычтан үткәрмәкче булалар. Дала яктан һәм Мәскәүдән зур һөҗүм оештырылачагы беленә. «Үтәмеш Гәрәй солтанның исем туенда кымыз, бал, буза урынына гөрләп мөселман каны акты»,—дип яза Батулла. Сафа Гәрәй хан хатыннарын, балаларын, якыннарын алып Болгар капкасыннан

чыгып кача. Ахырда Нугайдан, Кырымнан көчле гаскәр туплап, өченче тапкыр үз урынына, Казан тәхетенә кайта.

Сафа Гәрәйнең үлемен аңлатуда да әсәрләр арасында төрлелек күренә. Сөембикә тормышы турында беренче чыганакларга, ярлыкларга нигезләнеп шактый җентекле язган Һади Атласи моның сәбәбен ачыклауны, махсус тукталуны кирәк тапмый. Нәүрүзхан исә аның һәлакәтен очраклылыкка кайтарып калдыра, аты өркеп, тәмам котырып, урмандагы агачка бәреп үтерде, дип раслый. Шундыйрак хәл Батулла әсәрендә дә тасвирлана.

Батулла романында Кошчак образы бик мөһим урын били. Китап вариантында ул, тагы да алгырак планга чыгарылып, калкурак, эзлеклерәк бирелгән, аның кырыс, ачы язмышы, кешелекле, ярдәмчел, тугрылыклы табигате, зирәклеге, тиңсез батырлыгы ямктыртылган.

Сафа Гәрәй вафатыннан соң улы Үтәмеш Гәрәй хан дип игълан ителгәч, дәүләт белән идарә итү Сөембикәгә тапшырыла, ханлыкны ныгыту, мөстәкыйльлеген саклау эшендә Сөембикәнең бердәнбер ышанычлы, тугрылыклы терәге булып гаскәр башлыгы Кошчак кала. Ул Иванның күпләгән кара явына каршы тора, гаскәрен тузгытып, чигенергә мәҗбүр итә. Ләкин Гәүһәршад бикә, Булат бәк Ширин аның аркасына пычак кадамакчы, кырымлыларның барчасын кырып бетермәкче булалар. Кошчак углан белән өч йөз егет, хатыннарын, балаларын калдырып, төн уртасында Казаннан чыгып качарга мәҗбүр булалар. Ниятләре—Нугайга, Кырымга барып, Иван гаскәренең артына төшү була. Ләкин берсе дә исән котыла алмый. Капка төбендә дошман торган мәлдә, Казан гаскәре башлыксыз кала. Яуга каршы көрәшне оештыру бурычы үзеннән-үзе Сөембикә җилкәсенә төшә.

Басып алу логикасы раслаганча, илбасарның ерткыч рухы гүзәл ханбикә белән генә хушланмый, әлбәттә. Иван бөтен татар дәүләтен йоту ниятенә керешә. Моны, әсәрдән беленүенчә, соңлап булса да, моңарчы гел Мәскәү күзенә карап торган, аңа ярарга тырышып көн күргән татар бәкләре, мирзалары да, ниһаять, аңлап алалар, уянып, сискәнеп киткәндәй булалар. Оятларына көч килә, хурлыгын ничек күтәрергә белмиләр. Казан каласына бер могҗиза белән килеп ирешкән һәм тәхеткә хан булып күтәрелгән Ядегәр Мөхәммәт солтан җитәкчелегендә Казан халкы Иванның йөз илле меңле гаскәренә каршы яуга күтәрелә, тиңсез батырлыклар күрсәтә, соңгы сулышына хәтле фидакарьләрчә сугыша. Әдип дәүләт күләмендәге бу фаҗигане һәр көнен диярлек аерым тасвирлый. Автор раславынча, монда да дәүләтнең язмышын хыянәт хәл итә. Камай мирза Иванга Казан кешеләренең серен фаш итә, яшерен Ханчишмәнең урынын күрсәтә. Иван аны шартлаткач, Казан кешеләре сусыз калалар. Әмма шул шартларда да егерме көн буена сугышны дәвам иттерәләр. Ханлыкның бөтен гаскәре кырылып беткәч кенә, Иван изге Казан каласына килеп керә. Бу сугышта йөз илле меңнән артык татар һәлак була. Урыс гаскәре сигез яшьтән узган барлык ир балаларны, бәкләрне, муллаларны, шул исәптән Булат бәкне, Гәүһәршад бикәне үтерә.

Батулла үзенең әсәрендә, пролог рәвешендә, Сөембикә токымының һәм, гомумән, татар дәүләтчелегенең тирән тамырларын юллап, аралап бүгенге укучыга күрсәтә, «Сөембикә»гә илтүче сукмакларны ямктырта, Болгар, Казан тарихына бәйләнешле риваять, легендаларны теркәп уза, ханнар шәҗәрәсен күз алдына китереп бастыра.

Әдип Сөембикә нәселенең Идегәй әмиргә барып тоташканлыгын күрсәтә. Ягъни Идегәй Аксак Тимернең кияве була, Идегәйнең улы—Норадын, аның улы—Вәккас, аның улы—Муса, аның улы—Нугай мирзасы Йосыф, аның кызы—Сөембикә була.

Автор бик бай, образлы тел белән эш итә. Иҗат барышында аңа материалны бер үк вакытта тарихи һәм эстетик җәһәттән үзләштерергә туры килде. Ул кирәк чакта калын тарих катламнары арасында калып онытыла башлаган, пассивлашкан сүзләрне, телбизәк чараларын да эшкә җигә, дәвер сөйләменең аһәнен дә бүгенге укучыга күпмедер дәрәҗәдә сиздерергә тырыша.

Әсәрдә ул Сөембикә, Казан ханлыгы белән бәйләнешле тарихи фактларга тугрылыклы булып кала. Ләкин шулай да, иҗатчы буларак, Сөембикәнең тормыш юлын, кайбер бәйләнеш, ситуацияләрне үзенчәрәк күрә, үзе күргәнчәрәк сурәтли һәм шуңа укучыны ышандыра. Нәтиҗәдә, ул хәзерге укучыга бик якын, кадерле, аңлаешлы матур образ гәүдәләндерүгә ирешә.

Дөнья классикасында Сөембикәгә тартым затлар турында В.Шекспирның

«Антоний һәм Клеопатра», Ф.Шиллернын «Мария Стюарт» трагегияләре, С.Цвейгнын «Мария Стюарт» романы ише гүзәл әсәрләр барлыкка килгән. Болар арасында Сөембикә тинсез гүзәллеге, әхлакый сафлыгы, үткен акылы, халкына керсез мәхәббәте, милли мөстәкыйльлеккә, азатлыкка омтылышы белән, шәхси фаҗигасенен дәүләт фаҗигасенә тоташуы белән укучы күз алдына олуг, мәһабәт образ булып килеп баса. Шуна күрә, Клеопатра, Мария Стюартлар кебек, Сөембикәне дә дөнья халкына танытасы бар. Ә монын өчен Батулла романын төрек, инглиз һәм башка телләргә тәрҗемә итеп бастыру фарыз.

Батулланың романнары турында сөйли башлагач, Тукай турындагысын да искә алмый ярамас, чөнки ул Тукайның соңгы ике атнасына багышланган тетрәндергеч әсәр. Һәм ул Тукай бүләгенә лаек иде. 2006 елда Батулла шушы һәм "Сөембикә" кыйссалары өчен ул бүләккә ия булды.

## Драматург Батулла

«Батулланың Камал театрында бара торган «Кичер мине, әнкәй» пьесасы шикелле бер әсәр язсам, мин кабат берни язмасам да үкенмәс идем.» "Кичер мине, әнкәй"нең беренче күрсәтелешен (1980 ел) караганнан соң хискә бирелгән өлкән язучы Гариф Ахуновның бу бәясе бүген дә искермәгән әле. Бу пьеса озак еллар Камал театрында (ике тапкыр куелышта), Оренбург, Салават, Дербент, Махачкала театрларында, Татар яшь тамашачылар театрында туктаусыз уйнала килде, әле алда тагын яңа куелышлары да көтелә. Репертуарда озак сакланган рекордчы пьесалар ("Зәңгәр шәл", "Хуҗа Насретдин", "Әлдермештән Әлмәндәр", "Әни килде") арасында Батулланың "Кичер мине, әнкәй" әсәре дә бар. Аның шулкадәр вакыт сәхнәдән төшмичә уйналып килүенең сәбәпләрен ачыкларга тырышсак, мондый нәтиҗәгә килергә булыр иде. Әсәр катлаулы түгел. Җилбәзәк чибәр хатын никахсыз бала таба да аны үзенең туган апасы тапты дип хәйлә корып, ояттан котыла, апасы—кияүгә чыкмаган карт кыз—бөтен оятны үз җилкәсенә ала. Миргаян исемле бу ир бала үсмер булып житешкәч, аның үз анасы баласын кире кайтарырга дип Миргаян белән Минзифа яшәгән авылга кайтып төшә. Бала өчен тарткалаш, ямьсезләнеш бара. Бу ситуациядә Минзифаның бөеклеге, киң күңеллелеге, бала җанлылыгы чагыла. Аның "Ана" дигән исемне йөртергә хаклы икәнлеге раслана.

Әсәрнең уңышы аның сентименталь булуындадыр. Әсәрдә күз яшен чыгара торган күренешләр байтак, спектакль шаулап көлү һәм мышык-мышык җылау белән аралашып бара. Автор аны "трагикомедия" дип тә, "сагышлы комедия" дип тә атап караган, әмма Азат Әхмәдуллин "мелодрама" диде. *(Азат Әхмәдуллин. Күңелләрне уятыр. «Мәгариф» нәшр. 2007.)* Безнең тамашачы мелодраманы бик тә ярата.

Икенче сәбәбе әсәрнең сюжет динамикасының корылуында. Сәхнә күренешләре гел киеренке мохиттә, характерлар бәрелешен, вакыйгаларны карап тамашачы тик утыра алмый, ул ситуацияләр эченә кереп китә. Минзифаның үги ана, Дилфүзәнең баласын ташлап качкан ана икәне ачыклангач, Миргаян ике ут арасында кала. Матур, бай тормыш вәгъдә итүче үги атасы, үз анасы белән калага китәрме, әллә кыенлыклар белән үстергән үги анасы Минзифа янында калыргамы? Әсәрнең азагына чаклы Миргазиян шуны хәл итә алмый сыман, тамашачы Минзифа өчен ут йотып утыра. Асылда Миргаян бу мәсьәләне инде күптән хәл иткән: ул бер «калага ияреп китәм», бер «авылда калам», дип ташлап качкан апасының да, Минзифаның да башын гына катыра. Ул Минзифа янында кала, аны "әнкәй" дип атый, тегеләрне куып чыгара, халык ду китереп кул чаба, яшь аралаш елмая.

Өченче сәбәбе, холыкларның ярылып ятуында, бу әсәрдә баш каһарманнар, эпизодик каһарманнар дигән төшенчә юк, монда барысы да баш каһарман, аларның барысы да ап-ачык булып хәтердә кала.

Образлы теле, ситуацияләрнең оста корылуы белән әсәр озын гомерле булып туган.

Ләбиб Лерон язганча, Батулланың драматургиядәге күпсанлы әсәрләре («Ак күгәрченнәр», «Ләйлә белән Мәҗнүн» («Туйлар узгач»...), «Мин Америка ачтым», «Елантау», «Өчәү юлга чыктык» һ.б.) арасында игътибарга лаеруча лаек янә бер үзенчәлекле, әтрафлы әсәре бар. Ул—«Сират күпере» (1986). Үз вакытында ук Батулланың бу саллы пьесасын шагыйрь Равил Фәйзуллин бик дөрес бәяләде.

«Сират күпере»—Батулланың театр сәнгате өлкәсендәге билгеле бер уңышы, исемен драматургиядә тагын да ныгыткан житди хезмәте... Батулланың бөтен хикәяләре дә диярлек кинаяле, аларның һәрберсендә тел төбенә яшерелгән сер ята... Ул—янып, бирелеп, фидакарьләрчә эшләргә яратылган кеше, кешеләрне үзе белән әйдәргә, кешеләрнен дә йөрәкләрен үзенеке кебек яндырырга алынган кеше. Тынгысызлык, бирелгәнлек, иманлылык хас аңа. Батулла—безнең буынның бер бизәге, арабызда аның булуы үзе бер куаныч безгә».(«Социалистик Татарстан», 27.03.1988)

Батулланың куелмаган жиде яңа пьесасы бар. "Мур кырылышы" *(Казан утлары, 2007, 10, 11 саннар)*, «Китек күңел» *(Яңа татар пьесасы, 2007, 4 сан.)*, "Тиреләр йорты"—драма, "Төш"—драма, "Шомлы тынлык"—трагедия, "Иртәнге азан"—драма, "Яшел күлмәк"—бер кешелек драма.

Болары да басылыр, куелыр, тәнкыйтьчеләр алар турында үз фикерләрен әйтер әле.

## Батулла нәсерләре

Әдибебезнең сандыгында тагын әзер тупламалар бар. Аларның берсе—"Урыннары җәннәттә булсын" дигәне—2007 елда «Рухият»та дөнья күрде инде.

Нәсер остасы Батулла бу китабына мәрхүм булган татар әдипләре, сәнгатькәрләре турында беркемдә дә булмаган документлар, фактлар туплаган. Батулланың тагын «Уйларымны кеше белсен» дигән һәм «Иреккә чыгасы фикерләр» дигән тупламалары да бар әле.

Батулланың русча язган публицистикасы гаять популярлык казанды. Аның "Казанские ведомости", "Республика Татарстан", "Звезда Поволжья" гәзитләрендә басылган әсәрләре гел-гел бәхәсләр кузгата, кантарлы проблемалар күтәрә килә. Алар "Сказка про белого бычка" исеме белән ике тапкыр китап рәвешендә басылып чыкты (2001, 2002).

Батулланың бу китабындагы ачык хатлары аеруча игътибарга лаек. "Көрәшчелек түгел, бәлки чынбарлык..." (Рус шагыйре В. Устиновка), "Кем соң террорист, Буш әфәнде?" (АКШ президенты Дж. Бушка), "Русиянең бөтенлеген ничек сакларга? (Русия президенты В. Путинга), "Фәрьяд" (рус язучыларына) кебек әсәрләре җан ачысы белән язылган. Бу мәкаләләр—авторның гражданлык йөзен билгеле торган затлы публицистика.

Кыскасы, 70 яшьлек әдип Батулла иҗатында ун кешегә бүлеп бирерлек мал тупланган. Әгәр дә Батулла әнә шул ике томлык әкиятләрен генә язган булса да яки гүзәл хикәяләрен генә чыгарган булса да, 23 пьесасын гына куйдырган булса да, тарихи шәхесләр турында җыйган мәзәкләр, вакыйгаларын гына чыгарса да, нәсерләрен генә нәшер иткән булса да татар милләтенең олуг әдибе һәм милли каһарманы буларак тарихта калыр иде.

# ГАМЬЛЕ ШАГЫЙРЬ БАКЧАСЫ

Исемнәре татар әдәбиятында безгә мәгълүм Мөхәммәтшиннар өчәү: Галим (жан) Мөхәммәтшин (1911-1938), Газиз Мөхәммәтшин (1932-1972) һәм Гарифжан Мөхәммәтшин (1941). Пәйгамбәр исеме белән бәйле бу затларның икесе иҗатлары үрләр чакта яшьли дөньядан киткән. Шулай да, Галимҗан дигәне 30 нчы елларда, Газизе—60 нчы елларда әдәбият тарихында азмы-күпме эз калдыра алганнар. Ә Гарифҗан Мөхәммәтшин—безнең замандаш, кырык еллап әдәби-мәдәни хәрәкәттә актив катнашып килүче каләмдәш. Күпләребездән аермалы буларак, ул үз төбәгендә, туган туфрагында яшәп иҗат итә. Озак еллар җитәкчелек эшендә булды. Әмма табигате-асылы белән педагог-тәрбияче ул. Аның иҗади кредосы—кешеләргә күбрәк яхшылык эшләү, аларда күркәм сыйфатларны үстерүгә булышу, дөньяда иманны һәм ямьне арттыру... Ул—унлап китап авторы. Алар арасында балалар-үсмерләргә атап язылганнары да, өлкәннәргә адресланганнары да бар. Гарифҗан Мөхәммәтшин соңгы елларда Балтач төбәге тарихын өйрәнде, зур күләмле энциклопедик хезмәт чыгарды. Мондый җаваплы эштә автордан тикшеренүче галим булу да сорала. Бу җәһәттән аны галим шагыйрь дип тә санап була. Балтач төбәгеннән чыккан яшь каләм ияләренең иҗади үсешендә дә Гарифҗан Мөхәммәтшинның хезмәте хөрмәткә лаек. Яшь иҗатчылар өчен чын мәгънәсендә остаз әдип ул. Киң катлау укучылар аны тынгысыз публицист сыйфатында да яхшы беләләр. Көндәлек матбугаттагы даими чыгышлары шуны раслый. Соңгы елларда иҗат иткән эссе-парчаларын да истә калырлык яхшы әсәрләр дип исәплим мин. Шулай итеп, безнең замандаш Мөхәммәтшиныбыз, кеше буларак та, иҗатчы буларак та, язмышы белән элгәрге Мөхәммәтшиннардан бәхетлерәк булып чыкты.




Гарифҗан Мөхәммәтшинның «Робагыйлар бакчасы» дип аталган бу китабы тулысы белән дүртъюллык шигырьләрдән тора. Үзем дә, шигъриятнең кыска формаларына битараф булмаганга күрә, бу шигырьләрне аеруча кызыксынып укыдым. Ошый миңа кыска шигырьләр. Хикмәтле булганнары бигрәк тә! Гомумән, татар шигъриятендә кыска формаларның үсештә булуы сөендерә. Аз сүз белән җитди фикерләр әйтелә алу—әдәбиятның җитлеккәнлеген билгеле, әдипләребезнең профессиональ осталыгын күрсәтә. Димәк, шагыйрьләр сүзнең куәтен тулы җегәрендә файдалана беләләр. Хәзерге шагыйрьләрнең, яше булсын, өлкәне булсын, кыска шигырьләргә мөрәҗәгать итмәгәне юк та бугай. Әгәр элегрәк чорларга кайтып, әйтик, үткән гасырның 50 нче елларында чыккан шигырь китапларын укып карасаң, нигездә, эчпошыргыч озын шигырьләргә, су буе озын поэмаларга тап буласың. Шөкер, хәзер вазгыять бөтенләй бүтән. Заман таләбе—кыскалык, төгәллек, тирәнлек. Гарифҗан Мөхәммәтшин, бүгенге яшәү ритмын яхшы тоеп, заман егете булып иҗат итә.

Әйтә белүнең, бу очракта кыска формаларда бәян итүнең дә төрле ысуллары бар бит әле. Берәүләр ике юллыкның классик камил сурәтен таба, берәүләр, чәчәкләрдән экибана ясаган

Гарифҗан Мөхәммәтшин. Робагыйлар бакчасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 192 бит.

кебек, ирекле форма сайлый. Кем ничек булдыра ала да, укучы кемне үз итә. Соңгысы—Вакыт хөкемендә. Гарифҗан Мөхәммәтшин кыска форманың гасырлар буе сыналган робагый вариантын сайлаган. Робагый язуның отышлы ягы белән бергә, сагайта торган ягы да бар. Бик күп бөекләр таптаган юл бит, анда үз сукмагыңны сала аласыңмы? Чыннан да, мәгълүм тар кысаларда яшәеш фәлсәфәсенең киң төсмерләрен (яңасын!) табырга кирәк бит! Көнкүрешнең артык вак детальләрен дә бик үк өнәми бу форма. Бүгенге көндә робагыйлар язылырга алыну үзе бер тәвәккәллек.

Үрнәк өчен шагыйрьнең берничә робагыен китереп узыйк:

*Өзгәләнеп җилләр исә Болгардан—*
*Ерак калган әрнү тулы еллардан,*
*Шушы җилләр кагылу белән моң саркыла*
*Йөрәктәге киеренке кыллардан—*

дип халкыбызның фаҗигале язмышы тарихы турында уйлана. Шагыйрьне яшәешнең һәр проблемасы борчый, сызландыра.

*Үрсәләнмә әле, йөрәк, дөнья чуар,*
*Бетеп бара Кеше җанын аңлаучылар,*
*Ара-тирә үсмер чактан йомшак кешнәп*
*Нихәл, диеп сорый бары Алмачуар—*

дип бүгенге тормышыбыздагы ваклык-түбәнлекләр өчен көенә. Ә менә бу юллар Кешелек дөньясының мәңгелек рухи сугаручысы булган изге мәхәббәт хисе турында.

*Күзләреңә бактым—күзем алалмадым,*
*Тик әйтергә сүзләр генә табалмадым,*
*Алдыбызга өзелеп төште кызарып пешкән*
*Бер алмасы бакчадагы багалманың.*

*Җырлый-җырлый сандугач та картаямы?*
*Унсигездә күзең төшкән яр каямы?*
*Кинәт кенә шул сораулар килде башка—*
*Әллә инде минем баш та «янтаямы»?!*

*Өстәлләрдә касә тулы шәраб тора,*
*Күзен кысып миңа гына карап тора,*
*Шәраб эчеп, хурлар кочып гомер итү*
*Өч мизгеллек бу дөньяда ярап тора.*

Әлеге юлларда тирән киная, үтә кырыс җаннарны да елмайтырлык юмор хисе ялтырап ята.

Бу китапка Гарифҗанның 800 ләп дүртьюллыгы кергән. Бик зур сан. Аларның байтагы көндәлек матбугатта басылып укучыларга ирешә дә инде. Күпмедер сынау үтте дип әйтүем. Автор бу китапта аларны уннан артык төркемгә бүлеп урнаштырган. Болай эшләү, ягъни авторның дөнья, яшәеш турындагы фикерләрен шулай төрле фокусларга туплап бирү—шагыйрь белән укучы арасында араны якынайта, аңлауны җиңелләштерә. Ихтимал, ул төркемнәр фикер җегәрлеге җәһәтеннән тигез түгелдер, кайбер робагыйларның урыны үз төркемендә булмавы да бар, «Робагыйлар бакчасы» аллеясында төз нарат кебек, спай басып торганнары арасында кәрләләре дә бардыр... Вакыт үтәр, табигый сайланыш үз эшен эшләр. Бәлки сигез йөз саны сиксәнгә үзгәрер. Сайлар өчен иң әүвәл мөмкинлек кирәк. Ә китапта андый мөмкинлек бар.

Гарифҗанның бу китапка тупланган робагыйларын укыганда аның туган телебезне тирән белүенә сокланмый мөмкин түгел. Инде телебездән төшеп, югалып бара торган сүзләр, гыйбарәләр аның шигырьләрендә якты җәүһәр кебек балкып китәләр, телебезнең байлыгы, матурлыгы... язмышы турында уйландыралар.

Тирән фәлсәфи уйлануларга бай бу китапны укыгач Гарифҗанның ихлас һәм иманлы булуына сөендем. Шагыйрь өчен бик тә кирәк сыйфатлар болар. Авторның үзе белән таныш булмаган кеше дә, аның шигырьләрен укыгач, шагыйрьне, аның эчке дөньясын, кичерешләрен бөтен тулылыгы-барлыгы белән күз алдына китерәчәк. Һәрхәлдә, шәхсән үзем шагыйрьне яңадан бер ачтым, җанының зурлыгына, күңеленең байлыгына тагын бер кат инандым. Милләттәшләр, чордашлар гына түгел, фикердәшләр дә икәнбез бит! «Робагыйлар бакчасы»нда күңелгә хуш байтак «гөлләр» өздем, яшәеш турында янә кайтып уйландым, вакытның кадерен белеп, дөньяны ямьләргә дип иҗат итү хисе көчәйде. Укучыларның да шундый татлы халәт кичерүләрен телим.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

Миркасыйм Госманов

# ЗАТЛЫЛЫК

Соңгы еллар—егерменче йөзнең ахыры белән егерме беренче гасыр башы хәзерге татар әдәбиятына, мәдәниятенә бер-бер артлы зур югалтулар алып килде. Буыннарны, алар белән бергә чорларны да алмаштыра торган югалтулар...



Ике гасыр чатындагы иҗтимагый тетрәнүләрдән туган гомум үзгәрешләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән кискен борылышлар, «иман югалтулар» аз дигән төсле, аларга өстәлеп, бер-бер артлы шәхесләребез дә китә баралар. Һәрберсенең урыны бушап кала. Алардан соң бөтенләй башка кешеләр, башка иҗатлар, башка күренешләр киләчәк.

Әгәр килсәләр. Килә алсалар...

Арадан китүчеләрнең һәрберсе турында аерым-аерым сөйләп, дәлилләр белән язып булыр иде. Андый хезмәтләр, мәкаләләр бәлки, язылыр әле киләчәктә.

Мин исә бу язмамны—ул үзенә күрә истәлек тә, хушлашу сүзе дә булыр—күпләр арасында сирәк очрый торган, инде арадан китеп тә өлгергән бер замандашыма багышлыйм. Затлы холык-әхлагына, сөйкемле гадәтләренә төпле, нигезле гыйльми эшчәнлеге дә өстәлгән, бу юнәлештә аерым бер урын, хәтта төгәл бер өлкәне биләп торган, башкарган эшләренә фәнни тирәнлек, тормышчан, тарихи гаделлек хас, шул хезмәтләре белән үзеннән соң зур мирас калдырган замандашыма багышлыйм.

Рәис Нәүширван угылы Даутов (15.03.1928—28.08.2007) хакында сүзем.

• • •

Рәис агай белән танышлыгым әкрен генә башланып, сизелмичә генә урнашты кебек. Шуңа күрә үзен кайчан беренче мәртәбә күрүемне, кайчаннан сөйләшә, очрашкан саен күрешеп, бер-беребездән хәл-әхвәл сораша башлавыбызны төгәл хәтерләмим хәзер. Ләкин бер-беребезне шәхсән белә башлавыбызның Бауман урамындагы нәшрият йортының дүртенче катында булуы бәхәссез. Моннан кырык-кырык биш еллар элек студент, аспирант чагымда ук нәшриятка, яшьләр редакциясенә килеп киткәләгән вакытларда аны коридорда торган хәлдә күргәләвем истә. Янгынга каршы су бирергә тиеш кызыл төстәге калын торба төбендәге калай урна янында тәмләп кенә төтен йотып торган хәлдә. Үзем дә шул тирәдә тәмәке пыскытып алгалый идем. Һәрхәлдә, очрашкан саен исәнләшүләр, кыска-кыска сөйләшкәләүләр шул дүртенче катта башланды. (Әлеге дүртенче кат та, Бауман

урамындагы ул Матбугат йорты да, кызганычка каршы, тарихта гына калды хәзер...)

Мин аны, әлбәттә, беренче нәүбәттә нәшрият редакторы һәм аннары тәрҗемәче сыйфатында белә идем. Редактор-мөхәррирләрнең ул елларда төрлесен күрергә туры килде. Рәис Даутовның текст һәм авторлар белән ничегрәк эшләве ул вакытта миңа билгеле түгел иде әле. Шуңа күрә күп редакторларның берсе буларак кына тоела иде ул миңа.

Минем игътибарны иң элек аның тәрҗемәчелек сыйфаты күбрәк җәлеп иткән иде. 30нчы елларда татарча оригиналы харап ителгән «Мөһаҗирләр» романының очраклы рәвештә сакланып калган русча вариантыннан татарчага кайтарылган текстын укыгач (1968 елда), романның тәрҗемә икәнлеге бер дә сизелмәгән иде. Чөнки тасвирлана торган вакыйгалар барган, романның үзе иҗат ителгән чорларга хас телне дә, стильне дә тәрҗемәче, минемчә, уңышлы итеп кайтара, тергезә алган иде. Һәрхәлдә, миңа шулай булып тоелды Мәхмүт Галәү әсәрләренең яңа, дөресрәге, татарча беренче басмасы.

Рәис агай эшчәнлегенең бу ягына игътибар итүем очраклы булмагандыр, күрәсең. Чөнки ул елларда үземә дә беркадәре тәрҗемәләр белән шөгыльләнергә, шул рәвешчә студент-аспирант кешенең көнкүреш бюджеты хакында кайгыртырга туры килгәли иде. Әмма очрашкан саен сөйләшкәләп, сораштыргалап алырга ярата торган Рәис агайны икенчерәк нәрсәләр күбрәк кызыксындыра иде кебек. Хөсәен Фәезханов, Шиһабеддин Мәрҗани, Акмулла, Мөхәммәдьярлар хакындагы эреле-ваклы мәкаләләремне укып баруын әйтә, тагынниләр эшләвемне сораштыра. Шунда ук янә нәрсәләргә игътибар итүнең кирәклеге хакында да искәртеп куярга онытмый. Шундый сөйләшүләрнең берсе аерата истә калган.

Монарчы бер язганымча, Мөхәммәт Мәһдиев белән бергә әзерләнгән, «XX йөз башы татар әдәбияты һәм матбугат тарихының кайбер мәсьәләләре» дигән бер мәкаләбез басылып чыккач *(«Казан утлары», 1967, №7)*, ул рәсми идеология йомышлылары тарафыннан эзлекле тәнкыйтькә очраган, мәкалә авторлары «буржуаз милләтчелектә» гаепләнгән иде. Бер гыйльми конференциядә элекке партия идеологы профессор Камил Фәсиев һөҗүмнәренә тиешле җавап бирелгән булса да, «Социалистик Татарстан» битләрендә төгәл бер полосада күтәрелгән зур күсәккә— редакцион фикер рәвешендә басылган мәкаләгә каршы чара күрү мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә иде. Шулай аптырабрак йөргән көннәрнең берсендә, әлеге кызыл торба янында челемен суырып торган Рәис агай, исәнләшеп кенә узып китәргә теләгән җиремнән туктатып, үз янына чакырып алды. Бераз хәл-әхвәл сорашып, сөйләшеп торгач, әлеге гәзит тәнкыйтенә ишарәләп: «Күңелегезне төшермәгез, мондагы беркем дә аны житди кабул итмәде. Кемнәрнең кушуы буенча кемнең язуы да мәгълүм... Сез хаклы, күпме инде Риза казый, Фатыйх Кәримиләрдән күз йомып, Тукайның «Китмибез»еннән ахмак нәтиҗәләр ясарга мөмкин!»—диде. Аннары өстәп куйды: «Риза казый белән Фатыйх Кәрими эшчәнлекләре дә өйрәнелергә тиеш. Шул юнәлештә хәзергә шыпырт кына материаллар җыя барыгыз... Заман, һичшиксез, үзгәрәчәк. Ә гәзиткә килгәндә, аның иманы үзенеке һәм ныклы, хаклы булса, дүрт-биш мәртәбә исемен алыштырмас иде ул!»

* * *

Рәис агайның мөхәррирлек, бигрәк тә редактор-текстологлык сыйфатлары белән миңа бераз соңрак, узган гасырның 80нче елларында, якыннан танышырга, хәтта аның белән шактый тыгыз хезмәттәшлек итәргә насыйп булды.

Монарчы да миңа төрле редакторлар белән эшләргә туры килгән иде. Арада гадәти мәктәп укытучысы сыман имля хаталарын гына чүпләүчеләр дә, текстында берәр «борча» табылса, сине кимсетеп алырга теләүчеләр дә, үзләрен «политик белемле», системага тугрылыклы цензор рәвешендә тотучылар да, ниһаять, теләсә ничек чыксын, бераз укырлык кына булсын әле диючеләр дә очраштыргалаган иде. Шуларның барсыннан белеменең тирәнлеге, киңлеге, күзләренең үткенлеге, иң мөһиме, гыйльми дөреслеккә, документаль төгәллеккә, тарихи гаделлеккә тугрылыгы белән аерылып тора торганы, һичшиксез, Рәис Даутов иде. Мондый нәтиҗәгә мин аның белән дүрт-биш китап чыгару дәвамында ирештем.

Бергә-бергә эшләгән беренче китабыбыз Мифтахеддин Акмулла җыентыгы

булган иде. Ул эш уйламаганда, көтмәгәндә дигәндәй, кинәт башланып китте. Дөрес, минем монарчы да Акмулла иҗатына багышланган берничә мәкаләм басылып чыккан, шулай ук Алматы архивында һәм археографик эзләнүләр вакытында җыелган шактый яна материалларым бар иде.

1981 елның яз айларында көтмәгәндә мине нәшрият директоры Гарәф Низаметдинович Шәрәфетдинов чакыртып алды (монарчы да мина берничә китап, мәсәлән, Әбрар Кәримуллинның басылып чыкканчы ук «бәхәсле» дип исәпләнә торган монографияләрен, Габдрахман Таһирҗанов китабын чыгаруда нәшрият белән хезмәттәшлек итәргә туры килгән иде).

Директорның сүзләре кыска һәм катгый булды: мәгърифәтче шагыйребез Мифтахеддин Акмулланың (1831-1895) тууына 150 ел тула икән, шуны махсус билгеләргә кирәк, кечкенә генә булса да бер китап чыгару зарур. Ичмасам, ин киме, аның Шиһабеддин Мәрҗанигә багышланган «одасын» гына булса да. «Иске язуны, казакъ телен белгән кеше буларак, сезгә аны тиз арада башкарып чыгу кыен булмастыр»,—диде ул. Ризалыгымны биреп өлгергәнче: «Редактор—Рәис Даутов булыр»,—дип өстәп тә куйды.

Шулай итеп, көтмәгәндә тотындым мин бу эшкә. Әлбәттә, Рәис агай белән киңәшүдән башладым. Мине күрүгә ул: «Ризалыгынны бирденме?»—дип сорады. Ризалыгымны сорап-нитеп тормады дигән кебегрәк җавабыма каршы Рәис агай, үзенә генә хас көр вә калын тавышы белән әкрен генә ат кешнәгән төсле гәр-гәр килеп көлеп куйды: «Дөрес иткән, син эшләмәсән, кем эшләсен аны?»

Акмулланың нәрсәләрен, нинди әйберләрен сайлау хакында башлаган сүземне Рәис агай шунда ук бүлдерде: «Бөтен әйберләрен дә ал, бернәрсәсен дә калдырма! Аныкы икәнлеге бәхәслерәк әйберләр булса, аерым бүлектә басарбыз. Өлкә комитеты рөхсәт биреп, китап чыгаруны таләп итеп торган чакта мөмкинлекләрдән максималь рәвештә файдаланып калыйк! Түрәләр фикерләрен үзгәрткәнче—ике обком ярыша бит хәзер!—өлгереп калырга кирәк, тиз тотын эшкә!»

Бездә гел шулай инде, еллар буе йоклап ятабыз да, юбилей-мазар килеп җиткәч кенә, артка ут капкан төсле бер-беребезне этә-төртә алга томырылабыз. Һәм... эшләнгән була эшләр.

Гадәттә—«күнелдән ары...» дигәндәй генә...

Ике-өч айда Акмулла шигырьләренең корпусы әзер иде (көн саен диярлек эштән кайтып, ике-өч сәгать ял итеп алгач, төнге ун-унбердән иртәнге дүрт-бишкә кадәр, тып-тын шартларда утыра торгач, бара икән эшләр алга...). 1904, 1907 елларда басылган ике китапны төгәл күчергәч, архив һәм экспедиция материалларын да эшкәрткәч, шактый күләмле текст җыелган булып чыкты.

Рәис агай мин китергән материалларны, бисмилласын әйткән төсле авызын кыймылдатып, мәгънәле елмаеп кулына алды. Тиз-тиз карап чыкты. Канәгать чырай белән тезләренә шапылдатып сукты: «Болай булгач, өлгерәбез икән! Мин өйгә алып кайтып карап чыгыйм. Ике-өч көннән соң шалтырат әле».

Моннан соң текстларны бергә укыдык. Шагыйрьнең тапкыр, хикмәтле сүзләрен укыган саен ул чын күнелдән сөенә, «менә бит, менә ничек әйткән бит!»—дип соклана, сүз хикмәтләреннән ихлас рәвештә тәм табып ләззәтләнә. Аның телне нечкәләп тоюы сизелә. Хәтта үзенә аз таныш казакъча гыйбарәләрнең дә мәгънәләрен тиз аңлап ала, уңышлыларыннан тел шартлатып куя...

Мин тәкъдим иткән укылышка бәйләнгәләп алган вакытлары да булгалады. Дөресрәге, укылышның язылышыннан, төгәлрәк әйткәндә, хәзерге имлябызның зәгыйфьлегеннән канәгать түгел иде ул. Мин, билгеле, һәммә сүзләрне хәзерге гамәлдә булган орфография буенча язарга тырышкан идем. Ләкин бүгенге язуда хәрефләр җитмәү аркасында кайбер сүзләрнең элекке яңгырашлары төгәл чагылмаган икән. Бигрәк тә рифмаларда һәм ритмда. Шуна күрә мондый очракларда, гамәлдәге рәсми имлянын кагыйдәләрен җимереп булса да, транскрипция элементларын кертүне кирәк таптык. Минем кыюлыгым җитмәгән урыннарда Рәис агайның тәвәккәллеге алга чыкты. Нәтиҗәдә шигырьләр дөресрәк (бәлки элеккечәрәк!) яңгырый башлады. Моның шулай икәнлеген күрер өчен Акмулла шигырьләренең 50-60нчы еллардагы хрестоматияләрдәге басмалары белән әлеге юбилей җыентыгындагы яңгырашларын чагыштырып карау да җитәр иде.

Шул ук вакытта анын сирәк, архаик сүзләр мәгънәсен ачыклауда зур сабырлык күрсәтүе, ашыкмавы, «җиде кат үлчәве» дә гыйбрәтле иде. Еш кына анын «ашыкмыйк әле, уйлыйк әле» дигән сүзләрен ишетергә туры килә иде. Минем ашыгычрак әйтелгән искәрмәләрем дә төзәтелә барды.

Кайбер совет редакторлары элекке чорга караган әсәрләрдәге аңлашылмаган яисә күчерүчеләр тарафыннан үзгәртелгән, бозылган сүзләрне, шигъри юлларны җиңел генә сызып ташлау, шул рәвешчә тупас кыскарту юлына басарга күп сорап тормыйлар иде. Идеологик «зарарлы», мәсәлән, дини мотивларга карата башбаштаклык күрсәтү, аларны ботарлау, таптап узу гадәти күренеш иде (Акмуллада андый төшләрне шактый мул табарга мөмкин). Рәис агай исә бер дә мондый юлга басмады. Анын өчен тарихи текст кагылгысыз, хәтта изге иде. Шуңа күрә текстларны әзерләгән чакта «боларны редактор сызып ташламасмы» дип үзем дә шикләнгән, шулай да саклаган юлларның берсенә дә тиеп тормады ул, шуна күрә әлеге еллар өчен шөбһәле («зарарлы»!) дип исәпләнерлек урыннар да исән-имин сакланып калдылар, дөньяга чыктылар.

Димәк, Акмулла әсәрләренең яңа заманда басылган дөресрәк текстлары дөньяга чыга алган икән, монда редактор Рәис Даутовның да теләктәшлеге, саллы өлеше бар.

Рәис Даутовның әдәби мирас истәлекләрен яңадан бастыруда тарихи дөреслек, текстологик төгәллек принципларын ничек аңлавын, үз фикерләрен ничек раславын күрсәтә торган бер мөһим документ бар. Анын Акмулла юбилее көннәрендә конференциядә укыган докладының тексты ул. «Акмулла әсәрләрен бастырып чыгаруда текстология мәсьәләләре» дип аталган доклад конференция материаллары тупланган җыентыкта, мәкалә рәвешендә, урын алган *(«Поэт-просветитель Акмулла». Казан, 1983, 126-137 б.)*. Анда автор иң элек совет чорында Казан дәреслекләрендә басылган әсәрләрендәге төгәлсезлекләрне, кимчелекләрне билгели. Аларның «һәммәсе бездәге текстология белеменең чарланып, ныгып җитмәве белән» аңлатылуын искәртә.

Мәкаләнең икенче өлешендә Уфада чыккан Акмулла җыентыгының үзенчәлеге тәфсилләп анализлана. Оригинал рәвешендә тәкъдим ителгән әсәрләрнең башкортчага «яртылаш» тәрҗемәдә бирелүе, күпчелек очракта «тешләре үтмәгән» юлларны, строфаларны механик рәвештә кыскарту очраклары, яисә дини сүзләрне, фәлсәфи мәгънәле төшенчәләрне дөньяви, «сәвитчәрәк» яңгырый торган сүзләр белән алмаштыру, ягъни текстларны бозу фактлары күрсәтелә. Әйтик, кин вә махсус эчтәлекле «иман», «дин» төшенчәләрен «гыйлем» вә «мәгърифәт» ише таррак мәгънәле «дөньяви» сүзләр белән алмаштыру һәм, иң кызыгы, элекке Казан хрестоматияләрендәге кимчелекләрне, ялгышларны кабатлау күренешләре теркәлә. (Мәкалә дөньяга чыккач, ирешелгән хәбәрләргә караганда, Уфадагы кайберәүләр, күрсәтелгән бәхәссез хаталарны, бозуларны төзәтү турында уйлыйсы урынга, имештер, «татарлар бездән көләләр!» дип, партиянең өлкә комитетына шикаять белән барганнар, шул рәвешчә элекке гадәтләрен тагын да кабатлаганнар икән...)

* * *

1983 елда ЮНЕСКОның Париждагы «Новости» исемле бюллетенында Гәрәй Рәхимнең оештыруы белән минем «Кул Гали: восемь веков в народной памяти» дигән мәкаләм басылган иде (татарчасы: «Казан утлары», 1983, №9 һәм «Үткәннән—киләчәккә» дигән җыентык). Мәкаләнең язылу, басылу интригасын сөйләп тормыйм (совет чоры иде бит әле!). Шуннан соң нәшриятта «Кыйссаи Йосыф» нын үзен басмага әзерләү эше башланып китте.

Лингвист Фазыл Фәсиевнең күптәннән эшләнеп килә торган, мәгәр монарчы әллә ни хуплау, ярдәм тапмаган эшенә—«Кыйссаи Йосыф»ның җентекләп тикшерелгән тәнкыйди текстын бастыру өчен ишекләр киң ачылган иде. Югарыдан рөхсәт тә булгач, нәшрият эшләрне зурдан башлады. Әсәрнең оригиналы, ягъни Кол Гали үзе язган текст транскрипциядә, хәзерге татар теленә дә күчерелеп, русчага юлга-юл тәрҗемәдә, ниһаять, махсус искәрмәләре, барлык мәгълүм кулъязма күчермәләренең тасвирламалары белән бергә басылырга тиеш иде. Боларны башкарып чыгар өчен Фазыл Фәсиев (төп төзүче), Әхмәт ага Исхак (киңәшче), Рәис

Даутов (нәшрият мөхәррире) һәм миннән (текстолог-мөхәррирдән) торган махсус төркем билгеләнде.

Фазыл агай Фәсиевнең монарчы ук, текстны төрле кульязмалар буенча чагыштырып, искитәрлек зур эш башкарган булуы (транскрипция, тәрҗемәләр, искәрмә һәм тасвирламаларның беренче вариантлары эшләнгәнлеге) редакцияләү процессын шактый тиз тотарга мөмкинлек тудырды. Мин, гадәтемчә төннәр буе утырып, әсәр текстын транскрипцияләү өчен нигез итеп алынган кульязма вариантлары вә басма версиясе белән чагыштырып чыктым. Рәис агай да текстларның әзер өлешләрен өендә карап, төгәлсезлекләрне төзәтү, бәхәсле урыннарын искәрмәгә алу, аларны киңәшмәгә әзерләү белән мәш килде. Атнасына ике-өч мәртәбә, кайвакытларны көн саен диярлек, Р.Даутов бүлмәсендә җыелып киңәшә, бәхәсле, кыен мәсьәләләрне бергә-бергә хәл итә идек.

Хәзер уйлап карасам, үзенә күрә кызыклы, гыйбрәтле бер иҗади төркем оешкан икән. Әсәр текстының фонетик, орфоэпик һәм грамматик үзенчәлекләрен мөмкин кадәр төгәл сакларга омтылган лингвист Фазыл Фәсиев, кульязма текстының дөрес укылышына җаваплы археограф, ягъни мин фәкыйрегез, шигъри юлларның, гомумән әсәрнең мәгънәсен, поэтик үзенчәлеген яшьтән үк анына сеңдергән, күңелендә саклаган, шулай ук тәрҗемә өлкәсендә дә бай тәҗрибә туплаган өлкән шагыйрь Әхмәт ага Исхак. Образлы итеп әйтсәк, боларның өчесе үз мәнфәгатьләре белән мәгълүм мәсәлдәге Аккош, Чуртан һәм Кысланы хәтерләтә иде. Ләкин мәгънәсез вә зарарлы тарткалашулар булмады диярлек. Чөнки үзенә күрә төп тәңкыйтьче һәм оештыручы ролен башкара торган Рәис Даутов безнең тарафтан төрлечәрәк әйтелгән фикерләрне дә үзара якынлаштыра, бергә куша, нәтиҗәне булачак басманың файдасына таба юнәлтә ала иде.

Әлбәттә, фикер алышу вакытында кызып-кызып бәхәсләшүләр дә булгалый иде. Бигрәк тә транскрипциядә беренче нәүбәттә тел үзенчәлеген кайгырткан Фазыл агай кайвакытлар проблемалар да тудырып куя. Ул, мәсәлән, төрле кульязмалардагы фонетик күренеш кенә дип әйтерлек, күбесенчә соңгы заман күчерүчеләре керткән бер үк сүзләрдәге вак-төяк аермаларны да чагылдырырга тырыша, шунысы белән әсәр текстының халыкта яшәү үзенчәлеген, текст тарихын да чагылдыру кирәк дип исәпли. Телче күзлегеннән карасаң, дөрес алым бу. Әмма булачак басма иң элек әдәби истәлекне дөньяга чыгару булганлыктан мәсьәлә бәхәс тудыра иде. Гыйльми интереслары кульязмаларның тел-фонетик үзенчәлекләрен төгәл чагылдырудан гыйбарәт булган, шул юнәлештә үз карашларын фанатикларча якларга тырышкан Фазыл агай унификация буенча ясалган кайбер тәкъдимнәргә теш-тырнагы белән каршы тора. Өч-дүрт көнгә бер мәртәбә дигәндәй, «сезнең белән, егетләр, эшләп булмый башка!»—дип ачуланып, пыр тузынып, кул селтәп чыгып та киткәли иде. Тик иртәгесен, бер нәрсә дә булмаган төсле, тагын килеп җитә, эшкә тотына...

Кайчакларын, бергә-бергә эшләүнең әүвәлге көннәрендә, бәхәсләшүләр тавышлырак килеп чыкканда, нәшрият директоры Гарәф агай, сугышмыйлар микән болар дигән төсле, ишекне ачып шикләнебрәк карый, аннары гафу үтенгән сыман куллары белән ишарәләп кире чигенә, ишекне әкерен генә ябып куя иде...

Шактый кыенлыклар тудырган нәрсә шигъри әсәрне хәзерге әдәби телгә юлга-юл күчерү, русчага да тәрҗемә итү булды. Монда инде саф лингвистик тәрҗемә генә җитми—сүзләр әдәби әсәр контекстында икенчерәк төсмер, яңачарак мәгънә дә алырга мөмкин. Нәкъ менә шуларны хәл иткәндә Әхмәт Исхакның тәҗрибәсе, зәвыгы аерата зур роль уйнады. Гомумән, күпне күргән, күпне баштан кичергән, элекке чор психологиясен дә белгән Әхмәт ага еш кына киңәшмәләребезнең рухи үзәгенә әверелә иде. Ул вакыт-вакыт әсәрнең элекке тормышыбызда тоткан урыны, әдәби-эстетик үзенчәлеге, халык авыз иҗатына, яңа заман татар әдәбияты туу процессына ясаган тәэсирләре хакында кызыклы, гыйбрәтле мисаллар, күңелле вакыйгалар сөйләп, аңгәмәбезне җанландырып, хәтта нурландырып та җибәрә иде. Гомумән тормышка, аерым күренешләргә дә юмористик күз белән елмаебрак карый торган Әхмәт ага гап-гади нәрсәләрдән дә көлә белә, аларны үзенчә бәяли ала иде. Беркөнне ул, мәсәлән, билгеләнгән вакыттан шактый соңрак килде. «Һи, егетләр,—диде керүгә үк,—Бауман урамыгыз шул кадәр озынайган икән хәзер! Киләм, киләм, һаман җитә алмыйм...» Адымнар кыскарган, тиз йөреп булмый дип зарланып тормады ул.

Ана җитмеш сигез яшь иде инде.

Әмма ләкин төркем эшенең төп тоткасы, хәтта арка сөяге дә, һичшиксез, Рәис Даутов булды. Һәрвакыт диярлек елмаеп, ачык чырай белән каршы алыр, әйтелгән фикерләрне, тәкъдимнәрне игътибар белән тынлар, алар төрлечә булсалар да, уртаграк, үзара якынрак моментларын таба белер, шул рәвешчә мәсьәләне көтелмәгәнчә чишүгә ирешер иде. Кайберләребезнең бәхәс вакытында кызыбрак китүенә дә иң элек калын, бас кебегрәк матур тавышы белән, ат кешнәгән төсле гөр-гөр көлеп, дустанә мөнәсәбәт белдерер, шунысы белән тынычланырга мәҗбүр итәр иде. Күп сөйләүдән авызың коргаксып, телең ару сизелсә, ул гел чәйле торудан саргаеп беткән чәйнеген ярдәмгә чакырыр... Фикерләре аның әсәр текстын яхшы аңлауга, гомумән төпле белемгә, саллы дәлилләргә нигезләнгән булыр. Шул ук вакытта ул кеше фикерен дә хөрмәт итәр, дөрес булмаганнарының сәбәпләрен әдәпле рәвештә күрсәтер. Гомумән, Рәис Даутовның кешеләр белән мөнәсәбәтенә гаҗәеп бер табигый зыялылык, затлылык хас иде.

Һәрвакытта диярлек утырышларыбыз шулай эшлекле рәвештә, күңелле атмосферада узганга очрашуларга теләп, ашкынып килә идек. Һәрберебез үз эшебезгә зур җаваплылык белән карадык. Үзенә йөкләнгән тиешле эшне вакытында үтәргә, көттереп тормаска тырыштык. Мин, мәсәлән, Ф.Фәсиев тарафыннан редакция эшләре башлангач кына ашыгыч рәвештәрәк язылган, кайбер төшләре каралама хәлендә генә булган кереш мәкаләне Мәскәүгә алып барып, «Бартольд укулары» дигән бөтенсоюз гыйльми конференциясе көннәрендә, утырышлар вакытында да редакцияләү белән мәш килүемне хәтерлим...

Кыскасы, шулай кулга-кул тотынышып, күмәкләшеп, кызу темплар белән эшләү нәтиҗәсендә җәй башында ук булачак китапның кыяфәте күренә башлады. Зур гына кереш мәкаләне, өч версиядәге әсәр текстын, истәлекне саклаган 160тан артык иске кульъязманың тәфсилле тасвирламасын, күләмле искәрмәләрне һәм фотоиллюстрацияләрне эченә алган булачак китапның корпусыннан гыйбарәт иде ул «кыяфәт».

Рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов та көн-төн дигәндәй эшләп, китапның зәвыклы бизәлешен тәэмин итте.

Әзер, мәгәр редакцияләү дәвамында чуарланып беткән текстларны машинкада акка бастыру, корректорларга укыту... кадәресе, әлбәттә, Рәис күзәтүендә башкарылды.

Чамалы гына буйлы, кечкенә генә гәүдәле бу кешенең шундый—үз буена кире пропорциональ рәвештә—зур җегәргә, көчкә, затлылыкка ия булуы уйландыра да, сокландыра да иде!..

Шул рәвешчә ел ахырына таба зур форматлы, 543 биттән торган калын—фундаменталь китап чыгып та өлгерде. Халкыбыз арасындагы искитәрлек киң таралышы, яратып укылышы һәм әдәби фикеребезгә ясаган эзлекле тәэсире буенча беренче дәрәҗәдәге язма истәлеге булган «Кыйссаи Йосыф» дастаны, шулай итеп, яңадан калкып чыкты—язма әдәбиятыбызның елга башын билгеләгән алтын баганасы булып басты!..

Шул рәвешчә олы китап дөньяга чыккач, «Кыйссаи Йосыф» поэмасының 800 еллыгына багышланган юбилей тантаналары гөрләп узды. Казанда да, Мәскәүдә дә.

Тарихта беренче мәртәбә...

* * *

Олы фикер иясе, мул мираслы шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгарыйның Әнвәр Шәрипов тарафыннан төзелгән, сайланма шигырьләрне, поэмаларны эченә алган зур җыентыгын кульъязмалар белән чагыштырып басмага әзерләгәндә дә фәнни редакторның нәшрият мөхәррире Рәис Даутов белән сөйләшүләре, фикер алышулары гаҗәп эчтәлекле, мәгънәле һәм нәтиҗәле булган иде. «Нәтиҗәле» сүзен монда очраклы рәвештә кулланмадым. Шуны күрсәтә торган бер генә мисал: Утыз Имәни мирасына тарихи күзлектән дә бәя бирү кирәклеген миңа Рәис агай әйткән һәм шул мәсьәләне хәл итүне тәкъдим иткән иде. Нәтиҗәдә китапта, аның кушымта өлешендә, «Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгарый: чор, иҗат һәм мирас» дигән күләмле мәкалә урын алды (1986, 338-395 бб.). Шагыйрьнең

иҗтимагый фикеребез тарихында тоткан урынын билгеләү юлында киләчәктә эшлисе эшләрнең чикләре, күләме шәйләнә, күренә башлады. Аның эшчәнлеге гаять катлаулы, каршылыклы, бай мирасы никадәре олы, купкырлы икәнлеге, бу юнәлештәге «күтәреләсе чирәмнәр» дә төсмерләнеп җитә язгандай булды кебек...

Телгә алынган бу соңгы факт Рәис Даутовның гади мөхәррир бурычы белән генә чикләнмичә, китапларны эчтәлек ягыннан баерак, сыйфатлары буенча яхшырак итеп чыгару өчен дә тырышуына бер мисалдыр. Китапның күләме артасы булса, аны да директор белән сөйләшеп хәл итүне ул үз өстенә ала иде. Гомумән, нәшрият җитәкчелеге һәрвакыт диярлек аның тәкъдимнәре белән килешә иде.

Габделҗәббар Кандалыйның соңгы утыз-кырык ел дәвамында табылган, җыелган әсәрләреннән тупланган күләмле җыентыгын әзерләп бетергәч, аны нәшриятка тәкъдим иткән чакта, мин директордан мөхәррирлеккә Рәис Даутовны билгеләвен сорадым.

«Ә башка кем булсын соң,—диде Гарәф Низаметдинович,—аны алыштырыр кеше юк башка. Тик хәзергә кулы буш түгел аның, бер-ике айдан бушар, бәлкем».

Әмма Рәис агай элегрәк тә башлап җибәрде Кандалый әсәрләрен укуны. Эшләр, дөресен әйткәндә, майлап куйган төсле бик тиз, шома барды. Берәр принципиаль бәхәс чыгуын, кискен үзгәрешле төзәтмәләр кертелүен хәтерләмим. Менә, ихтимал, элекке китапларны әзерләү процессында минем шактый тәҗрибә туплаган булуым, бигрәк тә архаик һәм гарәп-фарсы сүзләрен дөресрәк язуда, аларның шигъри яңгырашларын кирәгенчә сакларга омтылуда ярдәмчел транскрипция алымнарыннан иркен һәм кыю файдалануым да сәбәп булгандыр. Әмма иң мөһиме, минемчә, үзенчә эпикурист Габделҗәббар хәзрәт шигырьләренең кабатланмас сыйфаты: искитәрлек гади матурлыгы, самимилеге, сәламәт шаянлыкларының тормышчанлыгы һәм чын халыкчан тапкырлыклары сәбәп булгандыр. Менә шулар икебезнең дә омтылышларыбызны бер юнәлешкә—болар тизрәк укучыларына җитсен иде дигән теләккә буйсындырды шикелле. Теләкләрнең шулай уртак булуы эш атмосферасының җиңел вә самими дустанәлеген тәэмин иткәндер. Һәрхалдә, китап өстендә эшләү процессы минә үзенә күрә бер табигый, күңелле бәйрәм сыманрак булып тоелган иде. Хәзергә кадәр шулай истә саклана.

Ниһаять, ялт иткән төсле китап—Габделҗәббар Кандалыйның монарчы мәгълүм, ягъни табылган, җыелган әсәрләре зур гына том булып дөньяга чыгып җитте. Әгәр анарчы ике мең чамасы шигъри юллары гына билгеле булган булса, хәзер, вариант һәм аныкы булуы ихтималларын кушып санаганда, тугыз меңнән артык шигъри юллары бергә тупланып, укучыларына барып җитте.

Җыеп әйткәндә, бу елларда, бергә-бергә дүрт-биш китап өстендә эшләү нәтиҗәсендә мин Рәис агайның Ходай тарафыннан редактор итеп махсус яратылган сирәк затларның берсе икәнлегенә ышандым. XIX гасыр белән XX йөз башы татар мәдәниятен, шул чор Казанының милли интеллектуаль хәятын яхшы белүе, телебезнең үзенчәлекләрен, нечкәлекләрен тоюы, шигъри текстларны дөрес, матур яңгыратуда, текстолог сыйфатында осталыклар күрсәтә алуы да мине сокландырды. Бу җәһәттән ул үзен чын гыйлем, нечкә зәвык иясе буларак күрсәтә, таныта алды. Бер үк вакытта ул гаять әзлекле, үткен күзле, зур мәсьәләләрне хәл иткәндә дә, өтер, аның урыны кебек «вак» нәрсәләрне дә күз уңында тота белүче нәшрият мөхәррире дә булып кала алды.

Халкыбызда кәгазь битен «кара язу» агарта, дигән бер хикмәтле әйтем бар. Талантлы әдип, җитди редактор каләменнән «кара язулар» тагын да агара төшә икән...

Әйе, Рәис агай Даутов белән бергә-бергә эшләү дәверендә мин анардан текстларны басмага әзерләү буенча күп нәрсәгә өйрәндем, мул тәҗрибә тупладым. Шуңа күрә, соңра административ эшкә күчкәч тә, башка мәшәкатьләр белән шөгыльләнгәндә дә, ул елларны сагынып яшәдем.

Хәзер дә сагынып искә төшерәм...

• • •

Монарчы язганнарымнан чыгып, Рәис агай белән безнең арада бөтенесе дә гел ал да гөл, һәрвакытта да пыяла өсте кебек шоп-шома, тигез булган икән дип уйларга мөмкин. Гомумән алганда, эш мәсьәләсендә мөнәсәбәтләребез шулай шома, дустанә

һәм эшлекле рәвештә барды. Шулай да беркадәре вакыт теге яки бу мәсьәлә буенча уртак тел таба алмыйча тезгенне төрле якка тарткалап йөргән чаклар да булгалый иде. Дөрес, ахыр чиктә, кайвакытларын үз сүзләремнән мин чигенеп, икенче очракта ул да үз раслауларыннан кайтып, бер фикергә килә язып, җинел сулап куя идек. Мондый чакларда төп этәргеч, минемчә, икебезнен дә бер максатка омтылуыбыз—текстларны бирүдә мөмкин кадәр тарихи дөреслеккә омтылуыбыз була иде. Аннары бит кайчакта, уйлана, эзләнә торгач, мәсьәләнен өченче варианттагы чишелеше дә ялтырап куя.

Бер мәртәбә уйламаган, көтмәгән җирдән сугыша да яздык әле. Болай килеп чыкты ул. Кол Галинен «Кыйссаи Йосыф» поэмасы басылып чыккач, югарыда бер әйткәнемчә, юбилей тантаналары башланды. Казандагы шау-гөрләрдән сон Мәскәүдә узачак бәйрәмгә зур делегация белән бергә Рәис белән икебезне дә алып барганнар иде. Тантаналы кичәдән, ыгы-зыгылы, түрәләр тулган рәсми фуршеттан соң кунакханәбездә дә бәйрәмне дәвам итәргә, бераз «пирәшләп алырга» булдык. Мәшһүр «Мәскәү» отелендәге Равил Фәйзуллин белән икебез урнашкан люкс бүлмәгә күршедәге Рәис агайны да чакырдык. Фуршет вакытында, зур агайлардан тартынып дигәндәй җүнләп ашый-эчә алмауның үчен алырга теләп, чәркә артыннан чәркә җибәрдек, гөрҗеләрдән дә уздырып ике бөртектән торган аудиториягә өченчебез тостлар сөйләде.

Сүз артыннан сүз чыкты һәм, кем әйтмешли, ... күз дә чыга язды. Чөнки бер ара Рәис агай, шаяртып алырга теләпмедер, минем хакта көндәшләрем, минем Казанда булуымны артык күрүче кайбер көнче каләмдәшләр тарафыннан әйтелә торган гап-гади, тик мина **ошамаган** бер сүз ычкындырды—килмешәк! Шайтан суыннан шактый җылытылган канымны әлеге ахмак сүз кинәт кыздырып җибәрде. «Нәрсә?! Әйдә, тагын кабатла!»—дидем мин анар усал төбәлеп, «кабатла!»—дип төпчендем. Ләкин ул кабатламады да, ялгыш әйттем дип гафу үтенеп чигенмәде дә. Ирлегемне итәм дигәндер, күрәсең. Мин исә аннан ары кызып бәйләндем үзенә.

Торып та бастык. Бер-беребезнең якаларына ук ябыштык... Әгәр арага Равил кереп басмаган булса, бәлкем, малай чаклардагы кебек борыннар да канавы ихтимал иде...

«Нәрсәне кабатлыйм, ни өчен кабатлыйм?!»—дип Рәиснең үрсәләнүен генә хәтерлим. Бүген уйласам, ул үзенең нинди сүз ычкындыруын үзе онытып та җибәргән иде шикелле.

Ниһаять, Равил икебезне дә аерып, мине эчке бүлмәгә куып кертте, этә-төртә Рәисне дә үз бүлмәсенә илтеп куйды.

Иртәгесен, йокыдан торып коридорда очрашкач, бер-беребезгә күтәрелеп карый алмыйча, беркадәре вакыт сүзсез генә тордык, аннары, алдан сөйләшеп куйган шикелле буфетка төшеп киттек, сөйләшмичә генә чәй эчтек. Шунда гына Казанга кайтачак билетларыбызның бер купеда икәнлеген искә төшердек һәм, шуннан канәгать булган төсле тынычланып, китап кибетләре эзләп киттек...

Шуннан бирле чирек гасырга якын гомер узды. Без бервакытта да әлеге һәм көлкеле, һәм күңелсез, шул ук вакытта мәгънәсез ызгышны искә төшереп, кем әйтмешли, «анлашып» тормадык (мин үзем бу хакта моңарчы берәүгә дә сөйләмәдем). Чөнки коридорда җиргә карап торганда да, сүзсез генә чәй эчкәндә дә, китап кибетләре эзләп киткәндә дә бар әйтәселәр «әйтелгән», шул рәвешчә, тәмам анлашылган, тулысынча килешенгән икән. Бары менә хәзер генә, шушы юлларны язып утырганда, мин ул «вакыйганы» тулаемы белән күздән кичергәндәй, хәтер янартып алдым. Һәм бер нәрсәне анладым: ул кичтәге кыланышларыбыз өчен оялсак та, үзенчәлекле сынау булган шул әкәмәт ызгыш өчен язмышка рәхмәтләр әйтәсе, шөкерләр итәсе икән. Чөнки ул «якалашу», аның өчен оялу безнең арада башка берниндн конфликтның, сүзгә килүнең, сүзсез генә дә үпкәләшүләрнең булмаганлыгын раслады. Чөнки «Кыйссаи Йосыф»ны редакцияләүдән соңгы мөнәсәбәтләребездә берннинди кер-тап булмады, бәлки хезмәттәшлегебез, бер-беребезгә карата булган ихтирамыбыз, ышанычыбыз арта гына барды.

* * *

Р.Даутов—«редактор-текстолог» һәм «нәшрият мөхәррире» дигән темага болай киннән тукталуым анлашылса кирәк. Әйе, мин Рәис агайның кеше һәм әдәбиятчы

буларак табигатен, сыйфатларын шул өлкәдә хезмәттәшлек итү нәтиҗәсендә белә алдым. Ләкин Р.Даутовның мәдәни тормышыбызга керткән өлеше, гомумән татар мәдәниятына калдырып киткән мирасы болар—мөхәррирлек эшләре, башкаларның китаплар чыгару белән генә чикләнми.

Рәис Даутов әдәбият мәйданына иң элек тәрҗемәче сыйфатында чыккан иде. Аның тәрҗемәгә нинди әдәби әсәрләр сайлавы, тәрҗемәләрне ничек, нindирәк дәрәҗәдә башкаруы махсус өйрәнүне сорый торган тема. Үземә ошаган бер тәрҗемәсе—«Мөһаҗирләр»нең тел сыйфаты, гомум стиле ничек икәнлеге хакында югарыда беркадәре әйткән идем инде.

Әдәбиятчы Р.Даутов эшчәнлегенең үзәк юнәлеше һәм гомер буена диярлек дәвам иткән икенче төп эше—ул яна заман әдипләребез иҗаты буенча био-библиографик белешмәләр төзү иде дисәм, әллә ни ялгышмам сыман. Конкрет әдәби истәлекләрне, хәтта берәр иҗатка багышланган җыентыкны да (мәсәлән, Дәрдемәнд әсәрләрен туплау h.б.), мөхәррир-текстолог, төзүче буларак матбугатка әзерләү эшләре, мәгълүм булганча, әлеге китапларның басылып чыгуы белән нигездә тәмамланган була. Ә менә хәзерге әдәби процессны чагылдыруга хезмәт итә торган, ягъни өр-яңа заманыбызда иҗат иткән, итә килә торган язучы-шагыйрьләребез хакында тәфсилле белешмәләр булдыру, аларны тулыландыра, янарта бару—бу инде очы-кырые, ахыры-чиге күренми торган даими процесс. Рәис Даутов нәкъ менә шушы юнәлештә ару-талуны, ялга туктауны, кирәгенчә рәхәтләнеп йоклауны да белмичә эшләгән кеше (ул, мәсәлән, эштән кайтып бераз ял итеп алгач, ярты төнгә кадәр язып-сызып утырырга гадәтләнгән).

Татарстан һәм гомумән татар язучыларына багышланган, китаптан китапка таба мәгълүматлары дөресләнә барган белешмәләрнең сыйфатларын күтәрүдә аның тырышлыгы, эзлеклелеге һәм югары дәрәҗәдәге җаваплылыгы бәхәссез иде. «Мәгълүматлары дөресләнә барган» дип әйтүем һич тә очраклы түгел. Чөнки соңгы вакытларга кадәр 1937-1938 елларда репрессияләнгән, шунда ук атып үтерелгән кайбер язучылар хакында рәсми оешмалар тарафыннан алар 40нчы елларда «үз әҗәлләреннән үлгән» кебегрәк фальсификацияле документлар бирелә иде. Белешмәләрнең элегрәк чыкканнарында шулайрак язылган да. Шуңа күрә Рәис агайга «үзен дә төзәтергә» туры килә иде. Һәрхәлдә, репрессия корбаннары булган совет чоры татар әдипләренең исемлеген, тәрҗемәи хәлләрен мөмкин кадәр дөресрәк яктырту юлында Рәис Даутовка бик күп тырышырга туры килгән иде.

Бер үк вакытта мираслары нигездә каттый рәвештә тыелмаган, мәгәр беркадәре үзгәртелгән, кыскартылган әдипләребезнең әсәрләрен сыйфатлырак, төгәлрәк итеп чыгару, элегрәк хөкем сөргән баш-баштаклыкларны, шапшаклыкларны киметү, бетерү юнәлешендә дә яна заман төзүчеләре белән бергә Р.Даутовның да тырышлыгы зур булды. Мәсәлән, Габдулла Тукай әсәрләренең соңгы елларда басылган күптомлыкларын алыйк. Андагы шигырьләр элекке совет чоры басмалары белән чагыштырганда күпкә тулырак булып, дөресрәк, матуррак янгырасалар, конкрет әсәрләре хакындагы белешмәләр дә сыйфатлырак булса, монда да, ул томнарның төзүчесе (мәсәлән, Рәшат Гайнанов) белән бергә, һичшиксез, мөхәррир Р.Даутовның да хезмәте зур иде.

Бу фикерем югарыда бер мәртәбә телгә алынган Дәрдемәнд җыентыгына («Исә җилләр» 1980) һәм тагын Галимҗан Ибраһимов (8 томда), Галиәсгар Камал (3 томда), Хәсән Туфан (2 томда) мирасларын басмага әзерләүгә дә карый. Гаяз Исхакый әсәрләренең кайта башлавында да («Зиндан» исемле җыентык, 1991) Рәиснең хезмәте бар. Классик мирасны бастыруда актив эшләве белән бергә ул хәзерге чор шагыйрьләрен дөньяга чыгаруга да (мәсәлән, Р.Фәйзуллин, 1976) катнашты.

Био-библиографик китаплар, белешмәлекләр әзерләү процессында ул андый хезмәтләрнең махсус аудиториягә адресланган вариантларын да булдырырга тырышты. Мәсәлән, мәктәпләр өчен дип эшләнгән «Балачак әдипләре» исемле оригиналь эчтәлекле, җиңел стиль белән язылган кулланманың өч чыгарылышы (томы) дөнья күрүен махсус билгеләргә кирәк дип исәплим. Әдәбият укытучылары, хәтта тырыш, эзләнүчән укучыларның үзләре өчен дә кирәкле, кыйммәтле кулланма болар.

Укучылар, мәктәп яшьләре мәсьәләсенә игътибар итүем очраклы түгел. Бу

проблеманың Р.Даутовны гел кызыксындырып торганлыгы, әдәбиятыбызның киләчәге өчен яшь көчләрнең килүенә әһәмият бирүе һәрвакыт сизелә иде. Бер мәртәбә шалтыратып, нәрсәләр «кырып утыруы» хакында сорашкач, ул яңа җыентыкларны карап, яңа исемнәр, аларның әсәрләре белән танышып утыруын әйтте. Күпме андый яңа исемнәр, өметлеләре бармы, дип кызыксынгач, ул яшьләрнең элекке, 60нчы еллар башындагы кебек үк актив булмавын, шулай да кайбер өметле генә каләмнәрнең күренгәләвен, мәгәр күпчелекнең телне бик белмәвен, аның нечкәлекләрен тоймавын әйтеп күрсәткән иде.

Рәис агайның Казанда җүнләп урнаша, тернәкләнә алмыйча кыенлыкларга дучар булган яшь авторларга рухи да, хәтта матди дә ярдәм иткәләве хакында ишеткәнем бар. Үзе андый игелекләре хакында бер дә сөйләми иде. Бу хакта күбрәк белүчеләр тәфсилләбрәк язса әйбәт булыр иде дип уйлыйм. Хәерхаһлык, ярдәмчеллек сыйфаты да кешенең асылын ача бит.

Ярдәмчеллек сыйфаты, әгәр ул табигый булса, исәннәргә карата гына түгел, минемчә, үлгәннәргә мөнәсәбәттә дә чагылыш таба. Шуның бер мисалын китерим.

Заманында Исмәгыйль Рәмиев (1895-1969) үзешчәнлек юлы белән тырышып, татарның рухи мәдәнияте тарихы буенча энциклопедик характердагы сүзлек өчен материаллар туплаган булган. Совет чорында, шәхси инициативага юл бирмәү хөкем сөргән заманда, ул материаллар басыла алмыйча, кулъязма килеш калып, онытылу, югалу хәленә төшә. Һәрхәлдә, фәнни оешмаларның әлеге хезмәтнең язмышы хакында кайгыртулары, кызыксынулары турында үземнең бернәрсә дә ишеткәнем булмады. Р.Даутов аның кулъязмасын табып, журналда өзекләр бастыра, аннары үзеннән яңа материаллар өстәп, төзәтеп, тулыландырып ике исем белән китап рәвешендә дөньяга чыгара *(Әдәби сүзлек. К., 2000.)*. Нәтиҗәдә И.Рәмиев хезмәте дә югалмый, белешмәнең сыйфаты да яхшыра. Өстәмә материаллар кертелү исә бик урынлы: И.Рәмиевтән соң тарихи белемебез арта, төзекләнә төште бит. Энциклопедик рухтагы белешмәләрдә мондый үзгәрешләр исәпкә алынырга тиеш.

* * *

Энциклопедия сүзе телгә алынгач, тагын бер мәсьәләгә тукталуны кирәк табам. 2002 елда, ниһаять, тарихта гомумән беренче мәртәбә булып, ана телебездә «Татар энциклопедия сүзлеге» дөньяга чыкты. Бәяләп бетергесез бу уникаль хезмәтнең әдәби редакторлар башлыгы Рәис Даутов булды (пенсиягә чыккач,—«лаеклы ялга» дип әйтә алмыйм: ул гел җигелеп эшләде—аны Татарстан Фәннәр академиясенең Энциклопедия институтына эшкә чакырганнар иде). Әгәр сүзлектә басылган, күп очракта төрле кешеләр тарафыннан русча язылган эреле-ваклы мәкаләләр татарча дөрес яңгырыйлар икән—монда да Рәис агайның өлеше, хезмәте аз түгел.

Фикеремне дәлилләр өчен, күпләгән мисалларны чүпләп тормыйча, бер генә характерлы үрнәккә мөрәҗәгать итү белән чикләнәм. Без гадәттә исем-фамилияләребезне русча шаблонга буйсынып язабыз. Мәсәлән: Әбүзәров, Әхмәров, Хәсәнов, Хөсәенов һ.б. дип. Р.Даутов редакцияләгән сүзлектә исә: Әбүзәрев, Әхмәрев, Хәсәнев, Хөсәенев, дип дөрес яңгырашта бирелгән. Аның шундыйрак карашны алга сөрүе миңа элек тә мәгълүм иде (үзем дә шулайрак эшләргә тырышкалыйм). Әгәр Рәис агай үз позициясендә нык тормаса, иманым камил, башкалар, «документта, паспортта шулай бит», дип, (ә паспортларны, документларны кайларда, нинди генә кемсәләр язмаган!..) «нечкә», нәфис әйтелешле татар фамилияләрен дә гел русча яңгыратыр, хәтта акыртыр идек (мисал кирәк булса, газитләргә, «фәнни» хезмәтләргә карагыз, радио да тыңлагыз: татарча тапшыруларда да Гялиев, Кядыйров дип әйтүләр, кызганычка каршы, кагыйдәгә әйләнеп бетте бит!..)

Энциклопедик сүзлегебезнең редакцион сыйфатлары турында язып утырам, үземне бер үкенечле хис биләп тора: ичмасам, энциклопедиябезнең киләчәктә татарча чыгарга тиеш тәфсилле томнарының (сүзлеге түгел!) беренче-икенче томнарын гына булса да, күздән кичерү «нәшрият редакторы» Рәис Даутовка насыйп булган булса?!. Алар, ичмасам, калган томнар өчен үрнәк булыр иде. Кызганыч...

Гомумән, Р.Даутов эшләгән, ул катнашкан кайсы гына темага кагылсаң да, узган һәм бүгенге (хәтта киләчәккә!) мәдәни, рухи тормышыбызның шактый мөһим,

кайчакларын ярыйсы гына катлаулы, четерекле, шул ук вакытта актуаль проблемаларына—зарур бурычларга килеп төртелер идек. Шул ук вакытта ул башкарган эшләрнең тарихи гаделлек, гыйльмилек ягыннан төпле, эстетик җәһәттән югары зәвыклы дәрәҗәдә үтәлгәнлеген дә икърар итәргә туры киләчәк.

Мин гомумән авыр тормышка тарыган, дөресрәге, таратылуга дучар ителгән совет авылында ярым ятим (атасы сөргенгә җибәрелгән), ач-ялангач хәлдә чабата үреп үскән, институт дип аталган гадәти генә провинциаль уку йортында (Сорбонна, Кембриджлар болай торсын, хәтта МГУ да түгел...) укыган кешенең шундый киң колачлы тирән белемгә, әтрафлы культурага ия булуының сәбәпләрен, җирлеген күпкә кадәр аңлый алмыйча йөрдем. Ниһаять, зыялылыкны, ан-белемгә хөрмәт хисен нәселдән-нәселгә бирә килеп саклый, үстерә торган аксөяк нәселләре генә түгел, хәтта эреле-ваклы руханилары, эшлекле, булдыклы урта хәлле игенчеләр катламы да кырып-себереп юк ителгән, өстәвенә, авыр сугыш елларында бригадир типкесе астында, люмпенлашканнар даирәсендә үскән, формалашкан кешедә затлылык сыйфатларының шул дәрәҗәдә табигый һәм мул чагылуы сәбәпләрен дә тиз генә аңлый, бәяли алмаган идем. Бары, кайбер асыл сыйфатлы шәхесләребезгә, җөмләдән Илһам Шакировка хас иҗади затлылык хакында уйлана торгач, мәсьәләне беркадәре аңлаган төсле булдым. Халкыбызның дәүләтчелеге чәчәк аткан, барлык социаль катламнары исән булган чорларда аның элитасына хас затлылык сыйфатларының сибелеп, «төшеп калган орлыклары...» әллә ничә буыннар аша узып, янадан тишелеп, шытып чыгарга сәләтле икән! Димәк, затлылык дигән сыйфатның, күренешнең социаль-иҗтимагый алшартлары да барлыгы шик тудырмый. Табигать тарафыннан куәтле зиһен, хис сизгерлеге, ихтыяр көче бирелгән чакта ерак ата-бабаларыбызның асыл өлешләрендә булган күркәм сыйфатлар да янадан калкып чыгалар икән. Димәк, халкыбызның киләчәгенә өмет багларга, оптимистик күз белән карарга мөмкинлек бар икән әле!..

Рәис Даутовның табигый затлылыгы кешеләр белән гади көнкүреш шартларында, хәтта гаиләдәге көндәлек мөнәсәбәтләрендә дә чагылыш тапты. Кайберәүләргә, бәлкем, көлкелерәк, төчелек күренеше булып тоелуы ихтимал «Диләрәм—Рәисем» дуэтының да күркәм җыр сыман бөтен гомер буена үзгәрмичә саклануы, дәвам итүе дә әлеге сыйфатның бер гүзәл чагылышы иде.

Рәис Даутовның үзлегеннән укып зур белемгә ирешүе, рәсми рәвештә исем-дәрәҗәләр алмаса да (дөресрәге, алар артыннан йөрмәсә дә), җаваплы эшләрне чын галимнәрчә башкаруы, минемчә, аның анадан тума табигый талантка ия булуыннан килә. Ул—сүзнең чын мәгънәсендәге самородок галим булды.

Яна заман милли мәдәниятебез тарихына шул сыйфатлары белән кереп калды. Әгәр киләчәктә, халкыбыз нормальрәк шартларда гомер итә алса, әгәр милли филологиябез белемендә «әдәби истәлекләр текстологиясе» дигән бер махсус гыйльми тармак үсеп чыга алса, аның тарихы башында, һичшиксез, **«текстолог Р.Даутов»** катнашкан эшләрнең тәҗрибәсе үрнәк сыйфатында да, бәхәс объекты буларак та үз урынын алачак.

* * *

Рәис агайның йөрәге 28 августта тибүдән туктаган икән. Мин 29ында төштән соң гына Казанга кайткан идем. Иртәгесен «Ватаным Татарстан» гәзитен ачуга... башыма күсәк белән суккан төсле булды. Мин исә, моннан атна-ун көннәр элек үк, ул Займищедан кайткан булса, сәламәтлеге, кәефе мөмкинлек бирсә, янына барып чыгармын, язып яткан кайбер истәлекләрем өчен аның шәхси архивыннан фоторәсемнәр сорармын һәм, гомумән, киңәшеп тә алырмын дип план корып куйган идем...

Көне буе исәңгерәгән хәлдә, эшкә кул бармыйча уйланып йөрдем. Ичмасам, соңгы юлына озата барып, каберенә бер уч туфрак ташлый алмавым өчен көендем...

Беребез дә мәңгелек түгел. Кемнең кайчан китәсе дә бәндә ихтыярында түгел. Тик якын кешеләребезне соңгы урынына озату һәммәбезнең дә изге бурычы. Иң нәтиҗәле хезмәттәшлек иткән, һәрбер мәсьәлә буенча уртак фикердә булган, ихтирам кылышкан замандашыңны озата алмау бигрәк тә үкенечле икән.

Болай килеп чыгуның минем өчен (бары минем өчен генә!) унайлы ягы да бардыр, бәлки? Табутта ятуын күрмәгәч, мин аның кыяфәтен бары тере килеш кенә күзаллыйм. Әнә, тагын да бәләкәйләнебрәк калган Рәис Даутов, таягына таянган хәлдә, «Диләрәм»е янында елмаеп, минем килеп җитүемне көтеп тора...

Соңгы мәртәбә бер җеназада күрешкән идек...

Шулай уйланып утыра торгач, төнге уннарда өстәлдә яткан ак кәгазьгә «Затлылык үрнәге» дигән сүзләр төште.

Бөтен көн буена әйтелгән, язылган беренче сүзләрем...

Әйе, каберенә бер уч туфрак сала алмасам да, аңар булган ихтирамымны хушлашу сүзе рәвешендә булса да, тәфсилләп әйтергә, әйтеп калырга тиешмен. Хезмәтләре, аларның әһәмиятләре хакында да. Бу минем шәхси бурычым...

Аның якты истәлеге алдында гомум бурычларыбыз да бар безнең. (Исәннәрне генә түгел, үлгәннәрне дә олылау, кадерләү, аларның истәлекләрен саклау аркылы халкыбыз хәтерен дә гомерле итү культурасына өйрәнә башлыйсы иде!..) Ә бурычлар исә, минемчә, якынча түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

Иң элек Рәис Даутов хезмәтләренең, аларны төрләре буенча төркемләп, мөмкин кадәр тулы исемлеген—библиографиясен булдырасы иде. Мондый хезмәт бер Р.Даутов мирасын барлау өчен генә түгел, бәлки әдәбиятыбыз тарихының актуаль мәсьәләләрен ачыклау, моңарчы ирешелгән нәтиҗәләрдән, казанышлардан файдалану өчен дә яраклы булыр иде. Бу библиографик белешмә өчен, минемчә, кирәкле материаллар Рәис агайның үз архивында да билгеле күләмдә сакланган булырга тиеш. Мәсьәлә аларны кирәгенчә эшкәртеп, берәр журналдамы, җыентыктамы бастырып чыгаруга кайтып кала. Мондый эшне башкарырлык фәнни көчләр бездә җитәрлек дип ышанам.

Икенчедән, беренче теләкнең дәвамы буларак, Р.Даутовның шәхси архивын,—ул әкренләп сүтелеп, берәмләп тарала, югала башлаганчы (хосусый шартларда саклана торган шәхси архивларга яный торган уртак бәла бу)—мөмкин кадәр тулы килеш саклау тәэмин ителәчәк җиргә тапшыру. Теләгемнең бу өлешен мин беренче нәүбәттә мәрхүмнең җәмәгате мөхтәрәмә Диләрә ханымга адреслар идем. «Рәисемнең» мирасы, истәлеге гомерле булуын теләсәк...

Өченчедән, гомеренең соңгы көннәренә кадәр Рәис агайның татар әдипләре хакындагы белешмәнең яңа варианты өстендә эшләве, аны нигездә тәмамлавы мәгълүм. Ләкин нәшрият тарафыннанмы, язучылар берлеге ягыннанмы (монысын төгәл белмим), ул белешмәне үзгәртә төшү таләбе куелганлыгы да ишетелде. Хәзер инде мәрхүмгә шулай эшлисе иде, болай төзисе иде дип теләкләр әйтү дә, таләпләр кую да мөмкин түгел. Димәк, хезмәт ни рәвештә эшләнгән, шул хәлдә басылырга тиеш. Бу килеш ул белешмә авторның соңгы ихтыяры да, әдәби фикеребез тарихының билгеле бер вакыттагы «сурәте» дә булып калыр иде. Үз элгәргеләренең мирасларына карата һәм замандашларының иҗатларына ихтирам, тугрылык үрнәген күрсәткән Рәис Даутов мирасына карата да без шундый ук мөнәсәбәттә булырга тиешбез. Татарстан китап нәшрияты белән Язучылар берлеге бу мәсьәләдә гадел фикергә килер дип ышаныйк.

Ниһаять, дүртенчедән, мәрхүмнең истәлегенә бер җыентык та чыгарасы иде. Анда, мәсәлән, Р.Даутовның тәфсилле биографиясе, әсәрләре вә хезмәтләренең югарыда телгә алынган библиографиясе, шәхси архив материаллары хакында белешмә, кайбер мәкаләләре, аның хакта истәлек-мәкаләләр, фоторәсемнәр һ.б. булырга тиеш. Бөтен гомерен татар китабын чыгаруга, мирас истәлекләрен хәзерге укучыларга китап рәвешендә кайтаруга багышлаган әдәби фикеребез каһарманының шундый истәлек китабына хакы бардыр дип ышанам.

Изге бурычыбызны күмәкләшеп башкарсак иде.

Аяз Гыйләҗев

# ГОМЕРНЕҢ БЕР ЕЛЫ

КӨНДӘЛЕК СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

**3 февраль, көндезен.**

Нишләмәк кирәк, дөнья халыкларының байтагысына коммунистик аң сөреме сеңеп калган. Россия коммунистлары съездга әзерләнә, Румыниядә властька коммунистлар килү ихтималы бар...Тагын, тагын...Әйе, халыкның власть түмен татып бозылырга, азынырга өлгергән төзәлмәс өлеше үзгәреш чорына яратып кигән битлеген бүген сала. Салырга әзер. Ә түбәндә ятып калган тамагыннан бүтәнне кайгырта белмәгән күпчелеге каты кулны юксына. Хуҗа кирәк аларга! "Эт үзенә ничек итеп хуҗа эзләгән" дигән тунгус халык әкияте бар иде без яшь чакта. Хәзер заман, замана балалары үзләренә хуҗа эзли. Мин әллә дин борылыш ясарга булышырмы дигән идем, коммунистик астыртын көчләр дингә капка ачып тормыйлар әлегә. Мөфти хәзрәтне салып таптау да, асылда, кара көчләрнең касәфәте. Урыс чиркәвенең үз яшерен оешмалары—КГБсы,МВДсы, Хәрби разведкасы юк дип кем әйтә ала?! Алай ук беркатлы булмыйк инде! Чиркәү—илдәге иң куәтле, яшертен көчләрнең берсе... Бу—шиксез. Халыкларның коммунистик оҗмахка омтылуларын көннән-көн, атнадан-атнага көчәюен күреп хурланам. Күпчелек тагын коллыкны сайлый. Шакмакларга бүленгән, чәйнәп каптырылган деспотизм идеяләре халыкка аңлаешлы вә якын икән. Тарихны кабул итә алырлык аңнар бездә юк әле. Ничә кеше чыкты икән явызлар партиясеннән? Бармак белән санарлыктыр, мөгаен. Район башлыклары—тоташтан коммунистлар. Сызгыр гына... һәммәсе "туктатып кына торалар". Кайчанга кадәр? Шул көннәр килеп җиттеме әллә?.. Рәис "эт башын җиргә куеп йоклый, җир аша тавышларны , хәрәкәтне ишетеп тора", дигән иде...

Бүген төн буе дымлы кар яуды. Җепшек диярлек. Кан басымы үзгәрде, тәнне тотып торган мускуллар йомшады, күкрәк җебеде. Уйласаң да каһәр суккан коммунистлар хакында гына уйларлык!

**5 февраль, Иске Әлмәт.**

Ишә дымлы кар, ишә... Җил китерәме куе болытларны, болытлар тынмас вә армас тыгыз җилне ияртеп йөриме, ишә, кар ява. Баш очымдагы тәрәзәгә ял итәргә ирек бирми. Тәрәзә бер мине күзәтә, борылып ак бураннарның әзенә карый, ара-тирә җылап та җибәрә: эри кар, эри...Төнлә ишегалдына чыгып кердем, дөнья белән җил аша гына аралашып, җилне тыңлап, уйларыңны җилгә генә сөйләп яту рәхәт. Бу тирәдә әле дөнья тыныч, ил сабыр, тамак тук. Әле Иске Әлмәт карчыклары казлар сыман тезелешеп ашка йөриләр, корьән чыга белгән абыстайларны түргә утыртып, дөнья хәбәрләрен сөйләшәләр, аллага вә әҗәлләренә якынаялар. Күңелләре тыныч диндарларның, аларны Иблис мәлгуньнән иңгән вәсвәсәләр борчымый, догалы күңелләренә йон тәпиле шайтаннар сыймый...

Язны агач бөреләре һәм кызлар әүвәл башлап сизә дип язганым бар. Белеп бетермәгәнмен, монда торганда гына искәрдем:язны Римны саклап калган сизгер казлар сизенә икән. Моңарчы, февральгә кергәнче, ишегалларында казлар барын белмичәрәк йөри идем, хә-ә-әзер!.. Аннан да, моннан да, ерак иха-

*Дәвамы. Башы 1нче санда.*

талардан ук ата казларның гайрәтле, егетләрчә аваз салганы ишетелә. Һәм бу язгы мәхәббәт авазлары торган саен көчлерәк яңгырый. Авыл тирәсендәге бөтен гадәти авазларны, тавышларны уздырып кычкыра казлар. Үзара сөйләшәләрме, җәй көне танышып, бергә-бергә инеш ярларында чирәм капкалап, сакчы күрмәгәндә яшькелт уҗым кыяклары белән сыйланып йөргән ахирәтләренә дәшәләрме, белмим. Илләгә мәгәр алар әлегә ябуда, араннарда, лапас асларында. Хәзер мин дә аларга сәлам биреп йөрим, авылда танышлар артты, "саумысез, казлар!" Ата казга сәлам бирмичә йөрсәң муеныңа кыярык чыга, диләр татарлар.

"Буран" дибез, юри генә зарланабыз да, ә илләрдә әллә ниләр бар. Колски ярымутравында штормнар, һәлакәт, шәһәр-авыллар утсыз-сусыз калды, атом-электростанциясен туктатырга мәҗбүр булдылар. Кабарда-Балкарда һәлакәт арты һәлакәт. Таулардан кар ташкыны төшә, автобуслар, машиналар кар асты төрмәләрендә калалар, кешеләр үлә. Тарлавыклардагы кар катламнарын күрсәтәләр... ай-һай, анда миллион сумнар давылларда оча, монда миллионнар кар астында кала.

Кичә Заирда биш миллион сумлык купюраларны күрсәттеләр. Ул җәһәттән бездән алда илләр бар икән! Әллә Рәчәй рекордчы булдымы дип йөри идем. Безгә дә килеп җитмәсме ул биш миллионлык кәгазьләр?..

Утырам—уйлыйм, ятам—уйлыйм. Уем берәүгә дә кирәк түгел, уйларымнан берәүгә дә юаныч яки куаныч юк, уйларым белән бер башым, үзем генә юанам. Кәгазьләремнең язган кадәресен кайтып укырга куркам... Кемгә кирәк алтмыш биш яшьлек картның казынулары? Гомумән, татар әдәбиятына мохтаҗлык калдымыни?.. Менә бүген Сарман урта мәктәбендә очрашу булачак. Машина килгәнне көтеп торам. Сарман мәктәбендә татар әдәбиятының тәэсире калганмы?.. Ай-һай... Дөрес, мондый шикчел уйларга баш бирергә ярамый... Алар башны ук алып китсә, ничек яшәмәк кирәк? Ничек?!

**6 февраль, Иске Әлмәт.**

Әлмәттә Мулли исемле туксан яшьлек карчык яши. Хас исеме Мөгаллимә. Гомере буе ялгыз, кызлыгын саклаган хәлдә гел ир-ат арасында уралды. Сарык асрады—көтүгә кумады, сарыклар үзләре чыгып, үзләре кайтып йөрде. Сарыгын суйдырмады, быел чыккан каз бәбкәләре икенче елга да кала килде. Нык эчте, аракыны стаканга салгач, "айнымасын" өчен стаканның авызын учы белән каплады. Тост әйтергә ратты. Хәтере шәп, әле искене, корьән аятләрен дә белә, шаулатып укый.

***

—Зиһеннең ныклыгы юк, әнә, догаларны гәҗит-журналларда гел чыгарып торалар, биклэп кенә булмый. (Биклэп—ятлапның нинди матур формасы!) Без сәвит карчыклары шул инде, күп нәрсәдән мәхрүм ителгән.

***

**8 февраль, Иске Әлмәт.**

...Фәнҗияләр "Ватаным Татарстан" гәҗитен алдыралар. Ул январь номерларын җыеп төшерде, куана-куана алып калган идем... юк, валлаһи дип әйтәм, газеталар мине ырлаталар гына! Күпләрнең җүләрлеген, ахмаклыгын күреп, тешемне кысып, утны тышка чыгармыйча яшәргә тырышам... ә гәҗитләр ахмакларның, татар җүләрләренең фикерләрен хуплап, һичбер аңлатмаларсыз халык арасында тараталар. "Маркиз оф Туран"—академик Әбрар Кәримуллинның куркыныч бер мәкаләсе[1] элегерәк басылып мине чын хафага салган иде. Юк бит шундый мәкаләләргә акыллы каршы төшүче дисәм, 22 нче гыйнварда Әмирхан Еникинең зур мәкаләсе басылган икән. Колак салучылар, уйланучылар табылырмы, мәгәр "Кем хаклы?» дигән мәкаләсендә Әмирхан ага тарих менгергән югарылыгыннан тагын бер тапкыр татар халкына эндәшеп карый. Сүзләре хак, хафалары урынлы, ул татарларны канлы бәрелешләрдән аралап алып калырга тырыша. Әлбәттә, бер генә дәүләт тә Россия белән арасын бозу бәрабәренә Татарстанның суверенлыгын тану юлына кермәячәк. Әлбәттә,

[1] Аяз ага катлаулы мәсьәләгә үз мөнәсәбәтен чагылдырган. Ред.

хәзер һәм алда да без Россия белән татулык шартларында гына яши алачакбыз. Моңа Татарстанның географик урыны да, җөмһүрияттән читтә яшәүче биш миллион татарның урыс дәүләтендә тозакта, биктә яшәве дә мәҗбүр итә. Нишлисең, татарның иле булса да, күпчелек халкы үз ватаннарыннан читтә яши... Бер генә нәрсәне әйтми Әмирхан ага: бүгенге көнгә җиде миллион татар—миф. Татарстанда, Казанда чын татарлар калмаганда, мәркәзебез татарлары бүгенге шартларда "ямаулы татарларга" әйләнгәндә, ерактагылар никадәр җитез кыланган булып маташсалар да кардәшләребез татарларны татар иткән сыйфатларын күптән югалтканнар, телләрен онытканнар. Әйе, өметне суытмыйк, бәлки татар канындагы татарлык генналары уянып, хәрәкәтләнеп, кемнәрдер аңга килер, әмма бүген аларга йөз тоту, татар язмышын алар кулына тапшыру—балачагалык, беркатлы ахмаклык. "Иттифак—халык партиясе ул" дию, әйбәт сүз яңгырату әйбәт, әмма... Әмирхан ага деликатный кеше, ул "Маркиз оф Туран"га да, партия кадәр партия рәисе Фәүзия Бәйрәмовага да каты бәрелми, салмак кына селкетеп, урыннарына утырта...

Бу көннәр бушка үтте. Романдагы "Татарлар" дигән мөһим бүлек язылмады. Аны бетереп кайтырмын дигән идем. Әле Әхмәтзыяның хатын архив папкаларыннан эзләп табасы бар. Ул бик мөһим, минем үткәннәремә төс бирә алырлык кадерле хат. Исән-аман кайтып егылсам беренче эшем шул.

3 февраль санында Газим абый Салиховның[1] мәкаләсе басылган. Безнең өчебезне телгә ала... Фроловны язып китүе гыйбрәтле. Чахотка белән авырган икән, бичара. Монысын белми идем... Миңа да бу фактны искә алып китү кирәктер...

**9 февраль 1993 ел, Иске Әлмәт.**

Монда соңгы көн, соңгы иртә. Салкын! Көн миннән разый түгелме, ач февраль җиле үпкәләдеме, төне буе сузып-сузып ыңгырашты. Кичә колхоз рәисе Нәҗиптән: "Авылда иң фәкыйрь кеше кемнәр? Һәм нигә алар фәкыйрь?" дип сорадым. "Бикмәттән берәү шактый вакыт зимагурлыкта йөри... Ахыр чик урыс марҗасына өйләнеп, үз авылына түгел, безгә, Әлмәткә кайтып төпләнә. Бәләкәй генә өе бар, сыеры, хатыны... Хатын димәссең, безнең басуларда чөгендерләр дә дәүрәк була хәзер. Ике баласы бар... Хәлләрен белешергә дип кердем. Отчет якынлаша. Сорау бирүләре ихтимал. Бер баласы яшь ярымлык, икенчесе яңа туган... Сөт шешәсеннән чак кына олырак... Шушы арада гына иренә карабодай ярмасы, егерме кило шикәр яздырып биргән идем. Сорыйм, "шикәрегез бармы?", "юк", ди... Ире егерме кило шикәрне исерек баштан бер яртыга биреп җибәргән. "Ни ашыйсыз соң сез?", дим... "Менә, ярма бар", ди... Чын ярлылар, мөгаен, шулар калгандыр".

**11 март 1993 ел, Түбән Кама.**

Һич истә-оста югында Кама ярына килеп утырдым бит, әй! Күптәнге дустым Рәшит Вәлиевич Абдулхәкимов "ял итәргә, эшләргә безнең якларга кил, урнаштырам!" дип кыстап йөри иде, тәвәккәлләдем!.. Кичә иртәнге автобус белән сәфәр чыктым. Көн матур, юл һәйбәт, очабыз гына! Рәшит Вәлиевич каршылады, выжлатып кына санаторий-профилакторийга китереп җиткерде. Авыл хуҗалыгы эшчәннәре-крестьяннар өчен нәкъ крестьянча ашык-пошык салынган өч катлы йорт икән. Ишек ярыкларыннан үтә-сүтә пәри малайлары шуып кереп йөрерлек, иддәннәре шикле пычрак, бәдрәф идәнендә башмак табаннары ябыша, кай почмакка карасаң да котсызлык, хуҗасызлык. Кат-кат басып, туктаусыз йодрык белән төйгәч кенә ут кабына, розеткалар эшләми, чәй кайнатыр өчен бүлмәдән-бүлмәгә чабып йөрисе, иң хәтәре—сап-салкын. Калын юрган астында йоклаганда әлләни сизелмәгән суык, урыннан калкуга кочып кына алды! Брр! Калтырата каһәр! Өстәмә җылыткыч куя алсак ярар да... Көндез һәйбәт кенә ашатканнар иде. Кич манный боткасы белән сап-салкын омлет бирделәр. Җирле баш врач Илбек Садыйкович Мөхәммәтҗанов дигән урта яшьләрдәге ир икән, Урта Азия тумасы, татарны белми диярлек. "Язучы" дигәч шүрәле күргәндәй булды, әллә инде татар әдәбиятының барлыгын ишеткәне дә бул-

---

[1] Г. Салихов—1950 елны А. Гыйләҗевтән дә, Г. Тавлиннан да сорау алуда катнашкан КГБ хезмәткәре. Ул аларның икесеннән дә әйбәт тәэсир калдырган. Ред.

маганмы? Сәер кеше. "Массаж бездә һәйбәт!" дип сөендерде. Тоташтан сызлаган кулларыма әз-мәз шифа, савыгу таба алсам ни куаныч булыр иде дә!..

**13 март, 1993 ел.**

Шактый салкын бүлмәмдә калын юрганга җылы тәнемне тапшырып монда өч төн үткәрдем. Алданучан тәүге тәэсирләр онытылып мондагы тормыш чынлыгына кереп киткәч "яшәргә була!" дигән фикергә килдем. (...дигәч снос белән аска кулдан язып куйган: "Хата фикер булган! Нык ялгышканмын." Бу санаторий-профилакторийдан Рәшит Вәлиевич Аязны ялын туктатып, Казанга китереп куйган иде. Аязның чырае зәңгәрләнеп күгәргән, мин каршы алырга төшкәч, калтырап-куркып калган идем. Кочкә-кочкә култыклап өйгә алып мендем. Авыруы көчәеп кайтты аның аннан. Минем дә гаебем булгандыр дип саныйм. Рәшит Вәлиевичтан аны әзрәк ялга урнаштырып алуын үтенгән идем. Чөнки ул елларда безнең көймә шактый нык комга терәлгән иде. Өйдә кысанлык: балачагалар фатирларына урнашып җитмәгән, каядыр барырга юллама алыр өчен акчабыз юк. Үзем көне-төне эшлим. Аязны ныклы күзәтү астында тота алмыйм. Ничек ярдәм итәргә белмәү чарасызлыгымнан бәргәләнгәнмендер инде. Н.)

Телевидениедән Хәйдәр шалтыратты. Зәй егете, якташ.

—"Язучы фикере" дигән рубриканы дәвам итәбез, яшәтәбез, Аяз абый. Хәзерге катлаулы заманда сезнең фикерне ишетәсе килә...

Чак егылып китмәдем: нинди фикер? Кемгә кирәк бүген язучы фикере? Кемнәр мохтаҗ аңа? Хәзер һәр адәм заманча философ, заманны узып алга китә алган акыл иясе... Җәмгыятьнең иң мескен, иң фәкыйрь, өлешсез вә киләчәксез калган төркеме әдипләр, сәнгать әһелләре. Шушы факт кына да аларның бүгенге көрәш сызыгыннан читкә тибәрелгән төркем икәнен күрсәтә. Күпчелек фикри адашулар арасында бутала... Дөнья буталган, асты өскә, өсте аска килгән. Бер авыздан да өметле, ышанычлы сүзләр, якты фаразлар чыга алмый, дөнья авызларны печәтләде, аннан бары тик зар-моң авазлары, бөтен Рәчәй милләтләрен берләштергән сүгенү сүзләре генә чыга ала...

***

Туктадым да бер ноктага карап онытылып торам. Ни булды? Аңламыйм. Ә-ә, тыкрык башындагы йорт ишегалдында балалар татарча сөйләшеп уйныйлар икән! Йа хода, мондый гүзәл манзаралар да бар икән әле дөньяда. Быел Мулиле авылына кайткан идек. Матур халык яши анда, кунакчыл, игътибарлы, кече күңелле... Ишегалларында балалар... бөтенесе урысча сөйләшәләр. Ил шәһәрләреннән ял итәргә кайткан татар балалары... Татар дип... Дамир Гарифуллин сөйләгән иде. Бер бала каладан кайткан ди,теттереп урысча да, татарча да сөйләшә икән. Авыл малае өенә кайткач шаккатып әтисенә сөйли икән: "Әти, әти, урысча белгән башы белән ничек оялмыйча татарча сөйләшә икән ул?"

**7 октябрь. 1993 ел.**

Йа, ходай! Күктә кояш та бар икән әле! Булгандыр, алтмыш алтынчы ел яшәп мондый мәрхәмәтсез көзләрне дә күргән бардыр... Аерма шунда гына:элгәрге ямьсез көзләр, авыр-дымлы һавалар, суга туксырган авыр җилләр мин яшьрәк чакта килеп-киткәннәрдер. Хәзер исә, гәүдә талкынган, аяклар авыр, тез буыннары сызлый—диабет сиздерә. Йокыдан торасың, әллә ял иткәнсең, әллә юк—йокыда чакта да шайтан сиңа йөк ташыткан, таш ваклаткан, балчык төяткән кебек. Рәхәтләнеп киерелеп тә булмый! Йөрисең шунда танавыңны тартып... Ниһаять, өч ел дәвамында мине хатирәләр белән тыгызлап торган, зиһенне тәмам биләгән, акылны яулап алган хатирәләр романы—"Йөгез, бер дога!" тәмам. Бишесендә мин аның соңгы сәхифәләрен журналга илтеп бирдем. Алдагы бүлекләр журналның унынчы санында басылып та ята. "Куанырмын, очыпочып йөрермен!" дип әсәрнең очын өзелеп көтсәм дә... юк, күңелгә нинди дер ят авырлык ишелеп төште. Өч ел! Ничәмә-ничә тапкыр мин әсәр бүлекләрен юлда йөргәннәрдә күңелем тирәнлегендә суздым, онытылган өлешләрне ялгадым, төн ката аерым-аерым вакыйгаларны хәтеремнән уятып, иртән сикереп торып яза башладым. Төн урталарында сердәшем машинкага ялварып сәхифәләрне теркәп-теркәп куйдым. Атналар буе кулымнан эш төшеп китеп газапландым.

Хәтта, язын, апрель аенда һич истә-оста югында романны ташлап торып "Уналты яшь" дигән хикәя дә язып алдым...

Өч ел! Шушы елларда ничаклы бәндәләр җанымда казынды. Гәзитләрне ачарга курка башладым... Туктаусыз яуган гайбәтләргә, өзлексез чыккан монафыйкларга җавабым бер—шушы романым. Мин монда җанымның властьларга, системага, күргән нужаларыма бирешмәвен, сау калуын бәян иттем. Китапта телгә алынган бер вакыйга да, күңелемнең давыллы диңгезләрендә һаман-һаман саклана торган бер генә кеше дә уйлап чыгарылмаган. Дөрес, адәм балаларының мәсләген, иманын ача торган фактларга дәлилләрне мин китаплардан, гәзит-журналлардан да эзләп алдым. Чөнки юлдашларымның төп фикер юнәлеше хәтеремдә булса да аларны укучыма җиткерү өчен байтак казынырга, эзләнергә туры килде.

Җанымны җылыткан, җанымны баеткан, ныгып җитмәгән иманыма тугры калырга булышкан тоткын-зекләргә үтә рәхмәтлемен! Сезнең затлы исемнәрегезне татар әдәбиятында булса да беркетеп калуыма сөенәм. Өч ел! Өч ел мин ал-ял күрмәдем. Быел хәтта Идел буйларына барып ял да итә алмадым. Ике тапкыр гына су кердем. Шуның нәтиҗәсеме, аякларым сызлый, баскычтан менгәндә уфылдыйм, баскычтан төшкәндә култыксаларга яки дусларымның иңенә ябышам. Ял кирәк, хәрәкәт кирәк. Ничәмә-ничә битләр басып, аларын ыргытып бәреп, яңадан эшкә керешмәдем мин!..

**14 октябрь, 1993 ел.**

Бүген сәфәр чыгам, Переделкинога. Былтыр да нәкъ шушы көннәрдә китеп, ике срок торып кайткан идем. Бер ел эчендә шактый зур аерма:көчем әз,кулаяклар сызлый, хәтер саеккан, бүтән якларда да җәрәхәтләр, яралар сизелә, ел эчендә адәм баласы үзгәрсә дә үзгәрә икән! Бер куанычым бар:роман-хатирәне язып тәмамлап журналга тапшырдым. Унынчы санда басылып чыгып та килә. Өч еллык газаплы хезмәтне артта калдырып барам бу юлы иҗат йортына...

**17 октябрь, 1993 ел, Переделкино. Иртә.**

Унбишендә килеп төштем, 107 бүлмәгә җайлы гына урнаштым. Мин үзгәрәм, күзәнәкләр ашыга-ашыга алмашыналар, дөнья да тик тормый: чайкала, болгана, тоташтан бурый. Аста, төптә ятканнар күбеккә әверелеп өскә калкалар, күзне камаштырып сукырайталар. Барчабызга тавык күзе булды, көндезләрен дә эңгер-меңгер сыман, аерып булмый...

Ямиль Мостафин каршы алды, шактый авыр чемоданнарны сөйрәп Казан вокзалыннан Киев станцасына кадәр җир аслый үтү җиңел булмас иде. Болай да пешеп-янып, манма су булып, гыжылдап, тырык-тырык барып җиттек. Ямиль дә "водоворот"ка, аның да суырып йота торган уртасына эләккән, секунд та тик тора алмый. Сөйли, үгетли, сүзләренә иярмәсәң үпкәли. Ельцинны адәм тәгәнәсенә чыгарып каһәрли, демократ исемен алучыларның тетмәсен тетә, яһүдләрне сүгә. "Шулар җитте Рәсәй башына". Ике сүзнең берендә Хасбулатовны мактый. Аныңча Руслан Имранович чат фәрештә булган икән! Ул "акыллы", "әзерлекле", "белемле", "үз юлында нык торучы шәхес", "ул сөйкемле", "әнкәсе белән бергә төшкән фотосын күрдем, булса да булыр икән сылу ир!" "Лидер, эрудит!" Коммунистик режимны үлеп сагына Ямиль. "Менә әйтеп кара:Ельцин күпме тапкыр вәгъдәләр бирде, халыкны ышандырды. Әйткән бер-бер сүзен үтәдеме?" Җылымса сүзләре белән генә мине үз ягына дүндерә алмагач, акчасын җәлләми, кочагы-кочагы белән гәҗитләр күтәреп кәрә. Көн аралаш, ашавын, эшен онытып Мәскәүгә чаба, фикердәшләре аны минут саен телефонга чакырып торалар... Иҗат йортында да аның тоткан юлын беләләр, хуҗалык эшендәге марҗалар, урыс-улак еш кына аңа мөрәҗәгать итә, аның белән янәшә күреп мине дә аның белән теләктәш дип беләләр. Егерме-егерме биш ел авызыннан сүзе чыкмаган ишек төбен саклаучы Лида да мине әгъвәли: "Яһүдләр генә гаепле. Рәсәйне шулар сата! Өченче-дүртенче октябрьләрдә, фетнә көннәрендә аларны карап тору кызык иде! Йорттан читтә, аулакта җыелырга сүз берләшәләр, унар-унбишәр кеше түгәрәк булып басалар да шыпырт кына сөйләшәләр. "Нишләргә? Качаргамы, калыргамы?" диләр бугай... Бу Переделкино иҗат йортын да үзләре өчен салдырдылар бит жидлар...Бушлай киләләр, бушка карт-корыларын, бала-чагаларын китерәләр. Алар өчен оҗмах иде бу! Кызга-

ныч, койрыкларына баса алмадылар". Сәясәттән бөтенләй читтә булганнарны да талаш-ызгыш мәйданнары уртасына өерләп кертте бу октябрь ае. Бөтен халык эшен ташлап, кешелек бурычларын онытып, белер-белмәс көйгә, сәясәт арбасына җигелеп чаба башлый икән—революция әнә шул инде ул.

Иртән, яктырганчы ук әз-мәз эшне кузгатып карадым. Ашыкмый, теркелди. Литвин белән уйланган повестька тотындым. Өйдә чакта исәп биреп бетермәгәнмен: тагын төрмә темасына ябышканмын икән! Хәерле булсын: Литвин тынгы бирми, көчләп яздырачак. Эшсез, мазасыз бер көн дә тора алмый бичара!

"Рабочая трибуна", "Независимая газета", мәшһүр генерал Лебедь мәкаләсе басылган "Лит. Россия", "Ком. правда"ның шимбә саны—үзе бер калын том. Соңгы елда гәҗит-журналларга игътибарымны нык киметтем, вакыт җиткереп тә булмады, сәмән ягы да касыкка өзмәс тӧрткәләп торды. Ни әйтсәң дә, кайсы почмакларга карап башырсаң да акча хуҗа!

Гәҗитләр кыю, Яңа Октябрь вакыйгаларына капма-каршы бәяләр биреп дөреслекне йон йомгак эченә яшерәләр. Йомгакның җеп очын эзләп таба алсаң да кайчан сүтеп бетерәсең әле аны!.. Станислав Говорухинның сугышчан отрядлар җыйнап, ашыгыч рәвештә Ельцин тарафдарларына каршы барырга өндәвен бер яклырак кабул итеп аңлаган идем. Электә коммунистик режимга ачыктан-ачык каршы төшкән, шул какшамас якты иманнары өчен мин яратып өлгергән, югары күтәреп йөргән кайбер шәхесләр дә бу чуалыш сәгатьләрендә Ельцинның гамәлләрен гафу ителмәслек явызлык дип бәяләгәннәр икән!

Станислав Говорухин исә бу дәһшәтле көннәрне "Россияне атып үтерү" дип бәяли. "Россиядә каһәрле көннәр башланды", дип тәмамлый ул "Известия" газетасындагы мәкаләсен.

Әйе, без—Сталин чоры балалары, Руцкой-Хасбулатовларны "атып үтереп кенә илне коткарып була!" дип санаган, аларга әҗәл-үлем теләп, кесәдәге йодрыкларны йомарлаганда...кешеләр тирәннәнрәк тә уйлаганнар икән! Синявский, Максимовлар да бер сүздә булып Ельцин гамәлләрен "ирекне буу!" дип бәяләделәр. Бу очракта мин тагын беркатлылык күрсәттемме? Кабат ялгыштыммы? Ельцин кай ягы белән "алдырды"соң?.. Беренче нәүбәттә ул коммунистлар партиясеннән чыкты. Икенчедән, ул җаһиллар партиясен таратты. Дөрес, таратуы азакка кадәр үк барып җитмәде, алай да, үз вакытында бу карар, тарату нияте миңа рух өстәгән иде.

Дөрес, гәҗитләрдә бара торган тартышлар, ызгышлар, телдән-телгә җиңел күчеп йөргән уйдырмалар уемнан какшата алмадылар, мәгәр Мәскәү мохитына барып кереп, йөк-йөк хәбәрләр төягән гәҗитләрне күзәткәннән соң, җанымда нидер кителде. Адәм җаннарын кыймыйча гына фашистик оппозициядән арынып булмас идемени?.. Безнең аңнар да шулай итеп канга сусаган булып чыктымы?.. Әллә ленинизм идеяләренең йогышыннан кан кою белән генә котылып буламы?

Быелгы 3-4 октябрьдән соң кемнәрдер тагын үзгәрәләр, көнгә-сәгатькә кулай битлекләр киеп алалар, андыйларның запас битлекләре бер чакта да үзләреннән калмый, әзер тора, мәгәр бер нәрсә ап-ачык:акыллы адәмнәрнең байтагы Ельциннан һич канәгать түгел! Мондый шик-шөбһәләр көннән-көн арта икән... ил башына Зюганов, Сажи Умалатова, Аман Тулеев менеп атланмасмы? Әйе, әйе, акыл дилбегәсен кулдан ычкындырырга да, җебеп калырга да ярамый. Руслан Хасбулатов булдымы Ил башы? Ничә айлар безнең өскә салкын сүзләр койган буш бугаз! Күз алдыбызда сансыз-исәпсез мәртәбә бездән—гади кешеләрдән мәсхәрәләп көлгән җирбит! Брежнев комсызга атап салынган 500 кв. метрлы зиннәтле әкияти сарайга бәгрәеп кереп утырды. Туксан проценты илне имеп күзләрен кан баскан коммунистлардан укмашкан парламентны тәмам котыртып җиткерде чечен-бандит!..

Болар хакында инде уйламам, чукынып китсен парламенты, чәнчелсен депутатлары, үз йөгем карт иңнәремә җитеп ашкан дип, гамьсезлеккә кул биреп килгән идем, Ямиль ишләре—коткы таратучылар соңгы юк хәлне ала. Кем өчен тырыша Мостафин? Аның татар-башкорттан җәяүләп качканын урыс-улак белмиме? Ни исньнә ул минем тирәдә? Бу юлы тагын бер соравы сагайтты: "Яшьләр арасыннан кемнәр Нурихан Фәттах янына барып йөри?" дип сорады. Юкка тыкшыну түгел бу, әй, юкка имәс! Нурихан белән кызыксынмыйлардыр, иллә мәгәр яшьләрнең эченә керәселәре килә! "Белмим, ишеткәнем юк, үзем

Нурихан белән ныклап аралашып яшәмим!" дип кырт кистем.

Мин тагын монда. Былтыр "Йөгез, бер дога!" белән җенләнеп ята идем. Быел роман журналда басылып чыгып килә. Куен дәфтәремә: "1 ноябрь, 1991 ел. Переделкинога килеп урнаштым, 114 бүлмәгә. "Йөгез, бер дога!"ны язарга исәп. Озаккарак сузылды", дип теркәп куйганмын. Аңа кадәр үк яза, материаллар туплый башлаган идем, 91дә бүтән эшләремне читкә куеп "дога" укырга керештем. "Коръән" белән генә ярты ел утырдым!..Тәңремә рәхмәт, ниһаять, быел ул эштән котылдым. Моның кадәр дә газапланганым, бәргәләнгәнем, җан талатканым, шушы чаклы интектергән, җан талаган әсәрем юк иде шикелле. Авыр язылды, инде алдагы бүлекләр тәмам дип исәпләгәндә дә романның ахыргы дип исәпләнгән өлеше юк иде әле. Азак хәзер дә канәгатьләндерми, ни эзләнеп, ни төпченеп, казынып, ахыргы фикерләремне югары, көчле тавыш белән күк күкрәтеп әйтеп бирә алмадым. Мондый рәвештә китап шартлап, дөньяны сискәндереп бетәргә тиеш иде дә, әлләни көчем җитмәде, фикерләр көпшәкләнде, сүзләр, рәткә тезеп утырткан домино шакмакларыдай авып таралдылар. Китап итеп әзерләгәндә актыкы күләмне яңадан ермачламый ярамас...

Рәшатлар июль-августта гына күченделәр. Инде "чыгып киттеләр, Аллаһы Тәгалә юлдашлары булсын!" дип дога кылырга өлгермәдек, иртәгесен Чаллыярдан туганнан туган тумачабыз—врач Лиюзә килеп җиткән. Кызын иярткән... Ниһаять, ул тулай торакка урнаштырылды. Рәшатның тау-тау мал-мөлкәте дә кимеде, тәрәзәләрдән тыш күренде, өй эченә август кояшы үтеп керде. Мин инде мин!.. Бүксәмне киереп машинкам-чытыр арбага ябыштым. Көн тукылдыйм, ике көн гамьсез генә үтә, өченче көнне аста, икенче катыбызда ниндидер ят хәрәкәт башланды. Тавышларның ниндие генә юк! Ватылып, туктап калган ЧТЗ тракторын баулар тагып каядыр сөйриләрмени?! Ачыкланды: астагы өч бүлмәдә яшәүче аңсыз-моңсыз хөрәсәннәрне, һәркаюсына аерым бүлмәләр биреп моннан чыгарганнар да, астагы фатирга төзелеш идарәсе башлыгының улы күчеп килә икән! Төшәрдән элек квартирга ремонт ясыйлар да бу олы эшкә миллион ярым акча тәгаенләнгән икән. Мин, татарның бичара әдибе, роман тәмамлап утырам, ә астагы катта кыямәт ишеген ачтылар. Кырык биш көн дәвамында, һични арттырмыйм, мин Тын океанның иң хәтәр дулкыннары бәргәләнгән ноктада "менә батам, менә батам!" дип салда йөздем. Мин өч-дүрт чәрексез бүрәнәләрне черек бау белән аркылы-торкылы бәйләгән салда йөзәм, ә астымда... җимерделәр, ваттылар, кузгаттылар, шудырдылар, эшерделәр, кистеләр, ташыдылар, кырдылар, ышкыдылар, таптадылар, төйделәр, кактылар, суктылар, чүкеделәр... Йөк машиналары тыз-быз килә-китә тордылар, куна җилкәле, дымлы кызгылт күзле, тырма куллы яшькелт бушлатлар астан-өскә чабып кына йөрделәр. Иртәдән кичкә кадәр тоташ гөрелте, Рафаэль Төхфәтуллин мактаган "таныш гөрелте" түгел, шайтаннар туе, иблисләр бәйрәме, аждаһалар җыены! Мин исә утырам, күңелем түреннән көр-изге гамәлләр эзләп, онытылганнарны хәтергә чакырып, татар тарихында калырлык "кыйссалар" язып утырам. Түздем, телне тешләп. Тел очымны чәйнәп бетердем, тешләремне шытырдатып кыса-кыса чәрдәкләп вакладым, йөзем сулды, колагым ишетмәс, күзләрем күрмәс булды...

Переделкинога чыгып китәрлек ихтыяр көчем калмады. Нәкыя кыстап, үгетләп юлга чыгарып җибәрмәсә, өненнән көнгә чыгарга өнәмәгән карт аю хәлендә, караватта аунап ятасы идем. Юлга чыгар алдыннан җентекләп карыйм: мүкләнә башлаганмын, валлаһи! Моңарчы яшәешемдә гел бер тәртип булды: өзгәләнеп-хурланып Казанда яшим-яшим дә, дөнья бәҗрәсы тынымны кысып буа башлагач чыгып таям, дөньяның шушы бәрәкәтле, юмарт почмагына килеп җитеп егылам. Октябрь айларында гел монда булам диярлек.

Переделкино яфракларының коелганын яратам мин! Гайрәт белән агачларны аралап килеп җиткән көзге җилләрен сагынып киләм бу төбәкнең! Тәрәз пыялаларының рәхәт салкынлыгына пеләшләнә башлаган кайнар маңгаемны терәп, өермә булып тузгыган сары буран ташкынына озак-озак карап торам. Көнне камаган давыл белән күкрәктәге ярсу хисләр бер-берсен эзләп табалар да мине өерләп-җиңеләйтеп күккә ашыралар. Кайный-кайный яфрак бураннар тузгыта көзге урман!

Быел соңгарак калганмын, урманнар тоташ шәрәләнгән, сукмакларга калын-

калын биелгы юрганнар түшәлгән. Яфраксыз калган шыр урман тавышларны төрле якларга тигез тарата. Быел, октябрь орышларыннан соң, тирә-яктагы тавышлар да үзгә, бүтәнчә яңгырый. Ике-өч кеше гөр-гөр килеп ашханә верандасының түбәсен ямыйлар—кеше тавышлары пулемет тырылдагандай була. Берәвесе төчкерсә—янда гына мина ярылгандай яңгырый. Борын сеңгерсәләр—бомба төштеме әллә, дип куркып торасың. Дөнья алмашынганда тавышлар да тиз-тиз үзгәрә.

Кичә-бүген ихата эчендәге борма сукмаклардан җил-җил йөрим, тынычлык зарыккан күңел киңәя, куана, инде ниятләп килгән эшне дә беркадәр алга җибәрә алсам...

"Казан утлары"ның 10 нчы саны укучы кулына барып җиткәндер. Йөзләрчә күзләрнең нуры роман-хатирәм юлларына түгелгәндер. Миннән башка моны беркем дә сизмәде, сизә алмады, мин "Балта кем кулында?" романын язып, бертөрлелеккә, бер катлы фикерләргә күнеккән стандарт татар укучысын үземнән читләштердем. Барлы-юклы әдәби хәрәкәт, укучыдан чак кына алдарак барырга тиешле әдәби тәнкыйть үз вазифасын—әдәбият белән укучы арасын яктыртуны үтәмәде. Роман тәнкыйтьчеләр йөргән быкырдык инештән югарырак иде шул. "Балта...", "Яра" повесте белән бер тышлыкта басылды. "Яра" повесте турында һаман сүз өзелми, әмма уй-фикер "Балта..."га барып җитә алмый. А. И. Солженицынның "Один день Ивана Денисовича" "Новый мир"да басылып илгә таралгач Ил Саттаров аны күтәреп алды, нигезле, әтрафлы, дәлилле гыйльми мәкалә язып Мәскәүгә җибәрде. Ул арада Александр Исаевичны чукый башладылар. Язганы югары дәрәҗәдә булса да дөнья күрмәде. Илнең гадәти булмаган фикерләү рәвеше, автор күңеленең чоңгылларына төшә алуы мине нык сокландырган иде. Яшерен өметләр белән мин аңа "Балта..."ны тәкъдим итеп карадым. Үз бәямне яшермәдем: "бүгенге көндә татар прозасында мондый югары дәрәҗәдәге әсәр юк", дидем. Озак укыды ул романны, ярты еллар үткәч бер очрашып, сүрән генә гәпләшеп тә алдык. Солженицынны аңы вә җаны белән яраткан егет минем әсәрне кабул итмәде шикелле. Инде ул да йөз чиергәч минем дә әсәргә мөнәсәбәтем үзгәрде... "Китабым хак бәя ала алмады", дип кыйналмыйм. Инде "Йәгез, бер дога!" да укучы күңеленә юл сала алмаса... Ни уйлармын?.. "Халкым белән бер арбага җигелеп бара алмадым, уф Алла!"—дип өметсезлеккә бирелүем бик ихтимал. "Балта кем кулында?"ны урысча чыгарып булмады, урысның зыялылары арасыннан әсәрне якын итәрлек адәмнәр табылыр да иде. "Кызлар хатлары" урысча басылып чыккач мәктәп балаларыннан ниндиен хатлар алмадым мин! Урыс ишле халык шул, балалары арасында әдәбиятны зәвык белән кабул итүчеләр бар, әзерлеклеләр күп. Безнең ни, һаман шул инде, авыл балалары укыштыра да сирәк-мирәк кенә авыл укытучылары да китап актаргалый. Татардан китеп бетмәгән, урыска барып җитмәгән йон төргәкләренә порнография белән детективтан башка берни дә кирәкми шул! Рәшат Миләүшәгә



*Аяз Гыйләҗев (сулдан икенче) һәм Сибгат Хәким (уңнан беренче) Вахит Юныста (сулдан беренче) кунакта. 1984 ел.*

өйләнде, килен килгән төшкә минем китапларны иснәп-иснәп карады да ташлады. Карыйм: укыштыра! Укыганы детектив! Ишле халык булгач урысның наданы әлләни күренми, ә безнең татарның кабак башлары чәчрәп күзгә кадалып торалар.

Кичә Вахит Юныска шалтыратсам...Вахит гаиләсен, йорт-җирен ташлап чыгып киткән икән. Зәйнәп белән бер йортка байтактан сыеша алмыйлар иде, мин моны күрмәмешкә салышып йөри идем. Ниһаять, чыдары беткән икән егетнең. Алтмышны узгач хатын аеру зур хата, моны Фәрваз Миңнуллин мисалында күреп торабыз. Харап була тәки малай!

Төрмәдән кайткач бергә укып йөрдек, җитдилеге янәшәсендә җиңеллеге, шуклыгы да бар иде. Баштарак мин өйләндем—ул кияү егете иде. Соңрак Сания исемле гап-гади, бер дә укымаган кызга өйләнде—кияү егете булып кыз алырга мин бардым. Ипле генә яшәп киткәннәр кебек иде, малай белән кыз үстерделәр...

Фәрваз димәктән. Язучылар союзында эшләгән чагын нык хәтерлим мин аның, үтә тырыш, намуслы, уңган егет иде. Союзның бөтен эшен берүзе алып барды диярлек. Мөдәррис Мусинны (обком) өнәмәде, яратмавын яшермәде дә. Үткән съездларның берсендә шыпырт кына "переворот" әзерләделәр һәм алдан чак кына да белдермичә Фәрвазны алып ыргытып, Разил Вәлиевне Чаллыдан кайтардылар. Шушы белдерү ясалганнан соң эшсез вә урынсыз калган гаепсез Фәрвазның кыяфәте күз алдымда... Әҗәлгә алып баручы чире шул съездан башланмады мыни?.. Көл төсенә кергән Фәрваз бичара янынннан шыпан-шыпан гына тайды съезд халкы. Ары-бире карангач, оятларына көч килеп, Шәүкәт Галиевне "эшеннән азат итеп" шул урынга Фәрвазны тәгаенләделәр. Егетне бөтенләй үк урамда калдырырга ярамаганлыгын бөтен кеше дә ачык белә иде. Шәүкәт урынына утырды Фәрваз... Тора-бара Фәрваз баш мөхәррир дәрәҗәсен алды, намусын сатмады. (Партия мәктәбен үтеп чыккан, әдәбияттан шактый читтә торган нәшрият директоры Харис Әшрәфҗанов белән эшләргә туры килде аңа.) Шушы җайсыз чорда әдәбият үсешенә кулыннан килгәнчә рыясыз булышып яшәде. Гаиләсе таркалды егетнең!.. Фәрваз җәмәгате белән формально аерылышты. Тиздән гаиләсен ташлап чыкты, Асия Минһаҗова белән язылышып, истә-оста югында алар тагын бер бәбәй алып кайттылар... Фатир алдылар. Бу эштә минем якын катнашым булды. «Безнең нәселдә алтмышны үткән ир-ат юк", дип белдерә иде Фәрваз. 94тә аңа нәкъ алтмыш тула. "Саулыгым какшады", дип элегерәк тә уфтана иде, менә ике-өч ел инде ул очраган саен зарлана. Егет дәва эзләп уңга-сулга каерылды, үләннәр эчте, дарулар йотты. Хәле торган саен авырлашты. Шифаханә кунагы булып китте берзаман Фәрваз. Кера, ята, тикшеренә, бик сирәк табыла торган әмрикән төймәләре алып чыга, шулар ярдәмендә җанын саклый. Ә күңелендә шом: "безнең нәселдә ир-аттан алтмышны үтә алганнары юк!" Күңел капкасын киереп ачып куеп ШОМга юл бирдеңме—беттең...

Китәремә атна калгач, карчыклар чуагының матур, йомшак бер көнендә Литвин белән Фәрваз янына кагылдык. Алексей Львовичның үз йомышлары, минем дә нәни генә белешәсе эшем бар, бер очтан саубуллашырга да кирәк. Кердек, утырдык, сүз ялганмый интектерде. Була бит, өчебезнең дә тел очында сүзләр туып сүнә, берәү дә ачыктан-ачык уртадагы суык учакка ботак ташларга ашыкмый.Фәрваз элек тә зарлангалый торган иде, ниһаять, өстәлгә түше белән ятып, янтаеп зарланырга тотынды. "Авырта... Теге дару сызлауларны баса торган иде элек, хәзер дару юк. Казанда да юк икән! Польшада бар диләр, кабы йөз мең сум! Ул кадәр акчаны мин каян алыйм! Һич түзәр әмәл калмады". Эссе көн, бөркү бүлмә, дәүләт оешмаларында ремонт гасырлар буе туктамый, коридордан буяу исе саркыла, тынны кыса. Фәрваз тәрәзәгә моңсу гына карап алды да:"Әллә иртәгә бер җай табып табигатькә чыгып керәбезме?" дип сорады. Без, Литвин белән, алмаш-тилмәш аның фикерен хупларга тотындык.

Килешенгәнчә, көндезге өчтә машина белән алар килеп җитте, мин чыгып утырдым, яңа диярлек "Волга" машинасы алга элдерде. Литвин белән Фәрваз арткы урыннарда, Фәрваз аякларын кая куярга белмәгәндәй, ярым ятып, кыймшанып, әйләнгәләп бара. Литвин үз дачасына барырга өнди. Мин "кая алай еракка? Ике сәгатьтән караңгы төшә, якты күздә кайтып элгәшергә иде!" дип кирегә сукалыйм. Чуар-чабыр киемнәргә төренеп каршылаган урман эчләп бе-

равык бардык, машинага юл еракмыни, "Аккош күле"нә якынлаштык. "Аккош күле"ндә туктыйбыз!"—диде Фәрваз. Без риза, җил ягыннан гына торабыз, Фәрвазга каршы сыңар уебыз да юк. Уңга борылдык, язучылар дачасына таба юл алдык. Бу сукмак-юлларда байтактан булганым юк иде, онытылган, ятсынып як-ягыма карап барам. Урман эчләп әллә нинди коттеджлар, йорт-куралар салып бетергәннәр, юан-юан аркандай койрыкларын селкеп олы, авыр авызлы этләр шигәеп озатып кала. Барып җиттек. Әдипләрнең тарихи, мәшһүр мәйданын уңда калдырып алгарак үттек, канатлары салынган капка белән җирне тырнап ачып дачаның эченә үк барып кердек.

**18 октябрьдә иртәнчәк дәвам итәм.**

Җирдә башлары көйгән өч-дүрт муртайган бүрәнә ауный, уртада агач төбе. Яндагы йортка ишарәләп Фәрваз: "Монда Равил Фәйзуллин тора", диде дә, "теге башында Мансур Вәлиев", дип өстәде. Литвин букчасыннан коньяк чыгарды, мин вак-төяк ризык хәстәрләгән идем, коньяктан соң йотарга су да ачтык. Фәрваз эчәрме-юкмы дип каранган идем, кулы белән ишарәләп "салыгыз миңа да!" дигәч каршы килмәдек. Коньяктан соң тел ачыла, Литвин килештереп кенә бер-ике анекдот сөйләп алды. Гадәтенчә, яһүдләр турында яһүдләр чыгарганнарны сөйли. "Урам якка такта кадаклаганнар һәм кайчы сурәте ясаганнар. Үтеп баручы ашыгып кына керә дә: "Чәчтарашмы монда?" дип сораган. "Юк,—дигән карт яһүд.—Монда сөннәткә утырту!" «Нигә алайса кайчы сурәте ясап элдегез соң?" Хуҗаның кашы өскә сикергән:" Ә нинди сурәт ясарга боерасыз?" Бу анекдотны Литвин ярата, очрашып салган саен тәмләп, матур итеп сөйли. Ихтыярсыз көләсең. Мин Литвинга, Фәрваз миңа ияреп көлде... Тәки коньякның башына җиттек, тәвәккәлләп Фәрваз да капкалады. Ризык чемченеп, шара-бара сөйләшкәләп басып тордык та баягы капканы йокысыннан уятып, шыгырдатып ачып, урман якка чыктык. Тәмле-татлы исләр таралып яткан урман юлы белән атлыйбыз, аякларыбыз, балачактагы кебек рәхәтлеккә чумып, кызгылт-сары яфракларны көрәп юл ачалар. Кинәт Фәрваз сүзсез генә алга ыргылды, бер җир буе барды, тукталды, иелеп җирдән нидер алды. Тын гына, каккан казыктай шунда хәтсез вакыт басып торды. Литвин белән без бер-березгә караштык һәм икебезгә дә бер уй, шомлы һәм аяусыз уй иңде: "Урман белән саубуллаша бит бу егет!" Борылып килгәч без аны сүзсез каршыладык, ул да аны-моны әйтмәде. Машина янына кайттык, төялдек һәм кайтыр юлга чыктык. Күл янына җиткәчрәк Фәрваз машинаны уң кул якка борды. "Волга"-быз күлгә терәлеп диярлек туктады. Машинадан төшкәч Фәрваз баягы җитезлек белән яр буйлап теге башка китте, тукталды, озак итеп күлнең җансыз, шыксыз суына текәлеп-текәлеп карап торды, башы очына шәрә ботакларын сузган таныш агачларга карады. Ул монда яшәгән ләбаса! Без баягы шомлы фикерне кабатладык: "Күл белән саубуллашуы егетнең!"—дидек. Бу юлы ул иплән, адымнарын санап, як-ягына җете каранып килде-килде дә шоферга багажнигын ачарга кушты. Шофер аракы чыгарды, ике чәркәгә яртышардан койды, Фәрваз үзе эчмәде, безне нык итеп, таләпчән тавыш белән кыстады. Нишлисең, тотарга туры килде. Ярлар котсыз, чүп-чар баскан, суы кимегән җансыз күл ягасында без озак тормадык, күз бәйләнә башлаган иде,шикле адәмнәр төялгән бер-ике машина да килеп туктады, эчтән кызлар чыркылдаганы ишетелде. Шофер алар ягына карап, яратмыйча гына: "Ишәләр... ярларны!" дип куйды.

Бармы гомере Вахитның? Булырмы?

Фәрваз белән "Аккош күле" урманына сәяхәткә чыгуыбыз миңа кире вә кискен тәэсир ясады... Шуңамы, яңа әсәргә ныклап тотынырдан элек, шушы хатирәләрне язып калдырырга булдым. Гомере озын булсын дустымның... Тәгәрәп үсеп килгән ике кызы бар. Аларны әзме-күпме аякка бастырасы, кеше итәсе бар ләбаса! Асия Минһаҗова күкләр телендә сөйләшә белсә дә җир-дөнья мәшәкатьләренә ул кадәрле үк яраклашкан җан түгел дип беләм. Татар әдәбияты һәм без ничек көн күрербез? Фәрваздан башка ул ничек яшәр?..

*Ахыры киләсе санда*

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ШУРА*** *г.* — Киңәш, совет. // *Шураи Гали* — Югары Совет. Шураи дәүләт — дәүләт шурасы, советы. *Шуралар Русиясе* — Совет(лар) Русиясе. // *1920 нче елда инде гражданнар сугышындагы галәбә тәмамән Шуралар Русиясе ягына авышты.* Ф.Әмирхан.

***ШУРӘЛЕ БАРМАГЫ*** — Борынгы казылма башаяклы моллюскларның (белемнитларның) бармаксыман кабырчыгы. Русларда — *"чертов палец"*. Халык медицинасында шүрәле тырнагын (бармагын) кырып ярага сибү ысулы кулланылган.

***ЫРЫМНАР*** *тар.* — Әфсеннәр, арбаулар, им-томнар. Рус һәм славян телләрендәге "заговор", "заклинание" мәгънәсендәге сүз.

Татар халкының ырымнар системасы шактый бай. Алар, әлбәттә, Исламга кадәрге чордан ук киләләр һәм кайбер ырымнарда Ислам кануннарының көчле йогынтысы сизелә, алар догалар белән тыгыз бәйләнгән булалар. Төрле авырулардан котылу өчен билгеләнгән ырымнар, бүгенге күзлектән караганда, аутотренинг алымын хәтерләтәләр, ягъни күп очракта аларның мәгълүм дәрәҗәдә файдасы тигән булуы ихтимал.

Халыкта ырым догасы мәгънәсендә "тел" сүзе дә кулланыла: мәсәлән, кан акканда укыла торган доганы *кан теле* дип атыйлар. Елан чакканда *елан теле* дигән ырым укыганнар.

Тормыш-көнкүрешнең төрле якларына караган берничә ырым үрнәге биреп китәбез.

*Мәхәббәт ырымы, сөйдергечләр.* "Җитмеш җиде кат җир өстендә арыслан киек торыр. Ул арыслан башында ут яна торыр. Ул арысланның баласы бар. Ул арыслан баласын күрмәсә, чыдый алмый ничек киләдер, бу фәлән (кыз) мине күрмәсә эче, җаны, бавыры, йөрәге белән тартып торса, торып түзмәсен, утырып түзмәсен, миңа килсен! Бу сары майны утка, эссе табага салгач ничек кайныйдыр, бу фәлән (кыз) миңа түшен түшкә куймаса, телен телемә куймаса, фәрәҗен зәкәремә куймаса, көнлек сәгатьләрендә, төнлек сәгатьләрендә — һәрбер сәгатендә бу фәләннең җаны ут кебек, йөрәге янып-көеп түзәлмәсен!"

Филология фәннәре докторы Марсель Бакиров 1760 елда бер шәкерт дәфтәренә теркәлгән мондый бер язманы китерә: "Гыйшык кылаем дисә, ушбу доганы укып җимешкә өргәй. Доганы тел астына куеп, кыз белән сүзләшкәй, дәхи бара торган юлына күмгәй".

*Җен догасы*
Кортның башын җуям,
Баш астына куям.
Киләсең булса — кил гөмбә,
Китәсең булса — кит гөмбә.
Кара диңгез артына
Бар да төплән син гөмбә!

*Дәвамы. Сүзлек 2004 елның 1нче саныннан басылып килә.*

*Күз тиюдән ырым*

Алтын тау. Алтын тауда алтын читән. Алтын читәндә алтын багана. Алтын баганада алтын карчыга. Кайчан да кайчан шул карчыгага күз тисә, бу балага да тисен!

Керәшеннәрдә күз тиюдән мондый ырым булган:

"Берәү, икәү, өчәү — очып китсен. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү — бизеп китсен. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алтау, җидәү — җилгә кузгалсын. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү, алтау, җидәү, сигез, тугыз — тузып китсен."

*Кан агуны туктату ырымы (кан теле)*

Алтын инә, алтын җеп
Алтын җөен җөйлимен.
Көмеш инә, көмеш җеп
Көмеш җөен җөйлимен.
Бакыр инә, бакыр җеп
Бакыр җөен җөйлимен.
Кызыл инә, кызыл җеп
Кан җөен җөйлимен.

М.Глухов бу борынгы ырымның керәшеннәр арасында йөри торган вариантын китерә:

Кызыл инә, кызыл җеп, кызлар җөйе җөйлийем.
Бакыр инә, бакыр җеп, бакыр җөйе җөйлийем.
Тимер инә, тимер җеп, тимер җөйе җөйлийем!

*Күзгә чыккан арпаны бетерү ырымы (керәшеннәрдә):*

"Бер, бер дә җук, бер, бер дә җук. Ай кайтсын, көн кайтсын. Бу кешедәге арпа көйгә кайтсын. Миннән мидәт булсын, синнән сикәт булсын. Кибәк урынына киптерәм. Тузан урынына туздырам. Сары май күк эретәм!"

*Бизгәк авыруын куркыта торган ырым түбәндәгечә яңгыраган:*

Тимер көрәк белән кырырмын,
Тырма белән тырмалармын,
Тимер себерке белән себерермен,
Кырдым, тырмадым, себердем.

*Чуанны ырымлап бетерү гыйбарәсе исә тулаем "саннар магиясе"нә иярүдән тора:*

Бер дисен — бер бетсен, ай бетсен,
Ике дисен — изгелеккә булсын,
Өч дисен — очып китсен,
Дүрт дисен — өне-төне бетсен,
Биш дисен — бизеп китсен,
Алты дисен — артта калсын,
Җиде дисен — җилгә очсын,
Сигез дисен — симермәсен,
Тугыз дисен — туфракка китсен.

Сихерне кайтару дога-ырымнары турында **"СИХЕР"** мәкаләсен карагыз.

***ЫСУЛ ДӘФТӘРИ*** *г.* — Бухгалтерия. *//Үзенең ысул дәфтәре белүе берлән бухгалтер дип, бер галантерейный магазинга конторга керә алды.* Гаяз Исхакый.

***ЫСУЛЫ ҖӘДИД*** *г.* — Укытуда "Яңа ысул". 1883 елда Исмәгыйль Гаспралы Бакчасарайда үзе ачкан мәдрәсәдә куллана башлаган "аваз ысулы". Бу ысул татар дөньясына да үтеп керә һәм яңа мәдрәсәләрдә (Мәрҗани мәдрәсәсе, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе һ.б.) кадими "иҗек ысулы"на алмашка килә. "Җәдидчелек хәрәкәте" дигән атаманың килеп чыгышы да шушы сүзгә бәйле.

***ЭНҖЕ*** — Җылы диңгезләрдә аерым төр моллюскларның кабырчыгы эчендә хасил була торган түгәрәк асылташ. Борынгы төркичәсе — *йинчү*, кытай телендәге *чүн чу* сүзеннән. Себер татарлары телендә *йенцү* — энҗе; муенса (Д.Г.Тумашева). Гарәпчә

энже бөртеге — *дөр данә*. *Лөәлөә / лүә-лүә* (*г.*) — энҗе. Тишелмәгән энҗе — *хәридә* (*г.*). Татарлар энҗене кәләпүш, калфак кебек баш киемнәрен нәкышьләп чигү өчен дә еш кулланганнар.

***ЭСПЕРАНТО ТЕЛЕ*** — Дөньяда шактый киң таралган ясалма (сонгый) халыкара тел. Исеме латинча "*өметләнүче*" мәгънәсендәге сүздән алынган. Аны 1887 елда Варшава табибы *Л.Заменһоф* уйлап чыгара. Хәрефләре латин алфавитыннан, сүзлеге исә Европа телләренең күпчелеге өчен уртак лексикага, ә грамматикасы агглютинация (тамырга кушымчалар ялгау юлы белән яңа сүзләр ясау) принцибына нигезләнә.

Казанда беренче эсперанточылар җәмгыяте И.Г.Мохов (Лидин) тарафыннан 1907 елда төзелә. Соңыннан ул Казанда чыгып килгән уникаль "Өегездә эсперанто" ("Эсперанто на дому") үз-өйрәткеч газитне редакцияли. XX гасыр башларында Ф.Әмирханның "Эсперанто теле кагыйдәләре" исемле татарча китабы дөнья күргән. Бу китабына язган кереш сүзендә Ф.Әмирхан: "Бер ай җитди шөгыльләнгән затлар эсперанто телен белүчеләрдән саналырга мөмкиндер," — дип укучыларны кызыксындырырга тырыша һәм бу сонгый телнең "бик җиңел рәсми хатлы" булуын мактый. Күренекле дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе Әхмәтһади Максудиның эсперанто телен өйрәнгәнлеге мәгълүм. Бу телне Лев Толстой да бик тиз үзләштергән.

Революциядән соң Совет Республикалары эсперантистлар союзының Казан бүлекчәсе иң зур бүлекчәләр исәбендә йөргән, мәктәпләрдә, завод-фабрикаларда, редакцияләрдә һәм хәрби частьларда бу телне өйрәнү түгәрәкләре эшләгән. Татар язучысы Шамил Усманов эсперантистлар союзының Мәскәү бүлекчәсендә рәис һәм язучы-эсперантистларның халыкара ассоциациясендә әгъза булып торган.

20 нче елларда бер сәләтле яшь татар язучысы үзенә Эсперантский фамилиясен алган (Мәгъжан Эсперантский, 1905-1925). Ул чит ил эшчеләре һәм коммунистлары белән эсперанто телендә хат алышкан, үзе язган мәкаләләрне Германиядәге эсперанто ассоциациясе җәмгыяте чыгара торган журнал һәм газиткә җибәреп торган. Эсперанто теле турындагы мәкаләләрен "Кызыл яшьләр" газетасында, "Кызыл шәрык яшьләре", "Октябрь яшьләре" журналында бастырып килгән. 1913 елда шәрык халкының әдәбият нәмунәләреннән гыйбарәт булган "Шәркы альманах" китабы эсперанто телендә басылып чыга. Бу альманахка Гаяз Исхакыйның "Калуш" дигән әсәре дә кергән, аны Йосыф Казаков тәрҗемә итеп биргән.

1927 елда *Поперечно-Большая* һәм *Поперечная 3-й Большой* исеме йөрткән урамга шунда урнашкан бакчачылык-яшелчәчелек техникумы каршындагы эсперанточылар үтенече белән *Эсперанто урамы* исеме бирелә.

30 нчы елларда эсперанто теле тыела, күп кенә активист-эсперанточылар репрессиягә эләгәләр. Казанда *Эсперанто урамы* коммунистлар партиясе җитәкчеләреннән берсе — А.А.Жданов исеме белән атап йөртелә башлый (1988 елга кадәр).

Хәзерге вакытта эсперанто теленнән 10 миллионга якын кеше файдалана.

Таралыш ала алмаган ясалма телләрдән тагын сонгый *воляпук* телен атап күрсәтергә мөмкин.

***ЮЛАВЫЧ*** *тар.* — Тизгер хәбәрче, курьер. Апостол, хәварийун мәгънәсендәге *йәлавыч* сүзенә (Сәгыйть Хәлфиннең кульязма сүзлегенә теркәлгән, Кашгарыйда да очрый, "Рисаләи Газизә"дә — *ялавач*) тәңгәл.

***ЮМАЧЫЛАР (ҖУМАЧЫЛАР)*** — Инҗилнең татарчага тәрҗемәсендә "ике йөзлеләр" ("лицемеры") мәгънәсендә алынган сүз. //Ай-һай сезгә, кенәгәчеләр, фарисейлар, җумачылар! Сез кешеләргә күк патшалыгын ябып торасыз: үзегез дә кермисез, керәсе килгәннәрне дә кертмисез. (Матфей, 23:13).

***ЮСЫК*** *бор.* — Йөреш-торыш кагыйдәләре; тәртип, устав; гореф-гадәт. //*Ал юсык*-хан сараенда йөреш-торыш кагыйдәләре. *Кара юсык* — гади халык арасында йөреш-торыш кагыйдәләре. *Юсык-юрык* — рәсми кагыйдәләр.

***ЯГЪМАЧЫЛЫК*** — Борынгы төркі сүз. Якын-тирәне талау өчен яу белән бару, ягъни юлбасарлык белән шөгыльләнү кәсебе. //Төрекмәннәрнең кайберләре, үлəнсез-

сусыз сахрада калып, кәрваннарны, әйләнә-тирәдәге авылларны басып-талап – ягъмачылык кәсебе белән шөгыльләнерләр. Заһир Бигиев.

***ЯДКЯР, ЯДКАРЬ*** *ф.* – Истәлек; һәйкәл; сувенир, реликвия.

Мөселманнар өчен мөбарәк ядкярләр бар. Билгеле булганча, Солтан Сәлим ибн Баязит заманында гарәп җирләре ике сугыштан соң төрекләр кулына төшә. Шул вакыт Мисыр хәлифәсендә Пәйгамбәребезнең таягы, мисвәге, башмагы, чәч һәм сакал бөртекләре (болары *муе мөбарәк* дип атала) аманәт булып саклана иде. Җиңүче төрекләр, ганимәт малларын төяп, шулай ук Пәйгамбәребезнең бу мирасын да Истанбулга алып кайттылар. Бу истәлекләрне көмеш сандыкларга салып, Солтан мәчетенең хәзинәләр бүлегенә куялар. Аларны тик Мәүлид бәйрәмендә генә халыкка күрсәтәләр. Бу истәлекләрне "Мәәван Мөбарәк" дип йөртәләр. Солтан Габделхәмид II Русия мөселманнарына аманәттән өлеш чыгарырга боерык бирә. Рәсүлулланың төкләрен балавызга утыртып катырган, гаять зур ихтирам һәм пөхтәлек белән эшләнгән, эче ефәктән, тышы фил сөягеннән гыйбарәт кыйммәтле сандыкка салынган бу бүләкне хаҗ сәфәре вакытында Истанбулга килгән мөфти Мөхәммәдъяр Солтанга тапшырганнар. Бу тарихи истәлек бүләк утта янмый торган сандыкка салына һәм бүгенге көнгәчә саклана. Мәүлид кичәсендә мөселманнарга күрсәтелә, салаватлар укыла.

Истанбулда Туб сараенда саклана торган иң кадерле әйберләрдән Рәсүлулланың төрле йорт җиһазлары һ.б. ядкярләр: 1) эсселектән саклый торган кием-салымнары; 2) кылычлары; 3) сакал төкләре; 4) хат, мөһри шәриф; 5) фәләкъ; 6) гыйльми шәриф; 7) Кәгъбәтулланың Госманлы хәлифәсенә күчкән вакыттагы ачкычы; 8) башмак шәриф; 9) Кәгъбә улагы; 10) Госман Коръәне; 11) имам Гали Коръәне; 12) Габделкарый җиләне; 13) беренче хәлифәләрнең киемнәре.

Бу истәлекләрне Шәгъбан аеның 15 нче көнендә зиярәт кылалар ("Иман" гәзите буенча).

*//Табигать ядкяре. Тарихи ядкярләр.*

***ЯЗЫК*** – Гөнаһ, гаеп эш, мәгъсыять, убал, ис(е)м (суфичылыкта); ялгышлык, хата; җинаять. Бу сүз күпчелек төрки телләрдә күзәтелә. Хәзерге вакытта актив кулланылмаса да, аның кирәге чыгарга бик мөмкин (мәс., русча *"проступок"* мәгънәсендә). // *"Язык (йазык) намәсе"* – "Гөнаһ китабы" (мөселманнарның дөньялыкта кылган эшләре язылып бара торган китап).

***ЯКҮН*** *г.* – "Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге" буенча: "Төп мәгънәсе: "булыр" дигән сүз булып, кулланылуы: 1)Җыенысы, барысы, суммасы. 2)Йомгак, нәтиҗә мәгънәсендә." *//Театр мәүсименең якүне* – Театр сезонының йомгагы. *"Кянә ләм якүнү"*-"Бар иде, хәзер юкка чыккан". *Көн фәякүн* – "Бул!" дию белән үк була" мәгънәсендә ("Йәсин" сүрәсенең 82 нче аятеннән). Шәкерт халкы арасында "Көн фәякүн аяте" дип тә йөртелгән бу аятьтә "көн" сүзенең гарәпчә ничек язылышын аңлатучы мондый калып булган. "Кәптерке нонга сәкен нон". Моның дөрес әйтелеше: "кяф"кә – өтер, "нун"га – сәкен, ягъни "к" хәрефе өстенә өтер, "н" хәрефе өстенә сәкен билгеләре куела. Өтер тартык өстенә куелса, бу тартык "о" яки "ө" сузыгы белән укылырга тиеш. Сәкен исә тартыктан соң сузык аваз булмавын күрсәтә (аңлатма "Татар халык иҗаты"ның "Табышмаклар" томыннан алынды).

**Танылган язучы, галим Адлер Тимергалинның "Миллият сүзлеге" шуның белән тәмам. Журналыбызда 2004 елның 1 санынннан башлап басыла килгән сүзлек—төп хезмәтнең сайлап алынган өлеше генә. Күптән түгел "Мәгариф" нәшрияты "Миллият сүзлеге"нең тулырак вариантын китап итеп чыгарды (журналның шушы санындагы "Яңа китаплар" сәхифәсендә бу хакта мәгълүмат бирелгән). "Казан утлары"на килгән хезмәтләр арасында Адлер Тимергалинның яңа кызыклы язмалары бар һәм алдагы саннарында сез аларны күрә алачаксыз.**

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Ашытбаш авылы

Ашытбаш авылы Арча районында, район үзәге Арча эшчеләр бистәсеннән 30 Казаннан 95 чакрымда урнашкан.

Авыл тарихи чыганакларда искә алына.

XVIII йөз мәгълүматларын эченә алган Д. А. Корсаков белешмәсендә Ашытбаш авылында 120 ясаклы татар яшәгәнлеге күрсәтелә.

А. Артемьев җыентыгында билгеләнгәнчә, Ашытбаш (Печән пакуслары) авылындагы 100 хуҗалыкта 394 ир-ат һәм 368 хатын-кыз исәпләнгән, авылда мәчет булган. И. А. Износков Ашытбашның икенче исемен Печән Пакуслары (Сенные Покосы) дип биргән. Ашыт суы ярына һәм Уржум сәүдә юлының уң ягына утырган бу авыл җирләрендә, бигрәк тә Ашыт суы башланган урыннарда, бик әйбәт печән үскән. Икенче исеме шуңа нисбәтән барлыкка килгән. Авыл янында борынгы зират бар. Авылның 120 хуҗалыгында ислам дине тотучы 477 ир-ат һәм 416 хатын-кыз яши, алар Печән Пакуслары авылы җәмгыятенә кергәннәр. Халыкның тормыш-көнкүреше әйбәт, кәсепләре: балта эше, умартачылык, мич чыгару. Анда вак-төяк сата торган ике кибет, су тегермәне бар. 1898 елгы җыентыкта Ашытбаш авылы татарлар яши торган урын итеп күрсәтелә. К. П. Берстель җыентыгында Печән Пакуслары (Ашытбаш) авылында 919 татар кешесе яшәгәнлеге әйтелә. Н. Б. Борһанова мәгълүматларына караганда, Ашытбаш авылы халкы июнь ае уртасында күршедәге Кысна, Иске Иябаш, Яңа Иябаш, Яңа Кырлай авыллары халкы белән бергә Иябаш җыенын яисә Кырлай җыенын бәйрәм иткән.

«Аксияк нәсел шәҗәрәсе» текстын 1973 елда уздырылган археология экспедициясе вакытында Татарстанның Арча төбәгенә караган Ашытбаш авылында Гатауллин Шәйдулла агайдан Марсель Әхмәтҗанов язып алган. Шәҗәрәнең язма легендалары юк, әмма авыл картлары Аксиякнең Олы Мәңгәр кешесе булуын сөйлиләр. Кайбер мәгълүматларга караганда, Аксияк шәҗәрәсе 1930 елларда «Крәстиән гәзитәсе»ндә басылган булган.

Атамасында Ашыт сүзе катнашкан Ашытбаш авылы оешу турында мондый бер ривайәтне 1971 елда Арча районы Ашытбаш авылында Гатауллин Шәйдулладан Марсель Әхмәтҗанов язып ала.

Ашытбаш авылына XVII гасырның икенче яртысында Мәңгәр авылыннан ике бертуган—Тимербулат белән Акбулат дигән кешеләр килеп утыралар. Алар килгән чорларда бу урында Уразай дигән чирмеш яшәгән. Авыл нигездә шушы өч гаиләдән башланып китә. Бүгенге Уразаев фамилияле кешеләр шул Уразай токымыннан икән.

Төрле кавемнәрнең ызгыш-талашсыз бергәләп гомер итү үрнәге түгелмени бу?

1765 елда Апаз, Иябашларны чукындырырга Әҗем ягыннан яу килә. Ул вакытта авылда илле-алтмыш йорт була. Апаз ягыннан бер атка атланган кеше килеп: «Качыгыз, яу килә!»—дип Ашытбаш авылына хәбәр сала. Бу хәбәрне ишетеп, авыл халкы урманга кача. Яу, бу авылда төрле катнаш халык икән дип, Ашытбашка күп туктап тормый, хәзерге Иябаш якларына юл тота. Әмма халык, кача-поса булса булса да, үз диннәрен тоткан. Чукындыру кан коюю белән барган. Арчага хәтле сузылган Кан елгасында чукынырга теләмәгән татарларның каны тулып аккан. Иябашта бер хатын кешеләрне такмаклап уятып йөргән:

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

*Уяныгыз, уянчы,*
*Югары очта яу бар,*
*Түбән очта туй бар.*

Унике мәчетле Миһербан авылы тар-мар китереп туздырылган, яндырылган. Халкы өч авылга бүленгән: Әзәк, Иске Иябаш, Яңа Кырлай.

Халыкны чукынырга ирексезли башлагач, «Чукынам» дип беренче ризалашкан кеше Әзәк исемле булган. Шуннан ул торган авыл Әзәк булып киткән. Әзәк авылы халкы Азак-Азов буйларыннан килеп утырган.

1773 елда Пычак авылыннан Гомәр дигән кеше килеп, Ашытбашта Пугачев манифестын укый. Авыл халкы бу Гомәрне бик яраткан. Пугачев Арчада торган вакытта, анда тугыз олау азык-төлек илткәннәр.

Ашытбаш авылында Шәйдулла Гатауллиннан 1972 елда Марсель Әхмәтҗанов язып алган «Әхмәтсафа» дип исемләнгән көнкүреш риваятендә мондый вакыйга турында сөйләнә. Әхмәтсафа үсеп буйга җиткәндә бик унган егет була, үзе авылда Гөлзифа исемле кызны бик яратып йөри. Аның Гөлзифасы бер кашык су белән йотарлык, иң матур, иң чибәр кыз була. Гөлзифага авылның бай егетләре дә кызыгып йөриләр икән. Алар кызны кулга төшерергә бик тырышалар, ди. Ләкин Гөлзифа Әхмәтсафаны гына ярата. Бу хәл авылның бай егетләре һәм кызлары арасында зур көнчелек тудыра. Алар Әхмәтсафа белән Гөлзифадан үч алырга телиләр. Әхмәтсафа яшьләр арасында бик данлыклы була, кичләрен скрипкада уйный, яшь егетләрне җырлата.

Ул замандагы гадәт буенча, яшьләр, староста һәм муллалар йорты янынннан узганда, уйнап яки җырлап узмаганнар. Әхмәтсафа исә бу гадәтне еш кына боза торган була. Шуңа күрә авыл байлары һәм дин әһелләре дә аны дошман күргәннәр. Шуның өстенә, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, бервакыт волость старшинасын канга батканчы кыйнап, бер амбарга ябып, бикләп куялар. Ахырдан «бу эштә Әхмәтсафаның да катнашы булган икән», дигән хәбәр тарала. Авыл кешеләре Әхмәтсафаның Зөбәер Зарифы белән бик дус булып йөрүен беләләр. Ә Зариф үзе яшерен оешмалар белән элемтә тоткан бер кеше була.

Менә бервакыт, җәйнең бер матур төнендә, тирән йокыда чагында, Гөлзифаның бер чәч толымын кисеп китәләр.

Бу эштә гаеплеләрне эзләп, барлык урыннарда тикшерү уздыралар. Ахырдан, ул кискән дип, Сафага яла ягалар. Дин әһелләре Сафаның бөтен гонаһларын күрсәтеп, шикаять язалар.

Күп тә үтми, бу хакта суд була. Суд Әхмәтсафа Мөхәммәтлатыйф угылын гомерлек сөргенгә хөкем итә.

Шулай итеп Сафаны сөргенгә җибәрәләр. Сафа үзе китсә дә, авыл халкы аны онытмый. Аның уйнаган көйләре һәм җырлары бик озак халык авызыннан төшми...

Ашытбашы атамасы авылның Ашыт суы башланган урынга урнашуына мөнәсәбәтле рәвештә бирелгән.

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, авыл халкы 5 нәселгә берләшеп килеп утырган һәм авыл нигезләгән: Уразай нәселе, Аксөякләр нәселе, Урак һәм Зуратлар нәселе, Иммәмәт, ягъни Мәмәт хуҗа нәселе, Иштирәкләр нәселе.

Уразай нәселен халык болай сөйли. Нәсел башы мари булган. Заманында Уразай бабай авылда бай тормышлы хуҗалыктан саналган. Аның уллары туганнары белән 4-5 хуҗалык булып шушы авыл оешасы урынга күчеп килгәннәр. Марилар авылда иң күп таралган нәселдән саналган, ягъни авылның ярты халкын тәшкил иткән. Татарлар белән марилар бергә тату гомер иткән, бәйрәмнәрне дә бергә уздырганнар.

Марилардан соң 4 хуҗалык булып тирә-юнь авылларыннан татарлар күчеп килгән: Олы Мәңгәрдән—2, Орнаштан—1, Түбән Сәрдәдән—1 хуҗалык. Күчеп килгән кешеләрдән туган балаларның балаларын шул кешеләрнең нәселеннән дип атап йөргәннәр, һәрбер нәсел аерым чәчүлек җирләрен билгән һәм басуларны шул нәселләрне башлаган кеше исемнәре белән атап йөрткәннәр. Аерым җир мәйданнары, елга-инеш атамалары шул вакытлардан калган: Мәмәт елгасы, Айтуган елгасы, Каз-күз елгасы, Бужна елгасы, Җәмкә елгасы һ. б.

Аксөяк нәселе турында авыл олылары болай сөйли. Нәсел турындагы язмаларны

шул ук нәселдән булган Сәйфелмөлек бабай башкарган. Бу язмалар ахырдан Гомәр бабайга күчә. Аның Зарифҗан исемле улы язмаларны калимчәдән җәдитчәгә күчереп яза. Шуннан соң бу язмалар Гомәр бабайның өлкән улы Госман кулында саклана.

Аксөяк баба Акполат һәм Тимерполат исемле бабаларының нәселен дәвам иткән. Аксөякнең улы Күксөяк, аның улы Иртуган. Иртуганның балалары: Иштуган, Ишмөхәммәт, Ишморза һәм Ишбулат булган.

1879 елда авылның Габдерәшит исемле кешесе тегермән салдыра. Ул 1952 елга кадәр эшли. Әтисе үлгәч, тегермән аның улы Хәбибуллага кала.

1914 елда авылның аръягына яна мәчет салына. 1938 елда анда пожар була. 1992 елда авылда яна манаралы мәчет төзелде.

1930 елда янган клуб урынына 1931 елда яңасы төзелгән. 1936—1937 елларда авылда 8 классльі зур агач мәктәп салынган, 1992 елда ул урта мәктәпкә әйләндерелгән.

Авылда кибет, китапханә, балалар бакчасы, медпункт эшли.

Ашытбаш авылы атамалары да үзенчәлекле: Кәҗә басуы, Әзәк авылы янындагы Туйгелде кыры, Уянчы елгасы, Кан елгасы. Сәетҗан елгасы янында Иске Ашытның бер кешесе базарда кемнедер үтергән дә, шушында качып яткан дип сөйлиләр.

Авыл яныннан Ашыт һәм Шушма елгалары ага. Ашытбаш белән Кысна елгалары арасында зур буа төзелгән. Елга аръягында Кәҗә басуы. Аның бер кырыенда Артышлык (монда артыш агачлары, чыршылар үсә, шундагы аланда ел саен сабантуе уздырыла), бер ягында Иске зират урын алган. Иске зират яныннан сукмак уза. Зират янында гына артыш, чыршы агачлары үсә. Каберлекнең чардуганнары сакланмаган. Авылда тагын Яңа зират бар. Аны чистартып, рәшәткәләрен төзекләндереп, буяп торалар.

Авылдан 3 чакрым ераклыкта урман башлана, аны Кырлай урманнарының дәвамы дип йөртәләр. Авылның бер ягында Ак чишмә исеме алган кизләү челтерәп ага. Авылга су колонкалар аша килә. Күп кешеләр суны өйләренә үк керткәннәр, авылда су кытлыгы юк. 1991 елдан бирле авыл халкы табигый газ яга.

Авылда 3 күпер бар: Олы күпер, Атау күпере һәм Су күпере. Басуларның күренеклеләреннән Текә тау басуы, Кәҗә басуы һәм Туйгелде басуларын искә алырга мөмкин.

Текә тау басуын хәзер Сталин басуы яисә Поселок басуы дип тә йөртәләр. Текә тау басуын бер яктан урман, икенче яктан Көек елгалары аерып тора. Басуның мәйданы 206 гектар. Элек аннан Кысна авылы халкы файдаланган.

Кәҗә басуы авылның төньягында, иң якын басуларның берсе. Аны төньяктан Кысна авылы басулары, көнчыгыштан Үрнәле елгасы, көньяктан Авыл елгасы, көнбатыштан Яу елгасы чикләп тора. Басуда бер күл бар. Чәчүлек җир мәйданы— 140 гектар. Басу борынгы заманнарда дәүләт яисә казна урманы дип йөртелгән. XIX йөз башларында бу җирне урманнары белән дәүләт урман идарәсеннән Кышкар авылының Муса исемле бае сатып ала. Авыл халкына ул урман агачларын китереп сата торган була. Муса бай вафат булганнан соң ул җирләр аның улы Мортазага кала. Урманның киселгән җирләреннән басу ясыйлар һәм иген чәчә башлыйлар.

Авылга каршы елганың болыннары барысы да Муса байныкы булган. Шуңа аны бай болыны дип йөрткәннәр. Хәзер ул болыннарда урам һәм йортлар, элек исә җыен, сабантуйлар шунда уздырыла торган булган.

Туйгелде басуы авылның көньягында, ул—иң ерак басу. Көньякта ул Яңа Кырлай басулары белән чикләнә, ә көнчыгышында урман, авыл ягында Чүк елгасы, көнбатышта Җанньік, Сәетҗан елгалары. Туйгелде басуы элек Әзәк авылы җирләре булган. Анда элек куе әрәмәлекләр булган дип сөйлиләр. Хәзер ул җирләр чәчүлеккә әйләндерелгән.

Бүген авыл зурая һәм матурлана бара. Хуҗалыклар саны 180 исәпләнә. Ул хәзер «Ашытбаш» исемле күмәк хуҗалык булып аерылып чыкты. Авылда яңа тораклар, йортлар торгызылды. 1992 елда авылда асфальт заводы, җиргә ашлама сибү өчен самолет төшәргә аэродром төзелде, амбарлар ишегалдына асфальт салынды. Авыл яныннан үтә торган олы юл да асфальтлы.

Соңгы елларда Ашытбаш авылында зур үзгәрешләр булган. Анда матур гына

агач мәчет үсеп чыккан. Урта мәктәп, агач клуб, балалар бакчасы, медпункт, таш кибет эшли. Амбар, гараж, фермалар да төзек. Авылда ике катлы кирпеч мәдәният йорты, кирпеч мәктәп салына башлаган.

Авыл янынннан Арча-Шушмабаш дамбасы уза. Асфальт әлегә Ашытбаш авылына кадәр генә, ләкин тиздән Ашытбаш—Шушмабаш, Ашытбаш—Акчишмә юлларына да асфальт җәю күздә тотыла.

Авылны басулар һәм тугайлар әйләндереп алган. Юл кырыйларына яшь агачлардан каен, сирень куагы утыртыла. Кысна авылы белән Ашытбаш арасында плотина корылган, Артышлык янында хәзер каз-үрдәкләр коена, карп балыгы үрчетмәкчеләр. Кич белән кояш баешында бу урын аеруча матур.

Ашытбаш кешеләре бәетләр иҗат итәргә маһир. Шундый бәетләрнең берсе «Резидә бәете». 1982 елның көзендә медпункт янындагы күпердән чыкканда комбайн елгага ава. Сеңлесе өчен кырга эшләргә чыккан Резидә һәм аның атасы фаҗигале төстә һәлак булалар. Бу фаҗига бар авылны тетрәндерә, Резидәгә багышлап бәет чыгарыла. Комбайн ауган җирдә елга кып-кызыл кан була. Шуннан бирле авыл халкы елганың комбайн ауган ягына төшмәскә тырыша. Бу бәетне һәм «Рамил бәетен» Сәкинә Хәнәфиева чыгарган.

*Бер мең дә тугыз йөздә*
*Сиксән икенче елларда,*
*19 яшьлек кыз үлде*
*Көзгә таба чорларда.*

*14 нче август төнне*
*Кичке сәгать уннарда,*
*Комбайн белән аудылар*
*Сикәлтәле юлларда.*

*Туган авылым Ашытбашка*
*Ялга диеп кайттым мин,*
*Иртә таңнан әти белән*
*Кырга чыгып киттем мин.*

*Көне буе киң кырларда*
*Комбайнда эшләдем.*
*Ашытбашның урамында*
*Үлермен дип белмәдем.*

*Сеңлем өчен кырга чыктым*
*Ял итсен диеп бераз,*
*19 яшьтә үлдем мин*
*Гомерем булды бик аз.*

*Комбайн өстемә төшкәч*
*Тыннарым бик тиз бетте.*
*Шушы яшьтән газиз башым*
*Кабер эченә китте.*

*Резидә үлгән дигәч тә*
*Әни niләр уйларсың?*
*Мин җан биргән урыннардан*
*Көнгә ничә урарсың?*

*Әткәй, әнкәй, туганнарым*
*Бик зур кайгы... түзегез.*
*Ять-яшь килеш каберләрдә*
*Ята сезнең кызыгыз.*

*Әнием мине көтеп алдың*
*Кайтыр көнемне санап.*
*Инде мин исеңә төшкәч*
*Кайнар яшьләрең тамар.*

*Соңгы кат мине күрергә*
*Дус кызларым кайтырлар,*
*Эшли торган цехларымда*
*Минем хәлне әйтерләр.*

*Иң соңгы әйткән сүзләрем,*
*Әти, китмәс күңелеңнән.*
*Ашытбашның зиратында*
*Минем гәүдәм күмелгән.*

*Мине якын күргәнегез*
*Килегез зиратларга.*
*Гомерләрем киселде бит*
*Яшьлек чәчәк атканда.*

*Инде минем киемнәрне*
*Киегез туганнарым.*
*Әнкәй, сиңа карт көнеңдә*
*Ярдәмчең булалмадым.*

*Калды инде әткәм-әнкәм,*
*Туганнарым, кырларым...*
*Магнитофон тасмасында*
*Калды минем җырларым.*

*Минем шундагы җырларны,*
*Авылдашлар, җырлагыз.*
*Тавышым—соңгы истәлегем*
*Беркайчан да бозмагыз.*

*Кызың үлде, әни, йөрәгеңдә*
*Үлчәүләргә сыймас кайгың бар.*
*Минем язмыш шулай булган инде.*
*Әнием бәгърем, зинһар, кайгырма.*

*Рамил, җаным, син дә зинһар өчен,*
*Мин үлде дип имә башыңны.*
*Авыр кайгы, ләкин түз бәгърем,*
*Миннән башка ярлар табылыр.*

*Син каршыма килдең минем,*
*Рамил, нигә йөрәк ике уйлады?*
*Нигә этием, син дә миңа шунда:*
*«Бар син, кызым, утыр»,—димәдең.*

*Нигә, нигә язмыш шулай,*
*Рамил безне читкә каерды?*
*Нигә, нигә минем гомерем шулай*
*Иң күңелле чакта өзелде?*

*Гомерләр өзелде...*
*Әниемдә калды газабы.*
*Мәхәббәт өзелде... Рамил,*
*Син тап инде минем дәвамны.*

*Хуш, әнием, минем иң кадерлем,*
*Күр син мине көн дә төшеңдә.*
*Газиз балаң шулай һәлак булды*
*Ашытбашның зәңгәр кичендә.*

Резидә үлгәннән соң сөйгән егете бик нык кайгыра. Ләкин тормыш дәвам итә. Рамил Җәүһәрия исемле кызга өйләнә. Туйлар үткәч Рамил эшкә чыга. Шул көнне аны машина таптап үтерә. Бу вакыйга 1985 елны була. Егетнең бәхетсезлеге турында «Рамил бәете» дигән бәет чыгарыла...

Авылда һәр хуҗалыкта газ яна, күп кешеләрнең өенә су кертелгән. Йортлар төзек, матур итеп буялган. Авыл зураюга йөз тота.

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

Нурулла
Гариф

# ГЫЙБРӘТЛЕ ХИКӘЯТЛӘР

## Алданрак уйлыйсы булган

Балага ничек тәрбия бирү турында акыл сату гына җинел ул. Бер мәҗлестә танышым күршесендәге урыс малаенын әтисеннән качып намаз укуы турында сөйләде. Әтисе белеп алгач, улын «наркоман булсаң яхшырак булыр иде» дип әрләгән. Хәер, бу гаилә чын урыс гаиләсе түгел. Малайның әнисе, безнеңчә тәрбия алмаса да, татар хатыны икән. Кызык, әгәр бу бала чиркәүгә йөри башлап, әнисе шулай дисә?

Өйгә кайтып, үз улыма баккач, башыма төрле уйлар килде. Аллам сакласын, үз улың шулар юлына басса, йөрәгең өзгәләнүдән ни эшләрсең дә, күнеленнән улыңа ниләр теләрсең икән? Үземнекен уйладым да, теге урыс мужигын анларга тырышып, чын күнелемнән җәлләп куйдым. Әмма шунысы да бар, диннен фаҗигасе түгел, катнаш никахларның фаҗигасе бу. Ә менә монысы турында теге урыс кешесенә алданрак уйларга иде шул.

## Оныклар күңеленә ничек кереп каласы?

Бер авыл чатында машина көтәм. Юл белән янәшә генә—зират. Анын борынгы, инде каберләре дә бик беленмәгән өлешендә яңа гына буялган чардуган тора. Шул чардуганлы кабер тирәсендә бер бабай белән яшь бала баядан бирле мәш килеп нидер эшли. Кызыксынуым сонгы чиккә житкәч, яннарына барам. Исәнләшәм дә, тел очындагы соравымны бирәм:

—Кем җирләнгән монда?

—Бабай,—диде бабай.

—Ничәнче буын бабагыз?

—Белмим.

—Ә башка бабаларыгызнын каберләрен беләсезме?

—Үз бабам сугыштан кайтмаган. Ә калганнарын юк, белмим шул.

—Монысын каян беләсез? Нигә бу каберне генә җыештырасыз? Нәрсә эшләгән ул бабагыз?

—Белмим. Үзем дә әтидән кызыксынып сорашкан идем, ул да әйтә алмады. Бабай да белмәгән. Бу бик күптәнге кабер, күрәсен.

—Ә нигә шулай карап торасыз?

—Әти кушып калдырды. Аңа бабасы әйткән булган. Борынгыдан килгән хөрмәт, тапшырылган васыять бу.

Янәшәдә торган балага сорау бирәм:

—Ә сиңа бу каберне карарга әтиең әйтеп калдырдымы соң әле?

—Юк, мин әйтмичә дә беләм!

Мин борылып үз юлыма китеп бардым. Хәзергәчә җавап табылмаган сорауларым тагын бергә артты. Оныклар күнеленә ничек шулай онытылмас булып кереп каласы икән? Монын өчен күпме яхшылыклар эшлисе дә, нинди изгелекләр кыласы икән?

### Җиңү бәласе

*(Бер танышым сөйләгән хәл)*

Мәктәпкә яна гына эшкә урнашкан чак. Тору урыны да шундагы кечкенә бер бүлмә. Кич белән директор килде. Бүлмәгә керде дә, «Шахмат уйный беләсенме?»—дип сорады. Әзрәк чамалыйм, мин әйтәм. «Әйдә, тез але тиз генә», ди бу, кулларын угалап. Биш партия уйнадык, бишесендә дә директор җинелде. Шуннан бер сүз әйтми башын иеп чыгып китте бу.

Икенче көнне озын тәнәфес вакытында яныма хезмәт укытучысы килде. «Кич белән директор мәктәптә булдымы?»—ди. Булды, мин әйтәм. «Шахмат уйнадыгыз инде». Әйе, мин әйтәм. «Тоташ җинелде инде». «Барын да каян беләсез, әйе, җинелде»,—дим. «Уйлаган идем аны,—ди бу.—Хатыны да мескен йокы күрмәгән, күзләре кып-кызыл. Иртәдән бирле укытучыларга да, өлкән класс балаларына да көн юк. Директор барысына да бәйләнеп йөри. Их, бу яшьләрне»,—дип үз-үзенә нидер сөйләнде дә, «Энекәш, тагын уйный калсагыз, соңгы партиянне булса да оттыр, мәктәпкә файдаң тияр»—дип, мине әрләп җибәрде.

Сүзен тыңладым. Тиздән директорның кәефе күтәрелеп, мәктәп эшләре дә кабат гөрләп китте.

### Ходай сезнең көнгә калдырмасын

Шулай бер сөйләшеп утырганда, «Үзең яшь булсаң да, фәлсәфәң сиксән яшьлек картныкы кебек»,—дип салпы якка салам кыстырган иде бер бай якташым. «Үзенә бер яхшылык эшлисем килә, ни дә булса сора әле, берәр үтенечең, кирәкле әйберең юкмы?»—дип тә өстәде ул. Түрә танышымның мөмкинлекләре дөрестән дә бик зур иде.

Ә мин, һәрвакыттагыча, сүземне үлчәп тормадым: «Рәхмәт. Теләгем шул, минем өчен Ходайдан сорагыз әле, тормышымда сезнең кебек кеше хакына кереп баючыларга ялынып, соранып барырга язмасын иде. Сорасагыз, яхшылыгыгыз шул булыр»,—дидем.

Түрәләр дә төрле була, барын да бер тәлинкәгә салып үлчәү ярамый икән. Үпкәләмәде тагы. Ризалашты. Соңыннан да бер-беребездән бәйсез, яхшы дус-танышлар булып калдык.

### Кем күпме югалткандыр...

«Соңгы кыңгырау» бәйрәме. Хезмәттәшләр җыелып, әзрәк «утырып алу» уе белән кибеткә сугыласы иттек. Кибет янында көннәр буе «хут чыкканны» көтүчеләр утыра. Кибеттән чыгуга шуларның берсе безгә иярде. Арабыздагы ана туган тиешле хезмәттәшебез, бездән унайсызланып, аны ияртмәскә тели. Куып та, аптырагач акча биреп тә карады. Юк, ризалашмый гына бит теге. Әле үпкәләп, мин синнән хәерчерәк түгел, дип, кесәсеннән бөгәрләнгән әллә ничаклы меңлекләр дә чыгарды. Аның үз сүзе сүз: «Минем эчәсем килми, сезнең сөйләшкәнне генә тыңлап утырыр идем».

Хезмәттәшебез үз сүзендә торды, туганын ияртмәде. Ияреп тә теләүче дә, бездән унайсызланып, артык карышмады. Башын аска иеп китеп барды.

«Барсын» дип әйтергә тел кычытса да, мин дә дәшмәдем. Әмма аңладым мин аны. Дөресен әйткәндә, үземнең дә сирәк кенә булса да шулар арасында утырасым, аларның ни сөйләшкәнен, дөньяга булган фәлсәфи карашларын беләсем килә. Тик, мәктәптә эшләгәч, яхшысынмыйм гына.

«Күңел ачып» утырганда безнең сөйләшү, һәрвакыттагыча, тәрбия мәсьәләсенә бәйле рәвештә, дәүләт сәясәтенә ризасызлык белдерүдән әллә ни ерак китмәде. Әлеге мәсьәләдә кибет янында утырып калучының фикерен

белү беребезгә дә зыян итмәгән булыр иде. Бергә утырып фикерләшмичә кем күпме югалткандыр, монысын да белә алмадым.

## Күршеләр

Йомыш төшеп, бер укымышлы танышымның фатирына барырга туры килде. Күп тапкырлар кыңгырауга басып, инде ишегенә ике-өч тапкыр шакыгач, каршы яктан күршесе чыгып: «Кайтып җитмәгәдер әле, өйдә булса ачар иде, алтын кеше ул безнең»,—дип танышымны мактый башлады. Үзенә кереп көтеп тору мөмкинлеге булуын да искәртте.

Ашыккан чагым иде.

—Күршесен мактаган үзе дә начар булмый ул, яманласагыз сөйләшеп тә тормас идем,—дип, юлымны дәвам иттем. Йорттан чыккан чакта эзләп килгән танышым очрады. Кирәкле сүзне сөйләшкәннән соң:

—Күршең яхшы кеше икән, бик мактады үзеңне,—дидем. Ә танышым, чыраен сытып:

—Әй, бер тулар-тулмас юләр нәрсә шунда,—дип кенә куйды.

Мин икеләнеп калдым. Әле генә, күршесен мактаган үзе дә яхшы ул, дип әйткән идем инде. Ә менә күршесен яманлаганның кем икәнлеген искәртергә кыюлыгым җитмәде.

## Язмыштан узалмаган ялгыш

Танышыбыз Нияз абыйның, улы Робертны армиягә җибәрмичә, бик тә үз янында калдырасы килгән иде.

—Әти кеше улына яманлык теләми. Сүземне тыңла. Дөнья син уйлап, син теләгәнчә, син күргән-белгәнчә генә бармый ул. Сез яшьләр тормышка артык җиңел карыйсыз,—дип, озак үгетләде ул. Тик яшьлек дуамаллыгы үзенекен итте.

—Әти, һәр чорның үз хаклыгы, бүген дөньясы да сез теләгәнчә генә бармый бит,—дип сүзне гел шаяртуга борды улы.

Роберт үз сүзендә торды. Чирен яшереп, хәрби комиссариатка үзе барды. Теләгенә иреште. Әфганстанга җибәрделәр, һәм шуннан кайтмады да ул. Дөрес, үлгән хәбәре дә килмәде. Әти-әнисенә тагын да зуррак яра салып, эзсез-нисез югалды.

Кордашымны менә кырык яше тулгач искә төшердем. Ул ни өчен яшәгәнен дә, ник һәм кемнәр өчен үлгәнен дә аңламыйча калды бугай. Бүгенге көндә дә Роберт яшьтәшем кебек уйлап, аның фаҗигасен кабатлаучы 18 яшьлек егетләр күп. Әмма, без үскәндәгедән аермалы буларак, бүген яшьләр генә түгел, аларның әти-әниләре дә улларының кая барып, кем өчен утка керәселәрен чамаламый инде.

## Әбиләргә ни кирәк?

Элегрәк авылга кайтканда карт-корыга күчтәнәчкә «Казан ипие» алсаң, шуңа шат булып, безгә карата һәрчак хәер-догада булырлар иде. Дөньясы күз алдында үзгәреп китте шул. Хәзергеләрен болар белән генә шаккаттырып та, ризалатып та булмый инде. Авылга кайту юлында чат саен кибет. Акчаң гына булсын. Авыл кибетләрендә товарның шәһәр кибетләрендә булмаганнары да очрый. Әйбер бәясе шәһәрдәгедән арзан булуына да аптырап торылгалый.

Авылга кунакка кайтучылар үзләре дә үзгәрде. Без дә хәзер күчтәнәчләрне шәһәрдән үк күтәреп ташымыйбыз. Менә бүген дә юл өстендәге кибеткә керәм. Сатучы кыз таныш. «Сәнлем, әбиләр нәрсә яратып ала, шуларны бир әле»—дип, акчамны сузам. Кибетче кыз берара югалып кала. Аннан ихластан елмаеп: «И-и-и абый, әбиләр нәрсә генә алмый хәзер»,—дип, карашы белән кибет киштәсен тулаем айкап чыга. Ә кибет киштәләрендә ризыгы, аракысы-

шәрәбы да йөз төрле. Аптыраудан бераз сүзсез басып торгач, үз жаным теләгән кучтәнәчләрне алам да, чыгу ягына юнәләм. Башымда уйлар өере. Шушы 10-15 елда башкалар әби булып өлгерде. Болары башка буын, үзгәреш чоры әбиләре. Шулай да барыбер бүгенге әбиләр ярыйсы әле ул.

Ә менә бу әбиләрнең бәбиләре үсеп житкәч ни күрсәтерләр тагы?!

## Заман үлчәве

Күрше карчыгынын кунакка кайткан оныгы әбисенен тәхәрәт ала торган жиз комганын күтәреп карады да, «Ничә кило тарта икән бу?»—дип сорады. Дәшмәдем, борылдым да чыгып киттем. Оныкнын баш миендә «Монын бәясе бер атна кәеф-сафа корырга житәрме икән?» дигән кебегрәк уй кайнавын аныШкан идем инде.

## Болар этиләрсез яши алмаячак

Дәрвишләр бистәсе. Поезд тукталышы. Алма төшәрдәй урын да юк. Әле яңа гына төзелгән перрон белән янәшә төзелеш калдыклары өеме. Шунда олы яшьтәге бер абзый ташландык бетон багананы тимер арбасына салырга маташа. Бар кеше шуны күзәтә. Багананың бер башын арбага куйганда икенче башы шуып төшә. Ник берсе булышсын.

Абыйның азаплануы артыкка китте. Янымда үзем укытып чыгарган бишалты егет басып тора.

—Егетләр, әйдәгез, булышабыз,—дим. Егетләр күз карашларын яшерә. Бер-икесе читкәрәк тә тайпылды.

—Борчылмагыз инде, абый. Әнә якын-тирәсендә ничаклы кеше басып тора, берсе дә булышмый бит. Нигә без булышырга тиеш,—диде берсе.

Ут йотып күзәтүемне дәвам итәм. Егетләр дә әкренләп кача тора. Янымда бер татар егете генә калды. Аңа борылып: «Энекәш, бәлкем, син барырсың. Икәү дә күтәреп сала алабыз аны, әйдә»,—дим. «Юк, бармыйм»,—дип, егетем гафу үтенә. Аннан «Ачуланмагыз инде, абый»—дип, уңайсызланып кызара.

Күршедә яшәүче таза гына урыс егетен чакырып китерәм.

—Әйдә—мин әйтәм,—син таза егет. Биш секундта күтәреп салабыз без аны,—дим. Юк. Ул да ризалашмый.

—Анда карамагыз сез, абый. Шунын белән борчылуыгыз да бетәр,—дип, әле кинәшен дә бирә. Житмәсә, янәшә басып торучы бер әби, егетләрдән сораган саен, «Барыбер бер булышучы да булмаячак»,—дип, күңелне төшереп тора. Үзем генә барыр идем, күтәрә алмам дим.

Абый тагын бер биш минут азапланды. Түзмәдем, перроннан төшеп янына бардым. Абзый үзе, әйткәнемчә, олы яшьтә. Шул сәбәпле багананың бер башыннан тотыгыз дип әйтүе дә уңайсыз. Кулымдагы кәгазьләремне бер урынга куйдым да, бисмилламны әйтеп баганага ябыштым. Ходай рәхмәте, эче куыш икән ләбаса! Перрондагы бөтен халыкны аһ иттереп, багананы бик жинел генә күтәреп арбага салдым. Аннан кулымны кар белән юып, кесәмдәге кульяулык белән корыттым. Татар бабае «икән». Рәхмәт, улым, кемдер килеп булышасын күнелем сизгән иде»,—ди. Үзе өчен дә тырышуы түгел. Урамда жыелып яткан суны жибәрү өчен шул урынга торба салмакчы икән.

Бабайга сокланып карап тордым да:

—Их, бабай, урамдагы һәйкәлләрне мин сезнең кебек кешеләргә куяр идем. Дөньяны сезнең кебекләр тартып бара да инде,—дидем.

—Улым, тартмый кая барасын. Әтидән биш яшьтә ятим калдым бит мин,—ди. Әмма анын белән озак сөйләшеп торып булмады. Үзенен килүен белгертеп, тукталышка якынлашкан поезд кычкыртты.

Мактанып сөйләвем түгел. Өлешчә үзем дә тәрбия биргән егетләр өчен борчылуым. Алар этиләреннән жиде яшьтә түгел, житмеш яшьтә калсалар да

дөньясында бер юньле эш тә майтара алмаячаклар. Мине тагын да ныграк куркытканы—тирә-якта аларга ярдәм итүчеләре дә булмаячак бит.

## Шулай да була икән...

Судта халык утырышчысы булып эшләгән чак. Аерылышырга дип бер гаилә килде. Каршыбызда курчак кебек киенгән, алтынга төренгән хатын һәм тәртипле, тыйнак карашлы ир. Икенче килүләре икән инде. Судья Гамирҗан абыйның боларны күрүгә үк төсе үзгәрде.

—Кабат килерсез дип уйламаган идем, ни җитми сезгә?,—дип сорады. Ир кеше сүз алып:

—Абый, мин тормыштан канәгать, без яхшы торабыз, мин аерылышырга теләмим,—дип сөйләп китте... Гамирҗан абый аның сүзен тынлап та бетермәстән, беразга чыгып торырга кушты. Ул чыгып киткәч, хатынга таба борылды:

—Нәрсә, кыйныймы әллә?

Тегесе хахылдап бер рәхәтләнеп көлде дә, «Юк, кая аңа кеше кыйнау, бик юаш бит ул,»—диде.

—Эчәме, акчасын алып кайтып бирмиме?

—Юк, гомерендә дә эчкәне юк, хезмәт хакының тиенен дә алып калмый.

—Алайса, ирлеге юктыр.

—Анысы да җитәрлек,—диде, кызарып та тормады хатын.

—Соң нәрсә җитми сиңа, сеңлем? Нигә аерылырга дип, икенче тапкыр гариза язып, минем башымны катырасың?

—Әй, кызык түгел аның белән яшәве, күп сөйләшми, артык тыйнак, тәртипле ул. Авыл хатыны кирәк аңа тормыш итәргә,—дип аерылу сәбәбен ачып салды хатын.

Мин боларның сөйләшүләрен тынлап, хатынның биографиясе белән танышам. Кибеттә эшли икән. Товарның дефицит чагы. Хатынның мөмкинчелекләре зур. Ир халкы белән аралашу даирәсе дә киң. Балаларының тәрбиясе дә ире кулында. Ягъни хатын ни теләсә шуны кыла, әмма шуңа да риза түгел.

Гамирҗан абый калтырый башлаган кулларын бер-берсе белән аралаштырып кысты да, хатынга чыгып торып, ирен дәшәргә кушты.

Ир кеше кергәч, «Энем, гаиләңне таркатып, балаларыңны ятим итәсең киләме?»—дип сорады.

—Юк, абый, килми,—диде тегесе.

—Минем дә сезнең гаиләне саклап каласы килә. Әмма, хатының тагын бер тапкыр гариза язса, сезне бергә калдыру хокукым булмаячак минем. Аңлыйсыңмы син шуны? Аңласаң, шул! Хатыныңны күңел ачканда бер җаен китереп тот та, кеше алдында яхшылап кыйна!... Ире кыйнаганга аерыла икән, дисеннәр. Хурлансын әзрәк! Судка бирсә, курыкма, төрмәсеннән үзем йолып калырмын.

Әнә шулай диде судьябыз. Аннан хатынны чакырып кертте дә, «Тагын өч ай вакыт бирәм сезгә, барыгыз, яхшылап уйлагыз»,—дип, боларны матур гына чыгарып җибәрде.

Мин сүзсез калдым.

Шушы очрактан соң бүтән суд утырышында катнашырга ризалыгымны да бирмәдем. Кеше өчен кайгырып йөрергә мин дә тимердән эшләнмәгән лә.

Әлеге суд тарихының ахыры ни белән беткәнен дә белмәдем. Гамирҗан абыйны да гаепләвем түгел. Теге вакытта, үз һөнәри антына каршы килсә дә, бердәнбер дөрес киңәшен бирмәде микән әле ул?!

## Язучы. Тәрҗемәче. Журналист.

Саимә Ибраһимова—танылган журналист, тәржемәче, язучы. Ярты гасырдан арткан иҗат гомерендә аның тарафыннан тәржемә ителгән дистәләрчә китаплар дөнья күрде. Казан педагогия институтының филология факультетын тәмамлаган яшь белгеч үз иҗатын әдәби әсәрләрне татар теленнән русчага тәржемә итүдән башлый. Аның тәржемәсендә А. Әхмәт, Г. Бакир, Д. Аппакова, А. Алиш, Л. Ихсанова кебек балалар язучыларының кайбер әсәрләре аерым китапларда һәм җыентыкларда дөнья күрде. Әмма С. Ибраһимованың әдәби тәржемә өлкәсендәге иҗади уңышлары күбрәк рус язучыларының һәм, рус теле аша, Көнбатыш Европа язучыларының проза әсәрләрен татарчага тәржемә итү белән бәйле. Аерым алганда, И. Ефремовның «Андромеда томанлыгы», Я. Казакның «Марьяна Радвакова», Р. Стивенсонның «Кара ук», С. Григорьевның «Александр Суваров», А. Чеховның күп кенә хикәяләре татар укучысына С. Ибраһимова тәржемәләре аша иреште. Аның кайбер тәржемәләре «Казан утлары» журналында да басылды.



Ибраһимова, тәржемәче булудан тыш, тәҗрибәле журналист һәм мөхәррир. Үз вакытында ул Татарстан китап нәшриятында, «Азат хатын» журналында эшләде. Әмма аның иң озак эшләгән һәм зур хезмәт куйган урыны—«Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы булды. Ул анда башта әдәби хезмәткәр, аннары әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, соңрак редакциянең җаваплы секретаре вазифаларын башкарды. Ул елларда бу газета бик күп яшь язучылар өчен төп иҗат мәйданы булды. Беренче шигырь-хикәяләрен «Яшь ленинчы»да бастырган яшьләр соңрак татар әдәбиятының төп көчләренә әверелде. Аларның бу уңышларында Саимә Ибраһим кызының да өлеше зур булды.

1974 елда журналистика өлкәсендәге хезмәтләре өчен Саимә Ибраһимовага Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бирелә, 1977 елда ул СССР Язучылар союзына әгъза итеп кабул ителә.

Саимә Ибраһимова соңгы елларда «Сөембикә» журналында эшләп, татар дөньясының күренекле шәхесләре белән әңгәмәләр үткәреп, укучылар өчен кызыклы язмалар бастырды. Шушы редакция канаты астында мәшһүр ханбикәгә багышланган «Сөембикә ханбикә» исемле С. Ибраһимова төзегән җыентык дөнья күрде. Бу җыентыкка Сөембикә хакындагы тарихи, фәнни хезмәтләр, бәяннар, әдәби әсәрләр, әсәрләрдән өзекләр тупланган. Тиздән Татарстан китап нәшриятында аның яңа китабы чыгачак.

Бу айда Саимә Ибраһимовага 80 яшь тулды. Без ана исәнлек-саулык, иҗат шатлыклары телибез.

## Язучының яшен сорамыйлар

Гадәттә, укучылар белән булган очрашуларда язучыларга еш кына бер сорауны бирәләр: Ничек язучы булып киттегез? Язучы буласы килү теләге кайчан туды? Шикләнмим, бу сорауны Гөлчәчәк Галиева да еш ишетәдер. Әле беренче китаплары «Тулгак» (2001), «Өзелгән өмет» (2003) басылып чыккач та очрашулардан кайтып керми ул. Яңа язучының үзен дә, әсәрләрен дә әдәбият сөючеләр яратып кабул итте. Матур йөгерек тел, тормышның үзеннән алынган вакыйгалар аның әсәрләрендә. Ни дип җавап бирә икән Гөлчәчәк Галиева ул сорауларга? Бәлки, Арча районының Сеҗе авылында туып-үсеп, әле хәреф тә танымаган бер чакта әтисе—күренекле мәгърифәтче, әдәбият укытучысы Кәрим Яхин кечкенә кызчыгына әкиятләр укыганда дипме? Яисә Арча педучилищесында бик күп әлифбалар авторы Рәмзия Вәлитова дәресләрен тыңлаганда, бәлки, инде туган авылына укытучы булып кайткач, булачак ире Әхмәт белән авыл сәхнәләрендә М. Фәйзинең «Галиябану»ын уйнаганда: «Их, шушындый әсәрләр язсаң иде, дип хыялланган идем»,— дипме? Бәлки, кияүгә чыгып (1951) әдәбиятыбыз мәркәзе булган Казан шәһәренә күчеп, тагын да зуррак дөньяга килеп кергәч, инде шәһәр мәктәбе шартларында балаларга белем бирә башлагач, укучылар белән теге яки бу әсәрне анализлаганда автор белән килешмичә, эчтән генә: «Мин бу әсәрне башкачарак язган булыр идем»,—дип уйланып йөргәндә тугандыр ул уй. Бәлки, нәсел буенча килгән зыялылык, укымышлылык, сәләт үзенең вакыты җиткәнен сабыр гына көткәндер. Ә Галиҗәнап Вакыт аңа мәрхәмәтле була.



...Аһ, бу күңелендә иҗат уты янган хатын-кызның язмышы! «Тәүлегенә нигә егерме дүрт кенә сәгать икән»,—дип ул да аз көрсенмәгәндер. Әле ул вакытта хәзерге кебек бәлешен, өчпочмагын, хәтта ашына кадәр пешереп сата торган сәүдә үзәкләре дә, үтүкләп үк чыгара торган чит ил кер юу машиналары да юк бит. Хәер, булса да, бәлки, Гөлчәчәкнең аларга исе китмәс иде. Күңел җылысын кушып пешергәнен ашатыр, үз куллары белән юганын киертер иде ул кадерлеләренә. Унҗиде ел бергә яшәгән кайнанасының көнгә унҗиде тапкырдан ким әйтмәгән: «И кызым, бигрәкләр дә уңгансың, Әхмәтемнең бәхетесең,—дигән бәһасе әллә-нинди әдәби премияләрдән дә өстенрәк була аңа.

Республикада гына түгел, Рәсәй күләмендә дә танылган Компрессорлар заводы директоры Әхмәтен эшкә, ир балаларын укырга озаткач, бәлки, иҗат итәргә вакыты калыр иде дә, юк шул, әле аның җилкәсендә тагын бер олы вазифа: Ул 18нче рус-татар эшче яшьләр мәктәбе директоры. Мондый мәктәпләрдә гади мәктәпләргә караганда авырлыклар, проблемалар икеләтә күбрәк. Укучылары да бит, кайсы инде үзе әти-әни, кайсыбере укуга әлләни исе китмәүчеләр, һәрберсенең көнкүреш табасы, мәктәбенең түбәсен ябтырасы, дигәндәй. Өстәвенә әле күпме җәмәгать эше! Татар теленә, тарихына, әдәбиятына каршы ачыктан-ачык көрәш барганда әлеге фәннәрне укытуның никадәр авыр булганын да ул чор укытучылары үзләре генә беләләрдер. Туган телебезнең бүгенге көнгә кадәр сакланып кала алуында, татар әдәбиятының талантларга бай булуында аларның да өлеше зур. Әгәр дә 18нче кичке мәктәптә Гөлчәчәк Галиева кебек фидакарь зат урынында татар халкына, әдәбиятына битараф башка берәү булса, белмим, фаҗигагә юлыккан Фәнис Яруллинның хастаханәгә килеп дәрес бирүләр оештырылыр идеме икән?

Ниһаять, әдәби-публицистик һәм тәнкыйть язмалары белән татар әдәбиятында

Гөлчәчәк Галиева исеме күренә башлый. Ничәмә-ничә еллар әдәбият белән янып-көеп яшәп, киләчәк өчен, телебез, милләтебез өчен чын күнелдән борчылып язылган язмалар бу. «Көнем өчен түгел, халкым өчен»,—дип иҗат итүче шәхесләр турында язарга ярата ул. Халкыбызның күренекле уллары Ф. Яруллин, Н. Фәттах, Т. Мөбәрәков, Т. Якупов турында ул язмалар. Әлеге мәкаләләр «Мәгариф» нәшрияты чыгарган «Күнелемә якын затлар» исемле (2007) өр-яңа җыентыкта да урын алган.

Әйе, әдәби эшчәнлеген тәнкыйть язмалары белән башлаган язучының үз-үзенә дә таләбе икеләтә булырга тиеш. «Тулгак», «Өзелгән өмет» повестьларында, «Барсам», «Энәле гөл» хикәяләрендә, эсселарында Г. Галиеваның бу таләпне һич киметмичә, тагын да арттыра гына төшүен күрәсең. Темаларны сайлый, заманча сурәтләр белән баета белә ул. «Тулгак» исемле беренче китабының «Ел китабы» конкурсында (2001) икенче урынны алуы да тиккә генә түгелдер. Һәр әсәрнең үзәгендә—хатын-кыз язмышы, бәхете, фаҗигасе. Нечкә күңелле, сизгер йөрәкле, тирән кичерешләр белән яши белә торган кешеләр аның героинялары. Инде хәзер укучылар «Газзәбану» повестеның китап булып чыгуын көтәләр. Кайбер газета-журналларда өзекләре басылганнан соң әсәрнең дәвамын, ничек тәгаллләнүен беләсе килеп чит төбәкләрдә яшәүчеләрдән дә хатлар ала ул. 1921 елгы ачлык китергән вакыйгалар аша кешеләрнең бер-берсенә булган кешелекле мөнәсәбәте, халкыбызның гореф-гадәтләргә бай тормышы сурәтләнә ул әсәрдә.

Гаиләдә дә ир белән хатын булып кына түгел, чын мәгънәсендә җандаш, фикердәш булып гомер итәләр алар. Бөтен вакытын казна эшенә багышлаган Әхмәт Галиевнең дә мәдәният хәлләрен кайгыртырга җай таба алуында Гөлчәчәк Галиеваның роле зур була. Мамадышта Шәйхи Маннурга һәйкәл куйдыруда да алар башлап йөри. Төрле газета-журналларның, язучыларның юбилейлары алардан башка үтми. Юк, әдәби кичәләргә, концерт-тамашаларга ял итеп кайтыр өчен генә килмиләр, Әхмәт Галиев күп кенә кичәләрнең кайгыртучысы, хәл кадәри матди яктан тәэмин итүчесе дә була. Юмарт, кешеләрне сөендерәсе килү кебек кин күңеллелеккә ия була алу сыйфатлары да күпләргә бирелми шул. Шагыйрь әйтмешли, без күп күрдек филдәй кешеләрне. Галиевләр беркайчан да: «Без фәлән кешегә төгән яхшылыкны эшләгән идек»,—дип сөйләп тә йөрмиләр. «Изгелек җирдә ятмый!»—менә аларның тормыш девизлары.

Кайчандыр ире янәшәсендә завод директоры Әхмәт Галиев хатыны буларак таныштырылса, бүген исә, киресенчә, очрашуларда Әхмәт абыйны язучы Гөлчәчәк Галиеваның ире буларак кабул итәләр. Әхмәт абый исә шат, Гөлчәчәгенең әсәрләрен укучылар яратканга, зурлауларына, хатынының язучы бәхетенә ирешә алуына чын күңелдән сөенә. Ил-көндә—гамәлен, кулында—каләмен, янында—хәләлен нур чәчеп торганда картлык та шатлыкка әйләнә ала шул.

Язучының яшен сорамыйлар. Нинди дер арифметик саннар белән билгеләнергә тиеш түгел ул. Язучының яше—аның узган һәм киләчәк гомере—язган һәм язылачак әсәрләрендә. Без исә сездән тагын да яңа-матур әсәрләр көтеп калабыз, Гөлчәчәк апа!

**Гөлзадә БӘЙРӘМОВА**

## Фатих Сәйфи-Казанлының туууна 120 ел

Фатих Сәйфи-Казанлы (Мөхәммәтфатих Камалетдин улы Сәйфуллин) 1888 елның 22 мартында элеккеге Спасс өязенең Карамалы авылында (хәзер ул Татарстанның Әлки районына керә) урта хәлле игенче гаиләсендә туган.

Булачак әдип гыйлем алуын Казан мәдрәсәләрендә башлый. Ераkларга даны таралган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый. Берникадәр вакыт Минзәлә өязендәге җәдит мәктәпләрендә укытканнан соң, 1906 елда Казанга кайта. Нәкъ менә шушы елларда ул язучылык-журналистлык эшенә керешә. 1912 елдан 1918 ел башына кадәр Уфада яши, берничә ел биредәге «Галия» мәдрәсәсендә тарих фәненнән гыйлем бирә.

Ф. Сәйфи-Казанлының 1906-17 елларда «Йолдыз», «Тормыш», «Ан», «Ялт-йолт», «Мәктәп» һәм «Ак юл» кебек гәзит-журналларда әдәби тәнкыйть һәм публицистикага караган байтак мәкаләләре дөнья күрә. Баштарак язмаларына ул Ф. Камалов, Исәнбай, Гареб, Бакыр күз, Батыр күз, Чәпи Камали малае дигән тәхәллүс (псевдоним) куйса, сонрак исә һәрдаим Фатих Сәйфи-Казанлыга күчә.

Октябрь инкыйлабына кадәр ул «Мөкатдәс хезмәт» (1907), «Безнең заман» (1909), «Ямьсез тормыш» (1915), «Җәмәгать хадиме» (1916) кебек пьесалар язып, драматург буларак та таныла.

Инкыйлабтан соң исә Ф. Сәйфи-Казанлы сәяси һәм иҗтимагый эшчәнлеккә чума. Башта Уфада татар эсерлары (социалист-революционерлары) гәзите «Ирек»нең мөхәррир-нәшире була, ә 1912 елның гыйнварында, Казанга кайткач, эсерлар белән арасын тәмам өзеп, Мулланур Вахитов җитәкчелегендәге Үзәк Мөселман комиссариатында эшли башлый. Бер үк вакытта ул татар-башкорт хәрби мәктәбендә тарих һәм иҗтимагый фәннәр дә укыта. Беренче татар совет гәзитләре «Эшче» һәм «Эш»тә публицистик язмаларын бастыра. Ул Мәгариф, Җир эшләре комиссариатларында җаваплы вазифалар башкара. 1923-25 елларда «Кызыл Татарстан»да (бүген—«Ватаным Татарстан» гәзите), «Крәстиян гәзите»ндә баш редактор булып эшли. Шул елларда ул татар алфавитын гарәп графикасыннан латинчага (яңалифкә) күчерү эшенә актив катнаша башлый. Татарстан Яңалиф җәмгыятенең беренче рәисе итеп тә билгеләнә. 1930-32 елларда «Яңалиф» журналының җаваплы редакторы була. Сүз уңаеннан, Татарстан мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылары оешмасының айлык әдәбият, сәясәт, сәнгать һәм тәнкыйть журналы буларак чыгарылган «Яңалиф»—хәзерге «Казан утлары»ның «Безнең юл»дан соңгы дәвамы. Журналыбыз бу исемдә латин имласында 2000-2200 данә тираж белән 1932 елның азагына кадәр чыккан.

Ф. Сәйфи-Казанлы үз чорының әдәби хәрәкәтендә бик актив катнаша, татар классик әдәбиятын өйрәнү һәм аны халыкка җиткерү буенча да зур эш башкара. 1929-31 елларда ул Г. Тукайның—өч, Г. Камалның—ике томлык җыентыкларын төзеп чыгара. 1930 елда исә аның «Өч татар классигы турында» (С. Сүнчәләй, Г. Камал һәм Ф. Әмирхан) дип аталган китабы нәшер ителә. Әдипнең бу чорда иҗат ителгән проза әсәрләрендә: «Елан токымы» (1931), «Кызыл эшелон» (1932), «Беренче адымнар», «Корбый иптәш» (1933) исемле хикәя һәм повестьларында үз заманы ачык чагыла.

...Әнә шулай киләчәккә зур өметләр баглап, җиң сызганып, иҗат дәрте белән янып йөргәндә генә... 1937 ел килеп җитә. Ни кызганыч, әдипнең зур иҗат планнары тормышка ашмый кала—ул репрессия капкынына эләгә. Әдипнең гомер юлы 1938 елның 5 августында өзелә.

♣

## Нәҗип Мадъяровның тууына 80 ел

Шагыйрь Нәҗип Гәрәй улы Мадъяров 1928 елның 3 мартында Арча районы Кызыл Утар авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туган. 1943 елда Кызылъяр авылындагы җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул үз колхозлары бухгалтериясендә хисапчы булып эшли. 1950-53 елларда армия хезмәтендә була. Аннан тагын туган авылына кайта һәм эшеннән аерылмыйча укып, 1956 елда бухгалтерларның ел ярымлык курсларын, ә тагын бер елдан Яна Кенәр урта мәктәбен тәмамлый.

1957 елда Н. Мадъяров Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Дүртенче курстан читтән торып уку бүлегенә күчеп, 1960-63 елларда Кызыл юл районында чыккан «Кызыл юл» газетасында, ә 1963 елдан, районнар берләшкәч, Арчаның «Коммунизмга» газетасы редакциясендә авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире булып эшли. Аннары Лениногорск шәһәренә күчеп китеп, яңа ачылган телевидение студиясенә хәбәрче булып урнаша. 1965—1980 елларда Балтач районының «Хезмәт» газетасы редакциясендә редактор урынбасары һәм авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире була. 1980 елда Нәҗип Мадъяров Чаллы шәһәренә күчеп килә һәм әдәби иҗат белән шөгыльләнә.

Н. Мадъяровның тәүге шигырьләре «Кызыл юл» район газетасында узган гасырның илленче еллары башында ук күренә башлый. Беренче шигырьләр җыентыгы—«Чык бөртекләре» 1960 елда басылып чыга. Аннан соң бер-бер артлы «Син генә уйларымда» (1963), «Ужымнар уянганда» (1964), «Чәчәк күрдем» (1969), «Җәйге яңгыр» (1970), «Йөз төрле уй» (1976) һ. б. шигырь китаплары дөнья күрә. Балачагын, яшьлеген авылда үткәреп, гомеренең күпчелек өлешен үз авылы, район тормышы белән бәйләгән шагыйрьнең иҗатында авыл темасы төп урынны алып тора. 1979 елны аның иҗат йөзен билгели торган төп әсәрләре тупланган «Рәшәле офыкларым» исемле зур гына җыентыгы басыла. Шул ук елны Нәҗип Мадъяров Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителә.

Шагыйрь балалар өчен дә күпсанлы шигырьләр, әкиятләр язды. Урта һәм кече яшьтәге балалар өчен аның дистәгә якын китабы дөнья күрде: «Ялкын ялды кара айгыр» (1966), «Ямьле кыш» (1971), «Утлы кыя» (1978), «Салават күпере» (1988), «Әби күзлеген эзли» (1997), «Ел айлардан җыела» (2001) һ. б.

Н. Мадъяров юмор-сатира жанрында да нәтиҗәле эшләде. «Көлке тоенчеге» (1985), «Әптән Гәрәе мәзәкләре» (1999), «Көлке көлтәсе» (2000) һ. б. китапларында аның юмористик хикәяләре, фельетоннары, мәзәкләре тупланган. Моннан тыш вакытлы матбугатта да аның шигырьләре, әдәби язмалары, юмореска-хикәяләре даими басыла килде.

Иҗат дәверендә шагыйрьнең төрле жанрларга караган ике дистәдән артык китабы дөнья күрде.

Нәҗип Гәрәй улы Мадъяровка 1991 елда «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

Н. Мадъяров 2002 елның 15 апрелендә вафат булды.

♣

# Д

**ДАВЫДОВ** Әнвәр Мортаза улы (23.3.1919, Самара губ. Камышлы ав. – 23.6.1968, Казан), шагыйрь. 1936 елдан Новосибирск шәһәрендә "Советская Сибирь" газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли. 1938 дә "Ферганская правда" (Үзбәкстан ССР) газетасында. 1939-40 Мордва АССРның Ләмбрә р-ны урта мәктәбендә рус теле һәм тарих фәннәрен укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша. Армиядән демобилизацияләнгәннән соң (1946) Камышлыга кайта, "Югары уңыш өчен" исемле район газетасында редактор булып эшли. 1952 дә Казанга килә. 1953-55 елларда ТАССР Язучылар берлегендә җаваплы сәркатип. "Беренче бөртек" дигән поэмалар, шигырьләр җыентыгы 1950 басылып чыга. Ул "Ташу" (1956), "Тормыш лирикасы" (1959), "Кеше бәхете" (1964), "Себер тракты" (1967), "Дәверләр диалогы" (1969; русча тәрҗемәдә "По законам марша", М., 1974) дип исемләнгән шигырьләр һәм поэмалар җыентыклары авторы. Д.ның күп шигырьләре революцион романтика, гражданлык пафосы белән сугарылган; ул Бөек Ватан сугышы елларында совет кешеләренең батырлыгы, дуслыгы, туганлыгы турында яза. Поэмалары фәлсәфи мәгънәнең тирәнлеге, образлылык белән аерылып тора. "Чорлар чатында" (1961) поэмасы һәм "Йокысыз төннән соң" (1972) роман-симфониясендә автор үз чорының әһәмиятен, заман рухын чагылдырырга омтыла. Лирикасына күтәренке рух хас. Метафораларның күплеге, төгәл ритмика, тәэсирлелек – Д.ның иҗади манерасын характерлаучы билгеләр. Д. балалар өчен дә иҗат итте. Аның Муса Җәлилнең сугышчан юлы һәм батырлыгы турындагы "Муса абый" (1964; русчага тәрҗемәдә 1966) повесте балаларга аеруча таныш. Д.ның күп кенә шигырь һәм поэмалары рус теленә тәрҗемә ителеп нәшер ителгән.

Әсәр.: Кояшлы көн хакына. К., 1979; Түгәрәк бәхет. К., 1984.

Әд.: Юзиев Н. Нурлы поэзия // Шигърият дөньясы. К., 1981.

*Р.А.Мостафин.*

**«ДАСТАНЫ БАБАХАН»**, 15 йөз (бүтән мәгълүматларга караганда 18 йөз) татар әдәбияты ядкаре. Авторы – төркитатар шагыйре Сәйяди. «Д.Б.»ның сюжеты нигезендә Шәрекъ дөньясында киң таралган Таһир-Зөһрә мәхәббәте ята. Дастан вакыйгалары Бабахан шаһ идарә иткән легендар Татар шәһәрендә бара. Аның Зөһрә исемле кызы вәзир Баһирның улы Таһирны ярата. Ярсыган шаһ Таһирны сандыкка салып зур дәрьяга агызырга әмер бирә. Бик зур кошлар сандыкны ярга алып чыгалар. Исән калып, Таһир Багдадка килә һәм шәһәр идарәчесе кызы Маһымга өйләнә, ләкин аның 6-н дустанә мөнәсәбәттә булып, Зөһрәгә җиде ел дәвамында тугрылыклы булып кала. Соңыннан ул үзенең сөеклесенә әйләнеп кайта Бабахан, моны белгәннән соң, Таһирны җәзалап үтертә. Шуннан соң Зөһрә, аны яраткан Кара Баһадир һәм Таһирны яраткан Маһым дөнья куялар. Аларның каберләрендә гаҗәеп матур чәчәкләр үсеп чыга. Былбыллар, Багдадка һәм Татарга очып килеп, гашыйкларның фаҗигале язмышлары турында җырлыйлар. Тора-бара бу вакыйга бөтен дөньяга мәгълүм була.

Әсәр эпик жанрга карый, үз ишләренә хас кайбер гарәп-фарсы алынмаларын искә алмаганда, теле бүгенге татар укучысына нигездә аңлаешлы. «Д.Б.» татарлар арасында сөйләм һәм язма рәвешендә таралган. Татарстан территориясендә дастанның 18-19 йөзләрдә татар каллиграфлары тарафыннан күчерелгән дастанның 5 нөсхәсе табыла. Иң тулы нөсхә 1818 елда Куян авылында (урыны билгесез) Йосыф мулла кызы Бибигамбәр тарафыннан күчерелгән. Ул РФА Шәрекъне өйрәнү ин-тының С.-Петербург бүлеге архивында саклана. Дастан шул нөсхә нигезендә 1998 дә дөнья күрә.

Хезм.: Сәйяди. Таһир-Зөһрә (Бабахан дастаны). К., 1998.

Әд.: Ахметзянов М.И. Татарские версии сюжета «Тахир – Зухра» // Средневековая татарская литература (VIII-XVIII вв.). К., 1999; Ахметова-Урманче Ф.В. «Дастан-и Бабахан» Сайяди // шунда ук. 114-118 б.; Хисмәтуллин Х. Гаделлек һәм мәхәббәт поэзиясе («Дастан Бабахан» әсәренә 550 ел тулу уңае белән) // Казан утлары. 1965. №7.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ДАУТОВ** Рәис Нәүширван улы (15.3.1928, Мамадыш кантоны Шәмәк а. – 28.08.2007, Казан), тәрҗемәче, библиограф, текстолог, ТАССРның атказ. мәдәни-

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

ят хезмәткәре (1978). Казан укытучылар ин-тын (1948) һәм Казан пед. ин-тын (1963) тәмамлый. 1953-93 елларда Татарстан китап нәшриятында мөхәрир булыр эшли, 1992-2003 тә ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында татар тексты мөхәррирләре төркеме җитәкчесе. Татар теленә М.Твенның «Янки король Артур сараенда» («Янки при дворе короля Артура», 1958), Ф.Куперның «Соңгы могикан» («Последний из могикан», 1962), М.Галәүнең «Мөһаҗирләр» («Мухаджиры», 1968), Ф.М.Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» («Преступление и наказание», 1974) романнарын, А.И.Купринның хикәя һәм повестьларын («Повестьлар», 1988), Р.Солнцевның «Көймә ватылса — утын» («Лодка пойдёт на дрова», 1978) повестен, О. Генри новеллаларын, Э.Хемингуэй хикәяләрен тәрҗемә итә. «Совет Татарстаны язучылары» (1986, Н.Б.Нуруллина б-н берлектә) биобиблиографик белешмәсенең төзүче авторы. И.Г.Рәмиевның кульъязмаларын тулыландырып «Әдәби сүзлек» китабын бастыра. З.Бигиев, И.Рәмиев, Р.Төхватуллин, Әнәс Камал, М.Галәү, репрессияләргә дучар булган татар язучылары турындагы мәкаләләр авторы. Дәрдемәнд («Исә җилләр», 1980), Г.Тукай («Шигырьләр һәм поэмалар» — «Стихотворения и поэмы» Л., 1988) әсәрләрен текстологик яктан әзерләүдә катнаша. З.Бигиев («Зур гөнаһлар», 1991), С.Максуди («Мәгыйшәт», 1994; «Англиягә сәяхәт», 1995), Ф. Кәрими («Истанбул мәктүбләре», 1999) әсәрләрен басмага әзерли (кереш сүзләр, искәрмәләр, аңлатмалар яза). Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә. ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2005).

Әд.: Гамбәр Н. Учак җылысы // Казан утлары. 1978. №3; Юныс М. Чишмәләрнең сафлыгы // шунда ук. 1988. №3; Фәйзуллин Р. Тирәбездә яхшы кешеләр // Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т.4.

**ДӘРЗАМАНОВ** Җәүдәт Харис улы (13.10.1945, Лениногорск р-ны Сугышлы авылында туа), язучы, җәмәгать эшлеклесе, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1972). 1971 елдан (өзеклек белән) "Татарстан" ДТРК ндә башта тапшырулар редакторы, 1999 дан әдәбият-сәнгать һәм музыкаль тапшырулар директоры булып эшли. 1988-94 елларда "Ялкын" ж-лы мөхәррире. Д.ның беренче шигырьләре 1960 еллар башында район газеталарында басыла башлый. Күбрәк балалар һәм яшьләр өчен яза. "Солдат булдым" (1977), "Төнге мажара" (1980), "Гөлназ мәктәпкә бара" (1983), "Безнең әлифба" (1985), "Илләр гизә Илгизәр" (1989), "Айбулат" (1991), "Күзле кычыткан" (2000) исемле шигъри җыентыклар авторы. "Җир авазы" (1987; русчага тәрж. "Зов земли", 2002), "Бизмән йолдызлыгы" (1994) повестьларының сюжет сызыгына фантастик элементлар да кертелгән; язучы монда әхлаклы, кешелекле, бер-береңә карата түземле булырга кирәк дигән карашны алга сөрә. Д. 2002-2004 елларда Татар интеллектуаль милек агентлыгы идарәсе рәисе.

Әд.: Баттал Ф. Егетлекнең бер баскычы // Мәдәни җомга. 1985. 3 ноябрь; Галимуллин Ф. Илле яшьлек сабый // Ватаным Татарстан. 1995. 28 ноябрь.

**ДӘҮЛӘТША ИШАН** (Дәүләтша бине Гаделша, Фазылша) (1767, фаразлар буенча Уфа губ., Эстәрлетамак өязе, хәзер Башкортстан Республикасы, Эстәрлебаш р–ны Эстәрлебаш а. — 3.12.1832, Оренбург өязе Түбән Чебенке а.), язучы, дин эшлеклесе. Каргалы бистәсе һәм Бохара мәдрәсәләрендә белем ала. Укып кайткаккан соң Кышкар, Югары Бирәзә (хәзергә Арча р-ны) мәдрәсәләрендә мөдәррис булып тора. 20 елга якын танылган татар дин эшлеклесе Габденнасыйр Курсави б-н бергә Казан өязе Югары Курса мәдрәсәсендә укыта. 1821 елда Оренбург губернасына күчеп килеп, укыту эшчәнлеген дәвам иттерә. Түбән Чебенке авылы мәчетендә имам була. Бохарада укыган елларында Ниязколый әт-Төркмәни шәкерте булып, аннан мөридләрне укытуга рөхсәт алган дигән фараз бар. Кульъязма рәвешендә сакланган динидидактик эчтәлекле «Рисаләте нәҗатийә» хезмәте авторы. Курсавине яклап язган хезмәте булуы мәгълүм. Д.И.ның вафатына багышлап аның шәкерте Һ.Салихов ике мәрсия яза.

Әд.: Искандаров Р.Ш. Верхние и Нижние Чебеньки. Самара, 1999; Фәхретдин Р. Асар. Оренбург, 1904. 1 том, 6 җөзья; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989.

*М.В.Гайнетдинов.*

*Дәвамы киләсе саннарда*

## Рафаэль Хәкимов

Хәкимов Рафаэль Сибгат улы 1947 елның 12 февралендә Казанда, шагыйрь Сибгат Хәким гаиләсендә туа. 1970 елда Казан университетының физика факультетында укып, радиофизика белгечлеге буенча диплом ала. 1971-73 елларда Таттранс идарәсендә өлкән инженер булып эшли. Техник белем иясе булса да, аның хезмәт эшчәнлеге, нигездә, гуманитар сферада—сәяси-фәлсәфи юнәлештә үсә. Ул озак еллар Казан университетында һәм культура институтында укыта. Мәскәү университетының философия кафедрасында стажировка үтә. Диссертация яклап, философия фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. 1989-91 елларда КПСС өлкә комитетының идеология бүлегендә эшли. 1991 елда Р. Хәкимов Татарстан Президентының сәяси мәсьәләләр буенча дәүләт киңәшчесе итеп билгеләнә һәм хәзергәчә шул вазыйфаны башкара. Параллель рәвештә, 1996 елдан ул—Татарстан Фәннәр академиясе каршындагы Тарих институты директоры да.



Үткән гасырның 90 нчы елларыннан башлап Р. Хәкимов эшчәнлеге Татарстанның Россиядә һәм дөньядагы сәясәте белән бәйле. Шушы 15-20 ел эчендә ул,бик күп илләрдә булып, күпсанлы халыкара җыеннарда, Татарстанның сәяси мәнфәгатьләрен яклап чыгышлар ясады, мәкаләләр бастырды, китаплар чыгарды. Аның Россиядәге федерализм мәсьәләләренә караган хезмәтләре аерым әһәмияткә ия.

Рафаэль Хәкимов иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенең кайбер сәхифәләре: Татарстанның Дәүләт суверенитеты декларациясе әзерләүчеләрнең берсе; Татарстан белән Россия арасындагы Шартнамә әзерләү комиссиясе әгъзасы; Чечен Республикасы белән конфликтны бетерү буенча оештырылган РФ дәүләт комиссиясе әгъзасы... Ул, шулай ук, Россия Конституциясен әзерләүдә Татарстан вәкиле булып катнашты. Бүгенге көндә дә «Россиядә федерализм үсеше перспективалары» проекты авторы... Соңгы елларда Тарих институтында татар халкының тарихына багышланган дистәләгән фундаменталь китаплар чыкты. Аларның дөнья күрүендә Р. Хәкимовның өлеше зур.

Рафаэль Хәкимов—төрле нәшриятларда басылган «Метаморфозы духа» (К вопросу о тюрко-татарской цивилизации), «Где наша Мекка?», «Смешная политика» һ. б. китаплар авторы. Журналыбыз авторы буларак, аның кайбер әсәрләре безнең «Казан утлары» журналында да дөнья күрде.

Аның балачагы язучыларның Аккош күле буендагы дачада үтә, ә соңгы егерме елда Идел ярындагы Боровое Матюшинода яши. Ул—Татарстанның җилкәнле спорт буенча федерация президенты.

Рафаэль Хәкимов—сәяси һәм тарихи темаларга язучы публицист буларак, 2007 ел ахырында Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

## Гөлфия Исхакова

Соңгы елларда Язучылар берлеге, гомумән әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан, Татарстаннан читтә яшәүче авторларга игътибар көчәя төште. Язучылар сафына әгъза итеп Башкортстан, Пермь, Төмән, Ульян һ. б. төбәкләрдән төрле яштәге, төрле хезмәттәге каләм ияләре кабул ителде. Байтак шигырьләр һәм Ижау басмаханәләрендә чыккан китаплар авторы Исхакова Гөлфия Заһит кызы да әнә шундыйлардан.



Ул 1957 елда Татарстанның Әлмәт районы Кәләй авылында туган. Соңрак Лениногорск районының Мөэмин Каратай авылында яши һәм урта мәктәпне шунда тәмамлый. Гомеренең төп өлеше Удмуртиянең Воткинск шәһәре белән бәйле: гаилә, эш, иҗат... Гөлфия Исхакова шигъряткә зур хезмәт юлы үтеп килгән кеше. Ул Воткинск машина төзүчеләр техникумын тәмамлый, озак еллар заводта техник-технолог булып эшли. Үзгәртеп кору еллары килгәч, ул татар иҗтимагый хәрәкәтенә кушыла, милли юнәлештәге мәдәни чараларда актив катнаша. Биш ел дәвамында «Юбилейный» исемле мәдәният йорты каршындагы «Дуслык» ансамбленең җитәкче урынбасары була, ә 1993 елны үзе «Тургай» дигән ансамбль оештыра. 1994 елдан республика күләмендә татар телендә чыга башлаган «Янарыш» газетасына килә һәм хәзер дә шул редакциядә эшләвен дәвам итә. Актив иҗат эше белән шөгыльләнә башлавы да шул елларга туры килә. Күпчелек шигырьләре иң әүвәл шул «Янарыш» газетасында дөнья күрә дә. Соңрак кайбер шигырьләре, җырлары «Мәдәни җомга» газетасында, «Казан утлары», «Идел» журналларында басыла башлый.

2002 елда Гөлфия Исхакованың Ижау шәһәрендә «Язларыма кайтам» дигән шигырьләр китабы чыга. Китапка кереш сүзне шул төбәкнең шигъри аксакалы Риза Шәфи язган. Ә үткән ел шул ук Ижауда Г. Исхакованың—«Ак моң алып каеннардан» дигән икенче китабы дөнья күрде.

2007 елның декабрь аенда, Кабул итү коллегиясенең карары нигезендә, Татарстан Язучыларының идарә утырышында Исхакова Гөлфия Заһит кызы Татарстан Язучылар берлегенә (тәкъдимнамә бирүчеләр—Фирая Зиятдинова, Шаһинур Мостафин, Ләйсән Кәшфи) кабул ителде.

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

*Ак җилкән*


Рәйсә
ЮСУПОВА


# ТЭТЧЕР МАҖАРАЛАРЫ

Үкерә-үкерә, улый-улый Серго маэмайны тәрәзәдән томырды.

Тәрәзә аша очкан мизгелдә Тэтчер купе уртасында, проводница кочагында үзе әле генә намусын саклап калган кызның яшьле күзләрен күреп алды; ачык ишек янына җыелган кешеләрне дә шайләргә өлгерде ул.

## Табылдык

...Мәрьям ханым, гаепле кешедәй, янә кабатлады:

—Өлгермәдем... Мин купе ишеген ачканда әзмәвердәй адәмнең көчекне тәрәзәдән томырган чагы иде инде.

—"Өлгермәдем" диюегез... ул—кыз балага кагыламы?



—Юк-юк! Нык кына курыккан булса да кыз бала, Аллага шөкер, сау-сәламәт калды. Поездыбыз Казанга кергәнче минем ятагымда йоклады. Ә менә аны коткаручы көчек...

Йөрәгем кысылып куйды, һава җитми башлады. Шулай да:

— "Көчек"?!. Аңа... ни-нәрсә булды аңа?—дия алдым.

—Жәл бит... Шундаен акыллы җан...—Мәрьям ханымның күзләре яшьләнде.—Алагаем томырды бит теге адәм... Ул төш урманның бик куе урыны. Берәр агачына бәрелгән булса... Ходай гына сакласын инде үзен!..

Мин җиңел сулап куйдым. Әүвәл курку салган өзек-өзек сүзләре өчен дә, маэмаем язмышына битараф булмавы, алай гына да түгел, хафаларга төшеп кайгыруы өчен дә ханымга күңелемнән генә рәхмәт укыдым. Инде үзен дә тынычландырырга ашыктым:

—Борчылмагыз,—дидем.—Беләсезме, аңа туганда ук фәрештәләр канат җәйгән.

Һәм мин Мәрьям ханымга Тэтчерымның дөнья белән «танышкан» беренче көнен тасвирлап бирдем.

—Безнең өстә, дүртенче катта, Галимҗан агайлар гаиләсе яши. Пенсия яшендә булуына карамастан, агай үзе көр күңелле, җитмәсә әле эшләп тә йөри—балта остасы. Февраль азагының бик тә салкын, әче буранлы бер кичендә менә шул күршебез кордашының хәл-әхвәлен белеп кайтырга ниятли. "Төнгә каршы кая барасың, карт җүләр?! Үзәккә үтә торган мондый ачы җилдә, кырык градус суыкта җүнле кеше этен дә өеннән чыгармый. Җөрмә!"—дип ялына карчыгы. "Эчем поша—күптәннән күрешкән юк,—ди Галимҗан агай таягына үрелеп.—Ә син борчылма. Ерак ара түгел бит; турыдан, ишек алларын аркылыга кискән сукмаклардан гына элдерермен".

*Дәвамы. Башы журналның 1 санында.*

һәм ул урамга ашыга.

...Бара-бара агаебыз шөлләп тә куя: буранлы ачы суыктан куркып барысы да ояларына качкан,тирә-юньдә бер генә җан иясе дә юк. Сукмакларны да кар күмеп бетергән. Баганалардагы лампочкаларга иш-куш дигәндәй, ярый әле йортларның тәрәзәләреннән иңгән яктылык бар. "Менә бу каршыдагы йортны үтсәм,—дип уйлый ул таягы белән кар астындагы сукмакны төя-төя,—аның артындагысында гына инде үзе—кордашның фатиры".

Ошбу уен уйлап бетерүе була, каршыдагы йорт подъездыннан чыгып килүче чиләкле берәүне шәйләп ала ул... Бәй, үзенә таба килә түгелме соң бу—шушы сукмакка борылды бит, күрче. Шулай икән шул, көрткә бата-чума булса да, әнә ничек ашыга—яшь нәмәрсәдер инде, бахыр.

Ялгыз түгеллегеңне тою гына да җылыта икән күңелне.—Галимҗан агай да җәһәтрәк атлый башлый. Тик каршыга килүче генә... көрткә батыпмы, әллә таяклы кешедән шикләнепме, тукталып кала һәм... чиләген дә кар өстенә каплый.

Бу кемсәнең шул урынга ашыга-ашыга чиләге белән кар өюе сәеррәк тоелса да (буран каплап китәр иде әле!), күршебез аны-моны уйламый гына юлын дәвам итә.

Әлеге бәндә өйгән кар тавы янынннан үткәндә аңа "ү-э" диган бер өн ишетелә. Буран елый, ахры, диган уй белән атлый бирә күршебез. Өн тагы кабатлангач, туктап кар өстенә күз ташлый һәм... бәс белән капланган бәләкәй генә бер бияләй—бала бияләе күреп ала.

Мине калдырып китмә дигәндәй, "бияләй" кыймылдап куя. "Тәүбә-тәүбә", ди Галимҗан агай, саташам, ахры. Шулай да бисмилласын әйтеп, бу "табыш"ны кулына ала. "Бияләй" агайның уч төбенә елышып, яңадан "ү-э" диган аваз чыгара. Шунда гына күршебез бу "бияләй"нең яңа гына туган эт баласы икәнлегенә төшенә. Һәм шундук ошбу бәләкәчне туны эченә, куенына ала. Таягы белән көртне актарса,— анда ике үле эт баласы! Аналарыннан аерып, яңа туган бу җан ияләрен сулы чиләккә тондыручы хәсис кереп югалган подъездга таба борылып, таягын селки-селки: «Адәм актыгы син, кансыз син!» дип кычкыра агай. Тавышка сискәнепме, куеныңдагы җан иясе кыймылдап куя.

...Бусаганы атлау белән карчыгына ул:

—Тиз генә сөт җылыт, әнкәсе; җәһәтрәк кыймылда,—ди, үзе исә куенында дер-дер калтыраучы көчекне чыпталы урындыкка куеп, чишенә башлый.

—Әстагъфирулла, шул гына җитмәгән ие... Ил-күз алдында мәсхәрәгә каласым, картаймыш көнемдә кеше көлдерәсем юк әле. Бар, кемнән алдың—шуңа илт!—дип, үз белдеген тукый карчыгы.

—Алла бәндәсе! Әйтеп бетергәнне көт алайса! Сулы чиләктә буранга чыгарып ыргыттылар яңа туган бу җан иясен. Ишетәсеңме, сулы чиләктә!.. Ярый әле мин очрадым; теге ике туганы кебек бозга әйләнәчәк иде бит бусы да. Инде уйлап бак: кемгә, кая илтим мин бу сабыйны!?

—Чистый Хозыр-Ильяс булдың инде. Алай бик җәлке икән, иртәгә үк әнә авылга, энеләреңә илт; байлыклары күп—капкаларын саклар...

—Эз-э, байлар капкасын саклау өчен исән калгандыр дип уйлыйсыңмы әллә син бу баланы. Әнә, туганнары сулы чиләктә үк тончыгып җан тәслим кылган, ә бу бәләкәч йөзеп өскә калыккан. Көрт астыннан да чыга алган. Өсләренә кар өючегә исән икәнлеген белдергән булса, чиләге белән башын изә иде бит теге кансыз бәндә. Кыймылдамаска, эндәшмәскә кирәклекне тойган сабый. Бу балада, беләсең килсә, җиде бабасының акылы тупланган. Хозыр хәзрәт дип дөрес әйтәсең син, әнкәсе. Ходай Тәгалә мине бу зәмһәрир суыкка шушы сабыйның гомерен саклап калу өчен чыгаргандыр да... Җә, нәрсә катып калдың, бар, сөтеңне кара!.

...Таң ату белән карчыгы чыптага төргән көчекне ятагыннан торып кына килүче картына тоттыра. "Бар,—ди ,—кеше-кара күргәләгәнче коридор баскычына, икенче каттагы батарея астына җылыга куй бу бәләкәчне. Берәр миһербанлы бәндә алып китмәсме әле үзен..."

Галимҗан агай аны кичен—кешеләрнең эштән кайтыр вакыты җиткәндә генә алып төшә. Әмма "урнаштырырга" ашыкмый әле...

Каш-керфекләрен бәс каплаган студент улыбыз Искәндәрнең подъездга якынлашуын күргәч кенә агайның күңеленә җылы йөгерә; куеныңдагы сабыйны батарея астына куеп, ул инде өскә, күзәтү өчен уңайлы баскычка күтәрелә. Һәм... һәм аскы катны күзәтеп: һай, караңгырак урын икән шул, ярый па күрә алса дип хафага төшә.

Агайның уйларын аңлагандай, көчек үзе янынnан узып баручы улыбызга "ү-э" дип аваз сала. "Ходайның рәхмәте,—дип уйлый күршебез,—кемнең кемлеген тәки тоя; миңа да шушындый тавыш белән "эндәшкән" иде бит бу сабый". Шушы мәлдә ул, Искәндәрнең көчекне күреп тукталуын шәйләп, җиңел сулап куя...

Искәндәр исә керә-керешкә үк бүлмәләргә күз ташлый.

—Әти өйдәме?—ди аннары пышылдап кына.

—Юк, кайтып җитмәде әле; иртәрәк түгелме соң?—дим, аның дулкынланганын абайлап.

—Хәзер, әни, бер әйбер күрсәтәм. Тик син "ачуланмыйм" дип сүз бир башта.

Улымның күзләре шундый да ялварып карыйлар ки, мин, билгеле инде, ризалыгымны белдереп башымны кагам.

Ул теге "әйберне" куеныннан алып, учларыма сала. Мин имәнеп китәм: ярабби, җанлы әйбер түгелме соң бу?!. Улым аңлатып бирергә ашыга:

—Дөньяның бер намуссызы безнең йортның баскычына китереп ташлаган бит аны, әни. Күр, күзләре дә ачылмаган яңа туган сабый ул. Икенче каттагы тәрәзәнең бер пыяласы да ватык әле, җитмәсә. Ә урамда, беләсеңме, нинди суык: 35 градус... Әти кайткач, яклашырсың инде, яме? Мин үзем... үзем караячакмын аны. Бу көчекнең бер зыяны да тимәячәк безгә, менә күрерсең...

Шул мәлдә, сискәндереп, колак төбендә генә әтиебезнең кырыс тавышы яңгырады:

—Җансыз курчак дип беләсезме әллә аны? Нинди җаваплылык алырга җыенуыгызны аңламыйсызмы?.. Әниең эштә, мин эштә, ә синең диплом язасың, госэкзаменнарга әзерләнәсең бар: кем карар дип уйлыйсың бу җан иясен?! Һәр көн иртә-кичен аның белән сәгать-сәгать ярымга прогулкага чыгарга, үзе белән даими рәвештә шөгыльләнергә кирәк. Сөйләшергә, аңлатырга, уйнатырга, йә, кайсыбызның вакыты бар?.. Авызыгызны да ачмагыз калдыру турында! Иртәгә үк мин аны заводка алып китәм; ә бүген аңа ванна бүлмәсендә урын әзерләгез...

Бу кичне ул үзе нишләптер ванна бүлмәсенә бик еш керде. Без исә сизмәмешкә салыштык.

Йокларга ятыр алдыннан гына үзем дә кереп карыйсы иттем. Күрәм: бәләкәчебез башын ванна астынарак алган булды: яшеренде, янәсе. Сөтен эчмәгән. Ә аның янәшәсендә тагын бер сулы тәлинкә хасил булган. Моны мин хәерлегә юрадым.

...Иртә белән иртүк безне йокыдан ишек кыңгыравы уятты.

Килендәшем икән. Базарга дип килгән булган да, суыкка чыдый алмыйча, безгә кергән.

Тиз генә чәемне куеп, аның янына залга чыксам... исем китте: көчегебез! Әйе, әйе, бәп-бәләкәй генә көчегебез... ванна бүлмәсеннән чыгып, чәнти бармакның яртысы хәтле генә тәпиләре белән кәнәфигә үрмәләргә маташа.

—Күрегез әле бу "Тэтчер"ны! Моңа хәзердән үк кресло кирәк!—дип, мин бүлмәләребезгә сөрән салдым.

—Абау, боларның этләренә хәтле министр исемен йөртә[1],—диде килендәшем бик төксе генә.

Иремә, мутланырга, кайберәүләрне үртәргә дә яратучы иремә җитә калды бу:

—Әйе, Тэтчер аның исеме! Тэтчер!.. Шәп исем бит, ә?!

Аның мондый җавабы сөендереп җибәрде: әйбәт фал иде бу!

...Маэмаебызның киләчәк язмышы ул иртәдә менә шулай ансат кына хәл ителде.

...Мине бүлдермичә генә тыңлап утырган Мәрьям ханымга текәлдем: йә, тынычландыгызмы инде, янәсе.

—Әгәр... әгәр көчек табылмаса, мин гомерем буе үземне гаепле санаячакмын, —диде ул, күз яшьләре аша елмаерга тырышып. Аннары өстәп куйды:—Туганнан соң ук үзен саклаган фәрештәләр хәзерге сәфәрендә дә юлдаш булсын, аны ташламасын иде инде, Ходаем!

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

[1] Тэтчер Маргарет – 1979-90 елларда Бөекбританиянең премьер-министры.

Роберт
Миңнуллин

## ДУСЛАРЫМ, ДУС-ИШЛӘРЕМ...

(ШУЛ ИСЕМДӘГЕ КИТАПТАН ЭПИГРАММАЛАР,
ШАЯН БАГЫШЛАУЛАР)

***

*Драматург Туфан Миңнуллинга*

**Бәлки, дөрес тә әйтмимдер,**
**Мин шулай уйлыйм гына:**
**Үзең—Туфан кадәр Туфан,**
**Үзең—Миңнуллин гына...**

***

*«Керим әле урманнарга»*
*җырының авторы*
*Гарифҗан Мөхәммәтшинга*

**Кер, Гарифҗан, урманнарга,**
**Җый гөмбәдер, җиләктер.**
**Лесник күрмәгәндә бирәр**
**Яңа җыр да эләктер!**

***

*«Таң җиле» романының*
*авторы Фоат Садриевка*

**Күңелләргә рәхәт бирә**
**Мөслим җиле, «Таң җиле».**
**Кайчакларда Фоатка да**
**Исеп куя дан җиле.**

***

*Халык шагыйре*
*Равил Фәйзуллинга*

**Шигырьләре**
**Елык-елык,**
**Бер юллык та**
**Ике юллык...**
**Әйдә инде,**
**Там, там, шигырь!..**
**Нәтиҗәдә,**
**Том-том шигырь!**

### Язучылар берлеге

**Бездә элек Союз иде,**
**Хәзер менә—Берлек.**
**Берлектә берлек булмавын**
**Хәзер генә белдек.**

***

*Шагыйрь Әхмәт Рәшиткә*

Гел шул «Беренче мәхәббәт»!
Куям үзен җәлләп тә!
Икенче-өченчеләрен...
Яшерә ул, әлбәттә.

***

*Шагыйрь Газинур Моратка*

Евтушенкодан ким түгел
Сәхнәдә безнең Морат.
Евтуштай гына шагыйрьләр
Бездә дә бар ул, брат!

## Үз исемем турында

Исемем татарча түгел,
Әйе, матур да түгел,
Тик гел исем үзгәртергә
Мин бит Батулла түгел.

***

*Шагыйрь Рәфикъ Юныска*

Рәфикъ Юныс ит ашамый,
Рәфикъ Юныс йөгерә:
Пегаска атланганнарга
Ул болай да өлгерә.

***

*Язучы Камил Кәримгә*

Камил Кәримне син инде
Әйбәт беләсең.
Концертта аны тыңласаң,
Көлеп үләсең.
Тик беркемнең дә үләсе
Килми, күрәсең.
Концертка килеп үләргә
Кем соң теләсен?
Шуңа күрә беркем көлми,
Белеп үләсен!

***

*Шагыйрь Гәрәй Рәхимгә,ягъни керәшен егете*
*Григорий Васильевич Родионовка*

Гәрәй Рәхим төшми һаман
Шәп шагыйрьләр чутыннан.
Язганнарын укып карыйм,—
Ничауа бит, чукынган!

***

*Шагыйрь Шамил Маннапка*

Үзен-үзе тирән белеп,
Үзен-үзе аңлап,
Мәзәкләр иҗат итәргә
Тотынды Ш. Маннап.

Бирә тора гәзитләргә
Мәзәкләрен әзләп.
Мәзәкләре көлдерә дә,—
Менә шунсы мәзәк!

***

*Прозаик Марсель Галиевкә*

**Марсель Гали юмор язган—**
**Марсельдән булыр, булыр!**
**Безгә дә кирәк бит инде**
**Көлдерми торган юмор.**

***

*Бер тәнкыйтьчегә*

**Бар белгәнең чүбек чәйнәү,**
**Бар белгәнең—тәнкыйть, тәнкыйть...**
**Тәнкыйть бетте бит инде ул,**
**Син дә тизрәк тәнкыйтьтән кит!**

***

*Шагыйрь Зиннур Мансуровка*

**Зиннур Мансур шигърияттә**
**Үсә зур тизлек белән.**

**Шигырьләрен яза Зиннур**
**Үзгә бер үзлек белән:**


**Хәтта аңларга да була...**
**Укысаң сүзлек белән.**

***

**Яшь шагыйрә шигырь язган—**
**Талантлы төсле бу Гөл!**
**Тик кереш сүзе нигәдер**
**Р. Гаташныкы түгел.**

## Көнләшүчеләргә

**Бик сыек бит шигырь язган**
**Язу карагыз...**
**Башта сез минем шикелле**
**Язып карагыз!**




*Төрле буын язучыларының бер төркеме Татарстан Язучылар берлеге бинасының бакчага чыга торган болдырында. 1996 ел.*



*Татар зыялыларыннан бер төркем Татарстанның халык язучысы М. Мәһдиев туган һәм яшәгән йорт ишегалдында. Уртада язучының апасы Равия ханым. 2000 ел.*



*Редакциядә очрашу. Сулдан уңга—язучы-журналист Саимә Ибраһимова, композитор Заһид Хәбибуллин, шагыйрь Мәхмүт Хөсәен, журналист Венера Ихсанова. 1964 ел.*



*Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов сугыш һәм хезмәт ветераны Габдрахман ага Фәйзуллин белән. 1997 ел. Аккош күле.*



*Замандашлар. Сулдан уңга— язучы Рәшит Гариф, җырчы Габдулла Рәхимкулов, язучы Әхәт Сафиуллин, музыкант Сафьян Ибраһимов. 1995 ел.*

## МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ХӘЛЛӘРЕ

Татарстан Мәдәният министрлыгының Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе концерт залында булып узган чираттагы киңәйтелгән коллегиясе 2007 елны йомгаклауга, 2008 елда башкарылырга тиешле эшләрне барлауга багышланды. Анда Премьер-министр Р. Миңнеханов, Россия мәдәният һәм гаммәви коммуникацияләр министры урынбасары А. Бусыгин, Татарстан Президенты аппараты, Дәүләт Советы, Министрлар Кабинетыннан вәкилләр катнашты. Утырышта төп доклад белән Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева чыгыш ясады.

—2007 ел Татарстан мәдәнияте елъязмасына тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен саклаучыларның VI Бөтенроссия корылтае, Татарстан халыклары съезды, Бөтендөнья татар конгрессы, «Алтын мөнбәр» халыкара мөселман киносы фестивале, Согыд Гарәбстаны Корольлеге мәдәнияте көннәре, Алабуга каласының 1000 еллыгы кебек зур вакыйгалар белән кереп калыр,—диде ул.—Хезмәт хакы күләменең түбән булуы мәдәният өлкәсендә һаман да әле иң борчыган мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. Былтыр бу өлкәдә уртача хезмәт хакы 5039 сум күләмендә иде. Бу сумма Татарстан халык хуҗалыгындагы уртача хезмәт хакының 45,2 процентын тәшкил итә. 2008 елда мәдәният өлкәсендәге уртача хезмәт хакын 14 мең сумга күтәрү бурычы куелды. Моның өчен, булганына өстәп, 1 миллиард 700 миллион сум акча юнәтергә кирәк. Бюджеттан мәдәнияткә өстәмә рәвештә акча бүлеп бирми торып, бу максатка ирешеп булмастыр. Хезмәт хакын арттыруның бер чарасы—мәдәният учреждениеләрен автоном статуска күчерү. Бүгенге көндә республикабызда андый статуслы 9 оешма эшләп килә. Озакламый аларга театрларыбыз да килеп кушылыр, дип уйлыйм. Мәгълүм булганча, автоном статуска күчерелү белән, оешма хезмәткәрләренә хезмәт хакын түләү һәм коммуналь хезмәт өчен тотылган чыгымнарын каплау барыбер хөкүмәтебезнең бурычы булып кала.

Тарихи, мәдәни һәйкәлләрне саклау мәсьәләсенә килгәндә, 2008 елга Болгарны һәм Зөя утравын республикабызның зур туризм үзәкләренә әверелдерү бурычы куелды. Музейлар эшендә иң борчыганы—Милли музейның фонд саклагычы булмавы һәм халыкара стандартларга туры килгән экспозиция мәйданнарының бик аз булуы. Мәгълүмати технологияләр өлкәсенә килгәндә, муниципаль мәдәният оешмаларын мәгълүматлаштыру эше һич тә канәгатьләнерлек түгел.

Китапханәләрнең искерә баруы да нык борчый. Халыкара стандартлар буенча китапханә фонды елына 5 процентка яңартылырга тиеш булса, бездә ул сан 2,6 процент кына әле. Кино тармагын үстерү, авыл клубларын сипләү, яңаларын төзү, халык иҗатын саклау, үстерү кебек мәсьәләләр дә житди игътибар сорый.

Нәтиҗә ясап, З. Вәлиева соңгы елларда мәдәният өлкәсенең үзе дә акча эшләргә өйрәнеп килүе турында әйтте.

Хисап докладыннан соң фикер алышулар булды. Чыгыш ясаучылардан язучы Р. Батулла, Казан хореография училищесы директоры Т. Шахнина, Кама Аланы муниципаль берәмлеге башлыгы И. Привалов, «Әкият» курчак театры директоры Р. Жаббарова, Качалов исемендәге театрның директоры һәм художество житәкчесе А. Славутский, Буа театрының баш режиссеры Р. Садриев һ. б. мәдәният өлкәсендә хәл ителергә тиеш мөһим мәсьәләләр күтәрделәр. Аерым алганда, Р. Батулла татар киностудиясе булмавы турында борчылып сөйләде.

Коллегия утырышына Премьер-министр Р. Миңнеханов йомгак ясады.

—Бүгенге көндә татарны мәдәни агарту буенча зур эш башкарган Г. Камал исемендәге театрда репертуар мәсьәләсе кискенләште,—диде ул.—Драматургиядәге кризисны татар милли классикасына күбрәк мөрәҗәгать итеп, яңа Туфаннарны үстереп, пьесаларны жиде кат иләктән үткәрер өчен театрларда сәнгать советларын кабат торгызып хәл итеп булачак.

Шул ук вакытта кайбер театрларыбызда сәнгать житәкчеләренең үз казаннарында гына кайнап яшәүләре дә безне борчый. Бу җәһәттән житди мәсьәләләрне бергәләп хәл итү өчен иҗади консилиумнар, коллегияләр оештырылганда әйбәт булачак.

Сүз дә юк, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры Татарстан мәдәниятен халыкара мәйданда танытуы буенча житди эш башкара. Әмма бүгенге көндә аның исеме җисеменә туры килми. Заманында татар операсы, татар балетының тууы татар мәдәниятен яңа бер баскычка күтәргән иде. Ә бүген алар юкка чыгу чигенә килеп житте, чөнки театрда аларга үгисетеп карау тенденциясе бар. Билгеле инде,

татар спектакльләре куелмагач, татар башкаручылары да үсә алмый.

Кайбер иҗат оешмаларында билет бәяләренең нык үсүе дә күнелдә борчу уята. Билет бәяләре 1,5-2 мең сумга җиткән театрлар бар. Бу җәһәттән театрлар халыкның аз керемле катлавын сәнгатьтән читләштермәсен иде.

Премьер-министр, шулай ук, тиздән Милли китапханә һәм курчак театры биналары төзелә башлаячак, дип белдерде.

Р. Миннеханов, автоном статуска ия килеш тә, дәүләт заказын үтәүчеләр буларак, Татарстан мәдәниятчеләре дә якын киләчәктә бюджет хезмәткәрләренең хезмәт хакларына өстәмә итеп Россия Президенты В. Путин тарафыннан тәгаенләнгән 14 процент акчаны алачакларын вәгъдә итте.

Утырыш ахырында бер төркем мәдәният эшлеклеләренә республика һәм ведомство бүләкләре тапшырылды.

### ҖЫРГА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Казан Кремлендә Әлфия Авзалованы кабул итте. Президент легендар җырчыны (ул—РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты, Республиканың Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты) 75 яшьлек юбилее белән котлады һәм ана Татарстанның иң югары бүләге—«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены тапшырды.

«Барлык татар халкы исеменнән Әлфия Авзаловага татар музыка сәнгатен пропагандалаганы өчен рәхмәт белдерәм. Әлфия Авзалова һәм Илһам Шакиров—безнең иң зур байлыгыбыз, татар моңының нәрсә икәнен нәкъ менә алар күрсәтте»,—диде Татарстан Президенты.

«Мин бөтен гомеремне җырга багышладым һәм бу минем иң мөһим эшем. Ходай миңа талант биргән һәм мин инде күп еллар буе җырлыйм. Татарстан Президентына күрсәткән игътибары һәм биргән ордены өчен бик зур рәхмәт белдерәм»,—диде җырчы.

Очрашуда шулай ук Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева, Президент аппараты җитәкчесе Юрий Камалтынов, Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе директоры Кадим Нуруллин катнашты.

### МӘШҺҮР ЗАМАНДАШЫБЫЗ ЮБИЛЕЕ

2 февраль көнне Казан Кремлендә Президент Минтимер Шәймиев Татарстан һәм Россиянең халык артисты, СССР һәм Татарстанның Дәүләт премияләре лауреаты Ринат Таҗетдиновка «Татарстан Республикасы алдындагы хезмәтләре өчен» орденын тапшырды.

Республика җитәкчесе актерның театрда гына түгел, кинода, радиода эшләвен, ТР Театр әһелләре берлегенә җитәкчелек итеп, иҗтимагый эштә актив катнашуын да билгеләп үтте. «Асылда аның актерлык таланты ярдәмендә без күренекле күп кенә шәхесләрнең, әйтик, Муса Җәлилнең ниндирәк булганлыгын, ничегрәк яшәгәнлеген күз алдына китерәбез»,—диде М. Шәймиев.

Шул ук көнне кичен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Ринат Таҗетдиновның 70 яшьлек юбилеена багышланган тантаналы кичә булды. Кичәнең беренче өлешендә тамашачы хозурына «Мәхәббәт турында сөйләшик» дип исемләнгән театрлаштырылган тамаша тәкъдим ителде. Аннары юбилярны хезмәттәшләре, республиканың иҗат берлекләре, театрлар җитәкчеләре, якташлары котлады. Котлаулар танылган сәнгать осталары—җырчылар Илһам Шакиров, Георгий Ибушев, Илсаф, Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор ансамбле, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, музыкант Рафикъ Таҗетдинов, шагыйрь Ркаил Зәйдулла һ. б.ның чыгышлары белән үрелеп барды.

Кичәдә Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева катнашты һәм чыгыш ясады.

### ЗУРАБ ЦЕРЕТЕЛИ КҮРГӘЗМӘСЕ

Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Россия Сәнгать академиясе президенты, СССРның халык рәссамы Зураб Церетелиның Милли Сәнгать галереясындагы күргәзмәсе белән танышты. Россия Сәнгать академиясе оешуга 250 ел тулу уңаеннан оештырылган күргәзмә—3. Церетелиның үзенчәлекле иҗат хисабы булып тора. Эшләр белән танышу барышында Минтимер Шәймиев аның скульптураларына аеруча игътибар итте. Күргәзмәдә аерым бер бүлек булып торган сыннар арасында Петр I гә, Федор Шаляпинга, Нико Пиросманига багышланганнары һәм башка темаларны яктыртканнары да бар. Күргәзмәне караганнан соң Илбашы тәбрикләүләр һәм тәкъдимнәр китабына түбәндәге юлларны теркәде: «Россия Сәнгать академиясе оешуга 250 ел тулу уңаеннан оештырылган күргәзмәгез өчен Сезгә бик зур рәхмәт. Сез чын мәгънәсендә талантыгыз белән дөньяны шаккатыру көченә ия шәхес. Киләчәктә дә иҗади уңышлар юлдаш булсын үзегезгә!» Үз чиратында, Зураб Церетели М. Шәймиевкә Россия Сәнгать академиясенең мактаулы әгъзасы итеп сайлануы турындагы диплом һәм күкрәк билгесен—«Абруй» медален тапшырды.

### СУРИКОВ ИНСТИТУТЫ ФИЛИАЛЫ АЧЫЛАЧАК

Агымдагы елның 1 октябрендә Казанда В. Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт академия сәнгать институтының филиалы ачы-

лачак. Бу хакта Зураб Церетели күргәзмәсен ачу тантанасында Татарстан Республикасы Премьер-министры—мәдәният министры Зилә Вәлиева хәбәр итте.

Институт филиалында 4 төркем булдырылачак. Анда «Рәсем сәнгате» белгечлеге буенча—12, «Графика» һәм «Сәнгать белеме» белгечлекләрендә 10, «Сынлы сәнгать» белгечлегендә 8 студент укыячак. Гомумән, филиалның беренче укучыларының саны 40 булачак. Кабул итү имтиханнарын 6 июльдә үткәрү планлаштырыла. Филиалны ачу тантанасы исә яңа уку елы башланган көнне—1 октябрьдә үтәчәк. Уку елын 1 октябрьдә башлау—Россиянең бөтен сәнгать институтларының традициясе.

Казанда Суриков институтының филиалын ачу турындагы килешү 2006 елда ук төзелгән иде. Институт ректоры карары нигезендә филиалның директоры вазифаларын башкаручы итеп Казан сәнгать училищесы директоры Мәхмүт Ваһапов билгеләнгән. Филиал үзе дә Казан сәнгать училищесы нигезендә төзеләчәк. Бүгенге көнгә училище бинасын төзекләндерү проекты әзер, ремонт эшләре бара. Шулай ук бу көннәрдә укыту өчен лицензия алу хәстәре күрелә.

## ТАТУ ЯШИК

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова «Ислам. Бәхәсләр. Тынычлык урнаштыру» халыкара конференциядә катнашучылар белән очрашты. Алар дөньяның 11 иленнән җыелган. Очрашу башында Римма Ратникова Татарстанның икътисади һәм мәдәни куәте, өстенлекле илкүләм проектларны гамәлгә ашыру буенча уңышлары хакында сөйләде. Халыкара тынычлык һәм татулык федерациясе президенты Виктор Камышанов барлык кунаклар исеменнән Татарстан хөкүмәтенә әлеге очрашуны оештырган өчен рәхмәт белдерде. Татарстан бөтен дөньяда үзенең толерантлыгы һәм республика биләмәсендәге мәдәният һәм диннәргә хөрмәт белән каравы белән билгеле, дип ассызыклады.

## КАЗАНЛЫЛАР МӘСКӘҮДӘ, УФАЛЫЛАР КАЗАНДА

***

13-20 гыйнварьда Мәскәүнең Кече театры сәхнәсендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры үз репертуарындагы иң яхшы сәхнә әсәрләрен тәкъдим итте. Гастрольне ачу тантанасында камаллыларны Кече театрның сәнгать җитәкчесе, СССРның халык артисты Ю. Соломин сәламләде.

Бу юлы мәскәүлеләргә «Зәңгәр шәл» (К. Тинчурин), «Кара чикмән» (Г. Хугаев), «Җанкисәккәем», «Алты кызга бер кияү» (Т. Миңнуллин), «Мәхәббәт турында сөйләшик» (И. Зәйниев) спектакльләре, татар театрының 100 еллыгына багышлап сәхнәләштерелгән «Гөлҗамал» (Н. Исәнбәт) драмасы, А. Чеховның «Өч сеңел»е күрсәтелде. Гастрольләрне Ф. Бүләков пьесасы буенча куелган «Go! Баламишкин» һәм «Дивана» (Т. Миңнуллин) спектакльләре дә бизәде.

***

Шул ук көннәрдә Г. Камал театры бинасында М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театры гастрольләре булып узды. Репертуар тематик яктан бай иде. Казан тамашачысына алты драма һәм ике музыкаль спектакль тәкъдим ителде. Алар арасында Б. Бикбайның «Кодача», Т. Миңнуллинның «Мулла», У. Галиевнең «Гомер алда әле», «С. Бүләковның «Эх, кугәрченкәйләрем!», К. Кезинның «Кәккүк оясы» әсәрләре буенча куелган әсәрләр бар иде. Яртылабы—яңа премьералар. Башкорт театрының күренекле ветеран артистлары һәм яшь иҗатчылар катнашында үткән «Яшьлекләргә кайтыйк әле!» дигән театраль тамаша казанлылар күңеленә бигрәк тә хуш килде.

## БЕЗНЕКЕЛӘР—МИСЫРДА

Январь аенда Мисырның Мәрсәләм курорт-шәһәрчегендә сәнгать фестивале булып узды. Анда Казаннан Геннадий Макаров җитәкчелегендәге «Ак калфак» балалар ансамбле, язучы Рабит Батулла, режиссер Салават Юзеев барды. Фестивальдә Р. Батулла сценариесе буенча эшләнгән «Алмыш падишаһның карары» дигән һәм С. Юзеевның «Татар театрына—100 яшь» дигән фильмнары күрсәтелде. Соңгысы махсус бүләккә дә лаек булды. Катнашучыларның һәркайсы медаль белән кайтты.

***

25 январь көнне Татарстан Язучылар берлеге идарәсе утырышы булды. Аны рәис Илфак Ибраһимов алып барды. Ике идарә арасында башкарылган эшләр турында Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, берлекнең Чаллы һәм Әлмәт бүлекләре җитәкчеләре Вахит Имамов, Данил Салихов хисап тотты.

Утырышта катнашучылар идарә һәм остаханәләрнең 2008 елның беренче яртысына эш планнарын карап тикшерделәр, язучыларның XVI съездына әзерлек мәсьәләләренә тукталдылар.

Идарә 2008 елда Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә яшерен тавыш бирү юлы белән шагыйрь Ркаил Зәйдулла («Мәгарә» китабы өчен) һәм прозаик Камил Кәримов («Ком сәгате» һәм «Сакау күке» романы өчен) кандидатураларын тәкъдим итте. Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге бүләгенә—язучы, «Салават күпере» һәм «Сәхнә» журналларының баш мөхәррире Зиннур Хөснияр («Терсәк сугышы» роман-дилогиясе һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен), Фатих Хөсни исемендәге бүләккә язу-

чы Әхәт Гаффар («Энә күзе» китабы өчен) тәкъдим ителде.

Идарә утырышында Казаннан шагыйрә Гөлзадә Бәйрәмова, Чаллыда яшәп иҗат итүче прозаик, драматург Равил Сабыр, Түбән Камадан шагыйрь Марс Хафизов һәм Әлмәттән прозаик Габделәхәт Хәбибуллин Язучылар берлегенә кабул ителде.

### ФАТИХ ХӨСНИНЕҢ ТУГАН ЯГЫНДА

Теләче районында Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе Фатих Хөснинең тууына 100 ел тулуны зурлап билгеләп үттеләр. Әдипнең якташлары бу олы вакыйгага алдан ук ныклап әзерләнде. Ф. Хөснинең туган авылы Олы Мәтәскәдәге музеена, авылның мәдәният йортына капиталь ремонт ясалды. Теләче районында Фатих Хөсни айлыгы игълан ителде. Мәктәпләрдә әдипнең иҗатына багышланган конкурс-викториналар үткәрелде, язучының әсәрләре сәхнәләштерелде.

Ф. Хөсни юбилеена багышланган чараларда катнашу өчен Казаннан бер төркем язучылар һәм әдипнең кызы Фәридә Бикулова кайтты. Район чигендә аларны Теләче муниципаль районы башлыгы Илдар Низамов һәм башка җитәкчеләр каршы алды. Аннары кунаклар әдипнең туган авылы Олы Мәтәскәгә юл тотты. Биредә алар музейда, мәктәптә булды, авыл мәдәният йортында үткәрелгән искә алу кичәсендә күренекле әдип турында истәлек-хатирәләре белән уртаклашты, район үзешчәннәре тарафыннан «Йөзек кашы» повесте нигезендә сәхнәләштерелгән җырлы-биюле тамашаны карады.

Аннары юбилей чаралары Теләчедә дәвам итте. Районның мәдәният йортында Фатих Хөснинең «Минем тәрәзәләрем» дигән автобиографик повесте нигезендә эшләнгән әдәби-музыкаль тамаша күрсәтелде. Соңыннан сүз язучыларга бирелде. Кичәнең бу өлешен район башлыгы, Фатих Хөснинең авылдашы, үзе дә әдәби иҗат эше белән шөгыльләнүче Илдар Низамов ачып җибәрде. Каләм әһелләре белән очрашуда Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, язучылар Мөгъсүм Хуҗин, Марат Әмирхан, Вакыйф Нуруллин, Рашат Низами, Әхәт Гаффар, Солтан Шәмси, Фоат Галимуллин, Нәбирә Гыйматдинова, Камил Кәримов, Ркаил Зәйдулла, Зиннур Хөснияр, Ләбиб Лерон катнашты. Аларның бөтенесе диярлек Ф. Хөсни премиясе лауреатлары. Быелгы бүләккә прозаик Әхәт Гаффар лаек булды.

### МӘХМҮТ ХӘСӘНОВНЫ ИСКӘ АЛУ

Гыйнвар аенда Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, прозаик Мәхмүт Хәсәновның тууына 80 ел тулу уңае белән Азнакай районында (гомеренең 20 елдан артык чорын әдип шушында үткәрә) татар әдәбияты көннәре үткәрелде. Анда Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов җитәкчелегендәге делегациясе катнашты. Тантанага килгән кунаклар арасында Мөсәгыйт Хәбибуллин, Марсель Галиев, Айдар Хәлим, Нур Әхмәдиев, Мөдәррис Вәлиев, Рөстәм Зәкуан, шулай ук Мәхмүт Хәсәновның хатыны Мәрьям ханым һәм балалары бар иде. Кунаклар төркеменә Азнакайда яшәүче шагыйрьләр Илдус Гыйлаҗев һәм Фәйрүзә Исмәгыйлова да кушылды. Алар ике группага бүленеп Әсәй, Кәкре Елга авылларында укучылар белән очрашты, Азнакайның үзендә әдипне искә алу кичәсендә катнашты. Кунакларны Азнакай муниципаль районы хакимияте башлыгы Мансур Хәйретдинов озатып йөрде.

Мәхмүт Хәсәновның юбилее Теләче районында да зурлап билгеләп үтелде. Әдипнең туган авылы Югары Кибәхуҗала әдәби-музыкаль кичә, район үзәгендәге Туган як тарихы музеенда «түгәрәк өстәл» янында сөйләшү уздырылды. Яшел Үзән һәм Теләче районында үткәрелгән чараларда Язучылар берлеге рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев, язучылар Фоат Галимуллин, Марат Әмирханов, Госман Садә, Әлфәт Закирҗанов, Нурислам Хәсәнов, Дания Гайнетдинова һ. б. катнашты.

### ШАГЫЙРӘНЕҢ ИҖАТ БӘЙРӘМЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында шагыйрә Эльмира Шәрифуллинаның 60 яшьлек гомер бәйрәменә багышланган иҗат кичәсе үткәрелде. Кичәгә Башкортстаннан каләмдәшләре Халисә Мөдәррисова, Динә Булгакова, якташлары—Мөслим, Актаныш һәм Яшел Үзән районнары вәкилләре, шулай ук аның шигърият дөньясын үз иткән күпсанлы әдәбият-сәнгать сөючеләр килгән иде.

ТР Мәдәният министры урынбасары Айрат Җаббаров, шагыйрәгә киләчәктә дә сүнмәс көчен тоеп, илһамлы иҗат белән яшәвен теләп, Президентыбызның Рәхмәт хатын, Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Вакыйф Нуриев коллегаларының изге теләкләре язылган Котлау адресы тапшырды.

Кичә котлау-тәбрикләүләр, истәлек-хатирәләр, театр артистлары һәм республикабызның танылган җырчылары чыгышлары белән үрелеп барды. Сәхнәдә кич буе шагыйрәнең шигырьләре, поэмалары, җырлары яңгырады.

### ГИМНАЗИЯДӘ—«КАЗАН УТЛАРЫ» БАЛКЫШЫ

Гыйнвар аенда журналыбызның редколлегия әгъзасы, филология фәннәре докторы, актив авторыбыз Хатыйп Миңнегулов һәм

журналнын поэзия бүлеге хезмәткәре шагыйрь Рәдиф Гаташ Казанның Дәрвишләр бистәсендәге 11 нче татар гимназиясендә булдылар. Махсус әзерләнгән милли бу кичәдә кунаклар бүгенге әдәбият, шигърият, шулай ук «Казан утлары» узган озын, мәртәбәле 85 еллык юл турында тәфсилләп сөйләделәр, күпсанлы сорауларга җавап бирделәр. Журнал тарихын чагылдырган «Сүнмәс утлар балкышы» китабын бүләк итү укытучылар һәм укучылар тарафыннан кыйммәтле бер мәдәни ядкяр буларак кабул ителде.

## ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНДӘ

***

Фәннәр академиясендә «түгәрәк өстәл» җыелышы үтте. Анда республикада тәрбияләнгән, хәзер чит илләрдә һәм Россия төбәкләрендә яшәүче галимнәр һәм вәкилләр катнашты. Соңгы 15 ел эчендә Татарстан тышкы сәясәтне алып баруның бик уңайлы ысулын—ТРның вәкиллекләре институтын булдырды. Бүгенге көндә Фәннәр академиясе әлеге тармакка һәрвакыт ярдәм күрсәтеп тора. Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан халыклары съезды алдыннан төзелгән Милли сәясәт концепциясенең икътисад өлешенә дә нәкъ бу юнәлеш буенча эшчәнлек нәтиҗәләре салынган.

***

8 февраль—Россия фәне көне иде. Татарстан галимнәре бу бәйрәмне үзләренчә, эшлекле төстә билгеләп үтте. ТР Фәннәр Академиясендә үткән тантаналы җыелышта ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Равил Моратов та катнашты. Ул республиканың инновацион үсеше турында лекция укыды.

Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров фән әһелләрен бәйрәм белән котлады, академик институтларның алдынгы хезмәткәрләренә гыйльми исемнәр, конкурс-бәйгеләрдә җиңүчеләргә диплом, стипендия һәм премияләр тапшырды.

## ОРКЕСТР ЕВРОПАНЫ ИҢЛӘДЕ

Казакъстан, Татарстан һәм Россиянең халык артисты, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты профессор Ф. Мансуров җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры Барселона (Испания), Бергамо, Верона, Турин (Италия), Гданьски, Краков, Варшава (Польша), Прага (Чехия), Берлин (Германия) шәһәрләренең абруйлы концерт заллары, театрларында чыгышлар ясады. Оркестр репертуары И. Штраус, Х. Родриго, Ф. Морено Торроба, С. Бакарисс, Дж. Россини һ. б. композиторлар әсәрләреннән тора иде. Ни кызганыч, алар арасында татар композиторларының әсәрләре юк иде.

## ЛАУРЕАТЛАР КОНЦЕРТЫ

Композиторлар берлегендә «Классика+» циклына караган чаралар дәвам итә. Соңгысы Мартина Монасыйпова белән Антон Семкинның «Февраль рапсодиясе» концерты иде. Ул көнне тамашачылар игътибарына Россия һәм чит ил композиторларының иң күренекле әсәрләре тәкъдим ителде. Пианистлар башкаруындагы Рахманинов, Гершвин, Брамс рапсодияләре аеруча җылы каршы алынды.

Концертта чыгыш ясаган Мартина Монасыйпова Казан дәүләт консерваториясендә укый. Ә Антон Семкин Казан музыка училищесындагы фортепиано классында укыта һәм концертмейстерлар классын җитәкли. Алар икесе дә Халыкара концертмейстерлар конкурсында лауреат исеменә лаек булган яшь музыкантлар.

***

Мәдәният өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Милли китапханәсе кульязмалар һәм сирәк очрый торган китаплар бүлегенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Әнвәр Нәҗип улы Хәйруллинга** Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Яз». **Булат Гыйльфанов** картинасы.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә **Луиза Янсуар**.

# Яңа китаплар



Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек.—Төзүче-авторы: **Адлер Тимергалин.** Казан: «Мәгариф» нәшр., 2007.—575 бит. Тиражы—1000 данә.

Колачы һәм эчтәлеге белән тармак сүзлекләре һәм белешмәләрдән аерылып торучы әлеге китапта, төрле характердагы, төрле өлкәләргә кагылышлы төшенчәләр бергә тупланып, аларга кыскача аңлатма һәм мисал-иллюстрацияләр бирелә. Сүзлек төрки асылга кайтырга, гомумтөрки сүз тамырларын кабат активлаштырырга чакыра.

Сүзлек гади татар укучысын язма чыганакларга, тарихи асылыбызга, иманыбызга якынайтуны, күп вакыт сарыф итмичә генә, күпчелек тарихи, дини, фәлсәфи әдәбиятны зиһенгә алу эшен җиңеләйтүне максат итеп куя.

Фундаменталь бу хезмәтнең төп өлеше 2004-2008 елларда беренчел булып «Казан утлары» журналында дөнья күрде.



**Гөлчәчәк Галиева.** Күңелемә якын затлар. Казан: «Мәгариф» нәшр., 2007.—127 бит. Тиражы—1000 данә.

Бу китапка Гөлчәчәк Галиеваның татар әдәбияты һәм сәнгатенең кайбер күренекле кешеләре турында язмалары тупланган. Алар—әдәби портретлар, публицистик уйланулар, истәлекләр. Китапның төп өлешен Фәнис Яруллин, Нурихан Фәттах, Таһир Якупов, Рәфикъ Юныс, Факил Сафин иҗатларына багышланган мәкаләләр тәшкил итә. Язучы һәм галим Тәбриз Мөбәрәков турындагы өлеш тә (бу бүлектә истәлекләр белән бүтән авторлар да катнаша) шактый күләмле. Ахырда автор турында биобиблиографик белешмә бирелгән. Китапка кереш сүзне Мансур Вәли-Барҗылы язган.



Луиза Янсуар

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)